
ISSN 0206-4189

# казан утлары

8. 1994





Җәлилгә сукмак өзелми.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**8**

**(862)**

**1994**

КАЗАН


*Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ


Н. НӘҖМИ. Көнләшү. *Шигырьләр* . . . . 3
Ә. ГАЛИЕВ. Һәр солдатның үз язмышы. *Документаль повесть* . . . . . . . . . . . 9
Роб. ӘХМӘТҖАН. Кызыл яран. *Шигырьләр* 28
АКЪЕГЕТ. Яңа шигырьләр . . . . . . . 34
Т. ӘЙДИ. Кардәшләр кочагында. *Сәяхәтнамә* . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Ә. ГАДЕЛ. Казан белән серләшү. *Шигырьләр* 106
ЛӘЙСӘН. Һаман әле хыялыңда гизәсеңме? *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . . 110
Л. ЗАКИР. Гөргөри. *Гыйбрәтле хикәя* . . . 114


ХӘТЕР


Ш. ӘХМӘТСАФА. Сез — хөкемдар! *Шигырь* 131
Н. НӘКЪКАШ. Бүләгем. *Шәмаил* . . . . . 134
Г. ФӘХРЕТДИНОВ. Кайда минем Илем? *Кыйсса* . . . . . . . . . . . . . . . . 136


ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XII СЪЕЗДЫ МАТЕРИАЛЛАРЫ


Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Язмышлар хәл ителгәндә . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Г. МОРАТ. Шигърият — сәясәт түгел . . . 162
Ф. ЗӨЛКАРНӘЙ. Фидаиләр эше . . . . . 165
Р. МИҢНУЛЛИН. Балалар дөньясы . . . 167
Р. МИНГАЛИМ. Уңай күренешләр . . . . 171
В. КОРЧАГИН. Тормыштан калышмыйча 173
Ә. ЕНИКИ. Хәерле сәгатьтә . . . . . . 174
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Сүз көче . . . . . . . . 176
Ә. БАЯН. Кыен чаклар . . . . . . . . . . 179
Татарстан язучыларының XII съезды резолюциясе, Декларациясе һәм республика житәкчеләренә мөрәҗәгате . . . . . . . . . 180
«Казан утлары» һәм Татарстан Язучылар Берлегенә яңа кабул ителгән әгъзалар турында белешмәләр . . . . . . . . . . . . . 184

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . 188
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 190

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрваз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
хатлар — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: документальная повесть А. ГАЛИЕВА «У каждого солдата своя судьба», повествование о путешествии в Турцию Т. АЙДИ «В объятиях родичий», поучительный рассказ Л. ЗАКИРА «Гергри», стихи Н. НАДЖМИ, Роб. АХМЕТЗЯНОВА, АКЪЕГЕТ, А. АДИЛА, ЛЕЙСАН.
«Память»: стихотворение Ш. АХМЕТСАФЫ «Вы — повелитель!», документальная повесть Г. ФАХРУТДИНОВА «Где моя Родина?».
Материалы XII съезда писателей Татарстана.
Дневник общественно-культурной жизни.
«На наших обложках»: «Дремучий лес» — картина художника З. Миннахметова; известная поэтесса К. Булатова.

## IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: the documentary narrative of A. Galiev «Each Soldier Has Ais Own Destiny»; narration about the journey through Turkey of T. Aydi «In the Arms of Kindred»; L. Zakir's story «Gergri»; the verses of N. Nadjmi, Rab. Akhmetzyanov, Akeget, A. Adil, Leysan.

«Memory»: Sh. Akhmetsapha's poem «You Are Sovereign», the documentary narrative of G. Phakhrutdinov «Where Is My Native Land?»

The materials of the XII Congress of Tatar Writers.

The diary of the social and cultural life.

In our corvers: Z. Minnakhmetov's picture «The Dense Forest»; the eminent poet K. Bulatova.

- Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.
- Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
- Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Марсель Галиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 18.07.94 ел. Басарга кул куелды 9.08.94 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 10 773. Заказ А-333. Бәясе 1100 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1994 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Наҗар Нәҗми

### Көнләшү

Көнләшү бит һәр кешегә ул хас,
Киләдер ул элек-электән.
Көнләштем мин кызлар башын бик тиз
Әйләндергән чибәр егеттән.
Әй яшьлекнең матур тилелеге!..
(Әй җырларым минем, җырларым)
Чибәр булмасам да башларын бит
Әйләндердем мин дә кызларның.
Чибәрлек бар, әмма матурлыклар
Тәтемәгән һәрбер чибәргә.
Матурлык — көч, бөек талант көче,
Талантлылар белә нишләргә.
Алар мине гомер тетрәттеләр,
Остазым да алар, киңәшчем.
Гомер буе, башым ия-ия,
Чын таланттан үлеп көнләштем.
Аларны мин мактап чыкканым бар
(Бакчаларына таш атмадым),
Мин аларны, сокланганым өчен,
Көнләшкәнем өчен мактадым.

*1991*

---

Наҗар НӘҖМИ (1918) — *Башкортстанның халык шагыйре, татар, башкорт һ. б. телләрдә дөнья күргән күпсанлы китаплар авторы, Башкортстанның Салават Юлаев, Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый премияләре лауреаты. Журналыбызда даими басылып килә.*

## Таяк

Татарстан белән Чечня Рәсәйнең 1993 елның март аендагы референдумында катнашмадылар.

*Хәбәрләрдән.*

И хакыйкать! — килде заман,—
Тарих өстеннән төшмә.
Коллыкта бит бер туганнар
Татарва белән Чечня.
Коллык дигән зур таякның
Алар бит ике башы:
Иң тәүге кол татар булса,
Соңгысы чечен халкы.
Дүрт гасыр озынлыгында
Шул коллык дигән таяк.
Ике башның арасында
Күпме мыскыллы хәят!
Күпме кан һәм кимсетелү
Күпме күз яше, хәсрәт.
Яман шеш булып тулышты
Тарих тәнендә нәфрәт.
Ничәмә гасыр ул таяк
Империягә тотка.
Димәкчеләр: суга батмас,
Ул таяк янмас утта...
Һәй акыл!

*1993*

## Яшьтәш

Шагыйрь Равил Фәйзуллинның әтисенә.

Габдрахман!
Берничә ел моннан элек кенә
Олуг шагыйрь — Синең малаең
Әйтә салды: минем әтиемә
Яшьтәшсең бит, Нажар агаем.
Дертләп киттем... Ни әйтергә белми
Мин югалып калдым — кит инде!..
Мин тәү тапкыр шулчак — шул сәгатьтә
Картлыгымны тойдым шикелле.
Күз каршымда ир уртасы — Шагыйрь,
Ә шагыйре нинди?! Чын-чыны!
Шигъриятьтә үз корыма тиңләп,
Якын күреп шигъри һәр чыңын
Яшәгәнгә микән, әллә микән
Булганга без Шигырь баласы,
Җуелган да, югалган да куйган

Яшь арасы, еллар арасы.
Җуелсын да ара, югалсын да,
Иң тәүдә без ата-анадан.
Ходайдан бер затлы бүләк булып,
Туа шагыйрь, туа яңадан.
Ходайлыкны Ходай сезгә дә, дим
Җәлләмәгән — сез дә маһирлар.
Ә азмыни шигырь язмыйча да
Олы җанлы җаннар — Шагыйрьләр!
Без икәүбез, яшьтәш,— ике ата,
Ә мин исә шигырь азгыны.
Кайсыбыз соң безнең бәхетлерәк,
Синме? Минме — шигырь язганы?
Син бәхетле! Миннән бәхетлерәк!
(Юктыр монда акыл сатасы).
Ата булу һәр ир-атка насыйп...
Син Шагыйрьгә ата! Шагыйрь атасы!
Әгәр Шагыйрь үз картлыгын тойса,
Шагыйрьлеге аның икеле.
Малаеңа илле! Мин тәү тапкыр
Картлыгымны тойдым шикелле...

*Ноябрь, 1993.*

## Көтәм

«Үзгәрде әшьялар төсе».

*Г. Тукай*

Урамдамы, юллардамы
Таныш-белешләр,
Басып торганымны күреп:
«Ничек соң эшләр?
Кемне көтәсең?» дип сорап,
Игътибар итеп,
Уңышлар һәм саулык теләп
Китteләр үтеп.
Әйе, көттем... Мин бер кызга
Мөкиббән киттем.
Сөймәгәнен белә торып,
Тилмереп көттем.
Көтеп алдым дусларымны
(Әй, дуслык, дуслык!),
Көткән кунаклар китердe
Шатлык һәм хушлык.
Көтеп алдым мин баламны!
(Бик озак көттем)
Көтелгән оныкларым, шәт,
Бәхетле итте,
Яман сүз ул үзе килә,
Яхшысын көттем.
Көтелеп бар килгәннәрнең

Пагын үз иттем.
Бүген дә торам мин басып
Төрле чатларда.
Уйларым белән кайтамын
Төрле чакларга.
Үткәннәр йөрәкне өтә,
Өтәләр һаман,
Заманы заман да соң ул,
Ялганы яман.
Дуслык саналган гомергә
Булмаган дуслык.
Дөньяда да, йөрәктә дә
Әрнүле бушлык.
Әшъялар төсе үзгәрде
Күңелдә буран.
Буталчык уйлар чатында
Мин басып торам.
«Кемне көтәсең?» дисәләр
Уелып китәм.
«Кемне көтәем соң? — димен, —
Үземне көтәм».

*1993*

## Күз яшь фонтаны

«Фонтан любви, фонтан печали».

*А. Пушкин.*

Бакчасарай... Кайчандыр бит үзе
Сарай һәм дә бакча булган ул.
Татар ханлыгында ул нурланып
Балкып та гына торган, торган ул...
Әй, язмышның каһәр кылмышлары:
Канлы җиңелүләр, җиңүләр.
Кыйралышны, тар-мар ителешне
Тантаналы мыскыл итүләр.
Бүген дә мин шул мыскылны күрәм:
Сарай өнсез, рухи хәрабә.
Гүя ханның бар шөгыле — хәрәм...
Ир куйнына керер өчен гүя
Хатыннары тота җирәбә...
Монда бүген урыс хакимлеге
Аңкып тора һәрбер диварда.
Әби патша белән Потемкинның
Зина кылып яткан диван да
Төп истәлек булып урын алган...
Пушкин булган монда — вакыйга!
Ул да татарны гел кан койдыргыч
Халык иткән — һаман вак көйгә.
Әмма фонтан урыс йөрәген дә
Тетрәткән һәм шигырь яздырган.
Димәк татар яу чаба да белгән,

Сөя белгән — эз дә калдырган.
Фонтан, фонтан! Һаман Кырым өчен
Тартыш бара ике арада.
Алар өчен татар бар ни, юк ни...
Күз яшьләре һаман тамалар.
Фонтан елый...

*1993*

## Бу минутлар онытырлык түгел

Бу минутлар онытырлык түгел,
Җаның, сының илаһ затыннан.
Карашларың кояш чыккан кебек
Күкрәп яуган яңгыр артыннан,
Җаның, сының илаһ затыннан.

Бу минутлар онытырлык түгел,
Соңгы минутларга кадәре.
Калган елларны да моңга манып,
Яшәр өчен гомер бар әле,
Соңгы минутларга кадәре.

Бу минутлар онытырлык түгел —
Мине утка салып киттеләр.
Алар бары сине сагына-сагына
Янар өчен генә үттеләр,
Мине утка салып киттеләр.

*1993*

## Игенче белән шагыйрь

Фәвил Ризвановка

Кешеләрне ризык йөретә, диләр...
Йөретәдер... Ризык җирдән бит.
Кеше канына ул туган җирнең
Күкрәк сөте булып сеңгән бит.
Вакыт җитү белән үз баласын
Аера ана күкрәк сөтеннән.
Үз сөтеңнән безне аерма, дип
Кеше гүя җирдән үтенгән.
Аермаган... Әмма яулап ал, дип
Бар байлыгын аңа үз иткән,
Ә игенче исә җаны-тәне белән
Тирен түгеп, җиргә береккән.
Ә кемнәр соң җиргә берекмәгән —
Шахтермы ул, нефтьче, ташчымы,
Очучымы, поезд йөретүчеме,

Хезмәткәрме, яки ашчымы;
Көтүчеме, галим, табибмы ул,
Кемне алма бары тоташтан
Игенченең хәләл хезмәтенә
Икмәгенә килеп тоташкан.
...Эш ташлыйлар шахта, заводларда
Куйган таләп гел үз көчендә,
Ә игенче әгәр эш ташласа,
Чәчү яки урак өстендә,
Нишләр иде, димен, башта үзе,
Шул ук шахтер, шул ук ташчылар,
Ә игенче туфрак кебек өнсез,
Аңа ят бит төрле шау-шулар.
Һәй, игенчем! Синекенә охшаш
Гомеремнең бөтен шөгыле,
Мин дә иген игәм, тик басуым,
Туфрагым тик — кеше күңеле.

...Күңелләргә кергән йөрәк мин,
Эш ташласам, кемгә кирәк мин?!

*1993*

## Татар генераллары


*Татарның атаклы улы, армия генералы М. Гәрәев бөтен татар генераллары һәм адмиралларының бергә җыелуын оештырды.*

(Гәзиттә хәбәр ителгәннәрдән).

Бер уйласаң, сез халыкның,
Милләтнең горурлыгы.
Кешесе аша билгеле
Халыкның булдыклыгы.
Булдыклы һәр чак булдыклы —
Йортта да, хезмәттә дә.
Булдыклының эше башка
Фәндә дә, сәнгатьтә дә.
Ә сездә гаскәри сәнгать,
Гаскәри булдыклылык.
Сезнең кылганны тормышта
Гаскәрсез булмый кылып.
Бардыр генералларның да
Гаскәрсез булганнары...
Гаскәрләрегез кайда соң,
Татар генераллары?!

Татар генераллары!

*1994.*



Әнәс Галиев

# ҺӘР СОЛДАТНЫҢ ҮЗ ЯЗМЫШЫ

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

Икенче кисәк

Безне вокзалга алып барып, товар вагоннарына утырттылар. Вагоннар репатриантлар белән дыңгычлап тутырылган иде. Чырчу, ата — улны, ана кызны белми. Арада яшь балалы хатыннар да бар. Тормыш бер урында тормый, һаман хәрәкәттә. Германиягә көчләп эшкә җибәргән кызларның күбесе бала табып та өлгергәннәр.

Мин Винница өлкәсенә кайтучы репатриантлар янына эләктем. Вагонда авырулар да бар иде. Каты авырулар, урыннарыннан кузгала да алмыйлар, сәкедә аунап яталар. Барысы да асларында. Искә чыдый торган хәл юк. Мин ишек янынарак елыштым. Ни әйтсәң дә монда җайлырак, ачык ишектән саф һава өреп тора. Госпитальдән киткәндә юлда ашап кайтыр өчен бераз сохари, концентрат тары боткасы бирделәр.

Вокзалда озак тоткарланмадык, халыкны төяп бетерү белән эшелон кузгалып та китте. Шуннан менә башланды инде... Бераз китәбез дә туктап торабыз. Туктап тору Польшага кергәч тагын да ешайды. Мондый тукталышлар башлыча авыллар, кечерәк-кечерәк шәһәрләр тирәсендә була. Моның сере бик тиз аңлашылды.

Эшелон начальнигы — чепи күзле, карсак гәүдәле бер лейтенант. Аның кул астында бер взвод кызылармеец бар. Алар эшелон уртасындагы бердәнбер йомшак вагонда кайталар. Айнык чаклары юк, гел сәрхүшләр. Шул исерек команда эшелон туктап торган арада, тирә яктагы авыллардан нәрсә туры килә, шуны талап алып кайта. Күбрәк ат, сыер кебек эре хайван эләктерергә тырышалар. Аларны саклар өчен артка махсус ике буш вагон тагылган. Буш вагоннарның берсе хайваннар өчен, икенчесе затлырак әйберләрне төяр өчен көйләнгән. Алдагы икенче

Ахыры. Башы журналыбызның 7 санында чыкты.

тукталышта вагоннарга төялгән әйберләрне саталар. Дөресрәге, затлырак товарга, күбесенчә бембергә — самогонга алмашалар. Поляклар атны бик теләп ала. Чөнки көзге кыр эшләренең кызган вакыты. Бар да тарту көченә чиктән тыш мохтаҗ.

Буш товар вагонының икенчесенә лейтенанттан башка беркемне дә якын китермиләр. Имеш, ул бу вагонга үзе белән өенә алып кайтасы әйберләрне генә төятә. Бер тукталышта, «Оппель» машинасын өстерәп алып кайттылар. Ул да лейтенант вагонына кереп чумды. Сөйләүләргә караганда, анда пианино, төрле музыка кораллары бик күп икән. Затлы кием-салымның исәбе-хисабы юк, имеш. Дөрестерме-юктырмы, эшелонны озатып кайтучы взводтагы һәрбер гаскәринең берәр чемодан акчасы бар, алар да шул вагонга төялгән дип сөйлиләр иде.

Хайван тутырылган вагон бушау белән солдатлар яңадан кәсепкә керешәләр. Хәтта үзләре сатып калдырган атны талап кире алып кайту очраклары да була, имеш.

Без барган юл уңаенда озатып кайтучы взводка каршы торырлык көч юк иде. Тора-бара алар шундый кызып киттеләр, үзләренә тапшырылган авыруларны азык белән тәэмин итү турында да оныттылар. Күрә торып ачтан үлеп булмый бит. Хәле бар авырулар үзләрен үзләре ризык белән тәэмин итәргә тотынды. Аларга да шул ук юл өстендәге поляк авылларын таларга туры килә иде. Полякларның каршылыгы көннән-көн көчәйде. Бик еш ашарга азык эзләп киткән авыруларның үле гәүдәләрен өстерәп кайта башладылар. Мәетне Польша җирендә калдырырга ярамый. Лейтенант ничә кешене юлга алып чыккан, чәчмитүкми алып кайтып җиткерергә тиеш. Кеше саны җитмәсә, качканга исәпләнә. Моның өчен ул вакытта нәрсә буласы билгеле...

Шулай итеп, кеп-кечкенә Польша җирен үтәр өчен айдан артык вакыт кирәк булды. Халык авырулардан кырыла башлады. Мең газапны баштан үткәреп, илгә кайтып җитәм дигәндә генә якты дөнья белән саубуллашу бик тә аяныч иде, әлбәттә.

Октябрь башларында безнең эшелон Буг елгасы аша салынган тимер күперне чыгып, Брест-Литовский вокзалына килеп тукталды. Көн саен, карлы-бозлы яңгыр ява иде. Авырулар бар да җәйге киемнән, анысы да сәләмә... Минем дә өс-баш киемем шәптән түгел иде. Хәмит тегеп биргән кепканы урлаткач, башыма бер француз әсире бүләк иткән берет кигән идем. Өстемдә Зорау шәһәрендә госпитальдә ятканда, чүплектән табып кигән иске костюм. Костюм эченнән немецларның агачтан эшләнгән тукымасыннан тегелгән дүрт кат күлмәк. Алар җир төсле каралып, былчыранып беткән, салып берәр җиргә куйсаң, бетләре өстерәп китүе бар үзен. Польша аркылы узганда бер кирәге чыгар әле дип, эченә мамык салып тегелгән, кара сукно тышлы бушлат сатып алган идем. Акчага түгел, әлбәттә, бер кап сигаретка алмашып алдым. Аякларымда иске солдат ботинкасы. Аны госпитальдән киткәндә өлкән шәфкать туташы Тәүхидә бирде. Һәрхәлдә, өстемдәге киемем мондагы салкынга чыдарлык иде.

Эшелон килеп туктау белән халыкны вагоннардан перронга куып төшерделәр. Перронда карлы-бозлы яңгыр астында аунап күпме ятарга туры килер — беркем белми. Хәтта аягына басарга хәле булмаган авыруларга да ярдәм күрсәтү турында уйлаучы юк. Ачлык үзен бик нык сиздерә! Ат — кешнәшеп, кеше сөйләшеп таныша, дигән борынгылар. Сораша торгач, якташлар табылды. Без дүрт кеше җыелдык. Лотфи, Искәндәр һәм Коля. Алар да, әсирләр лагереннан азат ителгәч, эвокогоспитальдә дәваланганнар. Искәндәр — Казанныкы. Лотфи Арча ягының Иябаш дигән авылдан. Коля Югары Осланныкы. Без Казанга кайтып җиткәнче бергә булырга, аерылмаска сүз куештык. Бергә чакта ризык юнәтү дә җиңелрәк. Мин иптәшләрне вокзалда билгеле бер урында утыртып калдырдым да шәһәргә чыгып киттем. Вокзалдан чыгып бераз киткәч тә, бер чатта «Эвакоапункт» дип язылган күрсәткеч күземә чалын-

ды. Кая барганымны үзем дә сизмичә, күрсәткечтәге юнәлеш белән киттем. Озак барырга туры килмәде, бер ишегалдына барып кердем. Анда, зур-зур агач кисмәкләрдән кайнар аш өләшәләр. Халык күп түгел. Чиратта бары егермеләп кеше басып тора. Мин дә билемә мунчала белән бәйләп тагылган ике литрлы, күгәреп беткән калай котелогымны тотып чиратка бастым. Кисмәк янында ике кеше басып тора. Берсе, чүмеч тотканы аш өләшә, икенчесе документларны тикшерә. Мин тиз генә куйнымнан госпитальдән бирелгән кәгазьне тартып чыгардым. Тикшерүче аны җентекләп укып тормады, күзен салды да, кулы белән мине кисмәк янына этәрде. Повар котелокка хуш исле аңкып торган токмачлы аш салды. Өстәп бер кисәк икмәк тоттырды. Икмәге яңа гына мичтән чыккан, кайнар. Урамга чыгып бер почмактагы таш өстенә барып утырдым да, ашны котелок кырыеннан чөмердем. Тамагыма да йокмады. Кире ишегалдына кереп чиратка бастым. Документлар тикшерүче танырмы дип курыккан идем, танымады. Әллә, танып игътибар итмәде инде. Бер котелок аш белән бер кисәк икмәк күтәреп иптәшләрем янына кайттым. «Барыгыз тизрәк!» — дип аларны аш өләшкән ишегалдына куып җибәрдем. Алар да югалып калмаганнар, минем кебек ике мәртәбә чират торганнар. Күрәсең, бу хәл монда нормага кергән.

Тамакны туйдырсак та, безнең хәл шәптән түгел иде. Карлы-бозлы яңгыр коя да коя. Вокзал эченә борын тыга торган түгел. Лычма су булдык. Кая кереп яшеренергә белмибез. Сизәбез, халыкны моннан тиз генә озатырга җыенмыйлар. Перронда мәетләр күренә башлады. Кинәштек тә, ничек итеп булса да моннан ычкынырга уйладык. Лотфи бездән олырак, катгый рәвештә, үз аягыбыз белән йөри алганда моннан китү яхшы, диде. Ә менә ничек китәргә, кая китәргә? Брест-Литовский аша бик еш кына Москва-Берлин, Ленинград-Берлин дип язылган экспресс поездлар уза. Алар монда бер-ике минутка гына туктыйлар. Кайсылары туктап та тормый, җил уйнатып китеп тә бара. Без шул поездларны атакалый башладык. Бәхеткә дип әйтимме, бер поезд шактый озак туктап торды. Озак дигәнем ун минут чамасыдыр. Арттагы вагонның кондукторы олы яшьтәге хатын иде. Көтмәгәндә, вагон ишегенә аркылы басып, минем белән ачылып сөйләшә башлады. Әсирлектән кайтып килүемне белгәч, кызыксынуы тагын да артты. «Абыемның сугышка киткәннән бирле бер хәбәре дә юк. Бәлки ул да плендәдер», — диде. «Бик мөмкин», — дидем мин, без инде СССРның барлык халкы әсирлеккә эләгеп беткән дип уйлый идек. Чөнки анда, Германиядә безнең халык немецләрнең үзләреннән күбрәк булып тоела иде». Бу хәбәр аның бертуган абыйсының исән булуы турындагы өметен ныгытты һәм канатландырып җибәрде. Шушы хәлдән файдаланып, мине һәм иптәшләремне тамбурга кертүен үтендем. Безнең Казанга кайтуыбызны белгәч: «Сезгә бит Мәскәү поезды кирәк, без Ленинградка кайтабыз», — диде ләкин тамбурга кертүдән баш тартмады. «Зинһар, безне бу җәһәннәмнән алып китә күрегез, — дидем мин бик ялынып. — Хәзергә безгә моннан ычкыну гына кирәк». Ул перрондагы хәлне үз күзе белән күреп тора иде. «Ярар, керегез, Благоеда төшеп калырсыз, аннан Мәскәүгә китү җиңелрәк булыр, чөнки ул узловая станция». Без тамбурга керү белән кондуктор ишекне шартлатып ябып та куйды. Бу шәфкатьле хатынның сурәте минем күңелемдә мәңгегә онытылмаслык булып уелып калды. Бәлки, ул хатын күптән дөньяда юктыр да инде. Ләкин мин аны ахыргы сулышыма кадәр онытачак түгелмен.

Без бер-беребезгә елышып, чүгәләп утырдык. Монда шактый җылы иде. Утырган килеш изелеп йокыга китүебезне сизми дә калганбыз.

Бернәрсә сизмичә озак йоклаганбыз. Кондуктор безне төрткәләп уятты: «Хлопцы, вставайте, приехали», — диде ягымлы тавыш белән. Без аңа иң изге теләкләребезне әйтеп, төшеп калдык.

Благое сугыш вакытында берничә мәртәбә кулдан-кулга күчкән зур станция. Моннан поездлар төрле тарафка йөри. Шәһәр хәрабәгә әйлән-

гән. Җимерекләрне тиз генә рәткә кертә торган түгел. Ярый әле монда озак тоткарланмадык. Әйләнеп, тулганып, күп мәртәбәләр ялына торгач, тагын бер вагонның тамбурына эләктек.

Октябрь урталарында Мәскәүгә килеп төштек. Минем Мәскәүне беренче мәртәбә күрүем иде. Иптәшләремнең дә башкалада булганнары юк икән. Ленинград вокзалыннан чыккач, ыгы-зыгы килеп кайнашкан халык ташкыны арасында кая барырга аптырап калдык. Сораша торгач, Казан вокзалын эзләп таптык тагын. Ләкин анда якын да килә торган түгел иде. Аптырагач-йөдәгәч, хәрби комендантның ишеген шакып карадык. Игътибар итүче булмады. Лотфи сыналган юл белән хәрәкәт итәргә — перронга кереп, нинди дә булса берәр Казан поездына эләгергә тәкъдим итте. Бу тәкъдим барыбызга да ошады. Ләкин перронга керә торган юллар ябык иде. Әйләнә-тулгана торгач, бер мәрхәмәтле бәндә безне ничек перронга керергә өйрәтте: «Казанга көн саен товар вагоннарыннан төзелгән халык телендә «пятьсот веселый» дип аталган поезд китә. Ул поездга армия хезмәтеннән азат ителгән солдатларны төйиләр. Сез ничек тә шул поездга эләгергә тырышыгыз»,— диде. Без әлеге кеше өйрәткәнне тыңлап, вокзал артында йөри торгач, нindidер ишегаллары аша, тимер юлга килеп чыктык. Шул юл белән кире килеп, перронга барып кердек. Перронда энә төшәрлек тә урын юк иде. Хәрбиләр белән шыгрым тулы. Бар да кот чыгарлык, зур-зур төеннәр күтәргәннәр. Трофейгә җыйган байлыкларын иңбашына асып, туган илләренә кайталар. «Әнәс абый, бу син түгелме?» — дигән сорауны ишетеп, туктап калдым. Минем алда старшина погоны таккан бер егет басып тора иде. Йөзе таныш. Ә исемен һич тә хәтеремә төшерә алмадым. «Син кем буласың?» — дип сорарга мәҗбүр булдым. «Ник, онытгың да мени, сезнең янга тулай торакка, абыем Гаяз янына килеп йөри идем!» Бар да дөрес. Аның абыйсы Гаяз белән бергә Казан финанс-экономика техникумында, татар классында укыдык. Алар Кече Әтнә кешеләре. Колхозлар башлангач, авылдан чыгып сызганнар. Завод урамында үз йортлары белән торалар. Гаяз кичләрен энесен ияртеп, безнең янга тулай торакка дәрес хәзерләргә килә иде.

Старшинага мин үземнең хәлемне аңлата башладым.

Әсирлектән кайтып килүебезне белгәч егет безнең яннан тайды. Шуннан соң миңа аның белән очрашырга туры килмәде. Абыйсы Гаяз фронтта һәлак булган дип ишеттем. «Пятьсот веселый» дип даны чыккан бу эшелонга утыртырга булышучы булмагач, вагоннар тирәсендә әрлебирле йөреп, таптанырга тотындык. Ачык вагон ишегенә аркылы баскан озын мыеклы бер солдат бармагы белән ымлап үз янына чакырып алды. Ул гимнастеркасын салып бер кат күлмәктән генә калган. «Казанга кайтабызмы? — дип сорады.— Тиз булыгыз, сәке астына кереп ятыгыз. Ишетсен колагыгыз, кайтып җиткәнче тынычыгызны да чыгармагыз». Бар да аңлашылды, артык сүз озайтып торырга ярамый. Күз ачып йомганчы, сәке астына кереп гаип булдык. Безнең килеп керүне, шунда бер кырыйда утырып торучылар да күрми калды.

Аруыбыз тәмам булып җиткән иде. Изелеп йокыга киттек. Мин бернәрсә сизмичә йокладым. Вагоннарның шалтыр-шолтыр килеп берберсенә бәрелүенә уянып киттем. Вагон эче тып-тын. Димәк, бар да йоклый. Сәке астыннан башымны сузып, вагон эчен күзәттем. Мин нәкъ ишек турысына эләккәнмен. Ишек ябылып җитмәгән икән. Менә поезд тимер юл күперенә килеп керде. Нindidер, зур су аркылы узабыз. Йокыга талган солдатлар берәм-берәм уянып ишекне киереп ачтылар. Үзара сөйләшкән сүзләреннән ишетеп, ышанырга да, ышанмаска да белмәдем. Идел-Зөя күпере. Шулкадәр озак йокланылган микәнни? Ни булса — шул, дип, мин дә сәке астыннан чыктым. Хәзер вагоннан төшереп калдырсалар да куркыныч түгел. Моннан Казанга җәяүләп тә кайтып җитеп була. Тиз генә ишек янына барып, шунда басып торучы солдатлар арасына кысылдым. Безне сәке астына кертеп яткырган мыек-

лы солдат та шунда басып тора иде. «Ә, егет, син икәнсең әле. Йокы туйдымы?» — дип сорады ул.— Әйдәгез, тамак ялгап алабыз. Сез бит, кичтән дә ашамый яттыгыз. Иптәшләреңне чакыр». Үзе ятып кайткан урынына барып, зур кара тышлы чемоданны ачты. Чемодан тулы ашамлык. Ак күмәч, колбаса, шоколад... Нәрсә җаның тели — бар да бар. «Тартынмагыз, тартынма. Җаныгыз теләгәнен алып ашагыз»,— диде, безгә чемодандагы ризыкны тәкъдим итеп.

Тамак ялгагач, күңел күтәрелеп китте. Мыеклы солдатка рәхмәтебезне ничек белдерергә белмәдек.

Халык вагоннан төшәргә әзерләнә башлады. Мыеклы солдат та әйберләрен җыярга тотынды. Яше белән ул Лотфи кордашы булгандыр. Безне әйткән дә юк инде. Лотфи да аны үзенчә олылап абый дип мөрәҗәгать итә иде. Исемен сорарга беребезнең дә исенә килмәде. Фасонлы итеп үстергән озын мыегы аны олысымак итеп күрсәтә иде. Шуңа күрәдерме, үзе белән бергә кайтучы иптәшләре дә аңа абый дип эндәшәләр иде.

Аның әйберләре иптәшләренекенә караганда күбрәк, берничә төенгә җыеп төйнәлгән. Тагын зур-зур дүрт чемоданы бар. «Сез, егетләр, вагоннан төшкәч, пригородный вокзалга барырга булышырсыз инде,— диде әйберләренә ымлап — нәфес дигәнең кызык бит ул, туймый, җыя торгач, шактый әйбер җыелган». Тәкъдимне бик теләп кабул иттек. Булышмыйбызмы соң! Әйберләрен генә түгел, үзен дә кулыбызда күтәреп барырга риза.

Әйберләрне җыйгач, сәке өстендә бер ертык одеал аунап калды. Абый аны миңа тәкъдим итте. Икеләнеп торганымны күргәч: «Ал, ал, анда һәрбер иске чүпрәк алтын бәясендә»,— диде.

Пригородный вокзалга илтеп өеп куйгач, солдатның йөге тау кадәр булды. Ничек вагонга утырып киткәндер, көтеп тормадык, вагондагы хөрмәте өчен кабат мең рәхмәтләребезне әйтеп, кулын кыстык та урамга чыктык. Беренче булып Искәндәр сүз башлады: «Ярар, егетләр, мин кайтып җиттем. Безнең үз йортыбыз, Кече Ямаш урамының бу башында, дүртенче номерлы. Хәзер үзгәрмәгәндерме, сугышка кадәр безнең капка турысында трамвай туктый иде, алай-болай Яңа бистәгә юлыгыз төшсә, рәхим итегез». Соңгы сүзләрен бик мескен булып әйтте. Сәбәбен шактый гомер үткәч кенә аңладым.

«Теге мыеклы абый янында, вокзалда калсам да була иде»,— диде Лотфи, миңа да шул Арча поездына утырырга кирәк. Монда сезне озатырга гына чыктым. Начар сүз белән искә алмагыз...»

Шулай итеп, Коля белән без урам чатында икәү генә басып калдык. «Әйдә, базарны карап чыгабыз,— диде ул,— ерак түгел, моннан ике генә адым». Без базарда иске-москы белән кулдан сату итүчеләр арасына барып кердек. Нәрсә белән генә сату итмиләр иде монда. Башканы әйткән дә юк, хәтта аракы да саталар. Шешәсе белән алырга көчең җитмәсә, стаканга салып бирәләр. Закускасын да кулыңа тоттыра.

«Чыгар теге одеялны»,— диде Коля. «Кит аннан, кем алсын ул искене». «Чыгаруыңны бел». Минут эчендә мине берничә кеше уратып алды. Берсе одеялны кулы белән тотып карады да: «Бигрәк иске икән. Товарлыгы калмаган...» Иенчесе: «Өч багана бирәм, шуннан артыгын өмет итмә»,— диде. Минем бер нәрсә аңламый катып калганымны күреп, куйныннан өч йөзлек акча тартып чыгарды. Һаман әле минем аңыма барып җитми иде. Акчаларын юри, мыскыл итәр өчен күрсәтә дип уйладым. Андый күп акчаны кулыма тотып карау түгел, төшемдә дә күргәнем юк иде. Мин аптырап торган арада, сатып алучы акчаларын куйныма китереп тыкты да, одеялны кулымнан тартып алды. Беренче булып сатулашкан кеше чәчрәп чыкты: «Нигә әле син монда кысылып йөрисең. Одеял минеке!» — диде, һәм алар тәпәләшергә тотындылар. Коля җиңемнән тартты: «Әйдә, яхшы чакта». Без читкәрәк тайпылдык.

«Ничек уйлыйсың, мунчага кереп юынып чыксак, начар булмас бит?» Коляның тәкъдиме күңелемә хуш килде. Сүз белән мавыгып, сулъяк болак буендагы мунчага барып житүебезне сизми дә калдык. Мунчада мин Казаннан киткәннән соң бер үзгәреш тә булмаган. Хәтта, билет бәясе дә искечә — 65 тиен. Кассада йөзлеккә кайтарып бирергә акча таба алмый алҗыдылар.

Мунчада кеше аз иде. Чишенгәндә беренче булып, шуңа игътибар иттем, эчке күлмәкләрем җир төсле каралып каткан. Өстәвенә бет баскан. Уйлап-уйлап тордым да, күлмәк-ыштанымны үзем белән мунчага алып кердем. Миннән күреп булса кирәк, Коля да шулай эшләде. Безнең мунчалабыз да, сабыныбыз да юк. Мунчачыга ялынырга туры килде. Кызыл утызлыкны күрсәткәч, барысы да тиз табылды.

Беренче эш итеп күлмәк-ыштанымны кайнар су белән беттән арындырырга керештем. Мунчада озаклап юындык. Батареяга элгән күлмәк-ыштаннарның кибүен көтеп тордык. Алар кибеп өскә киярлек булганчы берничә мәртәбә пар бүлмәсенә кереп, хәлдән тайганчы чабындык.

Без мунчадан чыкканда көн кичке якка авышкан иде инде. Мин тәмам әлсерәдем. Авызым кибеп, эчәсем килде. Бәхеткә, мичкәдән агызып, сыра саталар иде. Коммерция бәясе белән. Кружкасы 15 тәңкә. Мичкә янында ике-өч кеше генә басып тора. Без дә Коля белән чиратның коерыгына барып бастык. Кат-кат килеп йөрмәс өчен дүрт кружка сыра алдым. Ике кружкасын өстәл өстендә калдырып, тәрәзә төбенә барып утырдык та тәмләп эчәргә тотындык. Сусаганны басарга теләп, вак-вак йотып, озаклап эчтек. Ничектер, шулай вак-вак йотып, озаклап эчсәң, сусау тизрәк басыла дип ишеткәнем бар иде. Кулдагы кружкалар бушагач, өстәл янына икенчеләрен алырга барсак, сырадан җилләр искән. «Шаярмагыз, егетләр»,— диде Коля бер читтә безне күзәтеп басып торган сәләмә киенгән егетләргә мөрәҗәгать итеп. Сүзләренә игътибар итүче булмагач, Коля катгый рәвештә: «Яхшылык белән сыраны урынына китереп куясызмы?» — дип сорады. «Нәрсә,әле син безгә яныйсыңмы?» Берсе кулларын йомарлап, безгә таба ыргылды һәм әтәчләнеп Коляга ташланды. Коля югалып калмады, аягы белән аның касыгына китереп типте. Ул эт кебек чинап, идәнгә барып төште һәм өнсез булды. «Алыгыз, бу хәшәрәтегезне!» — дип кычкырды Коля боерган тавыш белән аның иптәшләренә. Алар безнең янга килергә кыймыйча тизрәк ишектән чыгып китү ягын карадылар. Мин тагын ике кружка сыра барып алдым. «Яхшы иттегез,— диде сыра сатучы хатын,— теге чыгып киткәннәренә дә бирәрне тондырырга кирәк иде». «Булмады бу, сыраның тәмен бетерделәр,— диде Коля авыр сулап,— сугышка кадәр югары Осланга Усиядән паром йөри иде. Мин шунда киттем. Бәлки, соңгысына өлгерермен». Ул миңа кулын сузды. Бу соңгы мәртәбә кул бирешүебез булды. Шуннан соң Коля белән очрашырга туры килмәде.

Юлдашымнан аерылгач, кая барырга белмичә, беренче болак күпере янында озак басып тордым. Островский урамының аргы башында әни ягыннан ерак бер туганыбыз бар барын. Үз йортлары белән яшиләр. Барсаң куып чыгармаслар иде, ничек тә бер кич кундырырлар иде. Аякларым анда тартмады, мине Акком асты урамындагы, сугышка кадәр яшәгән фатирыма өстерәде. Кырыгынчы елны июнь азагында, мин армиягә шул фатирымнан киткән идем. Татарстан урамының кыл уртасында, буйдан-буйга үсеп утырган бакчага кереп, Яңа Бистә ягына таба атладым. Менә Акком асты урамына да килеп җиттем. Бар да мин киткәндәгечә, үзгәрешсез... Уң якта, урамнан капка койма белән корып алынган сигезенче номерлы ике катлы агач йорт. Хуҗасы Гомәр исемле иде. Исәндерме, юктырмы. Йортның өске катында гаиләсе белән үзе яши. Аскы катында — туганы. Алар аның белән бертуганнар. Ул яз җиттеме хатын-кыз киеме киенә, көзгә таба ир кешегә әйләнә. Кызтәкә. Ялгыз яши. Ишегалды түрендә юан бүрәнәдән салынган бер катлы флигель бар. Мин шул флигельдә фатирда тордым. Без анда техникумда

бергә укыган Зөфәр исемле дустым белән яшәдек. Гаҗәп талантлы егет иде. Мин армиядә чагында ул үз-үзен үтергән. Хәзер ул вакыйгага тукталып тормыйм, исән булсам, аның хакында аерым язармын әле.

Флигель дә Гомәр абыйныкы. Анда фатирчы булып Миңнулла абый белән Бәдигол апа яшиләр. Революциягә кадәр үк яши башлагангамы, үзләрен бу флигельгә хуҗа итеп сизәләр. Шулай да, Гомәр абыйга күпмедер фатир хакы түлиләр.

Миңнулла абый белән Бәдигол апа картайганнар иде инде. Үз балалары булмаганлыктан, Зөлфия исемле бер кызны асрамага алганнар. Аның асрамага алынган кыз булуын яшерәләр. Ләкин ул Миңнулла белән Бәдиголнең үз әти-әнисе булмавын белә иде.

Фатирны техникум бетереп, Казан шәһәре финанс бүлегендә эшли башлагач, Зөфәр эзләп тапкан. Техникумны тәмамлагач, мине авыл районына җибәргәннәр иде. Тырыша торгач, Казанга күчерделәр һәм утыз тугызынчы елның ноябрендә шушы фатирга Зөфәр янына килеп сыендым. Бергә озак яшәргә туры килмәсә дә хуҗаларның хөрмәтен яулап өлгергән идем инде. Армиягә киткәндә Бәдигол апа күз яше белән елап калды.

Менә тагын кыяр-кыймас кына мин шушы фатирга барып кердем. Бәдигол апа өйдә бер ялгызы иде. Ачык йөз белән каршы алды һәм алдагы якка кертеп утыртты. Өй эче мин моннан киткәндәгечә түгел, үзгәргән. Беренче булып шуңа игътибар иттем, ишектән кергәч тә, Миңнулла абыйның эш урыны бар иде. Ул — итекче. Иске-москыны төзәтү белән генә чикләнми, яңаны да тегә. Шул һөнәре белән көн күрә. Үз гомерендә башка эшкә кереп карамаган. Кустарь булып яшәгән. Миңнулла абыйның эш урыны җыелган иде. «Бабай өйдә юкмы әллә, күренми?» — дип сорадым. Бәдигол апаның күзләре яшь белән тулды. «Миңнулла абыең юк шул инде. Вафат булды. Узган ел дөнья куйды. Алай бик карт та түгел иде үзе. Җитмешне генә тутырган иде». Күренеп тора, картын өзелеп сагына, күз яшен туктата торган түгел, чишмә булып ага. Исенә төшерүемә үкенеп куйдым. Сүзне икенчегә борырга теләп, Зөлфия турында сорашмакчы идем, ишектән кыз үзе килеп керде. Аны таный торган түгел. Тәмам җитеп беткән. Күкрәге тулып, битләре янып тора. Күрешмәгәнгә алтынчы ел китте, шактый гомер узган шул. «Абау, Әнәс абый, син түгелме соң?» — диде ул бераз аптырап. «Мин, сеңлем, мин. Син дә танымаслык булып үзгәргәнсең». Бәдигол апа ашарга әзерләргә тотынды. Икмәк кисте, мич авызындагы плитәдән кәстрүлне өстәлгә алып куйды. Сарык ите турап пешерелгән шулпа ашап туймаслык иде. Күптән, бик күптән мондый ләззәтле ризыкны авызыма ала алганым булмады. Шакмаклы токмачы ни тора. Андый токмачны бары татарлар гына әзерли белә. Чәй янына Бәдигол апа берәр прәннек чыгарып куйды. «Шул прәннекне кабып эч, күптән конфет, шикәр күргәнебез юк. Эшләгән кешегә шикәр карточкасы бирәләр үзе. Тик менә кибеттә шикәре генә булмый. Кайсы айдан бирле инде шикәр алганыбыз юк, кызым?» — дип, сорады Бәдигол апа Зөлфиядән.

Зөлфия мамык фабрикасында эшли икән. Эше җиңел булмаска кирәк. Хезмәт хакы да чамалы. «Хезмәт хакына калсаң, күптән аяк сузган булыр идек, — диде Зөлфия авыр сулап, — хезмәт хакы өчен түгел, икмәк карточкасы өчен эшләп йөргән булам инде шунда. Карточка эшләгән кешегә генә бирелә бит. Кулда икмәкнең бәясе өч йөз сум. Ничек аңа акча җиткерергә кирәк...»

Бәдигол апа беркайда эшләмәгән. Эш стажы булмагач, пенсия дә бирмиләр. Ул оста тегүче. Көн-төн башын күтәрми тегү машинасы артында утыра. Соңгы вакытта сырма тегеп сатарга җайлашкан. Тышлык белән мамыгын Зөлфия җүнәтә. Базарга чыгарып сату да аның өстендә. Хәер, базарга еш чыгарга туры килми. Күбесенчә өйгә килеп алып китәләр. Тегеп кенә өлгерт. Шул сырма тегеп сатудан килгән керем аларны ач итмәгән.

Сүз арасында Бәдигол ападан фатирга кертүен үтендем. Ул озак җавап бирмәде. Урын түшәп йокларга ятканда: «Ярар, вакытлыча үзебездә торып торырсың. Үзеңнең яхшылыгың өчен генә кертәм. Нихәл итәсең, читен булса да, түзәргә туры килә»,— диде. Үтенечемне кире какмавына мең рәхмәтләр әйтеп, чиста урынга менеп яттым.

Иртәгесен документларымны күтәреп, милиция бүлегенә киттем. Миңа кирәкле җиденче бүлек, Аркылы Тукай урамындагы ике катлы йортта иде. Андагы халыкны күреп, эчем жу итте. Чиратың иге-чиге юк. Ике җирдә чират торалар. Берсендә — паспорт алырга, икенчесендә — пропискага керергә. Чиратым төш вакытында гына килеп җитте. Кечкенә тәрәзәдән кәгазьләремне суздым. Анда утыручы начальник документларыма кырын күзен салды да, кире ыргытты: «Сезгә НКВДга барырга кирәк»,— диде.

НКВДның каядыр, Черек күл тирәсендә икәнен ишеткәнем бар иде. Сораша-сораша барып җиткәнче караңгы төште. Дзержинский урамындагы парадныйдан кабул итмәделәр, чатны борылып Красин урамыннан кердем. Барьер артында клиентларны кабул итеп, милиция өлкән лейтенанты утыра. Ул танылган артист Фәхри Насретдиновка охшаган. Бу кадәр кеше кешегә охшаса охшар икән. Мин артис Насретдиновны армиягә алганнар да, милициядә хезмәт итәргә калдырганнар, дип уйладым. Фамилиясенең дә Насретдинов булуы бу турыда шигемне калдырмады. Шундагы бер кешедән сораган идем, дөрестерме, юктырмы, артистның энесе дигән булды.

Насретдиов документларымны алып, эчтәге бүлмәгә кереп китте. Анда озак тормады, фильтрация үтүем турындагы белешмәне алып чыгып үземә тоттырды. Бер почмагына: «7 отд. мил. выдать паспорт, прописать»,— дип резолюция салынган иде.

НКВДдан чыккач башым әйләнеп, күз алдым караңгыланды. Егылмас өчен бакча рәшәткәсенә тотынырга мәҗбүр булдым. Шул вакыт башыма бер уй килде: «Туктале, нигә әле мин монда шәһәрдә каңгырап йөрим. Авылда әтием белән әнием бар. Алар мине өзелеп-өзелеп көтә торганнардыр. Иң беренче чиратта мин шулар янына кайтырга тиеш түгел идемме соң?»

Мин барып җиткәндә шәһәр яны вокзалында Арча поезды китәргә тора иде. Вагоннарга баш тыга торган түгел. Һәркайсы иңенә күтәрә алган кадәр йөк аскан. Бик тырыша торгач, бер вагонның тамбурына кереп кысылдым тагын. Керү белән чыгу турында уйлый башладым. Ник дисәң, миңа Арчага ук барып җитәргә кирәкми, Коркачык станциясендә төшеп каласы. Бу килештән вагоннан чыгу мөмкин түгел. Коркачык тукталышына җиткәнче төшеп калучылар булса гына инде... Мин алдан аяк киенеп куярга җыендым һәм әкренләп ишеккә таба елыштым.

Поезд Коркачык станциясенә килеп туктаганда вакыт кичке тугызлар тирәсе иде. Көн болытлы булгангамы чиктән тыш караңгы иде. Ярый әле төшүче халык шактый күп булды, ялгызым һич тә юлны табачак түгел икәнмен.

Вагоннан төшү белән бар да ут капкан кебек заготзерно ягына чапты. Сугышка кадәр дә шулай иде, ата — улны, ана кызны белми йөгерешәләр иде. Анда колхозлардан икмәк төяп килгән атлар була. Бераз «төртсәң», утыртып алып кайталар.

Кызганычка күрә, бүген икмәк китерүче булмаган, ахры, җигүле атлар юк иде. Бер кырыйда шактый халык бөялеп тора, нәрсәдер көтәләр. «Кайсы якка кайтасыз, егетләр?» — дип сорадым. Арадан берсе дорфа гына: «Моннан күренми» диде. Аның җавабы кәефемне җибәрде. Аптырап торганда бер яшь егет каршыма килеп басты да: «Абый, сезгә кая таба кирәк?» — дип сорады. «Кушлавыч», дигәнне ишетеп булса кирәк, тагын берничә егет безнең янга килделәр. Бу яшь егетләр күрше авыл — Югары Сәрдәнекеләр булып чыкты. Колхоз атлары белән шәһә-

рдә эшлиләр икән. Алмаш килгән дә болар әти-әниләре янына, ялга кайталар. Мин шушы егетләргә иярдем.

Баштарак егетләр шактый кызу атладылар, артларыннан көчкә-көчкә өлгердем. Бераздан җайга төштеләр тагын...

Арадан берсе тышкы кыяфәтемә игътибар итте: «Син кайдан кайтып киләсең соң, абый? Киемнәрең әллә нинди, безнең як кешесенә охшамаган»,— диде. Әйе, өстемдәге киемнәрем тел белән сөйләп кенә аңлата ала торган түгел иде шул. Башымда француз береты, өстемдә бер поляктан сигаретка алмашып алган кара сукно тышлы бушлат, аягымда солдат ботинкасы. Аларны бигрәк тә, башыма кигән берет гаҗәпләндерде. Ул чакта безнең якларда ирләр берет кимиләр иде. Шуңадырмы, минем баш киемем аларга кыргый булып күренде бугай. «Менә бу нәрсәңне әйтәм,— диде берсе бармагы белән төртеп күрсәтеп,— аны кигәч, көяз кызларга охшагансың».

Безнең юл өстендә авыллар бик еш утырган, аралары өч-дүрт чакрым гына. Казан елгасын аркылы чыгып тауны менгәч, Мулла иле, ул зур, бай авыл. Анда минем әти белән бертуган апамнар яши. Җизни — мулла. Аларга кереп кунып калырга да була. Кая ул тукталып тору? Кайтырга, кайтырга. Авыллар, авыллар... Сугыш алдыннан алар гөрләп торалар иде. Урамнар тып-тын. Ник бер йортның тәрәзәсендә ут күренсен. «Халык хәзер бигрәк иртә йокларга ята икән — дидем, иптәшләремә сүз кушып.— Элек алай түгел иде». «Яшьләр юк. Көн саен дип әйтерлек үлгән хәбәрләре килеп кенә тора. Карт-корыны үзең беләсең, тик яту белән бик тату. Аннан аның крачины да юк. Чыра яндырып озак утырып булмый бит».

Менә без Югары Сәрдәгә дә кайтып җиттек. Егетләрнең берсе: «Абый, әйдә безгә кереп бераз ял ит. Көн яктыргач, кайтып китәрсең»,— диде. Мин аның тәкъдимен кабул итмәдем. «Рәхмәт энем яхшы сүзеңә. Күп калмады, мүкәйләп булса да кайтып җитәрмен».

Югары Сәрдәне чыккач, Иске Җөлбигә кермичә, туры юл белән китәргә уйладым. Күпме эзләсәм дә өч ел буе үзем укырга йөргән сукмакны таба алмадым. Сугыш елларында бу сукмактан йөрүче булмаган, күрәсең... Сүземне сүз итәргә теләп, басу өсләп атлый торгач, ике су арасына — Иске Җөлби белән Кушлавычтан агып килә торган инеш кушылган урынга килеп чыктым. Уң якта Кушлавыч, сул якта Иске Җөлби. Аларны болын гына аерып тора. Ак Яр кырыена килеп туктадым. Ак Яр.. Минем өчен изге урын. Мин белгәндә өч-дүрт метр биеклектәге бу яр астыннан тешне камаштырырлык салкын чишмә агып тора иде. Ул кышның иң салкын көннәрендә дә туңмый. Чишмә агып торганга бу тирәдә шактый тирән булып су җыела. Югыйсә, җәй урталарында инеш кибә. Бары шушы тирәдә генә су җыелып кала. Без — бала-чага иртәдән кичкә кадәр анда су коенып көн уздыра идек. Шушы Ак Яр өстендә авылның иске зираты булган. Өч-дүрт йөз ел элек анда мәрхүмнәрне җирләгәннәр. Хәзер ул җир белән тигезләнгән. Кабер түмгәкләре дә анда-санда гына беленеп тора. Зират өсте сукаланмый, анда хайван да кертелми.

Ак Ярны күргәч, эчем жу итте. Аны ике инештән килеп бәрелгән язгы ташкын җимергән. Ул тәбәнәкләнеп элекке мәһабәт күренешен югалткан, сөзәк урынга әйләнеп өстенә үлән үскән. Никадәр эзләсәм дә яр астыннан ага торган чишмәне таба алмадым. Чишмә юшкын белән капланып юкка чыккан. Монда артык тукталып тормадым, инешнең таррак җирен сайлап, аргы якка сикердем. Аннан өскә күтәрелеп, Түбән болын дип аталып йөри торган җиргә килеп чыктым. Болынның авыл кырые иңкүлек. Яз көннәрендә шул иңкүлектә шактый тирән булып су җыела. Анда егетләр бүрәнәдән сал ясап, төне буе иртәнге таңга кадәр кызлар белән бергә күңел ачалар иде. Су кипкәч, болында котырып үлән үсә. Нинди генә чәчәкләр булмый иде анда. Хәзер болынга карарлык та түгел, казылып бөтенләй эштән чыккан, чокыр да чакыр...

Мин авылыбызның Түбән оч дип атала торган урамына килеп кердем. Җан иясе күренми. Күпчелек йортларның капка коймасы җимерек. Үзебезнең йорт турысына килеп җиткәч, тораташ булдым. Бакчадан җилләр искән. Анда 18 төп алма агачы, күпсанлы чия һәм башка җиләк-җимеш куаклары бар иде. Курка-курка гына ишегалдына кердем. Йорт исән. Бер якка кыйшайган. Шулай ук өйдә беркем дә юк микәнни? Баскыч төбендәге комганны күргәч, эчемә җылы керде. Әкрен генә почмак яктагы тәрәзәне кактым. Пыяласы коелып төшәргә тора. Тәрәзә каршына әти килеп басты. Сакал-мыегы агарган, аркасына бөкересе чыккан. Күзләре эчкә баткан. Аның шушы кыяфәте мәңге онытылмаслык булып күңелемә сеңеп калды. «Әти, мин бу — Әнәс». Исемемне ишеткәч, артка чигенеп куйды. «Торыгыз әле, тор!» — дип өйдәгеләргә эндәште. Өйалды ишеге ачылып, аннан энем Хәмбәл килеп чыкты. Мин киткәндә ул әле сигез яшендә генә иде. Хәзер буйга үсеп, танымаслык булып үзгәргән. Ул арада әти белән әни дә ишегалдына чыктылар. Бер-беребезгә сүз кушарга аптырап тынып калдык. Алар бер кат күлмәк-ыштаннан гына, түшәктән торып чыкканнар. Көн шактый салкынча, җиргә кырпак төшкән. Уңайсыз хәлдән энем Хәмбәл коткарды: «Салкын тидерәсез бит, нәрсә монда катып торасыз, өйгә керегез»,— диде. Керү белән ул мичкә әрем тыгып ут кабызды. Әни өшегән бәрәңгедән коймак пешерергә тотынды. «Мәсгүдә, абыең белән күреш»,— дип мич артына кереп качкан 8 яшьлек сеңлемне чакырып чыгарды. Ул мин белгәндә идәндә шуышып кына йөри иде әле.

Өйне такта белән икегә бүлгәннәр. Ягу кытлыгы үзәккә үтә икән. Җылы саклау нияте белән, өй яртылаш кечерәйтелгән. Мичкә әрем ягалар. Энем Хәмбәл аны чәчелми калган кырдан җыеп алып кайтып, ишегалдына өйгән.

Әти белән әнинең өстендәге кырык ямаулы киемгә күзем төшеп үзәгем өзелде. Әнием үз аягындагы ак сарык йоныннан бәйләнгән оекбашын салып, кулыма тоттырды: «Хәзер үк киеп куй, улым, идән салкын, суык тидереп чирли күрмә»,— диде. Каршы килеп маташкан идем, ишетергә дә теләмәде. Аякларым җылынгач, рәхәт булып китте. Кайнар коймак ашагач, бөтенләй изелеп төштем. Өшегән бәрәңгедән пешерелгән булса да, май сөртеп җибәргәч менә дигән, авызда эреп кенә китә. Күптән икмәк күргәннәре юк икән. «Иртәгә теге умачка саклап тоткан арыш оныннан берәр нәрсә әмәллә,— диде әти, әнигә мөрәҗәгать итеп.— Алла тагын җан биргәнгә җүн бирер әле». Чәйне ниндидер киптергән үлән салып казанда кайнаттылар. Шуны эчкәч, манма тиргә баттым.

Әни үзләре яткан урыннан ястыкны алып сәкегә түшәде. Башым тию белән йокыга китүемне сизми дә калганмын. Үлгән кеше төсле бер нәрсә сизмичә йоклаганмын. Иртә белән тәрәзә аша ишегалдыннан кергән тавышка уянып киттем. Ни арада ишетеп өлгергәннәр, хәл белергә килеп тә җиткәннәр. Иң элек өйгә мөэзин Фәйзрахман абзый килеп керде. Ул авылның иң өлкән кешесе. Яше сиксәннән узган, ярым сукыр. Фронтка китүчеләрдән авылга мин беренче булып кайтканмын. Үлгән хәбәре килгәннәрнең исәбе-хисабы юк. Бу хәбәрне мин дә өстәдем. Бәлки әйтмәскә кирәк булгандыр, ничектер ычкындырып ташладым. Чыпчык Әхмәтҗанының Харьковта, әсирләр лагерында тиф белән авырып үлүен әйтеп куйдым.

Иске Җөлбинең көрәшче Хөббулла малае Таһирны очратканымны әйткәч, бер сәгать тә узмагандыр, сеңлесе мине үзләренә кунакка чакырырга килеп җитте.

Бертуган сеңлем Өммегөлсем сугыш алдыннан Арчада медицина училищесы бетергән иде. Авыр көннәрдә әти белән әниемнең иң зур терәге шул сеңлем булган. Мин кайтканда ул авылыбыздан ун чакрым ераклыктагы Каенсар урманындагы балалар санаториясендә эшли иде. Чыбыксыз телефон минем кайтуымның хәбәрен аңа да илтеп җиткергән.

Төштән соң санатория аты җигелгән тарантаска утырып, ул да килеп житте. Үзе белән ярты бөтен ипи, бер умачлык он алып килгән. Кичкә таба сеңлем китәргә җыенды. Әти белән әнидән мине санаториягә алып китәргә рөхсәт сорады. «Сезнең монда ашау ягы хөрти, абыйны тәрбияләп, кеше рәтенә кертергә кирәк»,— диде. Яхшылап аңлаткач, алар аның тәкъдиме белән килештеләр. Әтинең өстенә карап тордым да, үземнең бер күлмәкне салып, аңа киерттем. Ярый әле Казан мунчасында яхшылап юып чыккан идем. Күлмәк күңеленә хуш килде. Бигрәк тә тезгә кадәр төшеп торган озын итәген килештерде. Киемнең мул итеп тегелгәнен ярата иде, мәрхүм.

Без юлга чыккач, көн яхшы ук суытты. Салкын чеметә башлагач, аякларны печәнгә төрергә туры килде. Кайтып керү белән сеңлем мичкә усак утыны ягып җибәрде. Борынны ярып өйгә хуш ис таралды. Җылы төшкәч, чиста итеп җыештырылган шушы кечкенә бүлмә эче миңа оҗмахтан да әйбәтрәктер төсле булып тоелды.

Иртәгесен йокыдан соң гына тордым. Ул арада сеңлем эшләсе эшен бетереп өйгә кайткан иде инде. Санаториядә авыру балалар дәвалана икән. Балаларны дәвалау бөтенләе белән аның җилкәсендә. Дару эчертә, укол кадый...

Сеңлем янында никадәр генә уңайлы булмасын, миңа нәрсәдер җитми иде. Йөрәгем урынында түгел. Моны сеңлем дә сизенә иде. Якшәмбе көнне Әтнә базарына киттем. Әтнәгә кадәр барасы сигез чакрым араны җәяүләп кенә үттек. Без барып җиткәндә базар гөрли иде инде. Базарга халык төрле яктан җыела. Марилар кичтән килеп куналар. Алар бүрәнә, такта, агач күмере, дегет, чабата ясар өчен юкә алып килеп саталар. Хайван базары аерым. Хайванны якын тирәдәге авыллардан үз аягы белән куып китерәләр. Бер якта арбадан кибет товарларын саталар. Сельпо кибетләре. Шул тирәдә йөргәндә авылдашым Гомәр белән очраштык. Өстендә милиция формасы. Үзе эндәшмәсә, танымаган булыр идем. Бик озак кулымны кысып җибәрми торды. Кырык өчтә яраланып өйгә кайткан. Бер аягы аксый. Кайту белән аны районга чакырып, милициягә эшкә урнаштырганнар. Хәзер паспорт бүлеге начальнигы булып эшли. «Нәрсә әле монда калкынып торабыз,— диде Гомәр сүзне икенчегә борып,— әйдә астагы урамны әйләнеп киләбез. Аннан сеңлемә мөрәҗәгать итеп: «Гөлсем, рөхсәтме?» — дип сорады. Ул мине теләмичә генә җибәрде: «Мин кайта торырмын. Озаклама, төнлә ялгыз читен булыр»,— дип кисәтте.

Әтнә зур авыл. Өчме, дүртме мәчете булган. Байлары белән дә данлыклы. Авылны икегә бүлеп, инеш суы ага. Утыз беренче елны инешнең уң ягы янды. Хаксызга йорт-җире конфискацияләнгән таза хәлле кеше үз йортына ут төрткән. Бер көн эчендә 500 йорт кара күмергә әйләнде. Төтене 12 чакрым ераклыктагы безнең авылга күренеп торды.

Гомәр мине инеш буендагы ашханәгә алып керде. Начальниклар өчен махсус бүлмә бар икән. Юлы аерым, арт яктан. Без шунда кердек. Өстәл янына утыру белән официантка йөгереп килеп җитте. Гомәр беренче сүзне графинга ымлап башлады. «Чистарагын китер»,— дип кисәтте. Аракыны мичкәдән агызалар икән, борынны ярып сасы ис килә. Ашарга тәлинкә тутырып ит бирделәр.

Без бик озак гәпләшеп утырдык. Бала чакны искә төшердек. Бергә уйнап үстек, яшьтәшләр. Ул минем документлар белән кызыксынды. Фильтрация үткәнлеккә бирелгән белешмәне игътибар белән укыды.Беләсеңме нәрсә, әйдә, мин сиңа үзем паспорт биреп җибәрәм»,— диде. Бу тәкъдим күңелемә хуш килде. Казанда чират торып маташканчы, монда эшне бетереп китсәм, яхшырак булыр дип уйладым...

Гомәр мине үзе белән фотографиягә алып кереп, тиз генә өч фотокарточка эшләтеп алды. Аннан милициянең паспорт өстәленә киттек. Милиция бүлеге Әтнәнең янмый калган ягында, элекке ике катлы Гатаулла бай йортында иде. Ярым җимерек хәлдәге ул йорт әле дә исән. Шушы

йортта Гомәр миңа өч айлык вакытлы таныклык язып бирде. Ничек дип рәхмәт әйтергә белмәдем. Ышанам, ул яхшылык эшләргә теләде. Ләкин, киресе килеп чыкты. Яхшылыгы тормыш юлымда ерып чыга алмаслык кыенлыклар тудырды. Паспорт кулга кергәч, башым күккә тиярдәй булды. Чөнки ул заманда авыл кешесенә паспорт алу бәхете тәтеми иде. Сеңлемнең ай-ваена карамастан, икенче көнне үк Кушлавычка кайтып киттем. Юл буе уйланып, шундый фикергә килдем: миңа һич тә авылда калырга ярамый. Әти мулла. 1901 елда Мәңгәр мәдрәсәсен тәмамлап, Кушлавычка имам булган кеше. Каты күзәтү астында яши. Булмаган гаепне бар итеп, НКВД ничек бәйләнергә белми. Башын юләрлеккә салып кына котылып кала. Алып китеп ничек җәзалауларын бары үләренә бер-ике ел кала гына сөйләде. Чәч үрә торырлык! Әтидән Алладан баш тартып, матбугатта белдерү белән чыгуны таләп иткәннәр. Берничә мәртәбә стенага терәп атабыз дип куркытканнар. «Үлем хак. Лә иллаһә иллә-л-Лаһ, Мөхәммәдә-р-расүлү-л-Лаһ, атыгыз дип күземне чөләйтеп тордым»,— ди торган иде. Куркытып эш чыкмагач, әшәке сүгенеп, кайтарып җибәрә торган булганнар. Әти сиксән яшендә 1954 елны дөньядан китте.

Әгәр авылда төпләнеп калсам, минем өскә әти «гаебе» янына әсирлектә булу өстәләчәк. Авылда калсам, җәһәннәмгә озатылырга беренче кандидат идем.

Өммегөлсем сеңелкәш миңа кәләш әзерләп куйган икән. Авылда калмаячагымны белгәч, бөтенләй коелып төште. Мин сөйләгәннәрне ишетергә дә, аңларга да теләмәде. Әти ярты сүздән аңлады: «Улым, син хәзер балигъ булып җиткәнсең, инде үзең чамалыйсыңдыр, ничек җайлы — шулай эшлә»,— диде. Әни: «Күргән кебек тә булмадым»,— дип суган суы сыкты. «Мин сезне ташларга җыенмыйм, кулдан килгән кадәр ярдәм итәрмен. Алла кушып тормышым рәтләнеп китсә, сезне дә үз яныма, шәһәргә алдырырмын»,— дигәч, икесе бер авыздан: «Һай, улым, көфер сүз сөйләмә, беркая да китмибез. Аллаһе тәгалә безне шушында туфрак итсен»,— диделәр. Китүемне авыл халкы да килештермәгән. «Бигрәк миһербансыз икән, карт әтисе белән әнисен ташлап китте»,— дип гайбәтемне таратканнар. Киткәндә әти белән әни мине авыл башына кадәр озатып куйдылар. Зират кырыендагы калкулыкка басып, мин күзләреннән югалганчы карап тордылар. Баштагы елларда хәлләрен белер өчен еш кайтып йөрдем. Һәр кайтуымда шулай озата чыгалар иде.

Бәдигол апа битәрләп каршы алды: «Шулай әйтмичә китәләрмени, дөньяда төрле хәл булырга мөмкин, куркып беттем»,— диде.

Әйтерсең, кулыма алтын кош тоттырганнар. Гомәр биреп җибәргән өч айлык таныклыкны чыгарып күрсәттем. Ул таныклыгымны ошатмады: «Әнәс, энем, ашыгып ялгышмадың микән, паспортны монда, шәһәрдә алырга кирәк иде»,— диде. Мин аның сүзләренә игътибар итмәдем. Милициягә барып пропискага кереп кайтам дидем. Бәдигол апа авыр көрсенеп: «Алай тиз генә эшләнә торган эш түгел ул»,— диде. Иң элек йорт хуҗасы Гомәр абыйның ризалыгын алдык. Ул каршы килмәде. «Армиягә шушы йорттан алынгач, каршы килергә хакым юк»,— диде. Ә менә урам комитетында пропискага керер өчен кирәкле бланкларны тутыру шактый мәшәкатьле булды. Комитет рәисе эштән кайткач, кичке алтыдан соң гына кабул итә. Без килгәндә ул эштән кайтмаган иде әле. Капка төбендә шактый халык чират тора иде. Бер кирегә китсә, китә бит ул. Урам комитеты рәисе эштән бик соң кайтты, җыелган халыкны күзеннән үткәрде дә: «Бик арыдым, бүген ун кешедән артык кабул итә алмыйм»,— дип өенә кереп китте. «Нишлибез?» — дип сорадым Бәдигол ападан. «Бәясен күтәрер өчен шулай дигән була, кабул итәр»,— диде ул мине тынычландырып.

Чират бик акрын барды. Аның янына кергәнче сәгатькә якын вакыт үтте. Ул безне бик салкын кабул итте. Йорт кенәгәсенең битләрен актарып чыкты да: «Сезнең монда кеше өстенә кеше язылган, торак

мәйданы кечкенә, урын житми»,— диде кырт кисеп. «Менә болай ул, Әхмәтжан,— диде Бәдигол апа кызыл утызлыкны өстәл тартмасына салып,— бу егет армиягә безнең йорттан китте, аны пропискага алмаска хаклары юк». Кызыл утызлыкны күргәч, Әхмәтжанның йөзе яктырып китте. «Аптыраган инде сезнең белән, валлаһи, сүзегезне тыңласам, үземә көч, тыңламасаң...»

Кайтырга чыккач: «Бәдигол апа, жаным, минем әлегә сезгә бирергә бер тиен дә акчам юк, көтәрсез инде»,— дидем. «Ала каргада аласың булсын дигән сүз бар, онытмасаң, бер бирерсең әле».

Икенче көнне милициягә киттем. Анда халык кара болыт иде. Кичкә кадәр чират тордым. Начальник документларны кире ыргытты. «Аңлатыбрак әйтегез әле»,— дип сорагач: «Кайдан килдең, шунда прописка-га кер»,— диде. Сөмсерем коелып, Бәдигол апа янына кайттым. Ул: «Кулдан килгән кадәр тырыштым, башкача булдыра алмыйм»,— диде. Дөрестән дә, нишли ала иде соң ул гарип карчык. Кая барырга, кемнән ярдәм сорарга? Башымны иеп, сугышка кадәр эшләгән урыным — Казанның Молотов райфосына киттем. Райфо кольцодан ерак түгел, Свердлов урамының бу башында, сул яктагы өч катлы йортта урнашкан. Мин армиягә киткәндә беренче катта иде, хәзер өченче катка меңгергәннәр. Эшләүчеләр бар да элеккеләр. Мөдир дә иске. Надан бер урыс. Сугыштан бронь белән котылып калган. Гражданнар сугышы вакытында партиягә кергән. Зыялы булуның ни икәнен дә белми. Кешедән тартынып тормый, кайда туры килсә, шунда төкерә, какыра. Бер туктаусыз гәзиткә төреп махорка пыскыта, төпчеген идәнгә ыргыта. Башта бик ачылып сөйләшә башлаган иде, әсирлектә булганымны белгәч, сөмсере коелды. «Син армиягә бездән алындың. Закон буенча иске урныңа эшкә кайтырга хакың бар, әлбәттә. Ләкин киңәш итмим... Чөнки бездә, онытмаган булсаң, хезмәт хакыннан башка бернәрсә дә юк. Хәзер халык чумаралы эшне эзли. Син дә чумаралы эшкә кер».

Аның сүзләреннән бернәрсә дә аңламадым. Ничек инде ул хезмәт хакына яшәп булмый? Чумара дигәне нәрсә инде аның. Шушы сүзләрдән соң мин аңа прописка турында сөйләп тормадым. Чыгып киттем. Аптырап йөрдем-йөрдем дә Наркомфинга барып кердем. Сугышка кадәр налоглар һәм җыемнар бүлегендә булганым бар иде. Шул бүлекне эзләп таптым. Анда өстәлләр шыплап тутырылган. Кыймыйча гына, ишекне кергәч тә уң яктагы, бер кырына «Бүлек начальнигы» дигән аншлаг куелган өстәл янына килдем. «Тыңлыйм сезне, егет»,— диде өстәл хужасы. Яковлев Данил Петрович керәшеннәргә хас акцент белән татарча сөйләшә. Өстенә кара сукнодан тегелгән гимнастерка киеп, билен киң каеш белән буган. Аякларында хром итек. «Сезгә эшкә кеше кирәк түгелме?» «Финанс эшендә эшләгәнегез бармы?» Техникум бетергәнемне белгәч, йөзе ачылып, минем үзләре өчен кулай кеше икәнемне аңлатты. «Безгә ревизорлар кирәк, районга йөрүдән курыкмасагыз, бүген үк эшкә тотынырга мөмкин». Нәрсәдер исенә төшкән кебек уйланып торды да: «Шәһәрдә пропискагыз бармы?» — дип сорады. Җавапны ишеткәч, кинәт үзгәрде. «Элек пропискага керегез, аннан килерсез»,— диде. Хәлне ахырына кадәр ачыкларга теләп, әсирлектә булуымны да әйттем. «Пленнан котылгач, тикшерү булгандыр бит, калганы безне кызыксындырмый». Аның сүзләре күңелемне күтәреп җибәрде. Бөтенләй кеше санынннан чыгарып ташламыйлар икән әле дип уйладым. Хәзер минем алга бөтен кискенлеге белән прописка мәсьәләсе килеп басты. Кире Әтнәгә кайтып, Гомәрдә калдырган НКВДдан бирелгән рөхсәт кәгазен алып килергә башым җитмәде, мәсьәләне үземчә хәл итәргә тотындым.

Наркомфиннан чыккач, урамда бераз басып тордым да Матбугат йортына кереп чыгарга уйладым. Ишекне ачып, бусаганы атлау белән озак еллар «Совет әдәбияты» журналында эшләгән Абдулла Гомәр очрады. Без аның белән сугышка кадәр яхшы ук таныш идек. Күрешү белән бушлат якасын ачып, нәрсәдер эзли башлады. Нәрсә эзләгәнен,

«Нинди орденнарың бар, карыйк әле»,— дип әйткәч кенә аңладым. Әсирлектә булганымны белгәч, ул тиз генә китеп барды.

Миңа «Совет әдәбияты» журналы редакциясе кирәк. Элек ул матбугат йортының уң катында иде. Хәзер күчергәннәр. Мин аны көчкә — китап нәшрияты белән бер катта эзләп таптым. Редакциядә шагыйрь Сәхап Урайский ялгызы утыра иде. Әлләни үзгәрмәгән. Озын итеп үстергән кара чәчен элеккечә артка тарап салган. Минем белән аягүрә басып күреште. Бүлмәгә Кави Нәҗми килеп керде. Сәлам бирде дә, Сәхаптан: «Бу иптәшне кем дип белик?» — дип сорады. Сәхап минем кемлегемне әйткәч Кави Нәҗми «Әнәс Галиев. Шигырьләрен укыганым бар, үзен күргәнем юк иде. Ярый, сез сөйләшегез, мин соңрак керермен» — дип чыгып китте. Мин Сәхапка әсирлектә язылган шигырьләрне күрсәттем. Шигырьләр чүплектән тапкан төрле кәгазь кисәкләренә язылган иде. Шул минутта ук Сәхап берничә шигырьне укып та карады: «Шигырьләрең миңа ошый. Ләкин без аларны журналга кертә алмыйбыз. Син, Әнәс энем, турысын әйткәнгә ачуланма...». Гүя башыма күсәк белән тондырдылар, егылып китә яздым. Кульязмамны кызуланып, чүп әрҗәсенә ыргыттым. Сәхап барып алды да, миңа тоттырды: «Син, энем, алай кызма әле. Кульязмаңны сакла, кирәге чыгар, дөнья һаман болай тормас, үзгәрер...»

Сәхап хаклы булып чыкты. Кыен шартларда, фашист концлагерьларында язылган шигырьләрем юкка чыкмады. Беренчеләрдән булып аларга Сибгат Хәким белән Әнвәр Давыдов игътибар итте. Берничә шигырьне Волгоград шагыйре Ю. Окунев тәрҗемәсендә «Татар поэзиясе антологиясе»нә керттеләр. Татарчасының редакторы Шәйхи Маннур турыдан-туры: «Мин фашист сандугачлары белән эш итмим!» — диде, алай дип әйтергә бернинди дәлиле булмаса да, шулай диде ул.

1958 елны «Кыен юл» исемле шигырьләр китабым чыкты. Китапта башлыча әсирлектә язылган шигырьләр тупланган иде. Китапны шагыйрь Хисам Камал редакцияләп чыгарды. Мин аңа чиксез рәхмәтлемен һәм бурычлымын.

«Совет әдәбияты» журналы редакциясеннән мин төшенке күңел белән чыгып киттем. Бу тирәдә үземне яклаучыны эзләү турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде. Ничек итеп булса да пропискага керергә кирәк. Кесәдә сукыр бер тиен акча юк. Ятим карчык Бәдигол апа исәбенә яшәү оят. Эзләргә, фатир табып пропискага керергә ниятләп йөргәндә, Искәндәрнең адресы искә төште. Кече Ямаш урамы, дүртенче номерлы йорт. Искәндәр, безнең үз йортыбыз, дигән иде, шуларга пропискага кереп булмас микән? Киттем. Трамвай билетына да акчам юк. Тәпи-тәпи атладым. Яңа бистәдә булганым юк иде. Авыр уйларга чумып, үзем эзләгән йортның капка төбенә килеп туктадым. Бер катлы ике агач йорт. Берсе капканың — уң, икенчесе сул ягында. Тәрәзәләре урамга карап тора. Уң яктагысының чардагы бар. Чардак тәрәзәсендә бер хатынның башы күренде. «Искәндәр шушы йортта торамы?» Җавап булмады. Әллә ишетмәде инде дип уйлап, соравымны кабатладым. «Теге бандитны эзләп килеп җиттеләр»,— дип мыгырдаганны ишетеп, егылып китә яздым һәм читкә тайпылдым. Тәрәзәдәге баш тышкы якка сузылды. «Әй, егет, тукта әле, тукта, кемне эзлисең?» Аңыма килергә өлгермәдем, хатын яныма төшеп тә җитте. Исерек ирләр төсле учларына төкереп, каршыма килеп басты. Яше кырыклар тирәсендә булыр, төскә чибәр, мамык шәл бөркәнгән, бертуктаусыз нидер мыгырдый, урысчалатып сүгенеп тә ала, сүзләрен аңлап бетереп булмый: «Башыңа нинди эш төште?..» — ди бу. «Турысын гына әйткәндә фатир эзлим, фатир кирәк». «Син өйләнгән кешеме, хатының бармы? Егет кеше?» «Бик яхшы. Мин сиңа кыз димлим, давай өйлән». Көтелмәгән тәкъдим мине аптырашта калдырды, ул һөҗүмне көчәйтте: «Фатирлы кыз табабыз, менә дигәнен, маневр ясап йөрмә, өйлән». Фатирлы кыз табам, ди бит. Акыллы киңәш. Өйләнәм дип фатирга керәсең дә, ошамаса чыгып таясың. Ул мине җитәкләп чардакка

алып менде. Чардак эче шактый иркен, пөхтә җыелган. Артык әйбер юк: бер караватъ, түрдә — сандык, тәрәзә каршында — өстәл, ике урындык. «Исемең ничек? Мин Фатыйма апаң булырмын. Син шушында утырып тор. Хәзер бер кыз алып керәм. Кара аны, җебеп торма, авызыңнан ут чәч. Шәһәр кызларын үзең беләсең...». Аның сүзләренә ышанырга да, ышанмаска да белмәдем. Озак көтәргә туры килмәде, Фатыйма апа бер кыз ияртеп кайтып та җитте. Кыз зәңгәр күзле, түгәрәк йөзле, көлтә кебек юан сары чәч толымын аркасына төшергән.

Фатыйма апа: «Сез сөйләшә торыгыз, мин хәзер керәм»,— дип чыгып та китте. Без сүз таба алмый шактый вакыт тын гына утырдык.

Бер татар карчыгының, сүз югында сүз булсын, ата казың күкәй саламы, дип әйткәне исемә төште дә: «Кайсыбыз туган минут икән, нинди тын»,— дип куйдым. «Синдер инде, син бит сөйләшмисең». Оста котылды, чая кыз күренә. «Исемегез Мәрьям дисезме, менә нәрсә, Мәрьям туташ, озын сүзнең кыскасы, миңа өйләнергә кирәк, бу тәкъдимгә ничек карыйсыз?» Ул кычкырып көлде. «Ай-яй, син бик тиз...» «Минем көтәргә вакытым юк». «Алай тиз генә хәл ителә торган эш түгел бит ул, бераз йөреп танышыйк...» Минем җавап кыска һәм катгый булды: «Әгәр кияүгә чыгарга теләсәң, күзне йомабыз да, иртәгә бергә тора башлыйбыз. Юк икән, юк...». Мәрьям урыныннан торып китәргә җыенды, әдәпле генә: «Хушыгыз»,— диде. Мин җавап кайтармадым.

Мәрьям чыгып киткәч, биш минут та узмагандыр, Фатыйма йөгереп керде: «Нәрсә, килешмәгән буламы, ялынма ул әҗәтканәгә, икенчене табабыз».

Чардак тимер мич ягып җылытыла. Ашарга да шул тимер мич өстендә әзерләнә. Фатыйма апаның ире Исхак исемле икән. Тиречә. Тире сайлау буенча зур белгеч. Аны алты айга Болгариягә командировкага, чи тире кабул итәргә җибәргәннәр. Беренче хатыны үлгән. Фатыйма апага Болгариягә китәр алдыннан гына өйләнгән. Минем белән әсирлектән бергә Казанга кайткан Искәндер — Исхак абыйның шул беренче хатыныннан туган малае. Фатыйма апа Искәндәрнең исемен дә ишетергә теләми.

Исхак абыйның үз йорты. Атасы үлгәч, мирас бүлгәндә аның өлешенә тигән йорт. Командировкага киткәндә хатыны Фатыйманы чардакка менгереп калдырган. Ягулык юк. Өйне базардан кочак белән утын ташып җылытырга туры килә. Астагы йортка, хакын бер елга алдан алып, фатирчы керткәннәр. Искәндәр шул фатирчылар янына кайтып сыенган.

Фатыйма апа чыгып китте дә, тагын бер кыз ияртеп кайтты. Өсбашы алама, кыркылган чәче яңа үсеп килә. Алгы бер теше юк. Озын буйлы, гәүдәсе нәфис. Бу юлы Фатыйма апа беркая да чыгып тормады, турыдан-туры өйләнешү турында сүз башлады: «Менә нәрсә Рабига, сиңа күптән инде кияүгә чыгарга вакыт. Әнәс кыз ээли, тот та кияүгә чык шушы егеткә». «Миңа өйләнергә риза булыр микән соң ул?» Минем өчен Фатыйма апа җавап бирде: «Риза, бик риза... Нишләп риза булмасын ул. Хәзер үк егетне әниеңә күрсәт». Рабига уйга чумып, тынып калды. Сөйләшергә сүз таба алмый утырганны күреп, Фатыйма апа катгый рәвештә: «Барыгыз, бар, әниегезне күреп ризалыгын алыгыз. Тимерне кызуында сугып калу яхшы»,— диде.

Рабига шушы ук ишек алдында, капканы кергәч сул яктагы кара каршы салынган йортның урамга караганында яши икән. Әнисе Өммегөлсем — Фатыйма апаның килендәше. Әтисе Исмәгыйль күптән үлгән. Йорт аның исемендә. Энесе Исхакныкы кебек үк әтисеннән мирас булып калган. Утызынчы елларда йортның тәрәзәләре түргә караганын сатып, налог түләгәннәр. Хәзер анда яңа хуҗа.

Булачак каенана Өммегөлсем мине бик салкын каршы алды. Ул җитез хәрәкәтле, чандыр гәүдәле, зур борынлы, алтмыш яшьләр тирәсендәге карчык. Без килеп кергәндә тәмләп чәй эчеп утыра иде. Бүлмә бик тар. Аркылыга сыймагач, караватны буйга сузганнар. Борылырга да

урын калмаган. Ишекне кергәч тә тимер мич. Мич янында өстәл сыман нәрсә. Урындыклар куяр өчен урын булмаганлыктан, ашап-эчкәндә караватка утырырга туры килә. Өй такта белән өчкә бүленгән. Сул яктагысында гаиләсе белән олы улы, уң яктагысында килене белән каенсеңелесе яши. Ишектән керү белән Рабига: «Әни, мин кияүгә чыгам»,— диде. Бу сүзләрне ишетеп, карчык урыныннан сикереп торды: «Әстәгъфирулла, тәүбә, әллә шаштыңмы, үзе...» Мин бик оялдым. Җир тишегенә кереп китәрлек булдым. «Шул җүләр Фатыйма болгатып йөри торгандыр инде. Кайда торырга уйлыйсыз?» «Анысын белгән юк әле». «Абыйларыңны күреп сөйләшергә кирәк, алар рөхсәтеннән башка эшләнә торган эш түгел». Карчыкның тагын бер улы бар икән. Анысы ике йорт арасындагы кечкенә өйдә яши. Егетләр икесе дә сугышның беренче көненнән үк фронтта булганнар. Шунысы кызык, бер-берсе белән хәбәрләшмәсәләр дә, сугыштан өйгә икесе бер көнне кайтканнар. Ана өчен моннан да зур шатлыкның булуы мөмкинме соң? Икесенең дә хатыннары, балалары бар.

Сүз белән вакытның узганы сизелми дә калган. Өйдә сәгать юк. Карчык күршегә кереп вакытны белеп чыкты да, кызына: «Син бик җәелеп утырма, иртәгә эшкә барасыңны уйла»,— диде. Кызым сиңа әйтәм, киленем син тыңла дигәнчәрәк килеп чыкты. Әйе, миңа китәргә вакыт. Ләкин, минем китәргә исәбем юк иде. Рабига минем уемны сизде булса кирәк: «Әни, Әнәсне караватка яткырабыз. Син абыйларга кереп кун. Мин ничек тә Фәхриҗиһан апа янына сыярмын әле»,— диде.

Карчык чыгып киткәч, Рабига белән озак серләштек. Ул үзе турында яшерми, барысын да сөйләп бирде. Яңа гына колониядән кайткан. Меховойның чимал базасында эшләгәндә бер кило тоз урлап эләккән. Ел ярым биргәннәр. Бар иде заманалар...

Ул күңелемне тәмам үзенә җәлеп итте. Сизәм, миннән олы, карт кыз бу. Шулай да, яшен сорарга читенсендем. Озак, бик озак гәпләштек. Төн уртасы узгач кына әтисе белән бертуган апасы янына йокларга чыгып китте.

Иртә белән мин уянганда алар бар да аяк өстендә иде инде. Карчык колхоз базарына барып кайтырга да өлгергән. Тимер мичкә ягарга бер кочак коры утын сатып алып кайткан.

Без Рабига белән берәр телем икмәк ашап, чәй эчтек тә ЗАГСка барырга җыендык. Абыйлары Рабигага Германиядән сугыш трофеясе— кием-салым алып кайтканнар. Өстенә агачтан эшләнгән ефәк төсле ялтыравыклы тукымадан тегелгән күлмәк, синтетик йоннан бәйләнгән кофта кигәч чибәрләнеп, танымаслык булып үзгәрде. Сугышка кадәр үк сатып алынган кыска итәкле туны сакланган. Ул да үзенә килешеп тора икән. Башына зәңгәр беретын киде. Мин аның янында карачкы төсле булып калдым. Ул елларны ЗАГС хәзерге Ленин урамында, пассаждан ерак түгел бер йортта иде. Анда берничә пар никахларын теркәгәнне көтеп торалар иде. Шулар арасында минем белән бер елны техникум бетергән Галя исемле бер кыз да бар. Ул үзеннән бик күпкә олы бер ир белән язылышырга килгән. Минем белән оялып кына исәнләште.

Никахны теркәүче татар хатыны иде. Паспортны кулына тоттыргач, әйләндереп-әйләндереп карады да: «Егет, сезнең пропискагыз юк икән, пропискасыз никахны теркәү рөхсәт ителми»,— диде. Милициядәге кебек документларны атып бәрмәде. Анысы өчен дә рәхмәт. «Әлек пропискага керергә тырышыгыз, аннан соң килерсез. Никахны теркәү бер минутлык эш. Күреп торасыз, чират юк...»

Урамга чыккач Рабигадан: «Инде нишлибез?» —дип сорадым. «Шулай хур булып калырмын микәнни? Кияүгә чыгу хәбәрем бөтен тирә-күршегә таралды». Күзләрендә энҗе кебек яшь күреп, чын күңелдән кызгандым. Юк, юк, мин аны ташларга тиеш түгел. Ничек соң, ничек соң никахны теркәтергә? Никахны теркәтүнең башка юлы да булган. Авылга кайткан булсак, авыл Советы никахны берсүзсез теркәгән булыр иде. Ул

вакытта бу турыда башыма кереп тә карамады. Ах, бу тәҗрибәсезлек. Рабиганы ничек юатырга белмәдем. «Шашма әле шул хәтле. Минем сине ташларга исәбем юк ич»,— дигәч кенә бераз тынычланды. Өйдә безне Рабиганың анасы тары боткасы пешереп көтеп тора иде. Чәй янына, хәтта берәр прәннек тә куйган. Безнең хәлне белгәч, бөтенләй коелып төште. Яучыбызны сүгәргә тотынды: «Җүләр Фатыймадан игелек көтәргә буламы соң?! Йөрисез шунда кеше көлкесенә калып». «Болай да эч поша, ичмаса син күңелне болгатма әле,— диде Рабига әнисенә каты гына итеп,— дошманнарга ачудан үз сүзебезне итәбез. Алла боерса, шулай бит, Әнәс». «Әйткән сүз, аткан ук»,— дидем аның сүзләрен җупләп.

Икенче көнне иртәдән үк шәһәр милициясенең паспорт бүлеген эзләп киттем. Анда барырга, урамда очраган, бөтенләй таныш булмаган кеше өйрәтте. Паспорт бүлеге профсоюз урамындагы мәгариф хезмәткәрләре йортын тулысы белән били иде. Мин килгәндә анда шактый халык җыелган иде. Начальник янына кергән кеше озак тоткарланмый, тиз әйләнеп чыга. Минем дә чират килеп җитте. Яһүдкә охшаган милиция полковнигы кабул итте. Минем документларга кырын күзен төшерде дә: «Кайдан килдең, шунда кайтып кит»,— дип кире ыргытты. Аңлата башлаган идем, «Следующий!» — дип кычкырды. Ул арада минем артта чират торган кеше атылып кереп тә җитте. Күз алдым караңгыланып, начальникны аерып торган барьердан читтәрәк, стена кырыена сузылган урындыкка барып утырдым. Бик озак утырдым. Начальник белән аның янына кергән кешеләрнең үзара сөйләшүләрен дә ишетерлек хәлем юк иде. Полковникның: «Син әле һаман мондамыни, тегеләй ителүе житмәгән татарин?» — дигән сүгенү сүзләренә сискәнеп, сикереп тордым. Ул ике милиционерны чакырып кертте дә: «Выбросите его на улицу!» — дип боерды. Ике кулым белән барьерга барып ябыштым. «Балта белән кулымны чабып өзсәгез генә, мине барьердан аерып ала аласыз». «Йөрәк ачыйгысы белән әйтелгән сүзләр тәэсир иттеме, «Не трогайте, пускай стоит»,— диде полковник кулын селтәп. Тәнәфес вакыты җиткән икән, алар ашарга киттеләр. Кире урындыкка барып утырдым. Шул утырудан беркая кузгалмадым. Тәнәфес бетеп, полковник тагын халыкны кабул итә башлады.

Кичке алты җитте. Полковник эшен бетереп, ишекне яптырды. Минем янга килде дә: «Нәрсә, син КПЗга озатканны көтәсеңме?» — диде. «Миңа барыбер...». Ул документларымны сорап алды. «Ничек инде авыл паспорты белән сине пропискага алырга кирәк? Паспорт та түгел әле, вакытлы таныклык...». Мин аңа бик тәфтишләп НКВДда булуымны, 7 нче бүлектән паспорт алып, пропискага керергә рөхсәт итүләрен сөйләдем. «Син монда кем янына торырга килдең?». «Хатыным янына кайттым. Кырыгынчы елны армиягә Сталин хәрби комиссариатыннан алынган идем». «Никахны теркәгән таныклыгыңны күрсәт». «Хатыным таныклыкны югалткан». Ялганларга өйрәнелмәгән иде шул. Колакларыма кадәр кызардым. Полковник өстәл артына кереп утырды да, нәрсәдер язып, документны миңа сузды. Анда: «7 отд. прописать» дип резолюция салынган иде. «Шушы кадәр газапларга кирәк идеме?». «Ну-ка, ну-ка, әле син һаман риза түгелме?». Ул документны кире алырга теләп кулын сузды. Өлгермәде. Яшен тизлеге белән урамга йөгереп чыктым. Ничек Яңа Бистәгә кайтып җитүемне сизми дә калдым. Шатлык бүлмәгә сыя торган түгел иде. Кайнанамның мактавына чик булмады.

Иртәгесен без тагын ЗАГСка мендек. Никахны теркәгәнгә 15 сум акча түләргә кирәк икән. Рабига белән бер-беребезгә карашып аптырап калдык. Рабига өйгә кайтып, әҗәткә акча алып килгәнче мин аны урамда көтеп тордым. ЗАГС мөдире никахны теркәү турындагы таныклыкны акча түләгәч кенә бирде.

Шул ук көнне кайнанай туй мәҗлесе оештырды. Табынны олы улы Гомәр яши торган бүлмәдә әзерләде. Күрше мөәзин Сәләх никах укыды. Ит турап пешерелгән токмачлы аш барыбызның да күңеленә хуш килде.

Рабига белән 45 ел бергә яшәдек. Тату гомер иттек. Алма кебек ике кыз табып бирде. Көнләшеп һәм акча сорап борчымады. Кайбер хатыннар кебек, тегене алыйк, моны алыйк димәде, нинди киеме бар — шуңа риза иде, мәрхүмә. Унөч яшеннән меховойның чимал базасында эшли башлаган. Нәселдән килгән һөнәрне — тиречә һөнәрен сайлаган. Салкында, эсседә тозлы суда басып торып, меңләгән чи сарык тиресен сайлап бер урыннан, икенче урынга ыргыту җиңел эш түгел, әлбәттә. Сәламәтлеге көннән-көн начарланды. Хәлебез чиктән тыш авыр булса да, пенсиягә ике ел кала эштән китәргә мәҗбүр булды. Күзе сукырайды. Ун ел дөнья яктысы күрми яшәде. Соңгы бер ел чамасы утырып тора алмады, кашык белән яшь баланы ашаткан кебек ашаттым. Һич тә дөньядан китәсе килмәде мескеннең. Мин аны ахыргы сулышыма кадәр тәрбияләргә әзер идем. Әмма адәм баласын, вакыты җиткәч, үлемнән йолып калып булмый икән шул... Барлык тереклек ияләренең соңгы юлы уртак, бертөсле.

Сөекле кешеңне ләхеткә салудан да авыр хәл бар микән..

Алар — төп Яңа Бистә кешеләре. Нәсел башы Казан ханлыгы чорына барып тоташа. Казанга тешләре-тырнаклары белән ябышып яшәгәннәр. Шәһәрдән куылмас өчен фамилияләрен дә урысныкына ошатырга мәҗбүр булганнар. Кайнанамның кыз фамилиясе Беляева, кияүгә чыккач Апакова булган. Хатыным Рабига фамилиясен үзгәртмәде, үлгәнче Апакова булып калды.

Алар бар да кул көче белән көн күреп яшәгәннәр — тиречеләр. Олы абыйсы Гомәр генә үзгә һөнәр сайлаган. Пенсиягә чыкканчы шофер булып эшләде. Утызынчы елларда шофер булып эшләү зур дәрәҗә итеп саналган.

Яңа тормыш корып җибәргәнне үзем дә сизми калдым. Алда берсеннән-берсе катлаулырак вакыйгалар көткән икән. Иң авыры — әсирлектә булганым өчен соңгы елларга кадәр ышаныч күрсәтелмәү, эзәрлекләнү булды. Ул турыда бер әсәрдә генә язып бетерү мөмкин түгелдер...

* * *

Бу повестька бәлки шушы урында нокта куйсаң да ярар иде. Уйлый торгач, шундый фикер туды, әсирлектә бергә булган ике танышымның соңгы көннәре турында язмый булдыра алмыйм.

1947 елның җәендә, Куйбышев урамы белән Островский урамнары чатыннан узып барганда мине бер хатын туктатты: «Әнә, трамвай тәрәзәсеннән сезгә кычкыралар»,— диде. Ул арада кемдер дугага бәйләнгән бауны тартып трамвайны туктатты. Ул елларны вагоннарның ишекләре юлда барганда хәзерге кебек бикләнми, ачык була иде. Вагон туктап торган арада бер кеше аннан сикереп төште дә, йөгереп яныма килде. «Кычкырам, кычкырам, ишетмисең. Тукта мин әйтәм, тагын кайчан мин аны очратам...» Авызын ерып каршымда басып торган Хәмитне күреп иңеп киттем. «Их, малай, Гаянны күрми калдың, җирләдек. Менә җидесеннән кайтып киләм.» Хәмитнең кайтуына ярты ел булган. Йортлар идарәсендә маляр булып эшкә урнашкан. «Әйдә, минем күгәрчен оясын күреп чык»,— дип мине үзләренә алып китте. Бауман урамында, хәзерге беренче гастроном өстендә, бишенче катта, кечкенә генә, тәрәзәсез бүлмәдә яшиләр икән. Хатыны, бер баласы бар. Хатыны да маляр булып эшли. Хәмит әчке дулкынлану белән бертуктаусыз Гаянны искә алып сөйләде: «Яткан килеш, шунда Америка госпиталендә дәвалануын дәвам иткән булса, һичшиксез,терелә иде. Ашыгып кайтты»,— диде. Ул бик газапланып үлгән. Авыруына чыдый алмый, асылынырга теләгән. Саклап кына торганнар. Атнага якын аңын югалтып, телсез-өнсез яткан.

Соңгы вакытта Хәмитнең үзен бик еш «Черек күлгә» чакыра башлаганнар. Машинага утыртып алып китәләр икән дә, төнге сәгать бер-

ләргә кадәр тотып, куып чыгаралар. Үзенең кайда булуын беркемгә, хәтта хатынына да әйтергә кушмыйлар икән.

Хәмитне иң нәфрәтләндергәне капчыкка утырту иде. Минем үземне дә «Черек күлгә» чакыргаладылар. Ләкин капчыкка утыртуны татырга туры килмәде. Бу хакта башка кешеләрдән дә ишеткәләдем. Әйе, кешене капчыкка утыртып, әкренләп тынын бетерү — тарихта күрелмәгән кыргый җәза. Ахыргы чиктә Хәмит, газаплауга чыдый алмады, башта эчкечелеккә сабышты. Аракы белән генә тынычлана алмагач, бишенче каттан ишегалдына, асфальтка сикереп төшеп, үз-үзен һәлак итте. Ашыгыч ярдәм машинасы килгәндә әле жаны да чыгып җитмәгән булган.

Якты дөньядан вакытсыз киткән шушы ике иптәшемнән соң, үзем белән әсирлектә бергә булучыларны очратмадым...

## АЛДАГЫ САННАРДА УКЫГЫЗ!

**ГОСМАН ГОМӘР. «ШАҺМИРАН» — МАҖАРАЛЫ ПОВЕСТЬ.**

**Ил күләмендәге икътисади һәм сәяси җинаять, аның чит илләргә сузылган җепләре... Әлбәттә инде — үтереш, эз югалту, җинаятьчене эзләү, ниһаять, мафиянең һәлакәте. Автор хәзерге заман мафиясе тормышына үтеп кереп, аның өшәкелекләрен төрле яктан яктырта, әдәби образлар аша фаш итә, кешеләрдә хаклык, гаделлекнең җиңәчәгенә ышаныч тудыра.**

**«Шаһмиран» — бүгенге көн әсәре, тормышыбызның әлегәчә аз чагылдырылган караңгы якларын яктырта.**

# Роберт Әхмәтҗан



## Кызыл яран

(ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР)

### Багышлау

Ул җыр сине эзләп табар әле,
синең эздән барыр,
бикфорд бавындагы
ут кебек.
Бер җылатыр әле,
сулкылдарсың —
үз капкасын тапмый
бәргәләнгән,
тәгәрәгән
мескен туп кебек!

Ул ут барыр янып синең эздән,—
кит офыкка,
хет аш болытка.
Яшен уты кебек гөлтләп янар,
күк чакмасын чагып, төнен табар,
ялкын булып тамар:
«Онытма!
Онытма!...»

Ә ул сине бер уятыр әле,
мең уйлатыр әле
яңадан.

---

Роберт ӘХМӘТҖАН (1935) — *шагыйрь, күпсанлы шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Үкенечле моңым бар анарда,—
күңел яраларын дәваларга
табылмас шул,
булмас дәвалар!

Мин ул җырны сиңа атап юллыйм,
бер сагынсын диеп Киләчәк.
Ник тыңладым, диеп, үкенерсең,
бер күрерсең әле,
бер күрерсең,—
Ул Киләчәк сиңа,
киләчәк!...

Күк астына аны җибәрәм мин,
болытларга,
атылып сайрар
тургай янына.
Комач усак итеп
кабызам аны
икәү йөргән
Мирәт тавында!

Тылсым итеп
мин җибәрәм аны,—
суга — балык,
күккә — кош итеп.
Ул җыр сине эзләп табар әле,—
тавышыңнан танып,
ишетеп...
Ул сагынып тәрәзәңә килер,
эңгер төшкәч
зәңгәр кич җитеп.

Ул җыр сине эзләп табар әле,—
бер янарсың
зәңгәр ялкында!
Бик ерак та түгел,
Бик якын да —
Ул җыр... ул җыр...
Синең хакында...

* * *

Әйткән идең: «Әткәй, мин кайтканчы
Ишегалдына син утырт тал...»
Тал — талланды,
Син дә кайттың, дустым,
Талга карап,—
Шуннан гыйбрәт ал.

Яфракланды вәгъдә, яңа чорга
Ябалдашы гүя тоташкан!..
Кайттың — киттең.
Әткәң йорты утыра
Тал рәхмәте булып тоташтан.

Киттең — кайттың...
Вәгъдә — иман бездә:
Талың жырлый синең каршылап.
Туган җиргә кайтып ни утырттың —
Шуны бел син элек яхшылап!

* * *

Үкен, үкен —
инде үтте ул көн,
очты җилгә тәтен —
очкан гомер...
Тәңгәл икән барысы — бергә-бер...

Очкан төтен,
җилгә очкан гомер —
моңлы төшем белән
бермә-бер!

Ни калдырдың?..
А, ул гүзәллекләр,
ул киңлекләр —
билдән — ак чәчәк!
Ике кулда чайпалдырып савыт,
ак сөлгесен иң өстенә салып,
ни китерә
көткән Киләчәк?

Ни китерә,
йә, әйт.
Дүрт күз белән аны көтеп алып,—
әллә язмыш балы,
әллә... агу —
күпме икән аңа
бирәчәк?
Шулай укмы
Үтеп китте гомер
качып,
басып аяк очына?
Сүнде ялкын,
калды көйгән күмер —
шуны кыстым
арык учыма.

## Кызыл яран

Тын гына түрдә балкып утыра,
Килер таңнарның җылысын тоеп.
Тын гына көтеп күңел яктысын,
Бер чәчәк атып,—
бер чәчәк коеп...

Керер кышлар да, карлар эчендә
Калдырмам һич тә сөйгән яранны.
Рәхмәт әйткәндәй, кызыл чәчкәсе
Төшәр дә
капылар
йөрәк
ярамны.

## Давыл иркендә

Идел күкрәккәе актарыла,
сыек таулар төшә капланып.
Уба упкын,
ап-ак сыртлы дулкын
офыкларга бәрелә күбекләнеп,
ак болытка сикерә
ак каек!

И, мин шундый давыл теләр идем,
тансыклаган күңел
давылны!
Давыл иркендәге чакырымнарда,
чагылларда йөзең чагылды!

Җир белән күк арасында йөри
Җил китергән
ерак тавышың...
И мин шундый давыл теләр идем,
давыл канатында җиләр идем,—
хет авазлар безнең
кавышсын!

Син бит миңа гомер буйларына
офыклардан килгән
тавышсың!

## Колшәриф монологы

I

Әстәгъфирулла, Рух!
Ошбу туфрак миңа сөйләгән иде,
Мөнәҗәт әйткән иде ошбу чаган...
Кая чыгасың, Колшәриф,
даулы шәһри Казанга,—
Дошманнарың күптер,
үзең бердер һаман.
Идел-йортта эшләр яман, яман!

Әстәгъфирулла!
Бистәләрнең хәле ничек анда,—

Ничә мичкә дары җибәрелгән.
Казан исән әле. Манаралар төп-төз,
Тик кяфернең күз-каш
Җимерелгән.

Үрмәлиләр әнә каршыбызга,
Безнең тарафларга төртеп бармак.
Яу киләсен сизгән идем алдан,
Иван явыз корган
мәкер-кармак...

II

Авыр төш күрдем, хәерлегә улсын,—
Итил, имеш, болытларга ашкан.
Коеп ява җиргә кызыл яңгыр,
Күкләр кешни,
Кан ягмуры коя
Бертоташтан.
Хәерлегә улсын:
(Яу чабасын сизгән идем алдан.)

Итил-судан килгән төялешеп,
Хөсетләнде Мәскәү, каныктылар
Изге йортка. Вәхшәт төяп килеп
Үз-үзләрен күптән таныттылар...

Әстәгъфирулла!
Мәдәт бирсен изге гамәлләрдә;
Тапсын татар имин үз кыйбласын.
Шуышалар изге туфрагыма,
Әстәгъфирулла,
Мәсҗетемә соң керүем улмасын,
Амин!

## Сувар җыры

Урман гизә бал корты,
Юкәдән бал эзләнеп.
Ә без килдек сезләргә,
Туганнарны сездә дип.

Түз, түз, күпер, түз күпер,
Атлар чыгып җиткәнче.
И туганнар, түзегез,
Сездә булып киткәнче.
Ике күке бер талда,
Төшкәннәр төшке ялга.
Үткәннәргә үкенмик,—
Күрәчәгебез алда!

## Татар иртәсе

Әле татар чукындырылмаган,
Җимерелмәгән Казан диварлары,
Колшәрифне кылыч чапмаган.
Сөембикә әле үсмер бала.
Кара яла ягып ак дөньяга,
Шаһгали дә денен сатмаган.

Милләтемнең таза, үсмер чагы,
Идел-йортның дөрли үз учагы,—
Иман бөтен әле безләрдә!..
Үт агызып кяфер бушанмаган,
Әле беркем җирдә ышанмаган
«Татар — батыр» дигән сүзләргә.

Офыкта юк хәвеф күләгәсе,
Итил-суда очкан кош шәүләсе,
Атларыбыз утлый чабында...
Олы юлда күтәрелми тузан.
Корган талга кунган бала козгын
Өмет итә нидер табынга...

Әле татар чукындырылмаган,
Дию бәйдән ычкындырылмаган,
Хыял — дәрья,— каерып иш кенә!
Тарихыбыз өчен бу — бер мизгел,
Ыруларым өчен керсез, изге
Сабый чакта күргән төш кенә!

Төш кенә...

# Акъегет



## Яңа шигырьләр

* * *

Хатын-кызлар,
Шәраб, көлү, күз яше...
Яфрак арты яфрак оча —
Үбешү ишарәсе.

Әбиләр чуагы.
Җан тынлык эзләмәкче.
Ял паркында
буш көймәләр әйләндерә
зур «Шайтан тәгәрмәче»...

## Казансуда каргалар

Кичләр бүген куе-зәңгәр,
Зәңгәр хәтта ак карлар.
Төнгә таба Казансуда
Шомлы өер — каргалар...

Нидер бар бу табигатьтә
Без белмәгән, тоймаган.
Ниләр искәртә кискен җил,
Исеп әллә кайлардан?

* * *

Дөнья тутырып килде май айлары,
Гомернең дә әле язы бит.
Кулларыңа каләм ал син бүген,
Бер утырып хатлар языйм дип.

---

АКЪЕГЕТ (Рөстәм ФӘЙЗУЛЛИН) — *1951 елда туган, шагыйрь, «Ак болыт шәүләсе», «Төнге сулар» исемле китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Хатлар яз син миңа, хатлар яз син —
Көткән көндәй озын булсыннар.
Гөрләвектәй аксын хат юллары —
Сөю хисе белән тулсыннар.

Хатлар яз син миңа, хатлар яз син,
Чакыр мине ерак-еракка.
Күңелем минем һәрчак яланаяк,
Изү чишеп карыйм офыкка.

* * *

Язгы җилләр сулышыма каба,
Кар суларын озатып калышым.
Карашымны зәңгәр күккә манып
Карап торам болыт агышын.

Ә болытлар ага кыйблаларга,
Болытларның миндә эше юк...
Бу дөньяда яшәдем дә сыман,
Тик гомерләр үтте — төш кебек.

* * *

Алма кызыл,
кызыл миләш,
кызыл инде балан да...
Ана йөзе,
Ата йөзе,
күчә бара балага.

Кышлар килә,
кошлар кунган
миләшкә дә, баланга...

Алма кызыл —
вакыт җиткән
тәгәрәргә ак карга...

## Туган нигез. Карап торам тәрәзәдән

Тәрәзәне чеметеп
көзге яңгыр ява,
Моржалардан чыга төтеннәр...
Бер ботакта
Алма башын игән —
Исән калган әле бу төннән...
Күрше килене
Мунча ягып йөри,

Мин танымыйм аны
бөтенләй...
Урамнан әнә
«Ул» да үтеп бара,
Кемдер дәште аңа:
«Әй, түтәй!..»

* * *

Яңа елдан
Көтә башлыйм язны,—
Яңа елдан көннәр озая.
Ноябрьләр, декабрьләр
Үтә кебек заяга.

Яңа елның офыгы киң,
Карлары да ак аның.
Кояшлы чана эзләре
Тоташа язга барып.

## Ай яктысы

Мәшрикътагы болытны
Алларга мана-мана,
Таңы белән хушлашып
Офыкта Кояш яна...
Төн дә инде, Ай чыкты,
Су буе калды тып-тын.
Өй артындагы шомыртлар
Тәрәз чиртте шыпыртын.
Ай яктысы... урамнарга
Атты гүя күңелне...
Чү!
Янәшәдә ике шәүлә:
Берсе балаң түгелме?!

* * *

Килер бер көн:
без аерылышкан чакта
озак-озак янар
утлар учакта...

Булыр моңсу,
булыр бик якты.
Кемдер авыр сулар:
акты сулар,
акты, акты...

* * *

Бүгенге көн —
Кичә була,
Кичә була иртәгә...
Кемнең җаны? —
Тәрәзәдә
Күбәләк бәргәләнә...

* * *

Эссене туңгач сагыну,
Кадер белү — югалтып...
Кешене бер елатмыйча
Буламы соң юатып?!

## Ирек

*Очар кошлар иле —*
*яфрак хыялы...*

Яфрак җирләргә ятканчы
Була әле җилнеке...
Җилдә түгел, җирдә түгел,
Ботакта ул чын иркең!

* * *

Астан караганда кыя,
өстән караганда — упкын...
Кайда торасың бит,
Дөнья шундый, дустым.

* * *

Менә миләшләрең.
Менә көз...
Яфракларга тимә,
Җилгә калдыр,—
Ачы җимешләрен генә өз...

* * *

Тоела гына дип уйлап,
мин аңа ышанмаган...
Ул чыннан да —
ул чагында —
«сөям»,— дип пышылдаган!

* * *

Әле яңа гына тып-тын иде,
Бу җилләр соң
чыкты кай ара?
Җилләр яфрак белән уйнагандай
Кем соң
Язмыш белән минем шаяра?!

* * *

Изге урын буш тормый ул.
Кояш батса, Ай чыга.
Бер күгәрчен очып китте —
Кунды ике карчыга.



# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



## Тәүфикъ Әйди

# КАРДӘШЛӘР КОЧАГЫНДА

СӘЯХӘТНАМӘ

### МИН — ЮГОСЛАВИЯЛЕ!

**1991** елның сентябрь аенда Төркиянең илгизәрләр ял итә торган Ялыкавак авылында узачак халыкара «Совет — Төркия хезмәттәшлеге» коллоквиумына чакыру килгәч, мин башта бик гаҗәпләндем. Галимнәр генә катнашырга тиешле фәнни җыйналышка язучыны ничек чакырасы иттеләр икән? Җитмәсә, әдәбият дөньясын аяктан егарлык әсәр язып шаккатырмаган, ни лауреат, ни депутат, хәтта, Язучылар берлегендә идарә әгъзасы да булмаган кешене! Дөрес, мин туган әдәбиятыбызның халыкара багланышларын, Татарстаннан читтә яшәүче күренекле милләттәшләребезнең эшчәнлеген өйрәнәм, соңгы вакытта «Казан утлары» әдәби журналының фән бүлеге редакторы, чит мәмләкәтләр белән дуслашуны, аларда яшәүче татарлар белән бәйләнешне кайгырту өчен корылган «Ватан» җәмгыяте идарәсе әгъзасы. Әмма, программасында күрсәтелгәнчә, коллоквиум нигездә ике дәүләт арасындагы икътисадый мөнәсәбәтләрне өйрәнүгә, хезмәттәшлекне алга җибәрү мөмкинлекләрен ачыклауга багышланачак иде. Монда инде экономика фәннәре докторлары яки сәүдә эшләрен яхшы белүче бүтән белгечләр катнашуы кирәк. СССРдан утыз бишләп кенә вәкил чакырылачак җыйналышка минем кебек кешегә ни сан? Кем эше бу Ялыкавакка чакыру?!

Төркиягә бару — күп татар язучысының хыялы. Чөнки без милли мәктәбебездә революциягә кадәр яшәгән байтак культура эшлеклеләребезнең Истанбулга барып укуын, аннан килгән китаплар һәм вакытлы матбугат белән азыклануын беләбез. Шунда дәрелфөнүн тәмамлаган, Уральскига кайткач, Габдулла Тукайга җитди йогынты ясаган Камил

---

Тәүфикъ ӘЙДИ (1941) — *әдип, «Елан угы» романы, «Божра» повесте, хикәя, эссе җыентыклары авторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Мотыйгыйны, «Галия», «Буби» мәдрәсәләрен ачуда үрнәк булган Истанбул дәрелфөнүнен, Төркиядә гыйлем җыеп кайткан һәм әлеге мәдрәсәләребездә сабак укыткан күренекле милләттәшләребезне дә онытмыйбыз. Бүгенге төрек әдәбиятының Көнбатыш Европада һәм АКШта елдан-ел киңрәк танылa баруын, аңа Совет галимнәренең дә «чын Европа югарылыгында» дип бәя бирүләрен истә тотабыз. Классикларыбыз яратып укыган Юныс Әмрә, Әхмәт Мидхәт, Хөсәен Рәхми, Нәмикъ Кәмалларга алмашка Гомәр Сәйфетдин, Газиз Нәсин, Кәмал Таһир, Рәшит Нури шикелле талантлы бик күп каләм ияләре үсеп җитүен ишетү генә түгел, аларның әсәрләрен дә яратып укуыбыз хак. Ниһаять, ул — дөньяда кардәш төрки халыкларның тулы бәйсезлеген саклаган бердәнбер дәүләте, без бары шунда гына тылмачсыз да иркенләп йөри, кем белән дә җиңел аралаша алабыз. Аннары шактый кырыс климатлы Татарстан кешесе өч тарафыннан җылы диңгезләр белән чикләнгән илнең мәңге яшел үзәнлекләрен, ишетеп яки укып кына белгән, кинофильмнәрдә яки телевизорда гына күргән зәйтүн, шәфталы, армут (груша) урманнарын, йөзем бакчаларын барып тамаша кылырга ничек кызыкмасын инде? Аның бит әле борынгы архитектура һәйкәлләре, алты манаралы мәһабәт мәчетләре, төрек солтаннары яшәгән гүзәл сарайлары, мәшһүр Тупкапы музее, бүгенге истәлекле корылмалары да күп.

Шуңа күрә минем дә күптән Төркиягә барасым килүе табигый. Моның өчен шактый ук чарасын күрүем дә хак. Болгария, Алмания сәфәрләремдә көньяк күршебезгә дә күперләр салынды, аннан Казанга килгән кунаклар да багланышларны көчәйтте, ике арада хатлар йөри башлады һәм, ниһаять, Измирдәге милләттәшләребез: «Ай буе торырсыз. Истанбул, Искешәһәр, безнең яклар белән танышырсыз»,— дип чакыру да җибәрде.

Ә бусы — бер атналык коллоквиумга, рәсми вәкил рәвешендә, барлык чыгымнарны Төркия күтәрәчәге искәртелгән гыйльми җыйналышка иде. Чакыруга коллоквиумны оештыручы «Йени форум» журналы мөхәррире профессор Айдын Ялчын кул куйган. Мин инде «Йени форум»ның бүтән төрек басмалары арасында иң абруйлы һәм җитди сәясиижтимагый, икътисадый журнал икәнлеген, күренекле галим, экономика фәннәре докторы А. Ялчынның анда сан саен кереш мәкалә бастырып килүен укып белә идем. Чакыруга кушымта итеп җибәрелгән реклама буклетында Ялыкавакның Эгей диңгезе буена, Бодрум шәһәреннән унсигез чакрымдагы гүзәл табигать кочагына урнашкан булуы, коллоквиумның илгизәрләр туктала торган экзотик «Монакус клубы»нда узачагы, елның шушы вакытында монда рәхәтләнеп ял итәргә бөтен мөмкинлекләр тудырылачагы, Измир шәһәре белән дә таныштырылачагы вәгъдә ителгән иде. Әмма... апрельдән калмыйча чыгышның тезисларын, майдан да калмыйча чыгышның үзен дә язып җибәрергә кирәк иде. Төрек яки инглиз телендә. Кабатлануларны булдырмас өчен моның алдан эшләнергә тиешлеге аңлатылган. Буклетта ихтимал темалар да тәкъдим ителгән. Бик кызыклы коллоквиум, әмма мин чагыштырмача җылы март ае килгәч салкын тидереп, ай ярымга шифаханәгә кереп яттым, аннары редакциядә үзем югында җыйналып көтеп торган кулъязмаларны ашыгыч рәвештә нәүбәттәге саннарга әзерләү эшенә чумдым, шуңа иҗат, юбилей ыгы-зыгысы да өстәлде. Доклад язу эше атнадан — атнага, айдан — айга кичекте. Казан университеты проректоры, әле күптән түгел Төркиягә барып кайткан профессор Миркасыйм Госманов:

— Айдын Ялчын — президент Тургут Үзалның үз кешесе, коллоквиум, мөгаен, хөкүмәт кушуы буенча оештырыладыр, алар Совет экономикасы хәлен, үсеш үзенчәлекләрен, перспективасын ачыкларга телидер. Җитди чыгыш ясый алмасаң, баруда мәгънә юк,— дип тәмам өркетте.

Ул арада «Аэрофлот» чит ил рейсләренә бәяләрне ике-өч тапкыр күтәрде, «Мәскәү — Истанбул — Мәскәү» авиабилеты еллык хезмәт хакыма тиңләшәчәге мәгълүм булды. Бу чыгымны да төрек ягы күтәрәчәге

хатта ачык әйтелмәгән иде. Язучылар берлеге Мәскәүгә чаклы да командировка бирмәячәге ачыкланды, чөнки бу сәяхәт алар эшенә кагылмый икән! Әйтерсең, мин анда культура багланышларын ныгыту, шуның өстенә, Төркиядә яшәүче милләттәшләребез турында мәгълүмат җыяр өчен дә бармыйм. «Ватан» җәмгыяте дә идарә әгъзаларының бушка эшләвенә генә риза, командировка хакында сүз кузгатсаң, син аңа өч тиенгә дә кирәкмисең, имеш. Кызык бу дөнья, билләһи!

Берзаман Ялыкавак коллоквиумына Татарстаннан тел галиме Мирфатыйх Зәкиев, язучылардан Разил Вәлиев, Мәдинә Маликова, Ринат Мөхәммәдиевлар да чакырылуы беленде. Барырга икеләнүемне әйткәч, халыкара мәйданга чыгып тәҗрибә туплаган Мәдинә белән Разил кычкырып көлеп җибәрделәр:

— Төркиягә чакыруны — кунак итү шарты белән түгел, үз хисабыңа илгә керергә, анда бераз торырга рөхсәт биргән кәгазьне генә дә илчелек тирәсендә бөтерелгән «эшкуарлар» безнең ике-өч еллык хезмәт хакына сатып бизнес ясый. Комфортта бушлай яшәү, дөнья күрү, зиһенеңне баету мөмкинлеге сиңа ошамыйдыр шул! — диделәр.

Мәдинә Татарстан хөкүмәт вәкиллеге эчендә әле яңа гына Төркиягә барып кайткан, Разил исә быел гына АКШ һәм Канадага визит ясаган иде. Курыкмыйлар, тагын юлга җыеналар!

Оештыручылардан өченче хат килгәч, Мәдинәләрдән виза һәм билет рәсмиләштерү серләрен ачыклагач, безнекеләрдән соңгы кеше булып, ниһаять, мин дә сәфәр хәстәренә керештем. Монда иң кызыгы РСФСР консуллык идарәсендә паспортка мөһер суктыру булды. Минем кәгазьләрне тикшергән Мозаффаров дигән хезмәткәр чит илгә командировкага җибәрүне үтенгән редакциябез мөрәҗәгатен укыгач:

— «Казан утлары» рәсми теркәлгән журналмы? — дип сорады.

— Әлбәттә, югыйсә үтенечне Язучылар берлегеннән генә яздырган булыр идем.

— Теркәлү индексын беләсезме?

Аның кайчандыр бер хаҗәте чыгасын кем уйлаган инде? Ярый әле төрле шундый мәгълүматларны җыеп саклый торган компьютерлары бар икән, кабаланып шул кабинетка йөгердем. Ләкин компьютер ватылган, имеш. Киттем гозер белән бүтән кабинетлар буйлап. Һәммәсенең ишеге төбендә чират, билгеле. Кире әйләнеп Мозаффаров янына кергәндә кәгазьләремә шулай да тагын бер имза куелган иде инде. Ул аларны конвертка салып, тышына тәртип санын язды да тыныч кына:

— Ике атнадан килерсең, — диде.

— Сез нәрсә, — дидем мин, гаҗәпләнеп, — ул чакта Төркиягә баруның хаҗәте дә калмаячак, коллоквиум тәмамланган була ич инде.

— Үзегез алданрак ни карадыгыз соң?

— Татарстан ОВИРы ай буе тикшереп, паспортыма Алманиягә бару рөхсәтен чәпегән, Министрлар Советы махсус комиссиясенең Төркиягә җибәрү карары кулыгызда. Ул кәгазьләрне ике атна буе сез тагын нишләтмәкче буласыз соң?

— Тәртибе шундый, — диде Мозаффаров. — Әле озаграк та каравыбыз мөмкин.

Бу бүлмәдә өч-дүрт хезмәткәр утыра, һәркайсы алдында чит илгә барырга җыенган совет гражданнары. Мозаффаров — хезмәткәрләрнең яшьрәге, араларында бердәнбер мөселман. Әллә татар, әллә үзбәк яки казакъ — кыяфәтеннән анык кына чамаларлык түгел. Шулай да татарчага күчеп штурмлый башладым:

— Чит ил паспорты белән миңа хәзер үк билетка барырга кирәк. Сез аны кире үземә бирегез әле алайса. Билет мине ике атна буе көтеп тормас.

— Безнең мөһер сугылмаса, сезне чик аша барыбер чыгармаячаклар.

— Беләм. Мин законнарны хөрмәт итәм, кагыйдәләрне дә бозарга җыенмыйм, паспортымны ике-өч сәгатьтән үк китереп тапшырырмын. Төркиянең чакыру кәгазен дә кире бирегез, консуллыкларында билгеләнә торыйм.

Тыңлады тагын, рәхмәт төшкере. Мәскәүдә ике ел укуның да файдасы тиде — таныш җирдә урнашкан Төркия консуллыгына ярты сәгатьтә барып җиттем. Кабул итү вакыты беткән, әмма боларда бюрократия Совет иленекеннән кимрәк, ахры, Айдын Ялчын хатын күрсәтеп, консуллыктагы ул атаган хезмәткәрне сорагач, кабул да иттеләр, гозеремне тыңлаганнан соң, илгә керту рөхсәтен дә паспортыма минуты белән язып, мөһерләп бирделәр. Иңгә канатлар үстемени, моннан инде «Төрек һава юллары» кассасына йөгердем. Анысы да — таныш җирдә. Монда инде минем исемгә язылган бару-кайту билеты әллә кайчан иясен көтеп яткан икән, эшем, консуллыктагы кебек, бик тиз хәл ителде. Йә, хода, бар икән әле синең кешене тинтерәтми генә йомышны йомышлый торган җирләрең!

Ике сәгать тулганчы ук мин яңадан Мозаффаров янына атылып кердем. Хәзер инде чират торып маташмыйм, ишек төбендәгеләргә:

— Кабат керүем, мине ул үзе чакырды,— дип кенә искәртәм. Чакырыр, көтегез!

Мозаффаровка исә:

— Эшне менә ничек тә йөртеп була икән,— дидем.— Консуллыкта — биш минут, кассада — биш минут, нәтиҗәсе менә: Төркиягә керергә рөхсәтем дә, очарга билетым да әзер. Сез хәзер паспортыма ике сүз сырлар өчен ике атна көттерәчәксезме инде? Татарстан КГБсы җиде бабама чаклы тикшерде ләбаса. Зинһар булышыгыз, шәхси эш белән йөрмәвемне беләсез, аннары ерак шәһәрдән килгән кеше ич мин!

Милләте билгеле булмаган, әмма татарча сөйләшүемне керфек тә какмый тыңлап торган хезмәткәр егетем паспортымны, билетымны актарып карады да күрше бүлмәгә кереп китте һәм бер-ике минут эчендә консуллыкның түгәрәк мөһерен суктырып чыкты, аннары үз кулы белән: «Фәләненче числога кадәр Төркиягә бара», дигән «тылсымлы» сүзләрне язып куйды.

— Хәерле сәфәр!

Шулай икән, максатыңа ирешер өчен бераз чаялык, әрсезлек тә, юлыңда Мозаффаров кебек күпмедер кардәшлек хисен җуймаган егетләр очравы да кирәк икән. Билгеле, ул миңа татарча ләм-мим әйтмәде, әмма шул ук бүлмәдә утырган бүтән хезмәткәрләргә мин болай кыю басым ясый алмаган булыр идем. Ил зур, Мәскәүгә, мәркәз кәнсәләренә кем генә килми, алар арасында татар агай-энеләр чагыштырмача күп түгел, йөзгә берәү генәдер. Ә кабинет хуҗалары арасында алар тагын да әзрәк, билгеле. Шулай итеп бәхетле очрак булышты — мин башкаланың Ширәмәт аэропортына вакытында килеп җиттем.

Аэропортның контроль зонасын узганнан соң ук чит ил башланды. Бинасы бер булса да, бирге заллардагы ресторан һәм буфетлар валютага гына эшли, имеш. Кибеттәге товар муллыгы да шуңа бәйләнгән икән — чит ил гражданнарына алар кирәкми, безнекеләр булган кадәр маясын мал арзанрак сатыла торган җиргә саклый.

Минем чит ил авиакомпаниясе очкычына беренче мәртәбә утыруым. Шунлыктан «Төрек һава юллары» хезмәт күрсәтүенә аеруча игътибар бирәм. Очкыч салоны уңайлы, стюардессалары ягымлы икән. Алар очу тәртибен, авария очрагында нишләргә кирәклеген төрек һәм инглиз телләрендә башта ук аңлатып бирде, аннары алдыбыздагы киң экранда без узасы араның картасы, әледән-әле очкычыбызның күпме җирне узуын, очу биеклеген һәм тизлеген, һава температурасын һәм бүтән мәгълүматларны сурәтләп, язып күрсәтә башладылар. Ике сәгать ярым гына очсак та, сыйлаулары хәйран — сусынны төрле-төрле сутлар белән басканнан соң, берсеннән-берсе тәмле-татлы ризыклар китерделәр. Нәни

тартмачыкларга салынган яки төрелгән тәгамнәрнең кайсы нәрсә икәнлеген, аларны файдалану тәртибен ачыклаганчы саташып бетәрлек. Истанбулда Измиргә бара торган киң вә юан корсаклы очкычка күчеп утыргач, сый тагын кабатланды, әммә, эчке рейс булгангамы, очу вакыты бер сәгатькә дә тулып җитмәгәнгәме, монысында ул кимрәк иде. Измир очкычында бер рәттә егерме ике урын тезелеп киткән, кинотеатрдан бер дә ким түгел. Ничә йөз юлаучы сыйгандыр, санап очына чыга алмадым. Анның һавага текә күтәрелүе, җиргә йомшак кына төшеп куныуы исә әле дә хәтердә.

Безнең яңа кешеләр белән танышуыбыз Мәскәү аэропортында ук башланды — татар вәкиллеге монда Киевтән баручы сурәтче Рафаил Мәсәгутов белән тулыланды. Габдулла Тукай, Муса Җәлил китапларын матур бизәп чыгаруы, соңгысын берьюлы ике телдә — украинча һәм татарча бастыруы, Казанда шәхси күргәзмәсен уздыруы, аннан да әүвәл Мәскәүдә үткән дөнья яшьләр фестивале эмблемасын иҗат итүе белән ул безгә күптән билгеле иде. Киевтәге татар җәмгыяте рәисе дә шушы кеше булганлыктан, без бик тиз аралашып киттек. Аннары Эстония, Литва, Украина галимнәре белән таныштык.

Очкычыбыз Мәскәүдән бер сәгать чамасы кичегеп кузгалды, Истанбулдан китәсе рейс тә соңга калдырылган иде. Шуңа күрәме, безне Измирдә каршы алырга тиешле кеше уяулыгын югалтып, кунакларның килеп җитүен абайламый калган, ахры. Без аны үзебез эзли башладык, якынлашкач үзе ачылып китә торган ишектән вокзал алды мәйданына чыгып, маңгайларына язу язылган автобусларны караштырдык. Ул арада янибызга килеп, безгә колак салып торган таксичылар:

— Сез кайдан? Кая барасыз? Үзебез илтеп куйыйкмы? — дип сүз куштылар.

Рәсәйдән, «казан төрекләре», коллоквиумга килгән галимнәр, язучылар икәнлегебезне белгәч, алар да хуҗаларыбызны эзләшергә керешге. Таксичылар кайда да елгыр халык, әммә боларның кыяфәтендә иман нуры бар, кешелеклелек, ягымлылык булуы куандырды. Метродан Ширәмәт аэропортына автобус билеты утыз тиен торган чагында, Мәскәү таксичылары ике йөз сум, чит ил юлаучыларыннан исә йөз доллар сорауларын, чынлыкта дәүләт машинасында кычкыртып талау белән шөгыльләнүләрен әле берничә сәгать элек кенә күреп килгәнлектән, без измирлеләрне сынап күзәттек. Аннары: «Боларның кеше кесәсенә кермәячәкләре, итагатьле хезмәт күрсәтеп, кирәк җиреңә, һичшиксез, илтеп куячагына, тиешен генә түләтәчәгенә шикләнмәскә мөмкин», дигән фикергә килдек. Май чүлмәге тышыннан билгеле — мөгамәләләре дә шуны раслый иде.

Ниһаять, хуҗаларыбыз табылды, алар безне икенче катта көтеп утырган икән. Автобусларын вокзал алдына китереп туктаттылар да кунакларны барладылар. Һәммәбез кереп урнашкач, салкын чишмә суы тәкъдим иттеләр. Суыкта тотылган, ике йөз илле грамм сыешлы полиэтилен капларга тутырылган суны кабын тишеп суырырга кавырсын көпшә да тоттырдылар. Ике йөз илле чакрым ераклыктагы Бодрум шәһәре аркылы Ялыкавакка юнәлдек. Мин шофер янәшәсендәге алгы кәнәфигә күчеп утырып, аңардан тегене-моны сорашып бара башладым.

Юлыбыз асфальт, әммә шәп сыйфатлы түгел. Ике йөз җитмеш чакрымдагы Ялыкавакка чаклы дүрт сәгать чамасы барырга туры киләчәк. Бодрумның даими халкы егерме меңнән артмас, ләкин җәен илгизәрләр, ял итүче кунаклар килеп тулгач, алтмыш-җитмеш меңгә дә җитә икән. Диңгез буенда урнашкан, соңгы елларда гына тәртипкә китерелә башлаган. Төрекчә «ялы» — яр буе, «кавак» — тирәк дигәнне аңлата. «Ялыкавак» — Тирәкле яр. Без барасы авыл, димәк, матур агачлар үсеп утырган диңгез буе икән.

Кичке тугызларда гына кузгалып киткәнлектән, тирә-якны әлләни тамаша кылып булмый, күз бәйләнгән иде инде. Әмма аэропорттан

Измирне әйләнеп, аннары шуңа тоташкан бүтән шәһәрчекләрне кисеп узганда, аларның әйбәт яктыртылуына таң калдым. Бензин колонкалары, Көнбатыш илләрендәгечә, яктыга коенып, балкып утыра, тирә-яктагы авыллар да күнелле җемелдәп, караңгылык диңгезендәге утраулар шикелле, күзгә ташлана. Юл буе билгеләре дә тәртиптә, яктылык кайтаргыч хасиятләре белән борылышларны, асфальт чиген ерактан ук күрсәтеп тора. Менә сиңа шәмнән, керосин лампасыннан котыла алмаган, артта калган Төркия! Ул электр энергиясен әле кайчан гына «алдынгы», «социализм маягы» дип мактадган Болгариягә дә сата башлаган икән!

Шофер белән сөйләшәбез. Хезмәт хакы гаиләсен — хатынын һәм дүрт баласын асрарга җитә. Бу автобус Төркиядә эшләнгән, кайбер детальләре генә чит илләрдән килә. Элек җиңел машиналар да чит илләрдән килгән детальләрдән җыйналган, хәзер инде Төркия һәр нәрсәсен үзе ясый. Япония фирмалары белән яңа автомобиль фабрикасын кору турында килешү төзелгән. Машина гына түгел, очкыч та җитештерелә хәзер, аны Грециягә дә сатачаклар әле киләчәктә. Бензинмы? Төркиядә нефть күп чыгарылмый, әмма ягулыкка кытлык юк, шөкер. Көндез бу юлда хәрәкәт бик тыгыз, хәзер басылган вакыты, баруы да рәхәт.

Ярты төн узгач, Ялыкавакка килеп җиттек. Бер-берсенә тоташкан икешәр катлы ике-өч бинадан гыйбарәт «Сәрәмәй» отеленә урнаштырдылар. Безне кыска җиңле кара күлмәк, кызгылт төстәге шорт кигән урта яшьләрдәге ябык ир кеше каршылады. Тиешле анкеталарны тутыргач, ул һәркайсыбызны аерым номерларга таратты. Монда без гел шушы әфәнде белән генә эш иттек. Иртән ачыклавыбызча, ул җитмеш урынлы шушы отельнең һәм каршыдагы — тар асфальт юл артындагы ресторанның да хуҗасы икән. Карап торырга һич тә бай әфәндегә охшамаган, Көнбатышның колониаль романнарында фәкыйрь җирле халык вәкилләрен нәкъ шушындыйрак кыяфәттә тасвирлыйлар! Хуҗабызның исә тышкы кыяфәттә эше юк, кайчан карама, бер үк киемнән йә отелендә, йә ресторанында, йә ишегалдында бөтерелә. Отель кәнсәсенең, ресторанының ишекләре тәүлек буе ачык, хәтта төнлә дә бикләнми, ләкин, хуҗасы анда утырмаса да, бер әйберенә дә тимиләр, күрәсең.

Номер — ике бүлмәле, өч урынлы. Кухнясы, бәдрәфе һәм душы бар. Кайнар суы бер дә өзлеп тормый. Әйбәт җиһазланган, бөтен җире пакь, таза. Гаиләләләр килеп, аш-суны үзләре әзерләп ашәргә теләсә, суыткыч та, электр плитәсе дә бар, шкафында табак-савыт та җитәрлек. Бормалы сукмак сине купшы гөлчәчәкләр арасыннан утыз метрдагы диңгез ярына алып чыга. Ак плафоннардан сибелгән яктыда нәни бакча хуш исе, кеше биеклеге үскән чәнечкеле гөлчәчәк куакларының караңгы яшел төсе белән әкияти тәэсир калдыра. Безнең ишек турысыннан икенче катка бормалы ак баскыч менеп китә. Сукмакларга таш җәелгән, беренче катның ачык әйван (терраса) идәне мәрмәр вагы сибеп бетонланган һәм шомартылган. Бүлмәләрнең һәм, гомумән, отельнең архитектор тарафыннан яхшы ук уйлап планлаштырылуы күз алдында.

Соң килсәк тә, Мәдинә белән Разил түзмәде, сөлгеләрен иңнәренә салып, асфальт юлның аргы ягында гына чапылдап яткан диңгезгә су керергә йөгерделәр. Ә мин монда сөйләргә тиешле нотыгымны тәмамларга утырдым. Аның тезисларын Мәскәүгә килгәндә поездда кәгазьгә төшергән, әмма язып бетерергә өлгермәгән идем.

Иртән диңгез яры буйлап «Сәрәмәй» отеленә орынып торган «Монакус клубы»на киттек — коллоквиум шул илгизәрләр шәһәрчегенең асфальт юл буендагы бер бинасында узачак — бинаның тыштан мәгарәне хәтерләткән аскы каты утырышлар алып барырга көйләнгән, өске катындагы ачык әйванлы рестораны туклану урыныбыз итеп билгеләнгән иде.

Әйваннан хозур күренеш ачыла — аста Эгей диңгезенең Ялыкавак култыгы җәйрәп ята. Сул якта диңгез күк белән тоташкан, офык сызыгы рәшә эчендә эреп югалган. Култыкның аргы ягында пеләшләнгән, әле

кеше үз эзен салырга өлгермәгән түбәләр калкып тора. Бирге ягы — «Монакус клубы», «Сәрәмәй» хуҗалары корган пляж. Анда ял итүчеләр кызынып өчен махсус ятаклар тезеп куелган. Юл белән пляж арасында гөлчәчәкләр скверы, билгә җиткән куаклар ак, кызыл, алсу чәчәкләргә күмелгән. Уртадагы түгәрәк түтәлдә башка гөлләр дә хуш ис таратып утыра. «Монакус клубы»ның монда үз буфеты да эшләп тора: кока-кола, сыра, каһвә, кәбап яки бүтән сыйларның күңелең теләгәнен сайлап алырга була.

Мине монда аеруча гаҗәпләндергәне һәм сокландырганы — култык эченә кереп торган егерме метр озынлыктагы басмага киндер түшәлүе иде. Су коенучыларга нинди хөрмәт — диңгезгә шул йомшак юлдан гына кәс-кәс керәсең дә уңайлы баскычыннан иплэп кенә дулкыннар кочагына төшәсең. Хәер, дулкыннар монда биек, куәтле түгел, яр буе сай, суы пакь — төптәге йомры ташлары басмадан җете күренеп тора.

Ресторанының исә күңелгә хуш, төрекләр әйтмешли, «чук гүзәл» үз хасияте бар икән — һәрвакыт уннарча төрдәге салат әзерләнә, күңеленә хуш килгәнен махсус өстәлдән өлеш тәлинкәңә үзең салып аласың: кыяр, помидор, кишер, чөгендер, ногыт, зәйтүн җимеше, торма, суган, кәбестә, тагын әллә нәрсәләр! Без, яшелчә сезоны тиз тәмамлана торган төньяк вәкилләре, «өйдә тагын кайчан элэгер әле бу», дип, һәммәсеннән берәр кашык авыз итәргә омтылабыз — ахырда тәлинкәбез салат белән түбәләмә тула. Билгеле, аны ашап бетерү җиңел түгел, чөнки сыйр, казылык, кызыл балык, уылдыклы бутерброд ише ризыклар да бар ич әле. Әмма витаминнан кем зыян күргән, сыйлаганда кадерен белү хәерле! Шулар янына кавын-карбыздан икешәр телем, йөземнән бер-ике чук, армуттан яки шәфтальдән берәр җимеш аласың. Әлбәттә, тәнгә шифа өчен чия, анар яки әфлисун суты эчәргә дә онытмаска кирәк. Чәй эчәргә, самолеттагы кебек, нәни тартмаларга тутырылган тәм-том кәтә сине. Төрек табынына һәрчак шешәле чишмә суы куела, чәй яки каһвәнең үзең теләгәнен китерәләр. Алардан элегрәк, әлбәттә, кыздырма, тавык боты яки шундыйрак янә берәр тәмле тәгам килә. Төшкедә шулпа да өстәлә. Нәрсә дип сыйлыйлар безне монда, байлыкта һәм муллыкта яшәүләрен күрсәтергә теләпме? Соңрак белдем — Төркиядә юл буендагы кафеларда да туклыклы ризык кына ашаталар икән. Билгеле, ул бик үк арзанга төшми, нечкә билле нәни касәдәге шикәрле чәй дә кимендә биш йөз лира тора, ягъни ун касә чәй (безнең үлчәмдә өч-дүрт стакан!) — бер доллар чамасы.

Менә шушы ачык әйванда без коллоквиумга килүчеләрнең бүтәннәре белән дә очраштык — алар арасында минем берничә танышым да бар булып чыкты: Үзбәгестан Язучылар берлеге секретаре, шагыйрь Мөхәммәт Салих, Алманиядән тел галиме һәм журналист Тимер Хуҗа. Тимер үзенә хас ихласлык белән мине кочаклап алып, инде моннан ун ел элек Мәскәүдә гәп корып утырган, өй адресларын биргән танышым М. Салих янына алып килеп:

— Бу әфәнде — Казаннан, Бохара турында җөдә яхшы роман язган татар язучысы...— дип мине тәкъдим итте һәм шунда ук әсәремнең уңай якларын да саный башлады.— Аның «Елан угы»нда басмачылар, әмир тарафдарлары совет идеологиясенә бәрабәр берьяклы күрсәтелмәйде, хәтта минем дәдәм дә кешелекле адәм сыйфатлары белән сурәтләнгән. Җөдә кызыклы әсәр, мавигип укилади. Тәүфикъ кардәш Үзбәгестанга баглы ике китап чигарыпты, ләкин Ташкент нәшриятләре ул кыйммәтли басмаларга һичбер илтифат бирмәйде икән...

Үтереп мактый мине Алмания егете, хәтта арттырып та җибәрә бугай, әмма мин аны туктатмыйм, мыштым гына елмаеп торам: ходай күпсенмәсен, еш эләкми ул безгә!

М. Салих әз сүзле, сабыр ир-егет. Тимер Хуҗаның да, аның атасының да кем икәнлеген бик яхшы белә. Атаклы сәүдәгәр, миллионер, Бохара җөмһүриятен коручыларның берсе, соңрак басмачыларга кушыл-

ган һәм мөһаҗирлеккә китәргә мәҗбүр булган Госманхуҗа Булатхуҗаев Үзбәгестан тарихында күренерлек эз калдырган шәхес. Аның улы Тимер исә галим генә түгел, «Азатлык» радиосы хезмәткәре дә. Шунлыктан, Тимер мактаган әсәр М. Салихны кызыксындырды, ахры, ул «Елан угы»н Ташкентка җибәрүемне үтенде.

Ул арада безне утырышлар залына чакырдылар. Хуҗалар коллоквиумда катнашучыларга «Йени форум» журналының яңа саннарын һәм тарихи, икътисадый эчтәлекле китаплар, каләм-куен дәфтәрләре бүләк иттеләр, түшебезгә типографиядә исемнәребез басылган, матур итеп пластмас кысага алынган визиткаларыбызны кадап куйдылар. Әзерлекләре менә дигән: папкаларыбызга, каләмнәребезгә «Ялыкавак коллоквиумы» билгесе һәм датасы да төшерелгән иде! Хатларымның конвертына әтием исеме иң соңыннан язылганлыктан, төрекләр аны фамилия итеп кабуллаган, шуңа күрә визиткамда «РАМАЗАНОВИЧ» эре хәрефләр белән басылган иде. Кызыксынган кешесенә түшендәге язуга карап эндәшүчеләр миңа тиздән:

— Сез Югославия мөселманымы, әфәндем? Мин Бәлкәнт университетыннан булам... Мин — Истанбулдан,— дип таныша башладылар.

— Беттең,— дип шаяртты моны ишетеп торган Разил Вәлиев.— Фамилияң Югославиянеке икән, үзең дә Татарстанга кирәкми. Йөр шунда Әдрән диңгез буенда каңгырап!

Әмма әүвәл һәркайсыбызга колоквиумда катнашырга кирәк иде әле.

## КОЛЛОКВИУМ

Гыйльми мәҗлес иртәнге сәгать ун тулганда профессор Айдын Ялчынның төрек һәм инглиз телләрендә сөйләнгән кереш нотыгы белән ачылды.

— Төркия вә Советлар берлегендәге экономик вә сәяси үзгәрешләр күз алдында,— диде ул.— Без демократияләшә барабыз. Базар экономикасына юл ачу дәүләтебезнең матди нигезен ныгытты, алга баруыбызны тизләтте. Табигый байлыкларыбызны, көчләребезне акыллырак файдалану, Көнбатыш тәҗрибәсенә киңрәк таяну мөмкинлеге туды. Советлар Берлеге дә хәзер шушы юлга басарга җыена. Үзара хезмәттәшлегебез яңа югарылыкка күтәрелә бара. Әле кайчан гына чикләребез ябык дип әйтерлек булса, хәзер көн саен Төркиягә СССРдан ун меңләп кеше килә. Ике якка да файдалы сәүдә, матди вә рухи байлыклар алмашу арта. Шушы хәрәкәтне моннан соң да үстерү, әле эшкә җигелмәгән мөмкинлекләрне ачыклау үзеннән-үзе көн тәртибенә куелуын күрү кыен түгел. Коллоквиумда катнашучылар ике якның да хәлен, үсеш перспективасын ачыклау, багланышларыбызны тәрәккъкый иттерү буенча үз анализларын, кыйммәтле фикерләрен һәм фаразларын уртага салыр, мәҗлесебез файдалы үтәр дип ышанырга рөхсәт итегез...

Көлсу чәчле, әмма төз атлап йөрүче нык гәүдәле, яшь кыяфәтле, йөгерек акыллы профессор Ялчынның җитмешне тутырганлыгын белгәч, мин таң калдым. Мавыгып китеп регламентка сыймаучылар да, төп темадан бик ерак култыкларга китеп адашып, кадерле вакытны әрәм итүчеләр, үз туксанын гына туксан дип санаучылар да теләсә кайсы гыйльми җыйналышта була. Шундыйларны, хәтерләрен калдырмыйча, олы юлга борып җибәрү, конструктив фикер алышырга этәрү докладларга, чыгышларга тиз анализ ясауны, сыгылмалыкны, кайвакыт әдәпле генә шаярта белүне дә таләп итә. А. Ялчын әфәнде коллоквиумны алып барганда нәкъ менә шундый сыйфатларга ия икәнлеген күрсәтте. Четерекле минутлар да булмады түгел. Мисалга, чакырылган дүрт-биш вәкил урынына Әзәрбайҗаннан утыз кешелек десант килеп төште, аларны урнаштыру, тукландыру үзе бер кыен мәсьәлә булса, аларның сүз сораган һәммәсенә вакыт табу читенлеген Ялчын әфәнде үзе генә аңлата алыр

иде. Җитмәсә, бакылылар шулкадәр актив, берсеннән-берсе актуаль мәсьәләләрне күтәреп, бүтән ил галимнәрен тәмам кысрыкладылар: «Әзәрбайҗанда әлифба алыштыру кыенлыклары», «Әзәрбайҗанда дини аң үзенчәлекләре», «Әзәрбайҗан әдәбиятында тәрәкъкый мәсьәләсе», «Әзәрбайҗанда тиҗарәт-сәүдә шартлары», «Әзәрбайҗан телендә икътисадый атамалар»...— кирәк бит бер Әзәрбайҗанда Ялыкавак халыкара коллоквиумында тикшерер өчен шулкадәр четерекле мәсьәлә җыйналырга! Берсе шул темаларның кайсындыр доклад итеп сөйли — ана егерме тугыз тыңлаучы шаулатып кул чаба, аннары кайнарланып бәхәсчеләре мәйданга чыга. Шулкадәр кызыксыну уя..ан Бакы нотыкчысыннан соң ничек инде нәүбәттәгесенә сүз бирмисең? Безгә җиңел ул, күршебез колагына: «Бакыда галимнәр калды микән? Әзәрбайҗанда шушы мәсьәләләрне җыйналып тикшерерлек урын нигә табылмый икән?»— дип пышылдаган булабыз. Нәүбәттәге нотыкчы ул арада дәртләнеп-дәртләнеп:

— Кардәшләр, Әзәрбайҗанда алтмыш җиде шәһәр бар, шуларның һәммәсендә Төркия кибетен ачарга мөмкин. Тиҗарәт, сәүдә — базар икътисадының нигезе, сәүдә кылып, төрек-әзәрбайҗан, Төркия — Советлар Берлеге хезмәттәшлеген ныгытыйк! Әзәрбайҗанның һәр шәһәре хезмәттәшлек мәйданына әверелсен! Шул чакта кардәшлегебез тойгысы һәр әзәрбайҗанлының кальбендә тамыр җибәрер!— ди.

Соңыннан бу кайнар нотыкларның этәргеч көчен ачыкладык: Әзәрбайҗан вәкиллегендә кичәге КПСС райкомы секретарьлары, шул партиянең республика эшлекләләре, элекке министрлар — визаны һәм чит ил паспортын җиңел кулга төшерә, чыгымнан курыкмый торган «галимнәр» күпчелек тәшкил иткән икән, аларның һәммәсе диярлек чемодан-чемодан мал төяп килеп, без коллоквиумда гыйльми яктан тикшергән мәсьәләләрне гамәлдә хәл кылып, бартер сәүдәсен башлап җибәргәннәр, имеш!

АКШ, Алмания, Литва, Мәскәү, Украина галимнәре аларны елмаеп тыңлый, хуҗалар кыенсына, Бакы ташкынын чикләргә талпына. Профессор Ялчынга Тимер Хуҗа ярдәмгә килә — реплика өчен сүз алып:

— Әфәнделәр, халыкара коллоквиумда шул төбәктә хәл итәргә мөмкин локаль мәсьәләләрне тикшереп мавыкмыйк!— дип искәртә.

Әзәрбайҗан вәкилләре, әлбәттә инде, моңа оешкан төстә протест белдерә, сүз бүтән җөмһүрият вәкиленә бирелгәч, аларның күпчелеге залны ташлап чыгып китә!

Моның файдасын күрмәдек түгел — шуннан соң Татарстан вәкилләренә дә сүз бирергә форсат табылды. Ринат Мөхәммәдиев республикабызда үзгәртеп кору ихтыяҗының ничек барлыкка килүен, Мирфатыйх Зәкиев — Төркия белән Татарстан хезмәттәшлегенең торышын, бу өлкәдәге мөмкинлекләр һәм өметләребезне бәян иттеләр. Аларны кызыксынып тыңладылар, әмма безнең утыз кеше килмәвебез дә акланды, чөнки Мәдинә белән Разил чыгышларында инде алдагы ике иптәшебезне кабатлау сизелә башлады. Шулай да мин Разилне:

— Миңа иң ошаган чыгыш синеке булды, әллә төрекчә кушмаганга инде, һәр сүзеңне аңлап рәхәтләндем!— дип мактадым.

Шаяруның кадерен белгән шагыйрь:

— Үзем дә, залда мине һич югы биш кеше аңласын инде, дип тырыштым!— дип көлеп җибәрде.

Безгә төрекчә гыйльми атамаларны төшенү җиңел булмаса, төрекләргә безне төшенү тагын да кыенрак иде. Чөнки күпсанлы халык аз санлы кардәшенең телен өйрәнүне кирәксенми. Төрек әдәби теле исә Ататөрек заманыннан безнең көннәргә кадәр бик нык үзгәргән — бездә файдаланылган күпчелек гарәп-фарсы алынмаларын кулланыштан чыгарган, гарәп-фарсы һәм Европа телләре атамалары урынына борынгы төрки хәзинә кайтарылган, шулар нигезендә бик күп яңа сүзләр ясалган. «Бак»тан «бакан» *(министр)*, ягъни багучы зат, «баш»тан «Башкан» *(рәис)*, ягъни, баш кеше барлыкка килгән. Гасырлар дәвамында ят

халыклар, ят мәдәниятләр йогынтысы астында калу төрки халыкларга туган телләрен үз нигезендә гармоник үстерергә комачаулаган, бу бәла бәйсез дәүләтләрен җуймаган төрекләрне дә атлап узмаган. Милли аңнары уянгач, Ататөрек җитәкчелегендә алар төп нигезгә кайтырга тотынганнар. Андый мөмкинлектән мәхрүм СССР төркиләре бүтән юнәлештә үсте, шунлыктан бүгенге төрек теле безгә егерменче йөз башы төрек теленнән шактый ерак! Тамыры, мәгънәсе уртак сүзләрнең дә төрекчә һәм татарча әйтелешләре шактый аерылганлыктан, тиз-тиз сөйләшкәндә, гәпнең ни турында баруын чамаласаң да, нотыкчыларның фикере зиһенгә төгәл һәм тулы килеп җитми кала. Нотыкларның инглизчәгә тәрҗемәсен тыңлар өчен бөтен шартлар тудырылган, әмма без чит телдә, гомумән, аксыйбыз.

Казагыстан вәкиле Самат Үтәниязов, чыгышы төрекләргә дә аңлаешлы булсын өчен, татарча сөйләргә тырышты. Аның: «Халкыбыз эчкечелеккә бирелде, ирләребезнең өйләнергә вакыты юк, шуның аркасында кияүгә китмәгән кызларыбыз саны ике йөз меңнән артты. Димәк, милләтебезнең табигый үрчеме дә кимеде, алкашлардан исә аңгыра балалар туа, генофондыбыз һәлакәт кичерә. Казакъ милләтен юкка чыгудан коткарыйк, кардәшләр!» дигән чакыруы тыңлаучыларны хафага салды.

Коллоквиумга читтән иң әзерлекле килгән вәкил миңа Эстония галиме Ивар Раиг шикелле тоелды. Ул сүз бирелер алдыннан залдагыларга республикасы турында типографик ысулда инглиз телендә тарихи һәм икътисадый белешмә басылган буклетын таратып чыкты, аннары менбәргә Эстония дәүләт әләмен чыгарып беркетте. Чыгышын төп темага багышлап, саф инглиз телендә ясады. Төрекчәгә синхрон тәрҗемә тәэмин ителгәнлектән, тыңлаучылар аңа гөрләтеп кул чапты.

Коллоквиумда Литва, Украина, Грузия, Әрмәнстан һәм Мәскәү экономистлары чыгыш ясаса да, алар Төркия галимнәренә күп яңалык ача алмады шикелле. Беренчедән, бездәге бүгенге күчеш дәвере, таркаулык алар өчен инде үтелгән баскыч; икенчедән, Совет иленнән азмыкүпме танылган белгечләр килмәгән иде. Аның каравы төрки җөмһүриятләрнең сәяси хәле, рухи үсеше, милләтара бәйләнешләр табигате, аларның Төркия белән хезмәттәшлеге мәсьәләләре төрле яктан яктыртылды. Кардәш төрки җөмһүриятләр үсешенә битараф булмаган хуҗалар бу җәһәттән канәгатьлек тапканнардыр дип уйлыйм. Безгә исә күренекле төрек икътисадчыларының, тарихчыларының үз илләре һәм бүтән дәүләтләр мисалында базар экономикасына күчү, банк-валюта системасын үзгәртү, төрле милек формалары яшәү үзенчәлеге, Төркиянең бүгенге хәле турында сөйләүләре тирән тәэсир калдырды. Турысын әйтергә кирәк, алар бу мәсьәләләрне, бездән аермалы буларак, профессиональ югарылыкта тикшерә торган белгечләр иде. Бу җәһәттән, коллоквиумны оештырган үзәк җитәкчесе Айдын Ялчын шәхесе әйбәт мисал була ала.

Ул офицер белән укытучы гаиләсендә Олыборлыда туган, шунда башлангыч белем алганнан соң, Истанбулның Хәйдәр паша лицеен тәмамлаган. Аннары Сәяси белемнәр югары мәктәбендә укыган, Лондон университетында белемен күтәргән. 1951 елда докторлык диссертациясен тәмамлаганнан соң, туган иленә кайткан һәм 1941 елда Сәяси белемнәр факультетында башлаган укытучылык эшен дәвам итәргә керешкән. Тиздән фикердәшләре белән бергә «Форм» журналына нигез салган һәм озак еллар шуңа җитәкчелек иткән.

1958—1960 елларда профессор А. Ялчын АКШның Колумбия университетында укыта. Төркиягә әйләнеп кайткач, ватанының сәяси тормышында актив катнашырга керешә—Хөррият һәм Яңа Төркия партияләрен оештыруга көч сала. 1965—1973 елларда ил парламентына Гаделлек партиясеннән депутат булып сайлана. Парламент комиссиясе рәисе һәм хөкүмәт вәкиллеге әгъзасы рәвешендә Европа илләренә,

АКШта һәм Советлар берлегенә визитлар ясый. 1973 елдан соң яңадан университетка әйләнеп кайта, укыта, фәнни эш белән шөгыльләнә, төрек һәм чит ил матбугатына язышa, байтак китаплар иҗат итә.

Профессор Айдын Ялчынның: «Ерак күршебез — Советлар иле», «Демократия, социализм вә яшьлек», «Экономик сәясәткә бәйле төшенчәләр», «Төрек коммунизмы хакында бәгъзе күзәтүләр», «Фашизмның тууы» китаплары төрек җәмәгатьчелеге зиһенен шактый баеткандыр, дип уйлыйм. Хөрмәтле галим замандашлары, иле өчен актуаль мәсьәләләрне күтәрә. Төркиянең уңга-сулга тайпылмыйча, тотрыклы урта юлдан баруы өчен көрәшә, җәмәгать фикерен төрле тетрәнүләрдән, ялгышлардан сакларга тырыша. Туган иленең тоталитар режимнар корбанына әверелүенә каршы чыгып, эзлекле төстә демократик принципларны, канунлылыкны яклый, матди эшчәнлектә базар экономикасы тамыр җибәрүе өчен көрәшә.

Югары уку йортларында озак еллар укытып бай тәҗрибә туплаган А. Ялчын студентларга ярдәмгә «Төркия экономикасы тарихы: госманлы дәверендә үсеш һәм артка тәгәрәү» китабын бастыра. Аның «Икътисадый доктриналәр вә системләр тарихы» университетның сәяси белемнәр факультетлары өчен уңышлы дәреслек булып таныла һәм инде өч мәртәбә нәшер ителә.

Исеменнән үк күренгәнчә, «Экономик доктриналар һәм системалар тарихы»нда кешелек дөньясы яралганнан алып бүгенгә кадәр матди җитештерү ысуллары, аның гасырдан-гасырга ничек үсүе-үзгәрүе бәян ителә. Борынгы грек галимнәре Әфләтун һәм Аристо (тель) карашлары, Рим заманы һәм урта йөзләр казанышы, төрек-ислам дөньясы манзарасы, аннан соңгы замандагы шәһәрләшү, сәүдә киңәю, Адам Смит, Мальтус һәм Рикардо фикерләре җентекләп анализлана. Китапта К. Маркс тормышы һәм эшчәнлеге, аның экономик теориясе дә киң яктыртыла, социализм һәм коммунизмның хыялдагы һәм гамәлдәге нигезләре, ленинизм, Рәсәйдәге революцияләр һәм аларның нәтиҗәләре тәнкыйть белән күздән кичерелә, марксизм-ленинизмның Төркиягә йогынтысы тасвирлана. Табигый ки, бу хезмәтне язганда автор төрле телләрдәге йөзләрчә чыганакка, фәнни басмаларга, кешелек дөньясының бөек акыл ияләре шушы тармакта барлыкка китергән асыл хәзинәгә таяна. «Феодаль», «капиталистик» Төркиядә марксистларның теоретик әсәрләре, СССРның коммунизм төзү «уңышларын» сурәтләгән китаплар да чыгарыла, алар белән танышу мөмкинлеге дә тормышка иркен ашырыла. Идеологик калыплар, тыюлар киртә салмаган илдә хөр акыл, аек фикер үзенә ышанычлы юл саба ала. Шуның нәтиҗәсендә Төркия хәзер һәр өлкәдә матур казанышларга ирешә килә. Бу үсеш-үзгәрештә Айдын Ялчын кебек җитди галимнәрнең — ватанын сәламәт нигездә үстерү өчен янып-көеп хезмәт итүче укымышлыларның шактый күп булуы шатландыра.

Артта калган Төркия хәлифәтенең егерменче йөздә алдынгы экономикалы, демократик рухлы җөмһүрияткә әверелә баруы хәзер байтак илләрнең фикер ияләре игътибарын җәлеп итә. Якын Көнчыгышның халык саны, икътисадый һәм мәдәни үсеше ягыннан беренче урында торган, соңгы дәвердә алга шактый зур сикереш ясаган мәмләкәте язмышы күпләрне кызыксындыра. Без шуның бер мисалын коллоквиумда да күрдек: АКШ галиме Жон Тедстром монда төрек телендә чыгыш ясады. Әйе, нәкъ менә төрек телендә!

Коллоквиумда кичке коктейль — үзара иркен танышу, аралашу мәҗлесләре дә булды. Мин шунда милләттәшебез профессор Сүбәдәй Туган белән аерым күрешергә ниятләгән идем. Әмма ул докладын сөйләгән көнне үк Анкарасына китеп барган икән. Арабыздан Разил генә аның белән танышырга һәм хәтта атасының — Зәки Вәлиди Туганның «Хатирәләрем» дигән кыйммәтле китабын сорап алырга да өлгергән иде.

Төркиягә килеп урнашкан кардәш төрки кавемнәр монда үз җәмгыятьләрен, вакыфларын оештырган, журналларын чыгарырга керешкән. Уйгырларның «Дугы Төркестан сәсе» («Көнчыгыш Төркестан авазы»). Үзбәкләрнең «Төркестан»ы — шундый басмалардан. Уйгыр журналының яртысы гарәп, яртысы латин хәрефе белән басыла. Кварталга бер басыла торган «Төркестан» дикъкатькә аеруча лаек. Ул яхшы кәгазьдә төсле итеп басыла. Эчтәлеге дә бай, мин анда коллоквиумга килгән М. Салихны гына түгел, бүтән үзбәк совет язучылары исемнәрен дә очраттым. Урта Азиянең үсеш мәсьәләләре, мәдәни һәм дини хәяте, милли гореф-гадәтләре, тарихы, архитектура һәйкәлләре, чит илләрдә яшәүче төркестанлылар тормышын гәүдәләндергән басманың баш мөхәррире Әхәт Әндиҗанлы гыйльми җыйналышыбызның актив катнашучысы, коллоквиумны алып баручыларның берсе булганлыктан, мин аның белән якыннан таныша алдым.

Университет доценты Әхәт әле дәрт-дәрманы ташып торган ир уртасы галим. Кызыксыну даирәсе киң, кардәшлек тойгылары кайнар. Ул танышкач ук миңа журналларында автор буларак катнашырга, «Казан утлары» белән «Төркестан» арасында бәйләнеш урнаштырырга тәкъдим итте. Вәгъдәле кеше икән, икенче көнне үк «Төркестан»ның дүрт санын алып килеп бүләк итте. Коллоквиум бәхәсләрендә ул аеруча актив катнашты. Туып-үскән, яшәгән һәм эшләгән иле Төркияне дә, озак еллар өйрәнгән, язмышы өчен сызланган ата-бабасы ватаны Советлар Берлеген дә яхшы белгәнлектән, аның һәр докладка карата фикер белдерергә ихтыяҗы туа, кайбер мәсьәләләрне ачыкларга теләге дә, белеме дә җитәрлек иде. Шуңа күрә берничә елдан аңа профессор дәрәҗәсе дә бирелде. Коллоквиумдагы чыгышымны мин нәкъ менә ул рәислек иткән өченче көндә ясадым.

## КҮП ТӨРЛЕЛЕК АША — БЕРДӘМЛЕККӘ

Кеше берәр хәвеф-хәтәргә юлыкса, гадәттә, аңа иң әүвәл ярдәм кулын туганнары суза. Бу — милләтләр арасында да шулай. Мисалга урысларны гына алыйк. Алар кан-кардәшләре болгарларга, сербларга һәм словакларга гасырлар дәвамында терәк булды, финнәр — эстоннарга, эстоннар — мариларга һәм удмуртларга булышып килә. Бу — бик табигый һәм әхлаклы бер эш. Әмма шушы матур гадәт соңгы дәвердә төрки халыклар арасында шактый ук җуелды. Моңа урыс шовинистларының «панисламизм», «пантөркизм» дигән карачкылары оеткы салды. Мәскәүнең аларга төрле дәрәҗәдәге дәүләтчелек бирүе, бер кардәш халыкның шактый өлешен күрше төрки республикага кертүе, һәр халыкта гомумтөрки хисләреннән элек тар кабиләчелек тойгыларын дөрләтүе дә таркату эшенә әйбәт хезмәт итте. Моны күреп тордык, белеп тордык, әмма җитди карыша алмадык. Карышканнарыбызны төрмәләргә һәм сөргеннәргә олактырып, ансат кына авызлыклый һәм юк итә тордылар. Менә ни өчен Татарстан бәйсезлеген игълан иткәч, төрки җөмһүриятләрдән бер генә җитәкче дә безне якларга ашыкмады. «Пантөркист» түгеллеген исбат итәргә һәм шулай «өлкән туганнан» янә бер рәхмәт казанырга теләптер инде, Казагыстан һәм Кыргызстан җитәкчеләре ашыга-ашыга: «Татарстанның бәйсезлек игълан итүе Союз килешүен төзүгә комачаулый»,— дип белдерделәр...

Туганнарның дус һәм тату яшәве нинди әхлакка сыймаска мөмкин? Ерткычлар әхлагына! Ике кардәш дуслыгын өнәмәгән кешенең «халыклар дуслыгы» дип авыз ачарга хакы бармы? Юк, әлбәттә. Әмма без бу хакта озак еллар сөйләшмәскә, хәтта уйламаска да тырыштык. Әнә шулай үзара мөнәсәбәтләребездә әхлаксызлык канат җәйде. Әхлаксыз тормыш кардәшләр арасында да бозык гамәлләргә, яман гадәтләргә, дөресрәге, гадәтсезлекләргә юл ачты.

Ялыкавык коллоквиумында ике күрше ил — Советлар һәм Төркия арасында сәяси, мәдәни, икътисадый бәйләнешларны ныгыту мәсьәләләре тикшерелде. Шул җирлектә төрки җөмһүриятләр, төрки халыклар элемтәсен киңәйтүгә, аларның үзара аңлашуын, ярдәмләшүен көчәйтүгә аеруча игътибар бирелде.

Мин нотыгымны сибелгән, чәчелгән татар өчен бигрәк тә актуаль булган бер мәсьәләгә багышларга тырыштым. Иптәшләремнең әйтүенчә, чыгышым коллоквиум өчен яңа бер сүз иде. Яңамы, искеме — эш анда гына түгел. Иң әһәмиятлесе — аның төрки халыклар арасындагы мөнәсәбәтләрне гадел, намуслы, әхлаклы һәм кешелекле нигезләрдә үстерүгә хезмәт итүе, күпчелекне шулай яшәргә һәм эш итәргә ышандыруы. Төрекләрнең фикерләремә артык сөенмәячәген аңласам да, мин нәкъ шул уйларымны уртага салдым. Түбәндә мин шул нотыгымны тулысынча китерәм.

* * *

**«Мөхтәрәм әфәнделәр!**

**Совет иле белән Төркия хезмәттәшлеге төрки халыклар үсешен иртәгә яңа баскычка күтәрүе ихтимал. Моңа уңай шартлар тудыру өчен без хәзер кичәге идеологик, сәяси концепцияләрне дә тәнкыйть күзлегеннән карап чыгарга, искергән, заман сынавын узалмаган эш-гамәлләрдән ваз кичәргә тиеш. Без моны никадәр тизрәк эшләсәк, шулкадәр яхшырак.**

**Югары мәдәнияткә, бай икътисадка ирешү өчен төрки милләтләрнең үз тарихи ватанында туган гореф-гадәт, йолалар, әхлакый канүннар кысасында гомер итүе шарт. Аерым шәхес, милләт туган телен, мәдәниятен, милли холык-фигылен җуймыйча яшәгәндә асыл сыйфатларын гармоник үстерә ала. Күнегелгән табигый тирәлектә генә тотрыклы рухи халәтне, яшәү дәртен һәм сәләтен саклау җиңел. Шундый шартларда шәхес тә, милләт тә төрле тетрәнүләрдән, тискәре комплекслардан азат була, гомер итүен билгеле бер тәртипкә салып, сәламәт тормышын көйләп җибәрә, башкалар тәҗрибәсен киң файдаланып, яңадан-яңа уңышларга ирешә.**

**Милли тормышны менә шулай итеп дәвам итү өчен һәр милләтнең сан ягыннан күплеге, сыйфат ягыннан югары баскычка күтәрелүе мөһим. Аның тарихи ватанында күпчелек тәшкил итүе сәламәт үсешкә өстәмә гарантия бирә. Кардәш милләтләрнең үзара оешуы һәм хезмәттәшлек итүе дә аларның аерым-аерым һәм тулаем көчәюенә зәмин тудыра. Моңа, мәсәлән, Төркиянең хәлифәттән җөмһүриятк҅ә әверелү тарихы ачык дәлил була ала. Хәлифәт халкының шактый өлешен славян, албан, грек, әрмән, гарәп, көрд һәм бүтән ят кавемнәр тәшкил итү заманында моның Төркияне нык кына зәгыйфьләндерүен беләбез. Чөнки төрекләр үзләренең шактый көчкуәтләрен шуларны буйсындырып тотуга багышлый, бу исә аны хәлсезләндерә һәм, хәтта, таркатып бетерә. 1927 елга кадәр асыл төрекләрнең һәм кардәш төркиләрнең (соңгылары күчеп килүчеләрнең биштән бере чамасында) кыска вакыт эчендә күпләп Төркиягә күчеп килүе һәм 13 миллион кешенең 6285 меңен тәшкил итүе хәлне кискен үзгәртә, илдә татулык, сәяси тотрыклылык тамыр җибәрә. Кардәш төрки милләтләрнең Казагыстан һәм Кыргызстанга килеп урнашуы да үз җөмһүриятендә азчылыкка калган төп милләт хәлен шактый ныгыта, уңайландыра.**

**Төрки халыкларның үзара аралашып яшәвенең файдасын Төркия белән Идел-Уралдагы егерменче йөз башы хәлләре дә раслый. Төрек вакытлы матбугаты, китаплары, югары мәдрәсәләре ата-бабаларыбыз үсешенә яңа мөмкинлекләр ача. Үз нәүбәтендә, татар халкы казанышлары, Й. Акчура, С. Максуди, З. Вәлиди, Г. Исхакый, Р. Арат, Ә. Курат, Х. Кошай кебек эшлеклеләребезнең Төркия үсешенә җитди этәргеч бирүе яхшы мәгълүм. Шушы бәйләнешләрнең 1917 елдан соң өзелүе исә безнең гореф-гадәт, дин, милли мәгариф, мәдәниятебез какшауга китерүе инде сер**

түгел. Без менә шуңа күрә: «Яшәсен төрки кавемнәр бердәмлеге!» дип аваз салабыз. Бу бердәмлекне туплауда Төркиягә аеруча зур өметләр баглыйбыз. Төркиләр хезмәттәшлеген юлга салуда төрек теле, мәдәнияте хәлиткеч роль уйнавын таныйбыз, аларның киңрәк таралуына куәт өстибез. Советлар Берлегендәге төрки җөмһүриятләрдә төп милләтләр теле һәм мәдәниятләре үсешенә дә теләктәшлек күрсәтәбез. Бу сәясәт дөрес, моңа беребез дә шикләнмидер.

Әмма бу юл — дөрес сәясәтнең яртысы гына. Аның икенче өлеше — Төркиядә һәм Советлар Берлегендәге төрки җөмһүриятләрдә кардәш азчылык кавемнәрне үз хосусиятләре белән саклау. Без хәзергә кадәр аларны төп милләт тарафыннан йоту, ассимиляцияләү гомум төрки мәнфәгатьләргә файдалы, дип исәпләдек һәм шуңа хезмәт иттек. Хәтта күбрәк санлы төрки милләтнең азрак санлы кардәш кавемен аның асыл ватанында да төрекләштерү, үзбәкләштерү, татарлаштыру файда гына китерәчәк, дип уйлый башладык, гамәлдә шуңа шартлар тудырырга керештек. Мисалга, Үзбәгестанның Хәрәзем өлкәсендә унөч мең (1970) урыс яши, аларга махсус милли мәгариф, мәдәният учаклары, матбугат, радиотелевидение хезмәт күрсәтә. Үзбәгестанда яшәүче йөз меңнәрчә, ягъни Хәрәзем өлкәсе урысларыннан дистәләрчә тапкыр артыграк Казан татарына аларның берсе дә тәтеми. Үзбәкләр татарны үз санын арттыруда, милли мәгарифен, мәдәниятен, экономикасын үстерүдә «донор» итеп кенә файдалана. Үз йөзен сакларга, милләт буларак яшәргә шартлар тудырылмаганлыктан, казан татарлары ассимиляцияләнә, ләкин зур күпчелеге үзбәкләшми, ә бәлки урыслаша. Үзбәк милләтенең татар кардәшләренә әнә шундый салкын мөнәсәбәте аркасында гомум төрки мәнфәгатьләргә дә зыян килә.

Казан татарына урыс, үзбәк яки төрек шундый мөнәсәбәт күрсәткәндә, нәтиҗәсен ачык белеп торуыбыз хәерле: татар, милләтсезләштерүче урыска һич тә мәхәббәт белән карамый, бүтәннәргә дә рәхмәт әйтми һәм әйтмәячәк. Моннан һәммәбез дөрес сабак алырга тиеш.

Үз тарихи ватаныннан читтә яшәүче төркиләр саны төрки дәүләтләрдә дистә миллионнан аша, аларга карата сәясәттә кискен борылыш ясалырга тиеш. Чөнки аларны донор итеп кенә файдалану азчылыкны тәмам хәлсез калдыра, зәгыйфьләндерә. Бары сәламәт төрки кавемнәр берләшкәндә генә аларның уртак көче иң зур үлчәмгә җитә. Үн чирле бер сәламәт кешене алыштыра алмый.

Кардәш төрки азчылыкны йоту омтылышы әлеге азчылыкны деградациягә китерүен татар-төрек мисалында да күрә алабыз. 250 меңле исланд халкы ел саен 700 исемдә китап, 150 исемдә журнал чыгара. Үз телендә! Аның әдәбияты вәкиле халыкара Нобель премиясенә лаек булды. Мәдәниятнең бүтән тармакларында да аның казанышы мул. Төркиядә чыгышы белән казан татары булып исәпләнгән халык саны сигез йөз мең чамасы. Ләкин аларның исландларга тиңләшерлек казанышлары бармы соң? Аларның зәгыйфь кенә, кечкенә генә бердәнбер журналы да төрек җәмәгатьчелегенең битарафлыгы аркасында инде күптән (1980) ябылган. Төркиядәге татарларның милли-мәдәни кыйммәтләр тудыруы тәмам юкка чыгарылган, димәк, ул дөнья мәдәниятенә өлеш кертүдә дә сүлпәнәйгән. Дөрес, төрекләшкән татарлардан бераз галимнәр бар, тик аларны бармак белән генә санарлык.

Үзбәгестанда мәсхәт төрекләре, Казагыстанда азәрбайҗаннар, Төрекмәнстанда казакълар хәле дә шундыйрак. Милләт буларак саклар өчен Татарстанда азәрбайҗан милли мәктәбе ачылмавы да шушы ук сәясәткә нигезләнә.

Төркиядә кардәш төрки халыклар хосусиятен саклауга әһәмият бирелмәгән гасыр башы өчен күпмедер дәрәҗәдә аңларга мөмкин. Ят кавемнәрнең мәмләкәтне таркатырга һәм юк итәргә тырышуына каршы көрәшкә бөтен куәтне тупларга кирәк иде. Ләкин хәзер хәл башка. Төркия, шөкер, инде аякка басты. Ул хәзер милли хезмәттәшлекне мәдәни юл

**белән көйләргә сәләтле. Хәзер тыныч рәвештә төрки кавемнәрнең үз шивә теле, мәдәнияте, милли аңы саклану һәм үсү төрки халыкларның гомум мәнфәгатенә зуррак файда китерүен, күптөрлелекнең саклануы төркиләрнең гаять зур үсеш чыганагы, көч-куәт, сыйфат ягыннан баю, камилләшү җирлеге икәнлеген аңларга һәм танырга кирәк. Алманиядә шивә телләрен, гореф-гадәтләрен, мәдәни үзенчәлекләрен саклауга җитди игътибар бирелә, аңа карап без Германияне Төркия яки Үзбәгестаннан зәгыйфьрәк, нимес милләте төректән, үзбәктән таркаурак, дип әйтә алмыйбыз. Төрки шивәләр, төрки халыкларның фольклоры, халык сәнгате — һәммәбезнең уртак байлыгы. Аларны закон чыгарып сакларга, тагы да үстерү өчен көчне һәм сәләтне кызганмаска кирәк.**

**Төрки кавемнәрнең бер-берсен йотуы — һәлакәтле күренеш. Безгә бербеебезнең хосусиятләрен хөрмәт итәргә, көчле төрки халыклар ярдәмлегенә күптөрлелек аркылы гына барырга кирәк. Кушылуны уңай, аерымлануны тискәре бәяләүчеләр — кешелек дөньясы үсешен тупикка кертүчеләр алар. Һәр шивә вәкиле үз табигый микроклиматы, хосусиятләре нигезендә яшәгәндә генә рухи комфорт тоя, шул очракта гына аның сәләте иркен, нормаль үсә. Күп төрлелек фикере безгә үзара рәхәт, ансат аралашыр өчен төрек телен өйрәнергә комачауламый. Уртак ата-бабаларыбыз рухы, ят халыклар чолганышында уртак мәнфәгатьләребезне саклар өчен берләшү ихтыяҗы — төреклекнең көчәюе өчен иң ышанычлы нигез һәм юнәлтүче чара. Без киләчәктә дә төрле булачакбыз, ләкин бер-беребез өчен җаныбызны да, каныбызны да бирергә әзер торачакбыз. Бары үз кавемең белән мавыгудан айну гомумтөрки мәнфәгатьләр өчен көрәштә соңгы киртәләрне алып ташлар, эчкерсез кардәшлеккә, дуслыкка, хезмәттәшлеккә киң юллар ачар».**

* * *

Төрекләрнең байтагы минем бу нотыгымны хупламаячагын, аңларга теләмәячәген дөрес сизгәнмен икән. Ул «Йени форум» (№ 271, 1991 ел) журналында, аннары «Төркия моделе вә төрек кокәнле җөмһүриятләр белән иске совет халыклары» (Анкара, 1992) җыентыгында басылып чыккач, доцент Һакан Кырымлының хәбәр итүенчә, Төркия җәмәгатьчелегендә шактый бәхәс уяткан. Азчылык милләтләр вәкилләре фикерләремне тулаем яклаганнар, кайбер төрек милләтпәрвәрләр исә аларны, безнең көчәюебезгә каршы килә, дип бәяләгән. Әхмәт Сәлим дигән берәү «Гаҗәеп манзарлар» мәкаләсендә («Заман» гәз., 10.Х.1992. Истанбул) нотыгымның төрек телендә басылып чыгуын төрекләрнең ваемсызлык күрсәтүе дип шәрехли. Нотыкның төрле урыннарыннан йолкып алынган өземтәләрне китерә дә: «Боерыгыз, күрик! Төркиядә төрекләр бүтән җирдән күчеп килгән төркиләрне йота, ассимиляцияли, имеш! Этник мәсьәләләрне ничек бизмәнләвенә багыгыз! Мөселман булу да, төрек булу да үз милләте булуга җитми икән!.. Дөньяга һәм тарихка болай каралса, бүгеннең һәм иртәгенең кайсы мәсьәләсе ничек хәл ителер? Безнең белән Америка да, инглиз дә, алман да уйнар»...— ди.

Ә. Сәлим әфәнде «төшенчәләрен» аңлау һич тә кыен түгел: безне дистә еллар буе өзми-куймый «интернационалист» булырга, язмышыбызны «өлкән туганга» ышанып тапшырырга өндәп килделәр, карышсак, акыл өйрәтергә дә күп сорап тормадылар. «Өлкән туганыбыз» да бары шул очракта гына «совет халкының» АКШка, Англиягә, ГФРга бирешмәячәген тәкърарлап килде! Кыскасы, татардан донор булуны, канын биреп, башкаларны яшәтүне генә таләп иттеләр.

«Өлкән туган»ның берсе куеныннан чыгарга өлгермәдек, безне икенчесе кочагын җәеп көтеп тора, имеш. Тукай шикелле, ирексездән: «Бу кызу җирдән чыгып, тагын сәкарьгә (тәмугка) ник керик?» — диярсең, билләһи!

Әмма Төркия җәмәгатьчелеге, шөкер, Ә. Сәлим кебекләрдән генә тормый бүген. Симпозиумда Татарстаннан килеп сөйләгән биш вәкил арасыннан абруйлы журналда беренче нәүбәттә минем чыгышны — четерекле докладны басып чыгарулары, аны җыентыкта да нәшер итүләре, азчылык мәнфәгатен яклаучыга соңыннан премьер-министр архивыннан кыйммәтле бүләк — ике томлы библиографик җыентык җибәрүләре дә дәлил моңа. Шул ук «Заман» гәзите, 1992 елда Истанбулга икенче мәртәбә килгәч, укучыларына мине ике мәртәбә танытты — сурәтем белән интервьюләремне басып чыгарды, башка төрек матбугаты да уй-фикерләремне уртаклашырга, хәтта үзләрен тәнкыйть итәргә дә мөмкинлек тудырды.

Төрек җәмәгатьчелеге күп катламлы бүген. Бу фикер йөртүдә дә, гамәлдә дә ачык сизелә. Барлык төрки кавемнәрнең «төрек» яки «мөселман» булуын гына куәтләүчеләре дә, бүгенге катлаулы чынбарлыкны танучылары да, тирәнрәк фикер йөртеп, үзара хөрмәт, дустанәлек нигезендә тигез хокуклы булып якынаю кирәклеген төшенүчеләре дә бар. Шунысы да анык: хәлиткеч гамәлне соңгылары кылса гына, төрки дөнья чын мәгънәсендә ныгый һәм чәчәк ата алачак. Моңа бүген өметләребез биниһая зур. Тик бу эш безнең һәркайсыбыздан зирәклек, тырышлык, җаваплылык таләп итә. Чөнки дөньяда безнең араны болгатырга омтылучылар, үзара якынаюыбызга һәм яңаруыбызга аяк чалырга маташучылар да җитәрлек. Алар кара ниятләрендә мәкерле, тәҗрибәле һәм куәтле. Шунлыктан, кабиләчелек кыйммәтләрен кайгырту уртак төрки мәнфәгатьләрне күмеп китмәсен өчен, төреккә дә, татарга да, бүтән төрки кавемнәргә дә гадәттән тыш уяу, алдан күрүчән булырга кирәк.

##ҺАКАН КЫРЫМЛЫ ҺӘМ «ӘМӘЛ»

Төркиядә чыгышы буенча биш-алты миллион кырым татары яшәвен мин электән үк ишетеп белә идем. Әмма танышларым аларның нигездә Искешәһәрдә һәм аның тирәсендә туплануын, күпмеседер Истанбулда урнашуын сөйләгәнлектән, коллоквиум узган Ялыкавак авылында адаш кардәшләрне очратырга исәп итмәдем. Чынлыкта исә монда иң күп аралашкан һәм эчкерсез дуслашкан кешем Анкараның Бәлкәнт университеты галиме доцент Һакан Кырымлы булды.

Һаканны без, Татарстан вәкилләре, барыбыз да яраттык. Ул үзе дә, Советлар Берлегенең бүтән төрки җөмһүриятләреннән килгән бөтен галимнәр белән ягымлы аралашуына карамастан, безгә күбрәк тартылды, гыйльми утырышларда гына түгел, ял вакытларында да яныбыздан китмәде — бергә кызындык, Эгей диңгезенең зәңгәр дулкыннарын бергә колачладык, «Сәрәмәй» отеле ханәләрендә һәм ачык террасасында чәйләп-мәйләп гәпләр корып утырдык. Төркия тормышына, мәдәниятенә баглы дистәләгән сорауларыбызга әтрафлы җаваплар бирде ул, чыгышларыбызны төрекчәләштерергә дә булышты. Холкы тыныч, мөгамәләсе хуш, Төркияне генә түгел, Румыйния, Алмания, АКШны да, андагы азчылык төрки кавемнәр хәятен һәм гыйльми даирәләрне дә тегеннәнмоннан ишетеп яки укып кына түгел, үзе күреп, танышып белгән, шуңа өстәп, Совет иле чынбарлыгыннан да хәбәрдар булган бер зат иде ул. Түгәрәк якты йөзле, калын кара кашлы, урта буйлы, тыгыз гәүдәле, җыйнак күзлек, кычкырып тормый торган пөхтә кием кигән. Әби-бабалары Добруҗадан булса да, үзен кырым татары санаучы һәм аларның Төркиядәге «Әмәл» («Гамәл») журналын чыгаручы ир-егет. «Казан утлары» редакциясендә хезмәт итүемне һәм кырым татар каләмдәшләрем әсәрләрен Казан шивәсенә тәрҗемәләвемне белгәч, ул миңа аеруча якынайды, мөһаҗирәттәге милләттәшләренең милли-мәдәни хәрәкәте хакында мәгълүмат бирде.

Һакан — Төркиядә тамыр җибәргән нәселенең өченче буыны, аның ата-анасы инде шушында туып үскән, ул үзе 1958 елда Балыкесирдә дөньяга килгән. Инглиз телендә укыта торган мәктәптә белем алган, аннары Анкараның Хаҗитәпә университетында икътисад факультетын тәмамлаган. Алманиянең Мюнхен шәһәрендә Украин ирекле университетында докторантура узарга керешкән, бераздан АКШка китеп, шунда җиде ел буе белемен күтәргән, кырым татар халкы тарихына багышлаган диссертациясен яклаган. Унлап гыйльми мәкалә, 1986 елда инглиз, төрек, кырым татар телләрендә «Кырым библиографиясе» китабын нәшер иткән. Алман, инглиз, урыс телләреннән төрекчәгә һәм кырым татарчага байтак әсәрләр тәрҗемә кылган. Тикшеренүләрендә ул Рәсәй, СССР төрки халыкларын игътибар үзәгендә алган.

— Мин фән юлына милләттәшегез Әкъдәс Нигъмәт Курат ярдәмендә килеп кердем, аның тәрбиясендә үстем,— диде Һакан.— Казан татарлары Төркиядә тарих гыйлемен алга җибәрүдә гомумән бик зур өлеш кертте, алар булмаса, ул һич тә бүгенге югарылыкка күтәрелә алмас иде. Чынлыкта нәкъ менә алар — Й. Акчура, С. Максудый, З. Вәлиди, Ә. Курат, Р. Арат, Х. Кошай, Г. Баттал, Ә. Тимерләр Төркиядә гуманитар фәннәр үсешен һәвәскәрлектән профессиональ нигезгә куйды. Төрекләр моны белештереп җиткерми яки белергә теләми бугай. Югарыда саналган зур галимнәр үзләренә әйбәт алмаш та әзерләде — мин үзем хәзер З. Вәлиди улы, икътисад фәннәре докторы Сүбәдәй әфәнде кулы астында эшлим. Аның бертуганы Исәнбикә ханым — этнограф, шулай ук фән докторы. Ә. Курат улы Йолагтәкин — тарих профессоры, берара университет ректоры да булды. Г. Исхакый кызы Сәгадәт ханымның профессор, С. Максудый кызы Гадилә ханымның доцент, дипломат булуларын сез инде беләсез.

Төркия һәм төрки халыклар тарихын тикшерүгә кырым татарларыннан фән докторлары Хәлил Иналчык, Илбәр Уртайлы һәм бүтәннәр дә өлеш кертә икән. Фәннең бүтән тармакларында көч түгүчеләрдән, зур эшкуарлардан, Төркия хөкүмәте министрларыннан да кырымлыларны атап китәргә мөмкин. Тик безнең әңгәмә озакламый яңадан матбугат өлкәсенә әйләнеп кайтты.

— Ватаныннан колак каккан халыкның язмышы аяныч,— диде Һакан.— Ул ят мөхиттә үзен милләт буларак югалта. Төркиядә саннары күп исәпләнсә дә, кырымлылар чыгарган бердәнбер милли басма — «Әмәл» генә. Аның да теле хәзер ярым төрекчә. Җәмәгать башлангычында нәшер итәбез. Әзерли торган профессиональ редакциябез, түләүле хезмәткәрләребез дә, гонорарыбыз да юк, һәммәбез, төп эшеннән бушагач кына, кулыннан килгәнчә катнаша.

«Әмәл» журналы 1930 елның гыйнварында Румыйниянең Базарчык (соңрак Болгариягә бирелгәч — Добрич, Толбухин!) шәһәрендә Мөстәҗип Өлкесал тарафыннан нигезләнә, әүвәл аена ике, аннары бер мәртәбә чыгарыла. Ул Добруҗа татарларының халык авыз иҗатын җыюга, әдәбиятын үстерүгә, милли аңын уятып, телен, гореф-гадәтләрен саклауга җитди өлеш кертә, байтак каләм ияләре тәрбияли. 1936 елдан алып ул Күстәнҗә шәһәрендә нәшер ителә. 1939 елгача — гарәп, аннары латин әлифбасында басыла. Аны чыгаруда Гражданнар сугышы дәверендә Кырымнан качып китәргә мәҗбүр ителгән укымышлылар да, Румыйниядә яшәүче төрекләр дә катнаша. Нимесләр СССРга каршы ачкан сугышка Румыйния дә тартылгач, «Әмәл» яшәүдән туктый. Аның юлбашчылары Төркиягә китеп югалырга тырыша, Добруҗа ир-атлары исә нимесләрне якларга тиеш татар батальоннарына хезмәткә чакырыла.

Сугыш Алмания һәм аның иярченнәре өчен күңелсез тәмамлана: Совет гаскәрләре Румыйниягә килеп керә. НКВД СССРдагы милли тигезсезлекне фаш иткәләп торган «милләтчеләр» журналы «Әмәл»не кара исемлеккә теркәгән була, аның вакытында эзен җуярга өлгермәгән

хезмәткәрләрен һәм даими авторларын тиз генә ятьмәсенә сөзеп ала да көнләшерлек җитезлек белән юкка чыгара!

Кырым татарларының мөһаҗирәттәге милли-мәдәни хәрәкәте алар күбрәк тупланган Төркиядә түгел, Добруҗада башлана, 1917 елда Бакчасарайда тегелгән күк төстәге милли байрак «Әмәл» журналының символы рәвешендә аның тышлыгын даими бизәп тора. Румыйниядәге оялары туздырылганнан соң Төркиягә кача алган Добруҗа татарлары монда кыска арада тормыш-көнкүрешләрен көйләүгә бөтен көчен бирә, әмма моңа ирешү шактый озакка сузыла. «Төрекчелек» йогынтысына бирелгән әүвәлге буын мөһаҗирләр исә милли идеаллардан инде ваз кичеп өлгергән була. Менә шуның аркасында «Әмәл» журналын яңадан тергезү бары 1960 елда гына эшкә аша. Ул әүвәл Анкарада, 1961—1982 елларда — Истанбулда, шуннан соң янә Төркия башкаласында басыла башлый. Хәзер «Әмәл» ике айга бер мәртәбә кырык сигез бит (аерым саннары — артыграк) күләмендә дөнья күрә. Мөхәррирләрнең берсе Һакан Кырымлы булса, икенчесе — Зәфәр Каратай. Журналны әзерләү, бастыру һәм тарату эшендә утыз-кырык әдәбият сөюче катнаша, башлап йөрүчеләре бүген дә — Добруҗадан чыккан нәселләр.

— Журналыбызның тиражы биш меңгә якын,— диде Һакан.— Шуның биштән бер өлеше кырык ике чит илдә яшәүче милләттәшләребезгә китә. Элекке елларда СССРга йөзәр данә җибәрә идек — Дәүләт иминлеге комитеты аларны кая олактырып баргандыр, белмибез. Без «Әмәл»дә халкыбызның ватаныннан сөрелүе, коточкыч геноцидка дучар ителүе, газаплар кичерүе турында гел язып тордык ич — НКВД башкисәрләренең аңа җеннәре чыгуы табигый! Хәзер кырым татар милли хәрәкәте белән багландык, диаспора ватандагы хәлләр белән кызыксына, анда милли дәүләтчелегебез тергезелүен өмет итә, шуңа теләктәшлек белдерә.

«Әмәл» әдәби әсәрләр генә түгел, бүген дә милли сәясәткә баглы бик күп мәкаләләр, документларны баса. «Казан» журналы ябылгач, ул Идел-Урал татарлары хәлен, мәдәни үсешен дә яктыртып барырга тырыша. Шуңа күрә аны чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең дә алдырып укып баруын мин Алманиядә үз күзләрем белән күрдем. Аларның кайберләре бу эшне «Әмәл»не чыгаруга ярдәм булсын дип тә эшли иде.

— Казан татарлары — безнең иң якын кардәшләребез,— диде Һакан.— Кырымда милли дәүләтчелегебезне тергезергә иң зур ярдәм күрсәтүчеләр дә — сез. Безгә карата эшләнгән гаделсезлекләрне матбугатыгызда фаш итеп торасыз, Кырымга кием-салым да җыеп җибәрәсез, яшьләрегез анда йортлар корырга да килде. Әдәбиятыбызны тәрҗемә итүгә, җыр-бию ансамблебезне җылы кабул итүегезгә рәхмәт — «Әмәл» укучыларына без бу хакта даими хәбәр биреп торабыз.

— Төркиядә бай кырым татарлары бардыр. Алар Кырымга матди ярдәм күрсәтергә әзерме соң? — дип сорадым мин Һаканнан.

— Милли дәүләтчелегебез тергезелсә, анда капитал салырга, хәтта күчеп кайтырга теләүчеләр дә табылыр,— диде ул.— Чөнки кырым татар милләтен бары шунда гына саклап була. Ата-баба җирен күрәсе, шунда яшисе дә килә. Кан тарта!

— Кырымда татар дәүләтчелеге тергезелсә, Төркиядән күпме кеше ватанына кайтып төпләнер иде икән?

— Әйтүе кыен. Мөгаен, бик күп җыелмас, бәлки кырым татарларының йөздән берсе генә җөрьәт итәр,— диде Һакан.— Монда бер тамыр җибәргәч, йорт-җир коргач, көнкүрешне көйләгәч, шуның һәммәсен ташлап китү кыен. Аннары Кырым бүген буш җир дә түгел ич әле! Без анда яшәүче бер милләткә дә, әгәр үзләре безгә тимәсә, дошманлык сакламыйбыз, тыныч хезмәттәшлек итәргә әзер. Әхлаксыз бер уч шовинист өчен бөтен халыкка үпкәләү егетлек булмас. Ләкин бер нәрсәне бик нык искәртәсебез килә: һәр халык үз тарихи ватанында яшәргә тиеш, аларны аннан көчләп аерырга берәүнең дә хакы юк!

Төркиядә аерым кырым татар авыллары да бар, Искешәһәрдә һәм шуның тирәсендә Кырым теле бүген дә яңгырый. Ләкин төрек чолганышында яшәү, төрек мәктәпләрендә уку үзенекен итә — милли үзенчәлекләр җуела бара. СССРда кырым татарларының чагыштырмача әз өлеше — ярты миллионы гына яши, алар да бүтән халыклар арасына азчылык булып сибелгән. Шулай да Ташкентта Шамил Әләдин, Риза Фазыл, Черкез Али, Хәйдәр Госманнар чыгарган әдәби-нәфис «Йылдыз» журналы «Әмәл»дән күпкә кызыклырак, сәнгатьчә хасияте югарырак. Кырым татарларының Совет илендә җәһәннәм михнәтләре чигүен яхшы белгән Һакан бу хакта ни уйлый?

— Советлар берлегендәге кырым татарлары ватаныннан аерылганга илле ел чамасы булса, Төркиядәгеләрнекен болай төгәл әйтеп булмый,— диде ул.— 1783 елдан бирле дулкын-дулкын күчеп киткән алар, димәк, кайсылары инде ун буын дәвамында башка халык арасында яши. «Йылдыз»ны бүген дә Кырымда ук язучы булып җитешкән яки алар тәрбияләгән каләм ияләре чыгара. Һич югы балачагы тарихи ватанында, татар мөхитендә узган кешеләргә телне, мәдәниятне саклау, шуңа таянып үсү җиңелрәк. Бу мин элегрәк әйткән хакыйкатьне тагын бер мәртәбә раслый: мөһаҗирлек — теләсә кайсы милләт өчен үлем. Шуңа күрә «Әмәл» үз укучыларында Кырымга мәхәббәт тәрбияләргә тырыша. Ватаннан килгән хәбәрләрне беренче нәүбәттә баса.

Төркиядәге кырым татарлары «Әмәл вакыфы»н оештырган, ул мәмләкәтнең төрле шәһәрләрендә һәм авылларында яшәүче милләттәшләрен җирле бүлекләренә тартып, аларга милли-мәдәни тәрбия бирергә тырыша. Бу эшне ул журнал аша да үткәрә, баеманың чыгымнарын да каплый. Мохтаҗларга булышу, сәләтле яшьләрне укытырга ярдәм итү, Кырымнан килүчеләрне каршылау һәм Төркия белән таныштыру — вакыфның мәшәкатьләре бик күп.

«Әмәл» журналының 200 ләп саны чыккан. Аның сәхифәләрендә казан татарлары, аларның күренекле әдәбият-сәнгать эшлеклеләре, галимнәре хакында да мәкаләләр урын алган. Төньяк Кавказны, Урта Азияне һәм Әзәрбайҗанны да ят итми ул.

— Безгә Татарстанның «Казан утлары» яки бүтән журналлары белән таныш булу кирәк, тыңлашу кыен,— диде Һакан.— Алар белән дуслашырга, хезмәттәшлек итәргә исә һәрвакыт әзербез. Чит илләрдәге кырым татарларының да күренекле галимнәре, язучылары бар, еш кына алар «төрек» булып танылa. Үз милләтенә тугры калганнары да юк түгел — тарих фәннәре докторлары, АКШта яшәүче Добружалы Гайшә Рүрлих, Кәмал Карпат, унлап романның авторы, хәзер Лондонда гомер итүче Чыңгыз Дагҗыларны укучыларыгызга таныту әйбәт булыр иде.

Коллоквиумда катнашкан төрек галимнәре арасында Бәлкәнт университеты укытучылары шактый иде. Моның серен ачуны үтенгәч, Һакан:

— Төркиянең иң яхшы, иң куәтле уку йорты булгангадыр бу,— диде.— Инглиз телендә генә укытканлыктан, аның күпчелек мөгаллимнәре Көнбатыш илләрендә белемен күтәргән, андагы казанышлар белән яхшы таныш. Күпчелек студентлар, анда укый башлаганчы, ике еллык әзерлек курсы уза. Университетның техник җиһазлары Көнбатышныкы дәрәҗәсендә, тулай торaклары уңайлы, туклану сыйфатлы. Шуңа күрә түләү дә югары — һәр студент семестр саен дүрт мең доллар кертергә тиеш. Сәләтле, әмма мохтаҗ шәкертләргә төрле вакыфлар стипендия билгели. Кыйммәт дип тормыйлар, ун мең студент укый бездә!

Һакан Төркиядә туып-үссә дә, күп кенә галимнәребезне, аларның хезмәтләрен белә, исемнәрен атый-атый, Г. Гобәйдуллин, И. Рәми, М. Худяков китапларын, Идел-Уралдагы җәдитчелеккә, хатын-кыз хәрәкәтенә, милли хөррият көрәшенә, матбугатыбыз тарихына багышланган әсәрләр турында сораша, мине китап алмашырга өнди.

— Сез аларны ничек укып бетерерсез соң? — дидем мин елмаеп.

— Хатыным Мәрьям дә тарихчы, университет укытучысы,— диде Һакан.— Икәүләшеп тә өлгермәсәк, улыбыз Кырымгәрәй үсеп килә, безгә җибәргән алтын хәзинәгез әрәм булмас!

Без, «Измир—Истанбул—Мәскәү» рейсе белән очачак Совет вәкилләре, коллоквиум тәмамлангач та, тагын ике көн Ялыкавакта яшәдек. Ресторанның диңгез ярына чыгып торган ачык әйванында безне элеккечә үк әйбәт сыйладылар, тау башындагы экзотик «Монакус клубы»,— соңгы төннә без шунда кундык,— затлы һәм уңайлы, текә аллеяларының һәр тарафындагы гөлчәчәкләр, кызыл миләш төсле җиләк сарган купшы куаклар, исемнәрен без белеп бетермәгән гөлләр һәм агачлар элеккечә үк хуш ис тарата һәм күзләрне иркәли, Эгей диңгезенең зәңгәр дулкыннары да, «Монакус» идарәсенең түбәсендәге махсус җылырак су тутырылган ачык бассейны да безне үз кочагына алырга әзер иде. Әмма безгә тулы комфорт өчен барыбер нидер җитмәде. Аннары аңладык: җитди сорауларыбызга да, «Бу нәрсә?» «Теге ник алай?» шикелле балаларча аптыратуларыбызга да тыныч кына җавап бирүче, иплән аңлатучы Һаканнан, кечелекле ягымлы терәгебездән аерылганбыз икән. Ул икенче төркем галимнәребезне Төркия-Совет чиге буена илтеп куячак автобуска утырып, Анкарасына китеп барган иде.

## ЯЛЫКАВАК — БОДРУМ

«Төрек һава юллары» самолетының Мәскәүгә атнасына бер генә мәртәбә очуы коллоквиумда катнашучы Совет галимнәренең яртысы өчен үзе бер куаныч булды. Батуми турысындагы Совет-Төркия чигенә Кавказ һәм Урта Азия вәкилләре автобуста китеп баргач, без, «Сәрәмәй» отелендәгеләр, коллоквиумның төп йорты булган «Монакус клубы» биләмәләренә күчендек. Махсус өстәмә программа буенча, без монда бер тәүлек ял итәргә, иртәгесен төштән соң гына автобус белән Измиргә китәргә, анда шәһәрне тамаша кылырга, «Марла» отелендә кич кунарга һәм егерме икенче сентябрь таңында гына Истанбулга, аннан Мәскәүгә очарга тиеш идек.

Рәсми ыгы-зыгылар басылгач, без, билгеле, әүвәл иркенләп кызынырга һәм су коенырга булдык. Көне эссе түгел, бераз җиле дә бар, әмма суы җып-җылы. Тозлы, шуңа күрә, суларлык дәрәҗәдә генә борыныңны калкытып чалкан ятсаң, бернинди хәрәкәт ясамасаң да, батмыйсың: диңгез үзе күтәрә. Тәнгә мондый ванна да бик кирәк, имеш, суда эрегән төрле-төрле мәгъдән-минералларның шифасы тиячәк. 1990 елның август аенда Латвиягә, язучыларның Юрмаладагы иҗат йортына баргач, ай буена өч тапкыр коендым микән? Балтыйк буеның иң җылы аенда да су унсигез градуслар чамасында гына, җитмәсә, пычранган, кермәвең хәерләрәк», дип кисәттеләр. Ә монда — көненә өч мәртәбә диңгез ваннасы: йөз, чум, хыялланып изрәп ят. Тирә-ягыңда — зөбәрҗәт Ялыкавак култыгы, фирүзә күк, кул сузымында — мәҗнүн таллар, горур сәлвиләр, хуш исле гөлчәчәкләр, акчарлактай ак виллалар, «Монакус клубы» биләмәләренең бөркет оялары. Төрек халкы шушында куәтле мәмләкәт төзеп, күршеләренә юмарт кунакчыллык күрсәтер дәрәҗәгә ирешмәсә, табигатьнең мондый хозур почамагында без кайчан болай иркәләнеп ял итә алыр идек икән? Чөнки чит ил туристлары шикеле үз кесәбездән көненә фәлән доллар — Совет акчасына күчергәндә, астрономик сумма түләп торуны башка сыйдыру да мөмкин түгел иде.

Артык киң булмаган Ялыкавак култыгы, елга тамагы шикелле тараеп, материкка ике-өч чакырым гына кереп тора. Ялыкавак авылы шуның дугасы сыртына — көнчыгыш һәм көньяк ярына, тау итәгенә урнашкан. Ул, итәкне тарсынып, тау башына да үрмәләгән. Без авылны төнлә узып китсәк тә, әле махсус барып карарга өлгермәгән идек. Диңгез ваннасыннан соң казанлылар җәяүләп шунда киттек.

Яңгырлар монда җәен гомумән яумаганлыктан, тау башлары гына түгел, итәге дә шәрә дип әйтерлек. Сугарылган бакчаларда гына чәчәкләр, яшеллек күренә. Коры, җылы һавалы көньякта йорт диварларының юка булуы табигый. Чүлмәк түбәләре җәлпәк, кайсысының түшәме-түбәсе бер — бетоннан. Төркиядә җир муллыгы,— Европада мәйданы буенча, Советлар берлегеннән кала, беренче урында,— Ялыкавакта да сизелә: хәтта, матур диңгез буйларында да файдаланырлык җирләр буш ята әле. Бәлки, бу төче су, дым җитмәүгә бәйледер, бәлки, Анадулы киңлекләрендәге сүлпән игенче, терлекче хәятеннән соң диңгез буендагы ыгы-зыгылырак тормышка ияләнү кыендыр. Хуҗалыкны бүтән нигезгә күчереп көйләргә сәрмая (капитал) да кирәк ич әле!

Ялыкавак — шәһәр сыманрак авыл, үзәк урамнары асфальтланган, кунакханәләр, кибетләр күп. Култыкка караган бер яклы урамы аеруча ямьле — аның икенче ягын ярга бәйләп куелган шхуна, баркас, яхта, катер, көймәләр тәшкил итә. Яр буена пальмалар, мәҗнүн таллар, гөлчәчәкләр матурлык өстәп тора. Кипарислар, чыршы кебек ылыслы агачлар да үсә.

Кайбер кибетләрнең бер ишеге диңгез култыгына, икенчесе янәшә урамга карап тора. Без шуларның киң, биек тәрәзәлесенә килеп кердек. Сатучысы — унбер-унике яшьлек малай. Идәннән түшәмгә чаклы кондитер ризыклары, эчемлекләр белән тулы шүрлекләр. Һәр әйбер матур итеп тәрелгән, ялык-йолык килеп тора. Шунда ук кайбер көнкүреш товарлары, табак-савытлар да куелган. Сатучы бала күзебезгә багып: «Ни аласыз, әфәндем?» — дип хезмәт күрсәтергә әзер тора, карарга гына керүебезне искәрткәч тә, кәефен төшерми, кызыксынып сораган әйберләребезнең бәясен, ничек, кайчан кулланылуын төшендерә. Алучылар күп керми. Көнбатыш илгизәрләре диңгез буенда яратып ял итә торган эссе көннәр артта калып бара. Ә малай тырыша, безне кызыктырырлык, ымсындырырлык нәрсә табарга талпына, конфет, печенье, уенчык — карашыбыз тукталган һәр нәрсәне секунды белән кулыбызга тоттырырга тырыша. Аның шулкадәр өтәләнеп, күзләрен мөлдерәтеп бер артыбызга, биш алдыбызга төшүеннән уңайсызланып, бер-беребезне нидер алырга кысташа башлыйбыз.

Теге елларда килсәк, без, мөгаен: «Капитализм балаларны да кызганмый, кавырсыны катмас борын җелеген суыра башлый, фәлән-төгән», дип кайтып сөйләгән, язган булыр идек. Бүген алай икейөзлеләнүнең мәҗбүрияте юк. Үз илемдәге һәр нәрсәдән кимчелек табарга, чит илнең һәр ялтыравыгын аһ-уһ килеп мактарга һәвәслегемнән түгел. Мин Казаныбызда Кутузов урамындагы кибеттә кырык-илле яшьлек ирләрнең бушаган сөт бидоннарын ничек итеп машинага төягәннәрен күзәтеп тордым: шундый итеп тондыралар — тимер булып тимер мондый мөгамәләдән соң атна эчендә ямьшәеп, ай эчендә тишелеп бетә торгандыр. Ә бу малай, үсеп җиткәч, андый ипсез, андый да белдергеч эшче булмас. Мәскәү газитләре күптән түгел Советлар Берлегендә җинаяте өчен хөкемгә тартылучыларның фәлән дистә миллионга җитүен хәбәр иткән иде. Төгәл саны хәтеремдә калмаган, әмма ул исәп буенча, һәр дүртенче яки бишенче кешенең гөнаһлы булганлыгы чамалана иде. Олылар арасында. Андый илдә зуп-зур кибетне, әлбәттә инде, унбер яшьлек малайга тапшырып калдыру хәтәр.

Үсмер официантны, эше кими төшкәч, туктатып:

— Энем, син мәктәпне ташладыңмыни? — дип сораган идем мин.

— Юк, укыйм,— диде ул.— Укудан соң киләм монда.

— Гаиләгез ишлеме әллә?

— Юк. Мин монда акча да казанам, чит телләр дә өйрәнәм.

Истанбулдагы дусларымның хатта: «Төркиядә чит тел белү үзе бер университет тәмамлауга тиң»,— дип язулары исемә төште. Чит телне исә туристлар күп кайнаган отель, ресторааннарда өйрәнү, мөгаен, ансатрактыр шул!

Хуҗалык товарлары, азык-төлек, бизәнү әйберләре кибетләренә керәбез. Аларның хуҗалары инде тәҗрибәлерәк: кыяфәтеңә бер күз салу белән, синең хуш күңелле сәйран чигүче яки потенциаль сатып алучы икәнлегеңне бик тиз чамалый, шуңа бәйле рәвештә күңелеңне күрә. Төрекчә камил сөйләшмәвебезне сизүгә, кайдан килүебезне сораша башлыйлар:

— Тормышлар сездә яхшымы? Мөселманнар күпме?

— Советлар Берлегендә дә төрекчә сөйләшәләрме?

Кибеттән буш кул озатасы килмәгәннәре морҗадан төтенен ничек чыгарырга кирәклекне чамалап, ягымлы елмаялар да:

— Без дә — татар,— диләр.— Ата-бабадан татар каны килә, кардәшләребез икәнсез, хуш килдегез, яхшы булды!

Урамнан бу тамашага кәефләнеп, гөр-гөр сөйләшеп барганда, еректан ук безгә колак салып якынлашкан, спортчыга охшаган җиңел хәрәкәтле, йомры гәүдәле, кечтеки мыеклы бер ир:

— Әллә сез татармы? — дип үзе сүз кушты.— Мин дә — татар.

Бусы инде хәйләкәр кибетче түгел иде, шуңа күрә җанланып урап алдык үзен.

— Әтием Румыйниянең Күстәнҗә шәһәреннән күчеп килгән, әнием — азәрбайҗан,— диде ул.— Фамилиям — Узар, төрекләрдә андый исем юк. Хатыным да, җиде яшьлек улым да — татар! Азуман белән Илкәр.

Без аның шундый әчкерсез, ягымлы булуына сокланып карап торганда, яңа танышыбыз Исмәгыйль барыбызны да янәшәдәге кафеның урамга чыгарып тезелгән өстәлләре янына чакырды һәм чатыр астына утыртып, чәй эчәргә тәкъдим итте. Тугыз-ун яшьлек официант малай минуты белән нечкә билле касәләрен күтәреп килеп тә җитте. Керт-керт шикәр тешләп чәй эчә-эчә, милләттәшебез Узар белән танышуыбызны дәвам иттек. Ялыкавакка Советлар Берлегеннән казан татарлары беренче килүе идеме, кафе хуҗасы да, күршедәге кибетләрнең ияләре дә ачык ишекләреннән кызыксынып безне күзәтте. Исмәгыйль әфәнде, безнең кемлекне ачыклагач, үзенең дә иҗат кешесе, заманында Истанбулның махсус сурәт мәктәбендә укыганлыгын әйтте һәм аяк өсте торган килеш, куен дәфтәремә үзенең рәсемен дә ясап куйды. Сүзләре рас икән, бер-ике сызык белән сурәтләде дә бирде үзен! Гәпләребез тагын да җанланарак төште, үтенечем буенча, Исмәгыйль Узар хәзер инде кәгазьгә мине төшерә башлады. Гомер тартмасам да, сигарет та каптырып куйды. Өстәлебезгә чәйнең янә дә кайнарраг ы килде. Профессор Мирфатыйх абый көлеп:

— Әйди монда да татарларын эзләп тапты бит әй,— диде.— Чыгачак китабына сурәтләре дә әзер!

Ә Узар әфәнде үзе рәсем ясый, үзе сөйли:

— Сурәтче булырга туры килмәде инде, илгизәрләргә хезмәт күрсәтүче гид мин. Татарстан матурмы соң? Казан зур шәһәрме? Аһ шул татар мәркәзен бер барып күрергә!

Без дә аңа байтак сораулар бирдек.

— Добруҗадан, Кырымнан күчеп килүчеләр Төркиядә бик күп,— диде ул.— Әмма монда, Ялыкавакта, безнең гаилә генә. Тормышны көйләдек инде. Татар — башлы, эшчән ич ул, кайда да югалмый.— Ул бу сүзләрен безгә колак салып торган унлап төрек алдында әйтте. Яшермичә, кыланмыйча, үз-үзенә нык ышанган төстә, горур рәвештә. Аның белән иркенләбрәк сөйләшеп утырасы килгәнлектән:

— Кичен «Монакус клубы»на килегез әле! — дип чакырдык.

— Кызганыч ки, әфәнделәр, бүген мин төштән соң эшлим, хәзер Бодрумга юлга чыгачакмын. Иртәгә булса менә...

— Иртәгә без дә китәбез шул инде.

Ул ясаган автопортреты өстенә адресын язып:

— Алайса мәктүпләшеп торыйк. Татарлар бер-беребезне җуймыйк! — диде.

Бу очрашудан соң Ялыкавак тагын да үзрәк, якынрак булып хәтердә калды.

Хуҗалар безне микроавтобуста Бодрумга да алып барды. Унсигез чакрымда дисәләр дә, урау юлдан ул шактый ераграк иде, ахры. Туры юл юк, Ялыкавак шикелле, Бодрум да, шул исемдәге култык ярында, таулар урап алган казанлыкта утыра. Култык тыныч булганга, йортлар тәбәнәк, сөзәк яр өстендәге тауга тәмам терәлеп утыра. Диңгез өслегеннән бер метр югарылыгында! Яр кырыенда буш урын юк диярлек — ачык һавадагы кафе, ресторан өстәлләре тезелеп киткән. Култык эченә салынган басмалар тирәсенә, туплаудагы көтү шикелле, эреле-ваклы көймәләр, яхталар якорь салган. Диңгездән караганда, Бодрум бик матур: ике-өч катлы ап-ак ташпулатлары, сәлвиләре һәм пальмалары белән ул пакь, көләч йөзле, җыйнак курорт шәһәре тәэсирен калдыра. Яшеллек әзрәк,



*Бодрум шәһәре.*

билгеле, йортлар тыгыз урнашкан, алар инде монда да тау башына үрмәләп менеп бара, арада дүрт-биш катлылары да күренә. Соңгы вакытта Төркиядә туризмны үстерүгә игътибар бермә-бер арту монда бигрәк тә ачык сизелә: Бодрум кырыендагы тау битләрендә шактый биеклектә ашыгыч төстә илгизәрләр өчен махсус шәһәрчекләр — карлыгач оялары корыла. Аларның тирә-ягы — тирән тарлавык, биек тау кашы, кыргый урман. Хәзер, әле төзелеш тәмамланмаган дәвердә, ул саргылт таш куышлар һич тә күңелне тартмый. Әмма «Монакус клубы» мисалында беләбез: тиздән алар сыланачак, күз явын алырлык итеп акшарланачак, матур һәм уңайлы итеп җиһазланачак, электр, кайнар су белән тәэмин ителәчәк, үзара уңайлы аллеяләр белән тоташтырылачак. Таш кантарларыннан тазартылган түтәлләрдә, аллея кырыйларында гөлчәчәкләр, бүтән ямьле куаклар тамыр җибәрәчәк, диңгез буена әйбәт асфальт юл сузылачак. Мондагы тәрәзәләрдән, балкон һәм лоджиялардан бөтен шәһәр һәм диңгез култыгы уч төбендәгедәй күренеп торачак! Диңгез дымы сеңгән саф тау һавасының сәламәтлеккә нинди шифалы икәнлеген инде сөйләп, язып торырга да кирәкмидер. Килегез монда Көнбатыш Европаның гигант фабрикаларында машина дөбердәүләреннән, конвейер ыгы-зыгыларыннан ялыккан эшчеләр һәм хезмәткәрләр — ел буе җыйналган сырхауларыгыздан, йончуларыгыздан арынырсыз!

һәм киләләр. 1990 елда аларның саны 4,6 миллионга җиткән, Төркия казнасына биргән керемнәре 2,6 миллиард доллардан ашкан. Төркияләр исә чит илләргә 2,4 миллион кеше барган, 440 миллион доллар тотып кайткан. (Бу саннар 1993 елда 3,2 миллион һәм 950 миллион күләмендә булды). Бу кунакка йөрешүдән Төркия казнасы 2,16 миллиард доллар откан. Якын киләчәктә үк ул санның икеләтә-өчләтә артасына шикләнмәскә мөмкин, чөнки туризмга салынган сәрмая үзен бик тиз аклый, шунлыктан дәүләт бу тармакны үстерүгә акчасын кызганмый. Шуның белән бергә, ул күп кенә кешеләргә эш урыны бирә, илдә житештерелә торган артык ризыкны һәм кайбер бүтән малларны еракларга илтеп сату мәшәкатеннән коткара, шул чактагы югалтуларны киметә. Илнең җылы диңгезләр кочагына урнашкан булуы, уңайлы һәм матур култыкларга, тарихи һәйкәлләргә байлыгы Төркияне халыкара туризм мәркәзенә әверелдерү өчен бик зур мөмкинлекләр ача. Кечкенә Болгарстан (халкы — 8,5 миллион) — тугыз миллион, Мажарстан (халкы ун миллион) — унсигез миллион, Греция, Испанияләр тагын да күбрәк илгизәр китереп, шулар исәбенә баеп ятканда, Төркиянең язмыш бүләк иткән мөмкинлекләрдән файдаланмавы үзе бер акылсызлык һәм җебегәнлек иде. Премьер-министр, соңрак президент булып сайланган Тургут Үзал моны бик тиз аңлап ала һәм туризмга йөз белән борыла. Шушы тармакка көч-куәтен салырга теләгән эшкуарларга кредитлар бирү, дәүләт хисабына юллар салу кадрлар әзерләү, туризм сәнәгате таләп иткән инфраструктураны булдыру сәясәтен үткәрә башлый. Нәтиҗәсе күз алдында: Бодрумда гына түгел, бүтән җирләрдә дә — диңгез буйларында һәм тау араларында туристик комплекслар яңгырдан соң шытып чыккан гөмбәләр кебек үсә. Шуның аркасында Төркия 1994 елда 8 миллион чит ил туристы килүен һәм алардан 4,7 миллиард доллар керем тупланууын көтә.

Казанның «Турист» кунакханәсе төзелешендә унбиш еллап эшсез торган күтәрү краны җил-яңгырдан, кар-бураннан тутыгып, череп бетә бугай инде, тик бинаның каркаслары әле һаман үзенә «ит» кундыра алмый. Ә монда кран-фәлән дә күренми, ләкин шәһәрчекләр тиз салына. Донбасс һәм Кузбасс шахталарында, Түбән Тагил, Магнитогорск, Түбән Кама комбинатларында тузан, корым, агулы газлар эчендә акча күрәргә киткән, әмма тапканнары көндәлек ризыктан артмаган милләттәшләребезне дә ел саен шушында ял иттереп, гомерләрен озайтасы иде. Тик кая инде ул безгә!

Төркиягә килгән чит ил туристы 1993 елда җан башына уртача 640 доллар тотканда, башка мәмләкәтләргә барган төрекләр акчаны шактый азрак сарыф итә. Моның сере, әлбәттә, чит ил туристларының баерак булуында. Хезмәт күрсәтү, ял иттерү культурасы, сыйфаты күтәрелгән саен аларның тагын да юмартрак акча туздырачагы, «типтерәчәге» билгеле — Төркия эшкуарлары баю гыйлемен әле яңарак үзләштереп килә. Шул ук вакытта төрек илгизәрләренең тыйнаклыгын, бәрәкәтлелеген алар арасында Германиядә һәм бүтән Көнбатыш илләрендә эшләүче ирләре, аталары янына кунакка баручы гаилә әгъзалары күплеге белән дә аңлатырга кирәк. Чыгымны шунда эшләүчеләр тота, Төркия дәүләт статистикасы аны исәпләп бетерә алмый.

Бодрумның култык эченә кереп торган биек борынында урта гасырларда салынган калын диварлы, мәһабәт манаралы ныгытмасын, җыйнак мәчетләрен, матур гына җәмәгать биналарын тасвирлау мөмкинлегем юк — безне автовокзалга алып килделәр дә шәһәрне тамаша кылырга бер сәгать вакыт бирделәр. Мыек үстерергә дә өлгермәгән яшь-яшь гидыбыз әле үз һөнәрен үзләштереп җитмәгән, безне Бодрум шәһәренең истәлекле урыннары белән таныштырырга әле әзер түгел иде. Хәер, кесәбездә «Йени форум» журналы басылачак докладларыбыз өчен алдан түләп куйган илле доллар гонорар әтәч булып кычкырып тынычлыгыбызны алганда, кая инде ул музей яки мәчет тамаша кылырга ашкыну!

Измирдә кибетләрдә йөрергә форсат тиярме — белгән юк, ә монда автовокзал кырыеннан ук сәүдә урамы башлана. Ни генә юк анда! Казанда тилмереп эзләгән кием-салым дисеңме, тукыма, келәм, йорт-җир җиһазлары дисеңме — һәммәсе өем-өем, төрле сортын, фасонын сайла да ал. Тик валютаң — илле генә доллар. Кибетләр тезелеп киткән бер урамнан икенчесенә борылып керәбез, банк витриналарына язылган, көн саен үзгәреп торган чит ил акчалары кыйммәтенә игътибар итәбез — бүген (X.1991) бер доллар 4700 төрек лирына тигез икән. Төркиядә инфляция шактый көчле, ләкин президент Тургут Үзал моңа борчылмый, үсеп килә торган илдә моны котылгысыз хәл, дип саный. Аның каравы, бүген төрек лирасы халыкара әйләнештә йөри, аны маркага яки долларга алыштырырга мөмкин. Кибетләрдә чит ил акчасын һичбер тоткарлыксыз кабул итәләр — сатучы малайларга кадәр микрокомпьютерларда халыкара әйләнештәге фәлән акчаның ничә төрек лирасына бәрабәрлеген берничә секундта исәпләп чыгара. Бичара Совет-Рәсәй сумнарына гына сан юк!

Инфляция дәвам итә, әмма Төркия экономикасының дөрес юнәлештә үсүен күрсәткән товар муллыгы, аның хәрәкәттә булуы һәм иртәмесоңмы лирасының тотрыклылыгына китерәчәге чамалана.

Безнең дә дөнья җиткән икән: Мәдинә көмеш беләзек, Ринат Яңа Гвинея папуасларын да кызыктырырлык чәчәкле шорт ала, бары Разил белән Мирфатыйх абый гына күн куртка, туннар киеп карап әвәрә киләләр. Әллә соң боларның запас валюталары да бармы? Безнең халыкны кем белеп бетерә, барыбыз да бер төрле генә түгел ич!

Сәгатьләргә карасак, кайту вакыты да җиткән, без кермәгән кибетләр исә — хисапсыз әле. Матур биналарга, әфлисун, банан, лимон, өрек, армут һәм бүтән җимешләр, яшелчәләр өелеп торган киштәләргә, өстәлләргә күз салырга да вакыт юк,— хәер, аларның монда чагыштырмача арзан һәм бик күп икәнлеген без болай да беләбез. Монда инде төрекләр белән «кунышырга» — сөйләшергә дә форсат тими. Күңелгә ошаулы (арзанлы!) әйбер алырга өлгермәвебезгә дә артык кайгырмыйбыз — алда безне тагын да баерак Измир көтә. Тәҗрибәсез илгизәрләрне кисәтергә телим: Бодрум шикелле туристлар оясында долларларыгызны (әгәр булса!), эчкәре кесәләрегездә сакларга тырышыгыз, угрылар хәвефеннән түгел, сатучыларның тәмле теленнән. Мондый җирдә әйбер, гадәттә, шактый кыйммәтрәк, бай илгизәрләргә исәпләнгән була!

## ИЗМИР. «МАРЛА» ОТЕЛЕ

Егерме беренче сентябрьдә төштән соң без «Монакус клубы» илгизәрләр лагере белән саубуллаштык. Ялыкавак култыгының көньягындагы калку түбәгә урнашкан шәһәрчектә гөлләр чау чәчәктә, ике катлы ак виллаларны чолгап алган, ботакларын сары мәрҗән — миләштәй җиләк сарган биек агачларда кошлар сайраша. Көне кояшлы, җылы, күге зәп-зәңгәр. Аллеяның уртасына таш шакмаклар түшәлгән, сулъягындагы асфальт тротуар аска баскыч-баскыч төшә. Профессор Зәкиевне җитмешен ваклаган карт дип әйтерлек тә түгел — портфелен җиңел генә күтәреп, егетләрчә атлый. Таудан түбән булса да, йөге авырлыктан, арабызда иң яшь Разил сыгылган — ул монда үзенә дә, республикабыз милли китапханәсенә дә төрек китапларын күп җыйганлыктан, чемодан да, сумкасы да — шыгрым. Мәдинә ханым, киресенчә, килгәндәгегә караганда җиңеләя төшкән: Казаннан алган «Шәфкать» романын һәм бүтән китапларын бүләк итеп бетергән — кайсын булачак тәрҗемәчеләренә, кайсын галимнәргә. Аның бер әсәрен Истанбулда быел җәен Казанга да килеп киткән язучы Сөвенеч Чокым, әллә тагын бүтән берәү ашыга-ашыга төрекчәгә тәрҗемә итеп ята, диләр. Көмеш беләзеге исә беләктә — авырлыгы сизелми. Шундый ук брошка һәм алкаларны

монда танышкан бер галимәсе бүләк иткәнлектән, бизәнгечләре хәзер тум-тулы. Ул, гадәттәгечә, шат күңелле, сөйләшергә комар.

— Мин бәхетле,— ди ул рәхәтләнеп, көр тавыш белән.— Нинди җирләрдә кемнәр белән ял иттем бит, егетләр! Берегездән-берегез укымышлырак, талантлырак, тәрбиялерәк...

Сүзләре — колакка бал, әмма хәйләсез түгел, Мәдинә ханым җилне кайсы яктан истерү үзенә файдалырак буласын беркайчан да онытмый. Тик карт чыпчык Мирфатыйх абыйны алдап кара! Ул кинаяле елмаеп, ял сүзенә юри басым ясап, йомшак кына:

— Синең ял бигрәк тә хозур булды бугай шул,— дип җөпли.— Кавалерларың да хәтәр иде — төрле милләттән, төрле мәмләкәттән.

Коллоквиумның спонсорларына күрсәтер өчен кирәк булганмы, программада Мәдинәбезнең исеме «профессор Маликова» дип басылган иде. Киң күңелле илдәшебез моңа да үпкәләмәде, «үзләре язганнар ич!» дип чырык-чырык көлде генә. Язучыларны доцентка, профессорга бүлү гадәте юк, бәлки ул чыннан да шушы дәрәҗәле исемгә лаектыр? Профессор гомере буена ике-өч китап чыгарганда, Мәдинәнең роман, повесть, хикәя, пьесалары һәм мәкаләләре егермеләп китапка тупланган, әле дөнья күрмәгәннәре күпме! Терелеге, чаялыгы аркасында, ул докладын «Мәскәү-Истанбул» очкычында ук янәшәсенә утырган юлдашыннан тәрҗемә иттерергә өлгерде, шунлыктан, язмасын Ялыкавакта төрекчәләштереп маташканнарга караганда, аның вакыты мондагы галим-голәмә белән танышырга да, аралашырга да иркенрәк булды.

Үзләре әйткәнчә, танышлары һәм туганнары белән күрешергә теләгәнгәме, әллә илдән алып килгән доллар, фунт стерлингларына иркенләп әйбер җыю ихтыяҗыннанмы, Ринат Мөхәммәдиев белән Рафаил Мәсәгутов Измиргә алданрак киткәннәр иде. Гариф Ахунов әйтмешли, «күп милләтле татар халкы»н белмәссең, берсе — күрше җөмһүрият парламенты депутаты, валютаны шуннан да савадыр, икенчесе — халыкара мәшһүр сурәтче, иҗат җимешләрен чит ил туристларына марка, долларга да сата ала — әйбәт картина кем алдында да бәясен югалтмый.

Зәңгәр күзле, җирән чәчле, озын буйлы, таза гәүдәле, күп нәрсәдән хәбәрдар, әмма гыйльми җыйналышта чыгыш ясарга һич тә ашкынмаган сурәтче Рафаилның бу колоквиумга нигә һәм ничек килүе миңа гомумән табышмак булып калды. Сәяхәтенең күбрәк өлешен яр буенда кызынып, Эгей диңгезе дулкыннарында иркәләнеп-назланып уздыруы сәламәтлеккә файдалы иде, билгеле, ләкин Киев егетенә кояшлы Кырым кул сузымы гына җирдә ләбаса.

Калган вәкилләр барыбыз да бер микроавтобуска сыйдык: Эстония, Литва, Украина, Мәскәү белән урысча сиптерәбез, әмма Казагыстан егете Самат татарча гәп корып рәхәтләнә. Күңелен борчыган фикерләрен коллоквиумда бәян итсә дә, ул әле һаман тынычланмаган иде.

Тирән ермак яры буйлап өскә, калкулыкка күтәреләбез. Юл бормалы, «дулмыш»ыбыз әле тарлавыктан, әле киңәеп киткән үзәнлек буйлап чаба. Үзәнлектә ялгыз утарлар да күренеп кала. Йомры ташларны биләмә кырыена җыеп, өеп, койма койганнар. Өйләре, абзар-куралары да шул ташлардан корылган. Үләннәр көйгән, берән-сәрән утлап йөрүче ишәкләр, кәҗә-сарыклар күзгә чалына, уйдык-уйдык агачлыклар үзәнлекләргә тансык ямь биреп тора. Өйләр тирәсендә кое буралары абайлана. Бетонланган таштан, әлбәттә. Әгәр монда яңгыр җитәрлек яуса, котырып үлән, бакчалар үсәр иде — җылы, якты шулкадәр мул! Юк шул, дым җитми, шунлыктан, эшкәртелгән җирләр кишәрлек-кишәрлек кенә. Әмма бензин колонкасы станцияләре тулы тәртиптә. Куаклар, гөлчәчәкләр дә утыртылган монда, тамак ялгарга, сусын кандырырга ашханәсе, нәни кибете дә эшләп тора. Көнен дә, төнен дә!

Бодрумда без зур Измир автобусына күчеп утырдык. Бодрум казанлыгыннан киң калкулыкка күтәрелгәч, иркен, тигез кырлар башлана. Сугарыла торганнары да бар, алар сөрелгән, хәзер ял итә. Агачлар

саргая башлаган, кырларда да сары төс, аксыл коңгырт, аксыл-кызгылт төсләр мул. Ара-тирә коры елгалар очрый — алар күзгә яңгырларны, кышкы явымнарны зарыгып көтә. Диңгез күренмәсме дип, сул тарафка күз тегеп барабыз, әмма күгелҗем үрләр, зәйтүн урманнары гына күзгә ташлана ярдан шактый ераклашканбыз шикелле.


Ярты юлга җиткәч, бензин колонкасы станциясенә килеп туктадык. Ягулык салдырырга түгел, юлаучыларны ял иттерергә икән. Дәррәү җиргә коелдык, буыннарны яза-яза, гаҗәпсенеп тирә-якка карыйбыз — ни бензин-керосин, ни мазут-май исе килми. Асфальтланган мәйдан кырыйларында гөлчәчәкләр, бүтән куаклар күзне иркәли, сәлвиләр, пальмалар сафы яшел дивар булып өскә күтәрелгән. Каршыбызда исә — зур пыяла тәрәзәләрен балкытып, көлеп торган ашханә. Аның киң вә озын ачык әйванында юлаучылар чәйләп, «төтен» эчеп утыра. Автобуслардан коелган пассажирлар арасында тәнен мөмкин кадәр иреккә чыгарырга тырышкан көнбатыш хатын-кызлары да, баштанаяк киемгә төренгән, йөзе генә күренеп торган шәрекъ гүзәлләре дә бар. Шагыйребез Рәдиф Гаташ янәшәбездә булса, мөгаен, аларга бер-ике ягымлы сүз әйтер, аннары: «Син бит, җаным, Измирская!» дип шигырь багышлар иде. Разил исә сәләтен бик бәрәкәтле сарыф итә — елына йә бер-ике җыр, йә бер пьеса гына яза, милли сәнгатебез тарихына кереп калыр өчен шул да җитә, дип хисаплый. Шунлыктан без ят туташханымнарга ерактан карап кына эчкә уздык, кулларны юып килдек. Билләһи, бер тамчы да алдамыйм, көненә меңләгән кеше керсә дә, бәдрәфләре, юынгыч бүлмәләре таза-пакь, сабын-сөлгеләргә кадәр куелган. Иркен, якты. Мин инде «Казан-Чаллы» юлы «уңайлыкларын» искә алырга теләмим, оят! Хәер, җәен ярый, сервиз — табигать кочагында... Бушлай!

Ә ашханә залы, әлбәттә, тагын да хозуррак. Өстәл-урындыклары гади, җиңел, уңайлы. Сыйлары — ресторан ризыгы. Безне озата баручы яшүсмер тиз генә заказ бирде — официант минуты белән салат, шулпа, гөлаш, эчемлекләр китерә башлады. Егерме минут эчендә без инде тукланырга да өлгергән идек, ашханәдән чыккач, төрек туңдырмасын да авыз иттек. Кара, бу фирма вәкиле бушка гына йөрми икән ләбаса, кунакларын сыйлап маташа!

Без ашханәдә хушланган арада станциянең елгыр малайлары автобусыбызны сабынлап юган — ул ялт итеп балкып тора иде. Әйе, Көнбатыш Европа белән аралашу, алар тәҗрибәсен өйрәнү бер дә әрәмгә китмәгән — сервиз, хезмәт күрсәтү шулар дәрәҗәсенә күтәрелгән икән монда. Бу юл халык тыгыз урнашкан Урта (төрекләр аны «Ак» диләр) һәм Эгей диңгезләре буен Измир белән тоташтырганлыктан, зур-зур автобуслар да, җиңел машиналар да агылып кына торганлыктан, автостанциядә күңелле җанлылык. Әмма беркайда да күңел кайтаргыч озын чират юк. Чират — социализм казанышы икәнлеген мин, әлбәттә, беренче ачкан кеше түгел.

Йөк һәм юлаучы ташуда Төркиядә төп урынны автотранспорт тотуын алдарак язган идем инде. Ишәк җиккән бер кучәрле арбалар хәзер ярдәмче рольне генә үти, дөяләр Анадулының чүл-дала төбәкләрендә генә калып бара.

Измиргә без кичке бишләрдә килеп җиттек. Көньяктан якынлашканда ул бик үк шәп тәэсир калдырмый, билгеле. Үзәнле-таулы җиргә урнашкан икән, бигрәк тә үргә салынган йортларның күпчелеге — бер катлы. Әмма зур сәнәгать учаклары — фабрикалары бар шәһәргә аяк басуың сизелеп тора. Әллә ничә төрле югарылыкта берсе икенчесен кичеп үткән күперле юллар, алардан йөгергән йөзләрчә, меңнәрчә машиналар кырмыска оясын хәтерләтә. Яшеллек әз, чүп-чар җитәрлек. Ләкин үзәккә якынлашкан саен урамнар матурая, йортлар биегәя бара. Аннары пөхтә, сөйкемле бульварлар башланды — Измирнең диңгез буе зонасына аяк бастык һәм тиздән биек «Марла» отеле каршысына килеп туктадык.



*Измир. Борынгы мәчет һәм сәгатьле манара.*

Өч йолдызлы, безнең төшенчәдә, коточкыч кыйммәтле, халыкара категорияле кунакханә икән бу. Кунак карточкасын тутыргач, кулыбызга ачкычлар тоттырдылар, чемодан-сумкаларыбызга бүлмә санибыз күрсәтелгән «Марла» бирkaларын чәпеп куйдылар, фирма киемен кигән җитез яшүсмерләр ул арада багажыбызны әләктереп, безне лифткә дә ияртеп кереп киттеләр. «Чук тәшәккер, кәндем күтәрәм!» — ягъни «күп рәхмәт, үзем күтәрәм», дип әйтеп карыйбыз, елмаялар, тыңламыйлар, бу — отельнең кунакка хезмәт күрсәтергә тиешле бер гадәте, янәсе. Начар йола түгел, әмма, җанкисәкләрем, совет илгизәрендә чәйлек бирергә дә валюта юк лабаса, уңайсыз!

Һәркайсыбызга — аерым номер. Телевизор, суыткыч, радиоалгыч, диварында — эстамп. Болары бик гаҗәп түгел әле. Гаҗәбе — идәнендәге калын келәмнең куе болын үләнедәй йомшаклыгы. Суыткычына шешәле чишмә сулары, тумбочкасында хат язарга «Марла» отеле грифе төшерелгән махсус кәгазь һәм конвертлар, юынгыч янында «Марла» сабыны, «Марла» шампуне әзерләп куелган. Кондинционеры эшли, телефоны — икәү, берсе — ванна бүлмәсендә. Кичке һәм иртәнге аш белән бергә, бу номер тәүлегенә җитмеш долларга төшә икән! Билгеле, халыкара категорияле кунакханәләрнең һич тә иң шәбе яки кыйбатлысы түгел «Марла», аның әле тәүлеге мең ярым долларга бәяләнгән номерлары да була. Ләкин безнең өчен монысы да бик һәйбәт, әгәр «Йени форум» журналы түләмәсә, кайчан туктала алыр идек әле «Марла»да.

Кичен ресторанга төшкәч, «Азатлык» радиосында эшләүче табындашым Ясин Аслан, Совет илендәге тормыш-көнкүрешне шактый яхшы белүче әзәрбайҗан егете, елмаеп:

— Ничек соң, «Марла» ошыймы? Сездә шушындый кунакханәләр бармы? — дип сорады.

Аның төрек отелен мактавымны, аңа соклануымны әйттерергә көтеп торуын чамалап:

— Казанның иң начар кунакханәсе дә моннан күпкә яхшырак! — дидем.

Журналист егет пырхылдап, сыгылып төште.

Сыйлану монда да шәп булды. Тегенгә шулкадәр күнегелгән икән, официант:

— Нинди эчемлек китерим, әфәнделәр? — дигәч, аптырап калмадык, ике төрле һәйбәт шәрабкә заказ бирдек.


Кыскасы, затлы итеп, күңелле утырдык кичке аш мәҗлесендә, Көнбатыш Европа туристларыннан бер дә ким түгел. Мюнхен журналисты Ясин, үзен дөнья күргәнрәк кеше санап, безне аш-су, төрек ресторанында сыйлану тәртипләре белән дә таныштырып кәефләнде. Әйдә, белдекләлеген күрсәтеп кинәнсен, казан татарлары тар күңелле түгел! Табында ул минем каршымда гына иде, Бакыдагы дус каләмдәшләремне искә төшереп тә гәп корып алдык. Рестораннан чыгып барганда официант нидер әйтә башлагач:

— Әфәндем, менә бу егет төрекчә әйбәт белә, аның белән сөйләшегез! — дип, һәммәбез өчен аңлашуны чая Ясин Асланга ышанып тапшырдык. Аңа төрекчә сөйләшү ни, әзәрбайҗан теле төрекчәгә татар теленә башкорт теле нисбәтендә якын ич.

Ярый әле шулай иткәнбез! Шәраб кичке ашыбыз исәбенә керми, аның өчен өстәп түләү кирәк икән. Алманиядән килгән кардәшебезгә, валюта янчыгын чыгарып, иплəп аңлашырга туры килде. Егет икән, сер бирмәде тагын үзе!

Кунакханә турында сүз киткәч, алгарак сикерелде бит әле. Әйберләрне кертеп урнаштырганнан соң, без башта ресторанга түгел, Измир белән танышырга чыгып йөгердек. Ашыкмый хәл юк, чынлыкта бу иптәшләремнең Төркиядәге соңгы көне, таң алдыннан алар Истанбулга, аннан Мәскәүгә очарга тиешләр, кибетләр ябылганчы теге рәхмәт төшкере илле долларны товарга әйләндереп өлгерергә кирәк иде. Илдә күчтәнәч көтүчеләрне онытырга ярыймы соң?!

Ә мин үзем, профессор Айдын Ялчын ярдәмендә, кайту билетымны нәкъ ике атнага кичектергән, бу хакта Измирдәге дусларыма телефон аша Ялыкавактан хәбәр итеп куйган идем. Тукталган отелемне белгерткәч үк, аларның мине моннан алып китәчәгенә шигем юк иде. Ләкин мин «Марла»дан аларга шалтыратырга ашыкмадым. Диңгез буе бульварына орынып торган шәһәр үзәгендәге комфортабельле кунакханәдә нигә әле иптәшләрем белән бергә кич кунмаска? Кичке һәм иртәнге ашка түләнгән, мин монда иртәгәге сәгать унбергә кадәр рәхәтләнеп яши алам.



*Иске Измир урамы.*

Шуңа күрә иптәшләр белән сәүдәгәрләр янына да чыгып йөгермәдем, әле иртән генә диңгез ваннасында рәхәтләнгән булсам да, гомеремдә бер килеп эләккән, нур чәчеп торган «Марла» отеленең оҗмахтагыдай ханәсендә юынып алырга ниятләдем. Ул фирменный сабын, шампуньнарны тәнемә тидермичә, шулкадәр тамаша йомшак, йонлач мунча сөлгесен иңемә ябынып сөртенмичә, ваннада изрәп яткан көе генә телефоннан сайрашмыйча китеп бару, кичерегез, гөнаһ булыр иде. Тик... бу телефоннан кемгә генә шалтыратырга соң? Измирдә белгән адресым әлегә берәү генә, тавышымны ишетү белән, алар үзләренә бүген үк алып китәргә комарлана башлаячак. Юк, юк, Мәҗитләргә чылтырату ярамый. Анкарадагы яки Истанбулдагы танышларга хәбәр бирергә дисәм инде... шәһәрара телефонның мәһәре кыйммәткә төшүе ихтимал, совет илгизәрләре моны күтәрә алмаска да бик мөмкин. Кызганыч!

Кәефен китереп ваннада чыпырдаганнан соң, иптәшләремнең әле һаман кайтып җитмәвен ачыклап, якын-тирә белән танышыр өчен урамга ялгызым гына чыктым. Җөмһүрият, Ататөрек проспектлары, Газый Җамал паша урамы, Диңгез буе бульвары. Монда инде — өч миллионнан артык кеше яшәгән шәһәрнең уртасы, йортлар төзек, урамнар тәртипле, атлаган саен банк, кунакханә, ресторан, кибеткә килеп төртеләсең. Гөлләр, купшы чинар агачлары, киоскылар, велосипед тәгәрмәчләренә көйләнгән җиңел арбаларын этеп, җиләк-җимеш, камыр ризыклары сатып

йөрүче вак сәүдәгәрләр. Алар берсен-берсе уздырып, кычкырып товарларын мактыйлар:

— Очсыз! Иң арзаны, әйбәте!

— Татлы, балдан татлы!..

Мәшһүр галимебез Шиһабетдин Мәрҗани 1880 елның сентябрендә хаҗга барышлый Измирдә туктала һәм көндәлегендә тәэсирләрен болай язып куя: «Пристане гүзәл булып, юнган таш җәелгән. Яхшы кунакханәләре бар. Тимер юлында бер ат белән трамвай йөри. Аннан башка да тимер юллары һәм гүзәл кибетләре бар. Йөк ташучылар ишәк, качыр, дөяләр, шулай ук арба белән һәм күтәреп һәртөрле нәрсәләр ташып яталар. Фаэтон һәм кареталар да бар икән. Бик зиннәтле сәүдәханәләр һәм машиналы фабрикалар бар. Йөзем, инжир, әфлисун һәм бүтән нәрсәләр бик яхшы һәм мул. Итнең яхшысы күп. Мәчет һәм чиркәүләр күп һәм гүзәл икән. Киң урамнары бар, күбрәге тар икән, ләкин һәммәсенә таш түшәлгән».

Мәрҗани монда милләттәшләреннән Әҗе (хәзерге Рязань өлкәсе), Кошман (хәзерге Татарстан), Тугай (хәзерге Башкортстан) авылы кешеләре белән очраша, алар Измиргә ничек килү, шушында ничек төпләнеп калуларын сөйлиләр һәм галимебезне шәһәр тормышы белән таныштыралар. Димәк, без бу урамнарда йөрүче беренче татарлардан түгел!

Хәзер инде Измирнең зур кибетләре нәкъ Көнбатыш Европадагыча: әйбер күп. Бер аермасы — төрек сатучылары дәртлерәк, җанлырак, товарын мактарга һәвәсрәк, ягымлырак.

Измир — Төркиянең халык саны, һөнәрчелек-сәнәгать үсеше, мәдәният һәм сәүдә учаклары ягыннан өченче урында торучы шәһәре, йөк әйләнеше белән Анкараны да уздырып җибәрә. Монда кар ятмый, диңгез суының җылылыгы кышын да ун-унике градустан түбән төшми. Азык-төлек Анкара белән Истанбулдагыдан арзанрак. 1923 елга кадәр греклар күпчелек тәшкил иткән шәһәрдә хәзер алар бөтенләй яшәми диярлек. Билгеле, монда гарәпләр, көрдләр, бүтән милләт вәкилләре бар-барын, ләкин алар урамда һәммәсе төрекчә генә сөйләшә. Шәһәр егерменче елларда, милли-азатлык сугышы заманында янгыннан һәм атышлардан бик зур зыян күргән, шуннан соң тәмам яңа баштан корылган. Торак төзелеше бик тиз киң колач белән алып барыла, әмма авыл халкының шәһәрләшүе шулкадәр көчле ки, су һәм канализация кертелгән йортлар әле һаман җитми.

Кичке аштан соң Диңгез буе бульварын гизәргә без барыбыз бергә чыктык. Ут алынгач, диңгез култыгы үзенә бер төрле ямьләнеп китте. Биек палубалы корабларда, эреле-ваклы катер, йөзмә ресторан, яхталарда әле һаман тормыш кайный — тәрәзәләре яп-якты, култыкның аргы ярындагы биек тау башларына чаклы сибелгән Каршыяка өйләре утлары җемелди, алар дулкыннар шадрасына якты тап булып төшеп, кире кайтарыла. Яшелле, кызыллы, зәңгәрле неон балкышлары чагылышы аеруча матур. Бульварда кыздырылган май, суган исләре таралган — сәйран чигүчеләргә ни генә тәкъдим итмиләр! Урамда өстенә чатыр гына корылган дистәләгән ашханә, чәйханә, каһвәханәләр тезелеп киткән. Ул да түгел, арбасының уртасына газ лампасы утыртып, аның тирәсенә төрле-төрле җимеш, кыздырылган кукуруз чәкәннәре тутырылган кырык тартмасын тезеп куйган яки кайнар сумса, эченә ит, суган кыстырып бөкләнгән ләхмаҗан (коймак) төягән сатучылар, товарын мактый-мактый, артыннан ияреп бара. Утыз-кырык адым саен каһвә, чәй тәкъдим итүчеләр мыжгып тора.

Шул арада берзаман урамны машиналар ташкыны тутырды. Барысы да каршы яктан агыла, кайберсенең пыяласы ачык ишегеннән егетләр тышка бүселеп чыгып, беришесе, хәтта, түбәсенә менеп кунаклап бара. Машиналар өзлексез кычкырта, егетләрнең шат, дәртле тавышлары яңгырый:

— Гүз-гүз-гүзтәпә! Гүз-гүз-гүзтәпә!..

Машина сигналлары шулар көенә аккорд бирә:

— Пип-пип-пиби-бип! Пип-пип-пиби-бип!..

Кайберләре сигналын гармун кебек уйната, кайсылары нечкә яки калын тавышлары белән колакны яра. Нәрсә булган боларга, милли бәйрәмнәре җиткәнме, күк капусы ачылганмы, нинди мәхшәр купкан? Нишләп, тузгыган корт иле кебек, гөжли, шаулый, юләр сата бу яшь-җилкенчәк һәм инде күптән акыл утыртырга, сабырланырга тиешле чем-кара мыеклы ир-ат халкы? Түзмибез, өлкәнрәк бер абзыйдан сорыйбыз. Ул көлемсерәп:

— Футболдан кайталар, яраткан командалары җиңгәндер, «Гүзтәпә»ләрен мәдехлиләр, данлыйлар әнә! — ди.

Исебез китеп карап торабыз: сабый да сабый, болар да сабый! Бүтән бер кайгылары да юк икән боларның, дөньялары түгәрәк икән. Язгы ташкын шикелле, ун минут агыла, егерме — һәр сафта дүртәр җиңел машина яки «дулмыш» — микроавтобус, аларның койрыгы күренми, дәртле, гайрәтле авазлар тынмый, ниндидер исемнәр атала, чакырулар яңгырый. Аннары тагын күмәк рәвештә кычкырган авазлар бүтән тавышларны күмеп китә.

— Гүз-гүз-гүзтәпә! Пип-пип-пиби-бип!..

Совет матбугаты дистә еллар буе: «Төркиядә — мохтаҗлык», «Төркиядә — наданлык!», «Төркиядә — эшсезлек», диде. Ә боларның, футбол җанатарларының, тамагы тук, өсте бөтен, күпмесендә — җиңел машина. Яныбыздан ничә мең үтте икән инде алар? Тавышлары көр, авазлары куәтле, әйтерсең, «Гүзтәпә» дөнья беренчелеген яулаган!

— Мирфатыйх абый, сез — профессор кеше, беләсездер, әйтегез әле: нишләп болар ач, ялангач, надан мескеннәргә охшамаган? — дибез.

Фән докторыбыз дәшми, елмая гына. Дөньяда үзгәрешләр булырга тиештер инде, янәсе. Ул үзе дә хәзер урыс теле белән татар телен якынайту, кушу эшчәнлегеннән чигенде ич. Артта калган Төркия нигә баемаска, укымышлы илгә әйләнмәскә тиеш әле?

Казан урамнарында да тизрәк шушы Измир бульварындагыдай шат авазлар яңгырасын, дөнья куып йончыган милләттәшләребезнең караңгы йөзенә якты елмаюлар кунсын иде. Без — тоташ укый-яза белә торган, «дөньяда иң алдынгы» лабаса!

Урамнар тутырып аккан машиналар гөрелтесендә, Эгей диңгезенең Измир култыгына таралган дәртле авазларда беркайчан да милли иреген җуймаган горур төрек халкының кайнар йөрәк тибеше, дәртле яшәеш рухы да чагыла иде булса кирәк. «Гөлҗамал»лар, «Карурман»нар, «Без кабызган утлар» моңына кереп сеңгән бу рух татарда да онытылмаган, ул безнең тамырларда, буыннарда үз сәгате сукканын көтә.

## МӘҖИТ БӘЙ

Йокы туйдырып, иртән ресторанга төшкәндә зал буш дип әйтерлек, Совет кунагы мин монда бер ялгызым гына идем инде. Иптәшләрем һавада, Истанбулдан Мәскәүгә таба очкан вакыт. Иртәнге дүрттә отель хезмәткәре телефон шалтыратып, мине дә уятты, һава аланына (аэропортка!) китәр алдыннан буфетка төшеп, тамак ялгарга чакырды. Мин аларга иптәшләремнән аерылып монда калачагымны искәртмәгән идем. Илдәшләрем белән кичтән саубуллашканлыктан, нәзакәтле һәм кайгыртучан хуҗаларга йокы аралаш аңгы-миңге рәвештә генә:

— Тәшәккер, бәй-әфәндем! — дип мыгырдандым да сукранып брак икенче ягыма әйләнеп яттым.

Иптәшләрем минем Төркиядә тагын ике атнага каласымны белгәч, көнләшеп тә куйдылар. Аларның да монда танышлары-дуслары бар, алар да әле төрекләр белән аралашып, кардәшләр илен гизеп, күреп

туймаган, шуңа күрә, билетемне кичектерү серен ачыклагач, иптәшләрем Айдын Ялчын әфәндегә мөрәҗәгать итеп карадылар. Үтенеч белдерергә әмма дә ләкин соңга калганнар икән — безнең юл мәшәкатьләрен хәл кылуны үз өстенә алган фирма вәкиле инде Ялыкавактан китеп өлгергән иде. Дөрес, Разил белән Мирфатыйх абыйның кайгырырлык, уфтанырлык җире юк, алар тагын бер-ике айдан Анкарага, төрки әлифбаларны камилләштерүгә багышланган фәнни конференциягә килергә тиешләр. Быел Төркиягә икенче мәртәбә аяк баскан «бәхетле» Мәдинә ханым шулай ук тиздән, Истанбулда романы нәшер ителгәч үк Мәрмәрә диңгезе буена янә сәфәр чыгачак. Шөкер, тырыш кешеләрнең киләчәге үз кулында. Юкка гына: «бирим дисә колына, чыгарып куяр юлына» димиләр ич!

Буфет өстәленә салатлар, кайнар ризык, эчемлекләр тезеп маташкан официант яныма килеп, инглизчә нидер аңлатты. Мин аңа шундук:

— Төрекчә генә куныышыюрым, бәй-әфәндем! — дидем.

— Сабаһлар хәерулсын! Боерыңыз, йимәкне кәнденез алыңыз, бәй-әфәндем! — диде.

Монда да ризык мул — теләгәнен үзең сайлап алып сыйланасың. Гөлләре купшы, бәллүр вазалары, кандилләре ялык-йолык итеп тора, залы тулаем ямьле. Әмма нигәдер кичәге кот, җылылык, күңел хушлыгы җитми. Бераздан чамалыйм: ялгызлык тойгысыннан икән бу. Ресторанда, отель фойесендә кунаклар тыз-быз килә, диварлар тышында өч миллионлы шәһәр кайный, тик алар мине бар дип тә белми. Шуңа күрә мин тизрәк бүлмәмә менеп, танышларыма шалтыратырга ашыктым. Ял көне бит, «кунагыбыз килмәс, ахры», дип берәр җиргә китеп барулары да ихтимал.

Мәҗит бәй — Алманиядәге дустымның дусты. Минем Төркияне күрергә хыяллануымны белгәч, бик ягымлы хат язып, мине бер айга хатыным белән парлап кунакка чакыручы. «Истанбул, Искешәһәр, Измир калаларының һәркайсында берәр атна, аннары татар авылларында яшәрсез, теләгәнчә ял итәрсез, безнең тормыш белән танышырсыз» дигән һәм хат янына рәсми чакыруын да теркәгән иде ул. Әмма чит илдән кунак китерү тәҗрибәсе җитмәүдәнме, чакыруын нотариустан раслатырга оныткан иде. Бәхетемә, коллоквиум эшне җиңеләйтте — бер атуда ике куянга тидердем.

Тавышымны ишетеп, кемлегемне белүгә, Мәҗит бәй:

— Шалтыратуыгызны көтеп, без кичә көне буе өйдә утырдык, хәзер кайда сез? — диде. — Бер сәгать эчендә килеп җитәрмен!

Бераздан бүлмәмә утыз яшьләр тирәсендәге, уртачадан югарырак буйлы, озынча йөзле, мыеклы, шат кыяфәтле таза-сау бер ир-егет килеп керде.

— Көттердегез, — диде ул, кочаклашып күрешкәч. — Кичә килгәнсездер ич, нигә шунда ук хәбәр итмәдегез?

— Әле кунак көйләп ялыгырга өлгерерсез.

— Нинди сүз ул, безнең күңелебез киң! Юлдашларыгыз да мондамы соң? Киттеләр? Кызганыч, күреп тә кала алмадым үзләрен. Йә, кузгалабызмы?

Кәефле генә чыгып барганда Мәҗит бәйгә «Марла» хезмәткәре белән кесәсен капшап аңлашырга туры килде — минем телефоннан сөйләшүем өчен түләтүләре, имеш. Бар икән күрәселәр, шәһәр эчендәге кешегә генә шалтыраттым, югыйсә!

Мәҗит бәй — инженер, бер фирмада машиналар белән сату итә икән. Җиңел машинасына кереп утыргач ук сәфәр хәлләремне, Татарстан тормышын сораша башлады.

— Безгә Кытай татарлары да килде әле, — диде ул. — Алар берничә ай элек кенә Казанга да барып кайттылар. Эгей университетында белемнәрен күтәрәләр. Булыштык үзләренә, күршебездә генә фатир табып бирдек, аны җиһазларга да ярдәм иттек.

— Мөслах белән Рауза түгелме алар?
— Сез аларны беләсезмени?
— Мөслах — авылдашым, мин әле: «Измирдәге адресларын да сорарга өлгермәдем, таба алмам инде үзләрен», дип хафаланган идем.
— Менә күрешәчәксез инде. Алар безгә Татарстаннан кунак килергә тиешлеген беләләр, керерләр.
Егерменче йөздә дөнья тарайды, диюләре дөрес, аһры. Әле кайчан гына Рауза Дәүш «Сөембикә» журналы редакциясендә Кытайда яшәүче татарларның туган телләрен саклау өчен ничек көрәшүләрен сөйләгән, Казанда — милли мәркәзебездә исә татарча сорауга урысча гына җавап кайтаруларына ачынып, «Горурлыгың кайда, татарым?» дигән шигырен укыган иде. Түгәрәк йөзле, җыйнак гәүдәле, әмма сандугач шикелле хискә-моңга бай җан икән — әлеге очрашу мәҗлесендә җырларыбызны да җырлап бирде. Ире Мөслах белән алар радио-телевидениебез аша да чыгыш ясадылар. Мөслах белән мин, алар инде юлга кузгалырга җыенганда, «Казан» санаторие холлында аяк өсте генә танышып, сөйләшеп алдым. Игътибарлы, милли хисле егет.
— Без тарихи ватаныбызга кайтырга, Казанда югары белем алырга теләгән идек. Татарстанда әйбәт каршы алдылар, ләкин Кытай хакимнәре безгә Төркиядә укырга гына рөхсәт бирде,— дигән иде ул.
Кытайда үзе балалар укыткан, хатыны — фельдшер, халыкны дәвалаган. Икенче мәртәбә булулары икән Татарстанда, былтыр туган якларын — Апас районының Урта Балтай авылын да күреп килгәннәр. Ягымлылар, уйгыр аһәңе белән шактый ук төзек татарча сөйләшәләр.
Машинабыз Диңгез буе бульвары буйлап култык сыртына таба йөгерә — уңда атка атланган Ататөрек — Төркия җөмһүриятен оештыручы, гаять авыр дәвердә иленең бәйсезлеген саклап калган каһарман һәйкәле, зур-зур отельләр, җыйнак скверлар күренеп кала. Аннары без сулга борылып, култыкның икенче ягына — шәһәрнең Каршыяка төбәгенә килеп керәбез. Мәҗит рульне бик ышанычлы тота, җитез бара, әйтерсең, шушында туып үскән дә машинадан бер дә төшеп тормаган!
Бабасы Нурый, әбисе Бибисара Идел буеннан Төркиягә күчеп урнашканда әле бала гына булганнар. Аларның 1911 елда туган уллары Мөхәммәт милләттәше Рабигага (1906—1985) өйләнеп, сигез бала үстергән. Мәҗит — шуларның төпчеге икән. Башта абыйлары Измиргә китеп эшкә кергән. Тора-бара аларның иң өлкәне — банкта, икенчесе — төзелештә, өченчесе — бензин колонкасында хезмәт итә башлаганнар. Тырышлыклары, намуслылыклары белән алар монда хөрмәт казанып, һәркайсы өйләнеп, үз оясын корып җибәргән. Туганнарның берсе Алманиягә үк китеп мал табарга керешкән, әле дә шунда көн күрә. Кыз кардәшләр дә Измирдә оя корган, бала-чага үстереп яталар. Аларның барысының да университетлы шәһәрдә тамыр җибәрүе төпчек малайга югары белем алуны шактый җиңеләйткән.
Мәҗит үзе дә авырлыктан, эштән курка торган егет булмаган. Студент чагында ук апасы Кодрәтләргә йорт салырга булышкан. Аннары шул йортның икенче катын бергә-бергә аның өчен җиткезгәннәр. Татулыкта, бердәмлектә бәрәкәт — туганнар Мәҗит белән Хәсибәнең туен күңелле бәйрәм итеп уздырганнар, хәзер җиде яшьлек Бурҗыга, өч яшьлек Айбикәгә өлкән кардәшләрнең балалары күз-колак була. Чөнки, күпчелек төрек-татар хатын-кызларыннан аермалы рәвештә, югары белемле Хәсибә өйдә генә ятмый — мәктәптә балалар укыта.
Тыштан әлләни соклану уята алмаслык гади генә ике катлы бер таш йорт янына килеп тукталдык. Тирә-ягы шәрә такыр. Әмма эчтән фатир уңайлы икән, дүрт бүлмәсе, коридоры, кухнясы, ванна-бәдрәфханәсе, су кайнарлату системасы, канализациясе бар, әйбәт кенә җиһазланган.
— Ләкин киләсе юлы сез яңа фатирыбызга аяк басарсыз инде,— ди Мәҗит.— Анысы матуррак районда, мәркәздә корылып ята. Гаиләбез ишәя, иркенрәк оя кирәк.

Ә монысын алар тулысынча үз көчләре белән генә салганнар икән. Төзү материалларын гына сатып алганнар. Билгеле, ул чакта шәһәргә яңа күчеп килгән авыл яшьләренең юмарт тотарлык акчалары да булмаган. Хәзер исә Мәҗит Сүзәрнең айлыгы илдәге уртача хезмәт хакыннан өч мәртәбә югарырак. Эш мал табуда гына түгел, тапканны тота белүдә дә. Мин Мәҗитнең бу җәһәттән үрнәк кеше икәнлегенә үзем күреп ышандым.




*Яңа Измир. Каршыяка районы.*

Бер көнне без шәһәрне гизәргә чыгып киттек. Үзәк урамнарны тамаша кылдык, исәпсез-хисапсыз кибетләр тезелеп киткән базарга да кагылдык һәм, йөри торгач, арыдык, ачыктык, билгеле. Хәсибә шәһәрдә генә тамак ялгарга тәкъдим итте. Мәҗит бәй уйлап торды-торды да машинасын өйгә таба борды. Ул түгел, мин дә ресторан, ашханә сыенын Төркиядә әйбәт сыйфатлы, ләкин шактый кыйммәт торуын чамалаган идем инде. Хәсибә арыган, бәлки кеше әзерләгәнне авыз итәргә ымсынган булгандыр, ләкин алар миллионер түгел ич әле. Өйдә арзангарак төшереп сыйланырга да бик мөмкин!

Мин моны Мәҗитнең саранлыгын күрсәтер өчен юри язмыйм, андый булса, ул кунагын өендә бик әйбәт тәрбияләмәгән, Измирдән озатып җибәргәндә, алдан вәгъдә иткәнчә, ары таба булачак юл чыгымнары өчен кесәсенә түгәрәк сумма салмаган, көчләп диярлек кулына затлы бүләкләр дә тоттырмаган булыр иде. Хәләл көче белән таба ул акчаны, аны уңга-сулга ваемсыз чәчә-сибә башласаң, ыштансыз калуың да бик тиз. Мәҗитнең исә ниятләре дә, хыяллары да әле зурдан!

Аннары Төркиягә күчеп килгән милләттәшләребез дә буш җирдә нигез салганнар, бу аларны чама белергә, барны саклык белән тотарга өйрәткән, шул сыйфат яшьләргә дә күчми калмаган, күрәсең.

Бервакыт Мәҗитнең атасы хатынына:

— Бераз сыйр китер әле. Ул ашказанын ныгыта, әпититне ача,— дигән.

— Өйдә сыйр юк шул,— дигән Мәҗитнең анасы.

— Бик әйбәт,— дигән ата кеше.— Сыйр ул ашказанын боза, теш камашларын зәгыйфьләндерә.

Хатыны гаҗәпләнеп:

— Синең бу капма-каршы фикерләреңнең кайсы дөрес соң? — дигән.

— Әгәр өйдә сыйр булса — беренчесе, булмаса — икенчесе,— дигән гаилә башлыгы...

Бераз ял иткәч, Каршыяка базарына киттек. Сатып алучыларга уңайлы булсын өчен, атнаның төрле көнендә төрле мәхәлләдә уза икән ул. Бүген — Мәҗитләргә иң якын урамда гөрли. Тау-тау җиләк-җимеш. Хәтта нинди бай Алманиядәгедән дә мулрак монда, чөнки армурт, анар, банан, йөзем, шәфталы, тагын башкалар барысы да үзендә үсә. Уртача хезмәт хакы (дүрт йөз доллар чамасы) алучы да, әлбәттә, бу җимешләр белән Татарстан халкыннан ешрак һәм күбрәк сыйлана. Кишер, кыяр, помидор, укроп ише яшелчәләр дә: «Мине ал, мине!» дип кычкырып

торалар. Юк, ияләре такмаклый-такмаклый сатып алучыларны җәлеп итәргә тырыша икән. Сәүдәгәрләр көндәшлеге шулкадәр куәтле ки, алар бер-берсен уздырырга омтылып юмакайлана, дөньяда иң әйбәт товар үзенеке генә икәнлеген белдереп шәрран яра яки бүтән берәр хәйләгә керешә.

Мәҗит инде уңнан-сулдан сайлый-сайлый, куш йодрыктай алмалар, помидорлар, өлгерүе, пешүе тәмам җиткән армутлар, шәфталылар, бүтән кирәк-яраклар белән ике сумкасын да тутырып, базардан чыгып барганда, кавын сатып торган абзый:

— Гөнайдын, бәй-әфәндем! Бусы бәндән сезә һәдия улсын! — диде дә бер кавынын Мәҗитнең ачык сумкасына очырды. Ягъни «Хәерле көн, морза-әфәндем, монысы миннән сезгә бүләк булсын!»

Бүләккә каршы бүләк бирү йоласы Төркиядә изге! Мәҗит бәй миңа карап башын чайкый-чайкый чарасыз елмайды да, сумкаларын асфальтка куеп, акча янчыгын чыгарырга мәҗбүр булды:

— Тәшәккер идәрем, монысы — миннән һәдиядер.

— Сау улыңыз, бәй-әфәндем, сау улыңыз!

Ярый әле сытылуы ихтимал алморт, шәфталылар минем кулда иде. Кавынчының исә бар кайгысы — сату, чөнки малы таудай өелгән, аны кире төяп кичен өенә алып кайтудан ни мәгънә? Теләсә ничек акчага әйләндерергә кирәк кавынны. Лирның атна саен бераз арзанаюы мөмкин, әмма ул бозылмый. Банкта сакласаң, яки тотрыклы валютага — доллар, маркага алыштырсаң, бигрәк тә оттырмаячаксың!

Базарда кием-салым да, безгә ияреп чыккан нәни Айбикәне мавыктырырлык уенчыклар, аквариумдагы берсеннән-берсе матуррак аллыгөлле озын канатлы, озын койрыклы балыклар, өреп тутырылган җиңел һава шарлары да бик күп. Шунда ук чыж-пыж нидер кыздыралар, пешерәләр — сатучылар һәм алучылар борычлы, сарымсаклы-суганлы, укроплы әче яки төче ризыклар ашап тора. Авылча гади киенгән бакчачылар, шәһәрчә көяз алып-сатарлар, «мин кем?!» дигән тәкәббер кыяфәттәге бизәнгән-ясанган яшьләр дә болгана монда. Шулай да базарда кеше бер-берсенә йомшак мөгамәләле, әдәпле, кайберәүләр инде, ахирәт дустын очратканмыни, әй чүкердәшә, әй ширбәт елгалары агыза! Баксаң, товар бәясенең йә чиреген, йә уннан берен төшерү максатында сайрашу икән бу.

Мәҗит — техника кешесе. Фирмасы машиналарын сатыр өчен гарәп илләренә дә баргалый, безнең КамАЗларны импортлау белән дә кызыксына. Китап та укымый түгел — шәхси китапханәсендә Төркия тарихына кагылышлы фәнни басмалар да, роман-хикәяләр дә бар. Артык күп түгел, чөнки төп игътибары, дәрт-дәрманы матди тормышны көйләүгә китә бугай. Сигез балага ата-анадан мираска әлләни калмый, һәммәсенә үз көчләре белән аякка басарга туры килә. Мәҗит инде бу җәһәттән шактый уңышка ирешкән, үзеннән өлкәнрәк кайбер авылдашларын әллә кайчан узып киткән — моны Измирдәге, Алашәһәрдәге һәм авылдагы кайберәүләр тормышы белән танышканда бик ачык күрдем һәм тойдым мин. Шуңа да карамастан, һавалану гадәте юк, киң күңелле, ярдәмчел. Аның яшь мөһаҗирләр Мөслах белән Раузага, аларның балаларына җылы мөнәсәбәте теләсә кемне сокландырырлык иде.

Мөслах, чыннан да, без кайтып җитүгә, Мәҗитләргә килеп керде. Бергәләп базарга бардык, табынга утырдык. Ул, билгеле, авылдашы ук килер дип фараз итмәгән. Күргәч шатлануы табигый иде. Чөнки ул әдәбият ярата, Казаннан күп кенә китаплар җыйнап кайткан, аларны укый гына түгел, «Идегәй» дастанын төрекчәгә дә тәрҗемә итә башлаган иде. Кытайда үскән татар төшенмәслек сүзләр анда хәтсез, сүзлеге юк, сорарга монда белдекле кешесе дә юк. Үзен туган телендә саф, камил сөйләшәм дип санаган Мәҗит, мин уенын-чынын бергә кушып, «сөйләшүең, чыннан да, татарчаны хәтерләтә», дигәч, башта миңа аптырап карап торды, аннары кычкырып көлеп җибәрде. Билгеле, ул татар телен-

әдәбиятын белү ягыннан Мөслахтан үзе генә өйрәнә ала иде. Менә шунлыктан, авылдашым ходайның һәр бирмеш көне Мәҗитләргә керә дә миннән сәгатьләр буе Совет иле тәртипләре, татар мәдәнияте дөньясы турында сорашып утырырга ияләнде. Якташы (Мөслахның бабалары Татарстанның Урта Балтай авылыннан) килгәч, бик уңайлы һәм рәхәт бит бу эш!

Беренче сыйныфта укый башлаган улы да — бу өйдә үз кеше, Бурҗы белән Айбикәнең уен иптәше, ә Рауза ханым төрекләрне кытай имчеләре шикелле дәваларга керешкән. Авырулар, докторның үз телефоны булмаганлыктан, гозерләрен Мәҗитләргә әйтә, Мәҗитләр исә аларга йә кабул итү шартын, вакытын аңлата, йә үтенечләрен тапшырырга вәгъдә бирә һәм, чыннан да, бу вәгъдәләрен бик төгәл, җиренә җиткереп үтәп баралар иде. Тиз арада шундый эшчәнлек җәелдерү яшь мөһаҗирләрнең тормыш алып бару мөмкинлеген шактый яхшыртуы бәхәссез.

Мин Мөслахларга — күрше йортларның берсендәге фатирга килеп кергәндә, алар монда инде бик күптән яшәгән төсле тәэсир калды. Җитмеш-сиксән квадрат метрлы торакта көн итәрлек бөтен нәрсә бар — идәнгә палас — келәм түшәлгән, тыйнак булса да, мебель тезеп куелган, табак-савыт, суыткыч, радио-телевизор, ванна бүлмәсендә су кайнарлату системасын күреп шатландым. Канализациясе дә төзек, тәмам шәһәрчә әйбәт көйләнгән һәм шактый арзанлы фатир иде бу.

— Милләттәшләр бик нык булышты,— диде Мөслах.— Югыйсә, чемодан белән генә килгән ике студентка бик читен булган булыр иде Измирдә.

Юкка гына: «Ил төкерсә, күл булыр», димиләр шул!

Без беренче көнне үк шәһәрдәге бүтән милләттәшләребез белән дә таныша башладык. Аларның берсе — Фәрит Йылмаз гаиләсе иде. 1934 елда Әфәнде Күпере авылында туган, аннары Гөрсу авылына күчеп яшәгән абзый ул. Измирдә тамыр җибәрүләренә дә егерме ел. Хуҗа кеше монда агач кисү, такта яру белән мәшгуль икән. Төркиядә яши башлаган татарларның өченче буыны исәпләнсә дә, теле — саф татарча.

Туган телне мондагы милләттәшләребезнең төрлесе төрле дәрәҗәдә саклый. Төрекчә кушып җибәрә яки бөтенләй төрекчә генә җавап кайтаручылар да бар. Соңгылары — шәһәрдә туып-үскән яшьләр инде. Фәрит абзыйның тотрыклылыгы, бердән, гомеренең төп өлешен татар авылларында уздыруы булса, икенче сәбәбен мин җырыбызга бәйләдем. Матур җырлый икән, туган җырын җуймаган кешедә өмет бар!

Фәрит Йылмазларга тиз арада якын-тирәдәге таныш татарлары җыйналды һәм без алар белән бергәләп кайнар, хуш исле чын каһвә эчә-эчә, Измир һәм Татарстан турында җанлы әңгәмәгә керештек. Алар мине җырларга да кыстады, мин яшелле-зәңгәрле тавышымны милләттәшләр хөрмәтенә яңгыратып алган да булыр идем, әмма көньякка килгәч кенә салкын тидереп, гел йөткереп-төчкереп утыргач, сирәк очрый торган «талантымны» ача алмадым. Измирлеләр четерекле хәлемне күреп, гафу иттеләр, мин моңсызрак кеше икәнлегемне фаш итүдән котылып калдым.

Мәҗит, ял көнен тулырак файдаланырга теләпме, шушы ук кичтә тагын бер милләттәшебез гаиләсе белән таныштырды мине — үзе белән бер фирмада эшләүче Нәҗати Якайларга да алып барды. Беренче көнне үк кеше саен йөрүне яхшысынмавымны белдергән идем, Мәҗит:

— Курыкма, бездә килешә ул,— диде.— Бервакыт туйга барырга дип урамга чыккан идем, бер танышым очрады. Кая юл тотуымны белгәч, үзен дә иярткүен үтенде. Минем икеләнүемне күргәч: «Борчылма, туй уздыручы хуҗа мине бик яхшы белә», диде. Киттек икәүләшеп. Барып кергәч, хуҗа кеше: «Ә бу юлдашың кем соң?» диде. Юлдашым, күзен дә йоммый: «Менә, менә, әйтүем хак булмадымыни, мине әнә ничек тиз танып алды», диде.

Бу юлы без туйга түгел, шулай да әрсезлек тормыш иткәндә ярап куя ул! Менә күрерсең, килүебезгә сөенерләр дә әле!

Нәҗати тимер коючы икән. Һөнәре керемле, ахры, биш катлы йортның бер почмагын алып торган фатиры иркен, бик шәп җиһазланган. Бала тәрбияләү, гаиләсен карау белән генә мәшгуль хатыны Назыймә ханым тиз арада табын әзерләде — аңа буй җиткән кызлары Нурхәят белән Нилген дә булышты. Нурхәят — адвокат, Нилген — математика укытучысы. Унҗидегә чыккан уллары Нәҗдәт тә университетка керергә әзерләнә.

Нәҗати — олпат кыяфәтле, сабыр-салмак холыклы, сүзгә ашыгып керешми торган зат. Назыймә ханым исә йөгрек акыллы, чая, телгә оста, Татарстанның тормыш дәрәҗәсе белән дә, гаиләбез белән дә кызыксына. Яшьләр Казан, аның мәдәни тормышы хакында сораулар бирә. Республикабызның театрлары, филармониясе, музейлары, һәйкәлләре, татар спектакльләренә, концертларына билетларның бер ай алдан сатылып куелуы, тамашачыларыбызның әдәби кичәләргә дә бик теләп йөрүен белү алар өчен зур яңалык. Гәзит-журналларыбызның, китапларыбызның киң таралуы, татарның укырга комарлыгын ишетү дә һәммәсенә ошый. Казан университетында, татар гимназияләрендә төрек теле укытыла башлавы, әлегә бу эш өчен мөгаллимнәр җитешмәвен сөйләвем һәм кызларны Казанда эшләргә, яшәргә чакыруым аларны таң калдыра:

— Бу эш, чынлап та, гамәлгә ашарлыкмыни? — дип сорау бирәләр.

СССР чигендә заманында тимер пәрдә корылу аркасында, ватан белән мөһаҗирләр элемтәсенең тәмам өзелеп бетүе күз алдында — аларга хәзер Татарстан турындагы теләсә кайсы хәбәр яңалык иде. Өйләрендә бер генә татар китабы, журналы яки гәзите юк. Төркиядә бөтен татарларны берләштергән җәмгыять 1955 елда оешса да, тарихи ватанында тәрбия алган буын картайганнан соң, инде күптән таркалган. Милли мәктәбе юк, «Азатлык» радиосының татарча тапшыруларын даими тыңлап яшәүне дә гадәткә кертмәгәннәр ичмаса, кайдан милли рух алырга тиеш бу Нурхәят, Нилген, Нәҗдәт кебек сөйкемле, әмма татарлыгын әкренләп җуеп барган яшьләр?

— Татарстан белән багланышлар юлга салыну, сезнең шушылай килеп торуыгыз безне кабат терелтер, ата-баба нигезенә мәхәббәтебезне яңадан дөрләтер, алла боерса,— ди Мәҗит.— Журналларыгызны җибәреп торыгыз, чыгымын үзебез күтәрербез, шулай ич, Нәҗати?

— Җибәрсеннәр. Безнең теш үтмәсә, балалар укыр,— ди өй хуҗасы.— Олыларга яңа әлифба өйрәнү кыенрак, әмма безнең балалар әзерлеклерәк ич.

— Утыз хәрефне ятлап алу әлләни кыен түгел инде,— дидем мин.

Яшьләр бу фикер белән килешә. Аларны алда әле башланмаган озын һәм сикәлтәле тормыш юлы көтә.

## САК-СОК ЯЗМЫШЫ

Иртәгесен тагын ялтырап кояшлы көн туды. Мин йокыдан уянганчы ук мәче кебек җиңел, йомшак атлап, мыек астыннан гына елмаеп йөрүче Назмый Сүзәр Мәҗитләргә килеп җиткән иде инде. Шушы атнада еллык ялына чыкканлыктан, мине татар авылы Гөрсуга ул алып барачак иде.

Ялда булса да, ниндидер йомышларын үтәр өчен без башта Назмыйның эш урынына — бензин колонкасына сугылдык. Назмый Измиргә килеп урнашкач ук шушында машина мае сатарга керешкән. Егерме ел буе өзлексез бер җирдә хезмәт иткәнлектән, аны монда һәркем белә, үз итә. Аның кунагы булганлыктан, миңа да хөрмәт күрсәттеләр — диспетчерләрнең берсе тиз генә каһвә кайнатты, һөнәремне, эшләгән җиремне, гомумән, «казан төрекләре» хәлен, тормыш-көнкүрешебезне сораша ба-

шлады. Төрекчә иркен укуыма һәм җиңел төшенүемә гамәлдә ышангач, диспетчер аеруча җанланып:

— Без — кардәшләр, бәй-әфәндем! — диде.— Казан төрекләрен күптәннән беләбез: хезмәтсөярләр, гаделләр, динлеләр. Илегездә генә камунислар дәһрилек таратмыш икән.

— Хәзер мәчетләр, мәдрәсәләр ачабыз, Коръән вә башка китаплар бастыра башладык,— дидем мин.

Татарстанда мәчетләр корырга, дини әдәбият нәшер итәргә керешүебез диспетчерне шулкадәр куандырачагын кем уйлаган! Ул гадәттән тыш сөенеп:

— Бәрәкалла, чук гүзәл! — дип балкып китте. Шундук өстәл тартмасыннан куен дәфтәре чаклы гына китап чыгарып: — Сез Сәет Нурсый хәзрәтне беләсезме? — дип сорады.

— «Күпрү» дәргесеннән аның хакында укыганым бар.

— Ә мин сезә аның вәгазьләрен һәдиә кылам,— диде диспетчер, әлеге китабын кунагына сузып.— Динсез төрек — төрек дәгел. Без — хак дин тотучы мөселманбыз, алланың иманлы бәндәләрейез, Сәет Нурсый хәзрәттәй, ислам дине терәге улмагыбыз лаземдер...

Диндар булмасам да, диспетчернең вәгазьгә охшаган гәпләрен, каһвә эчә-эчә, кызыксынып тыңлап утырдым. Хуплаган рәвештә: «Әвәт, әвәт» (әйе), дип тә куйгаладым, ә ул, иманымның чамалы икәнен сизгән сыман, ходайның илаһи кодрәте, адәм баласының ул кушкан юлдан гына йөрергә, ихлас гыйбадәт кылырга тиешлеге һәм башкалар, һәм бүтәннәр хакында сөйләвен дәвам итте, бензин колонкасы кәнсәсенең икенче катында Назмый нәүбәттәге намазын укып тәмамлаганчы, хак дин тотуның нинди зур бәхет һәм игелек икәнен төшендерде. Иманны әнә шулай ныгыткач, диспетчергә исәнлек-саулык теләп, ял көнне кунакка өенә килергә чакыруы өчен кат-кат рәхмәтләр әйтеп, юлга кузгалдык.

— Өйгә кагылып, хатыным Фәтхия белән улым Хәмзәне дә алып чыгыйк инде,— диде Назмый.— Алар да авылны күреп кайтырга булдылар.

Назмый тышкы кыяфәте безнең тугызлы «Жигули»гә охшаган «Дуган» җиңел машинасын ипле йөртә, хәрәкәт кайнап торган шәһәр үзәгеннән диңгез култыгының каршы ягындагы өенә шактый тиз алып кайтып житкерде. Төрек шоферлары, дәртле тәвәккәл, алдагы машиналарга тагылып диярлек чабалар. Урамнарда машина ташкыны исә көне-төне тынмый. Җәяүлеләргә юлны аркылы чыгу җиңел түгел, әмма алар да әрсез: әлеге ташкын арасында әз генә бушлык абайлануга, бисмилласын укып, теләгән тарафына кузгала. Артык кабаланмый, йөгерми, җай белән атлый. Шоферлар да аларга бездәгечә сүгенеп тупасланмый, тизлеген киметә яки җәяүлеләрне урабрак узарга тырыша.

Назмый Мәҗиттән сигез яшькә олырак, ләкин янәшә торганда да аның абый икәнлеге артык сизелми. Укымышлы энесе зуррак гәүдәле, мыеклы, фикер йөртү, гәп коруда үзен бәйсез, кыюрак тота. Ә Назмый аны тыйнак кына тыңлап утыра. Тик тормыш алып баруда ул һич тә төшеп калганнардан түгел. Өйләренә барып кергәч, мин моңа тагын бер кат ышандым. Җәмгысе бер йөз алтмыш квадрат метрлы фатирының һәр бүлмәсе бик әйбәт җиһазланган. Мебельләре затлы, келәмнәре йомшак, тәрәзә пәрдәләре күз явын алырлык матур бизәкле. Урын-җир, табак-савыт, суыткыч, телевизор һәм башка нәрсәләре житеш. Коридорлары киң, түшәме биек. Ваннаханәсенә кул юарга кергәч, мин аның зурлыгына хәйран калып, «нигә монысын зал итмәгәннәр икән?» дип уйладым. Бәдрәфнең икәү булуы да «сәерсендерде» — барин түгел ләбаса инде Назмый! Ә балконнан ачылган күренешләр нинди хозур: бер якта, кул сузымы җирдә — Каршыяка тавы күккә ашкан, икенче якта, шәһәр мәхәлләләре артында — дымсу сулышы сизелеп торган диңгез култыгы. Офыкның ул тарафы бик ерак, күгелҗемләнеп эреп, әллә кайда җиргә тоташа. Бишенче кат балконында ни тузан, ни чебен-черки юк — тәмле

ят ризыклар белән сыйлана-сыйлана утыр да тамаша кыл Измир күренешләрен, кардәш төрекләр тормышын! Күршедәге тәбәнәгрәк йортларның түбәләрендә көмешсу цистерналар тезелеп киткән — кайнар су әнә шуларда кояш җылысы белән җылытыла икән. Яссы түбәдә кер киптерергә баулар да сузылган. Әнә шундый берничә йорт артыннан без җилдереп кайткан олы юл уза. Тормыш сулышын, тибешен тоясың килсә, андагы ташкынны күзәтеп тор: шау-шуы монда кадәр килеп җитми, әмма хәрәкәт җанлылыгы бик ачык күзгә бәрелә. Шуңа карап, Төркиядә тормыш ритмы егерменче йөз ахырында инде Көнбатыш Европаныкына бик нык якынаюын чамаларга мөмкин.

Чәй касәләрен өстәл уртасына этеп, гаилә фотоальбомын актарырга керешәбез. Менә Фәтхия ханым баштанаяк традицион төрек киеменә төренеп төшкән, рәсемнән йөзе генә күренеп тора, анысы да кепка козырегы төсле алга бүлтәйгән яулыгы күләгәсендә. Ул соңгы дәвергәчә ярым күчмә тормышта яшәгән, очраклы рәвештә генә татар авылында тукталып калган йөрек кабиләсенең бер вәкиле. Яшь гаиләнең әүвәлге шатлыгы, беренче горурлыгы Фәридун — быел гына университетның хокук факультетын тәмамлаган егет. Уртанчы уллары Хәмзә каршыбызда утыра. Йөгерек күзле, балкып торган якты йөзле, җиңел сөякле, ни сорасаң да, «ярар» дип кенә торучы, әмма вәгъдәсен шундук онытучы бик сөйкемле, бик ягымлы егет. Әнә шундый ягымлы, сөйкемлелеге аркасында аңа үпкәләп тә, ачуланып та булмый! Ул хәзер Истанбул университетының икътисад факультетында өченче курста укый. Алай бөтенләй вәгъдәсез үк тә түгел инде ул: Румыйния татарлары белән дә кызыксынуымны белгәч, Күстәнҗә университеты студенты Ислам Мәтин адресын минуты белән язып бирде. Нәкъ менә Хәмзә ярдәмендә соңрак без Ислам белән таныштык, хатлар язышa башладык, шулай итеп Добруҗа татарларының Румыйниядәге өлешенә янә бер бәйләнеш җебе сузылды. Ләкин монысы — соңрак... Хәзер исә без фотоальбом актарабыз. Назмый белән Фәтхия ханымның өченче баласы — Фигән, быел Анкарада лицей тәмамлаган кыз. Назмый, ялгызы гына эшләсә дә, кызын да алга табан укытырга тели. Фәтхия ханым, Төркия хатын-кызларының йөздән җитмеше кебек, өен, гаиләсен карап, тәрбияләп тоту белән мәшгуль.

Коридордан сандугач чутылдаган сыман тавыш ишетелде. Телефон икән. Минем Казанда һәм илебезнең бүтән шәһәрләрендә фән докторлары, шактый дәрәҗәле түрәләр өенә кергәләгәнем бар, әмма Измир шәһәренең гади бер бензоколонкасында машина мае сатучы Назмыйның торагы аларныкыннан кысанрак, начаррак дип әйтә алмыйм. Киресенчә! Чит илдә хезмәт хакын, әйбер бәяләрен сорашуны өнәмиләр, ләкин мин кызыксынмый түзә алмадым.

— Бу йортны без, булачак күршеләр, кумәкләшеп төзеттек,— диде Назмый.— Минем фатир алтмыш миллион төрек лирына төште. Долларга күчерсәк, унөч мең чамасы.

Измир — җылы як, монда кышын кар ятмавын алдарак искәрткән идем инде. Шуңа күрә йорт диварларын бездәгедәй калын итеп саласы юк, бер кирпеч тә бик җитә, бары авырлыкны күтәрүгә генә чыдасын. Сууткәргечләрне дә тирән күмү хаҗәт түгел, җир туңмый. Җиңел-юка ишек, бер кат тәрәзә белән кышлау табигый. Кыскасы, йорт-җир кору монда бездәгедән шактый арзангарак төшә. Әмма шулай да Төркиядә һәркем Назмыйныкы шикелле әйбәт, иркен фатирлы түгел, билгеле. Әлегә илдә, алда әйткәнемчә, уртача айлык хезмәт хакы дүрт йөз доллар чамасы. Төркиядә гаиләләрнең күп балалы икәнлеген, хатын-кызларның өйдә генә кыштырдавын истә тотсак, әлеге керемне байтак өлешкә бүләргә туры килә, димәк, унөч мең долларны җыяр өчен озак еллар акчаны кысып тотарга мәҗбүрләр. Берәүләр шундый мая туплауга балалары кул арасына керә башлагач кына ирешә. Назмый исә тырышлыгы, кәсебендә егерме ел буе остаруы аркасында, хәзер аена 745 доллар ала.

Ел ахырында хуҗасы үз табышыннан өлеш чыгаргач исә, бу сумма соңгы дәвердә ике мең долларга җиткән. Аңлашыла ки, Төркиядә бик күпләрнең төшенә дә керми торган байлык бу. Шундый мөмкинлек ачылмаса, өч баласын да түләүле уку йортларында укытып яткан Назмый әле тиз генә югарыда сурәтләнгән фатирына ия була алмас иде.

Назмыйның керемен аныклагач, мин инде фатирның иркенлеген, әйбәт җиһазлануын бик табигый бер нәрсә итеп кабул иттем. Әмма шулай да гаҗәпсендергән бер як табылды — майлы буяу белән киндергә төшерелгән картиналар. Аларның берсендә — чәчәкләр, икенчесендә — табигать күренеше сурәтләнгән иде. Соңгысы аеруча үзенчәлекле: алгы планда — чинар агачы ышыгында утырган ялгыз йорт. Арттарак — яшеллек каплаган үрләр. Ә иң еракта — очлы түбәле күксел таулар. Табигатьнең мәһабәтлеге, төрлелеге, адәм баласының шул табигать кочагында тыныч-имин гомер сөрүе, мизгел һәм мәңгелек бәйләнеше — бу картинага бик күп фикерләр салынган иде. Шагыйранә хисләр дә уята иде бу рәсем. Көне буе бензоколонкада, машина, керосин-бензин, майлар арасында кайнашкан, өй хуҗалыгын алып баруны хатынына тапшырган кеше эштән соң, гадәттә, диванга кырын ятып телевизор карый, гәзит укый яки ишегалдында гәп сата, сыраханәләр тирәсендә бөтерелә. Инде бер дә булмаса, арзанлы кәгазь плакат, календарь-фәлән: бездә — берәр гүзәлкәйнең ярым шәрә сурәтен, Төркиядә — атаклы берәр мәчет рәсемен алып кайтып диварга ябыштырып куюны да аңларга мөмкин булыр иде. Ә монда... Тукта, йөрек кабиләсеннән килә торган романтика түгел микән бу?

Назмый көлемсерәп, соравыма сорау белән җавап бирде:

— Сурәтнең берәр җитешсез җире бармы әллә?

— Әйбәт рәсем, миңа бик ошый.

— Буш вакытымда шуларны ясап ял итәм мин. Йә журналдан карап, йә табигатьтән күчереп.

— Башка картиналарың да бармы?

— Әйе. Туганнарыма да ясап биргәләдем.

Менә сиңа сигез сыйныф белемле бензин, май сатучы! Мин ул картиналарны профессиональ сурәтче иҗат итүенә һич тә шикләнмәгән идем.

Авторының кемлеге беленгәч, картиналарны тагын да җентеклébрәк тамаша кылдым: әле ерактан, әле якыннан, әле турыдан, әле яннан! Билгеле, белгечнең алардан кимчелек табуы да бик ихтимал, әмма мин бу сурәтләрне һич тә халтура дип исәпли алмадым. Тиешле җирдә укып, өйрәнеп, үзен бары шундый иҗатка гына багышласа, нинди уңышларга ирешкән булыр иде икән бу Назмый? Ә ул шәһәрдән авылга, авылдан шәһәргә йөреп сәүдә итә — табигать биргән сәнгати сәләтен арып-талып төп эшеннән бушаганнан соң гына файдаланырга мәҗбүр!

Ерак юлга чыгар алдыннан Назмый «Дуган»ны тагын бер кат күздән кичерде, мотор тавышына колак салып торып, аннан ниндидер җитешсезлек тапты, капотын ачып, кайсыдыр шөреп-гайкаларын боргалады. Машина — Мәҗитнеке, «аксөяк» хуҗа аны тиешенчә үк карап тотмый иде, ахры. Назмый инде ваемсызлыкны күтәрми, алны-артны кайгыртып йөрү канына сеңгән икән.

Бара торган юлыбыз тигез, киң.

— Анкара асфальты,— диде Назмый кыска гына.

Минем юл буенда күренеп калган шәһәрләр, авыллар турында күбрәк беләсем килә, әмма Назмый бар игътибарын машина йөртүгә биргәнгәме, әллә гид булырга белеме җитмәгәнгәме, сүзгә һич тә җәелеп китмәде. Хәмзәнең инде мәгълүматы чикле иде, шуңа күрә үзе дә ялтйолт каранып кына барды. Фәтхия ханым исә җыен ирләр арасында гәп корып «затсызлануны» килештереп бетерми иде, ахры.

Алтмышынчы-җитмешенче елларда Совет матбугаты Төркиядә әйбәт асфальт юллар салуны да гаеп итеп күп язды, бу эшне хәтта СССРга

каршы дошманлык дип күрсәтүдән дә тартынмады: имеш, аларны НАТО хәрби максатта, төньяк күршегә хәвеф тудыру ниятендә төзи! Дүрт күз белән тамаша кылам — юлда ник бер танк, туп, хәрби машина очрасын. Кирпеч, он-ярма, цемент капчыклары, әрҗә-әрҗә җиләк-җимеш, ташкүмер, төрле-төрле бүтән чимал, товар төягән йөк машиналары, тәгәрмәчле тракторлар, җиңел машиналар һәм мотоцикллар, ишәк яки ат җигелгән бер күчәрле арбалар агыла. Халкы өч миллионнан ашкан Измирне халкы дүрт миллионнан ашкан Анкара — ил башкаласы белән тоташтырган асфальт юлда хәрәкәт бик көчле, чөнки аның буенда дистәләгән бүтән зур шәһәрләр, йөзләгән авыллар да утыра ич әле. Төркиянең көнбатышына кергән бу төбәктә халык тыгызрак урнашкан, авыл хуҗалыгы да нык үскән, фабрикалар да бик күп, турист кәсепханәләре дә гаҗәп тиз үрчи. Юллар теге яки бу мәмләкәтнең икътисади үсеш, мәдәни алга китеш дәрәҗәсен бик ачык күрсәтә. Шөкер, бу җәһәттән көньяк күршебез чын мәгънәсендә әйбәт тәэсир калдыра. Юллары уңайлы дип әйтү генә аз, аңа хезмәт күрсәткән бензоколонкаларда, автовокзалларда ягулык та, запчастьлар да, агымдагы юу-төзәтү эшләрен башкаручы остаханәләр дә, мөсафирларга уңайлыклар гарантияләгән ашханә-каһвәханә, кибетләр дә даими эшләп тора. Юлаучылар, «билет ала алмам, урын булмас», дип, шоферлар, «ягулык табалмам», дип хәвефләнми. Пассажирлар агымы артса, автобус рейсләре көне белән күбәйтелә, чөнки моның өчен рөхсәтне, бездәге шикелле, әллә кайдагы фәлән түрәдән сорап җәфаланасы юк — хуҗа үзе яки фирма вәкиле хәл итә. Юлаучылар күбәюенә ул бары куана гына — кереме артачак.

Измирне чыккач озак та бармадык, юлның ике ягында да берничә гектар җирне каплап алган кызыл кирпеч өемнәрен күреп гаҗәпләндем.

— Алучы юк,— диде Назмый саран гына.

Коры җирнең алтыдан бер өлешен биләсәк тә, балчыктан яндырылган шушы нәрсә Советлар илендә гел дефицит саналды бит. Кирпеч сугарга балчык җитмимени, Мәскәүдә минем белән ике ел буе Югары әдәби курсларда бергә укыган урыс язучылары: «АКШка Аляскаы сатып харап булдык», дип көн саен яшь койды. Хикмәт җир, балчык күплектәмени? Барны файдалана белүдә ул! Мин инде американнарның Аляскада — мәңгелек туңлыкта берән-сәрән яшәүче эскимос торакларына кадәр кайнар су үткәрүләрен тәфсилләп язып тормыйм, «мәдәни» халык аны җылы Краснодар краенда да күпчелек урында һаман тәэмин итә алмый ич әле.

Ул арада без Гәдиз елгасы үзәнлегенә килеп кердек. Иген кырлары, бакчалар башланды. Тәгәрмәчле трактор арбаларына кавын-карбызлар төялгән, ияләре аларны юл буе:

— Татып багың: иң татлысы, иң очсызы! — дип мактый-мактый сатып бара. Бер-икене генә теләгән Назмыйга бакчачы абзый шактый күбрәкне алдыртты. Үскән җирендә беркадәр арзанрак икән шул.

Кәмалпаша, Тургутлы, Әхмәтле, Салихлы калаларын уздык та олы юлдан кечесенә борылдык. Үзәнлек тарайды, аны ике яктан чикләп торган калкулыклар юлга якынрак елышты. Тимер юлны көньякка аша чыккач, тар асфальт безне бөтенләй кукуруз кырлары, йөземлекләр арасына алып кереп китте. Ачык һавада табын корып, ял итәргә урын күзләп барган Назмый «Дуган»ын бер чишмә буена, чинар күләгәсенә туктатты. Су җирдән метр ярым чамасы калкып торган таш дивар эченнән — чуен торбадан агып тора, юл уңаена ике якка сузылган бетон улакларны яртылаш тутыра да аннан тут агачлары тезелешеп киткән үз юлыннан Гәдизгә таба йөгерә иде. Һава эссе, туфрак коп-коры булып кипкән, елның бу фасылында су, әлбәттә, ерак китми җиргә сеңеп бетәдер. Улакларның мал-туар эчәргә көйләнүе күренә. Эштән иренми торган Назмый шундук нинлидер калай калак табып, әлеге улакларны тазартырга — кукуруз кыяклары, тут, чинар яфракларыннан, ләмнән

арындырырга керeште, аннары юынды-пакъланды һәм кукуруз кыры чигендә үскән биек чинарның куе ябалдашы күләгәсендә намазга оеп алды. Ул арада Фәтхия ханым өйдән махсус алып чыккан нигъмәтләрен чирәм өстенә җәйгән ашъяулыкка тезә башлады. Яшелчә, җиләк-җимеш янына чүпрә белән әчетеп, кабартып пешергән күмәч туралды, касәләргә термостан кайнар чәй агызылды. Төркиядә ипи белән күмәчнең бик яхшы сыйфатлы, тәмле итеп пешерелүен аерым искәртәсем килә. Мин инде илебезнең байтак тарафларында, кайбер чит мәмләкәтләрдә дә булдым, әмма мондый хуш исле һәм йомшакны, әйбәтне сирәк очраттым. Бездә авылларда кабартып үз мичләрендә пешергәлиләр, ләкин хәзер инде анда да халык казна ризыгына күчеп бетеп бара, бугай.

Ә менә чишмә суы Татарстанныкына җитми икән. Бездә ул боздай салкын, әллә ничә төрле файдалы матдәләр, тозлар эрегәнлектән, тәмлерәк һәм шифалырак! Хәер, Төркия зур, аның чишмә сулары да төрле-төрледер.

Тамак ялгап, хушланып алганнан соң сәфәребезне дәвам иттердек. «Дуган» җимеш агачлары арасыннан — яшел чатыр астыннан елдам йөгерә, беркадәр Урта Азияне хәтерләткән табигатьне тамаша кылып бару, әлбәттә, хозур иде. Әнә шулай без Алашәһәрне узып киттек, аннары бераздан көнчыгышка, авыл юлына борылып кердек. Һаваның эсселеге, җирнең дымга сусавы шунда гына ап-ачык беленде — артыбызда, асфальттан аерылгач ук, мул гына тузан болыты бөркелеп күтәрелде. Унда биек, төз байтирәкләр, армурт, инҗир, купшы тут агачлары ышыгына сыенган төрек авылы калды, ярлары киң, әмма төбендә чыпчык эчәрлек тә су акмаган коры елганы кичтек һәм кеше биеклеге үскән бөрлегән куаклары арасыннан Гөрсу (Каракуа) авылына килеп кердек.

Милләттәшләребезнең бер өлеше үткән йөз ахырында Төркиягә күчеп килгәч, Күтәһия виләятенең Гәдиз илчәсенә (безнеңчә — район) кергән Әфәнде Күпере авылына нигез салганнар. Тора-бара алар күбәйгәннәр, җир, аннан да бигрәк, су кытлыгы сизелә башлаган. шуннан соң инде тынгысызрак җаннар башка чыгар өчен уңдырышлырак, дымга баерак һәм иркенрәк җир эзләргә тотынганнар һәм 1954 елда Әфәнде Күпереннән йөз егерме чакрымнар чамасы көньяк-көнбатыштарак шушы үзәнлектә тамыр җибәрерлек урын тапканнар.

Гөрсу «Т» хәрефе рәвешендәге ике урамнан гыйбарәт утыз йортлы авыл икән. Өйләр, абзар-куралар монда саман кирпечтән салынган, күпчелеге тыштан акшарланган. Җәлпәк түбәләре — чирәптән. Коймалары да саманнан, таштан өелгән, урам ягында рәшәткәдән корылганнары да бар. Урамнарында яшеллек күп түгел, өйалды бакчалары да сирәк күренә, койма буйларындагы чирәм инде күптән саргаеп, кибеп беткән. Урам уртасыннан саргылт такыр юл уза. Авылның бердәнбер матуррак, төзегрәк бинасы — мәчет. Манарасы аңа аерым бер купшылык, көязлек бирeп тора.

Без кайткан йорт бикле — Назмыйның бажасы бөтен гаиләсе белән кырда булып чыкты. Күршеләр өйрәтеп җибәргән сукмактан басуда йөзем киптерүче хуҗаларны эзләп киттек. Бакчаларында яки шуларга ялганып киткән кырларында матавыкланып йөргән милләттәшләребезнең әле берсе, әле икенчесе, кемне эзләвебезне ачыклагач, безгә Баһаветдин Чәлекнең кай тарафта икәнлеген кычкырып күрсәтеп, адашмый барырга ярдәм итеп тордылар. Кызык: сукмагыбыз әле бер, әле икенче хуҗаның шәхси биләмәсе аркылы уза. Байтирәкләр «коймасын», бөрлегәннәр «бакчасын» уздык. Җире коры булса да, сазлыктагы шикелле йомшак түмгәкләргә дә басып атладык — яңгырлы айларда уйсулыкта күл хасил була, ахры. Бөрлегәннәр әллә иясез, әллә алар монда бик күп — җиләкләре бүгенгәчә пешеп утыра, җыючы табылмаган.

— Гөрсуда балалар әз хәзер, — диде Назмый. — Яшьләр шәһәргә күчеп китә. Шунлыктан йорт-җирне карап тотуга да игътибар кимегән.

Кемгә дип янартырга, янәсе, барыбер әрәм булып калыр. Элек монда җанлырак, күңеллерәк иде.

Ниһаять, Назмыйны, Фәтхия белән Хәмзәне хуҗалар танып алды, зур мәйданга полиэтилен җәеп, шунда йөзем киптереп — аны таратып, чүбен чүпләп йөргән җирләреннән күтәрелеп, аргы баштан безгә таба килә башладылар.

Татар авылы икәнлеге сизелә шул — хатын-кызлары, төрекләр кебек, баштанаяк чүпрәккә төренмәгән. Йөзләре ачык, буй житкән Үлия Хәмзә абыйсының муенына ук килеп асылынды, үбешеп күрештеләр. Балачактан дуслардыр, мөгаен. Буй җиткән, дисәм дә, кызга әле нибары ундүрт кенә яшь икән. Көньякта алар әнә шулай тиз үсә-җитлегә.

Бөтен кыяфәте белән безнең авыл агаен хәтерләткән Баһаветдин, кул биреп күрешкәч һәм танышкач:

— Без менә шушында көн күрәбез инде,— диде.— Татарга охшаганмы соң без? Эссе монда, әмма кызуның сүрелгәнрәк ае хәзер. Бүген күктә бер болыт әсәре дә күренде әле, яңгыр яумагае, дип, йөземне каплап куярга әзерләнеп маташабыз.

Аларга күршеләре дә булышып йөри икән — кунакның ерактагы тарихи ватаннан килүен ишеткәч, барысы да бергә җыйналды. Сорашу, күңелле гөрләшү китте. Бераз гәп корып торганнан соң, җиләге җыеп алынган йөземлекне карап чыктым. Баһаветдин инде аны кышка әзерләү белән мәшгуль икән: картайган ботакларын кисеп ташлый, кышлыйсыларын, бәйдән чишеп, җиргә яткыра. Йөземчелек, аннан көтелгән керем, хуҗалык итү серләре хакында сорашуыма, көлемсерәп:

— Элек арпа, көнбагыш кебек игеннәр иктек,— диде.— Мамык та үстереп карадык. Мамыктан баемадык, арпа Татарстанда да үсәдер, дөньяга йөзем кирәгрәктер, дип уйладык. Татып карагыз әле: әнә нинди баллы, гәрәбәдәй коңгырт-сары, эре ул!

Авыз итеп карыйм: чыннан да, ифрат татлы, тешсез җимеш икән.

Баһаветдинның көпчәкле тракторы бар, ул аны хәзер кырдан йөк ташуга көйләгән — артына беркетелгән биш-алты капчык әйбер сыешлы калай әрҗәсенә кибеп өлгергән җимеш тутырылган. Күнегелгән гадәт буенча, сәгать ничәдә эшкә бару-кайту хакында да сорашам. Баһаветдин тагын көлемсери:

— Кайчан телибез, шул чакта,— ди.— Дәүләткә уңыштан салым түләгәч, бездә берәүнең дә эше юк. Теләсәң — эшлә, теләмәсәң — түшәмгә төкереп ят.

Әмма Гөрсудагы милләттәшләребез андый хөрәсәннәрдән түгел, әлбәттә. Сату өчен товарлыклы йөзем үстерүдән тыш, алар үзләре өчен дә еллык яшелчәсен, җиләк-җимешен әзерли, терлек тә асрый. Тормыш дәрәҗәләре төрлесенеке төрлечә. 1954 елда монда килеп урнашканда өлкән буын күпме җир алып өлгерүенә, шуның хисабына ничә җан көн күрүенә бәйле. Баһаветдиннең яшьтәше Әхмәт Зәки Атасевәр өч баласы, хатыны, әнисе белән бергә Күтаһия каласында яшиләр, җәен Гөрсуда унбер гектар йөзем үстерәләр. Хәйретдин Кыяк гаиләсендә — алты җан, җир биләмәсе — егерме өч гектар. Эш аеруча күп чакта ул кеше ялларга мәҗбүр икән. Баһаветдиннең исә биләмәсе кечерәк, йөзем сатудан ул, елына карап, өч-дүрт йөз доллар керем ала. Моны бүгенге Төркия шартларында күп дип әйтеп булмый, шунлыктан аңа бүтән кәсепкә дә керешергә туры килә. Кызлары Хәтиҗә белән Үлияне, улы Назыйфны укытыр өчен, моннан унсигез чакрымдагы Алашәһәргә барып йорт салган. Балалары каникулларын гына авылда уздыра, хатыны белән үзе ел дәвамында Гөрсу белән Алашәһәр арасын таптый: тегендә дә, монда да иренмәгән кешегә эш табылып кына тора.

Кайту уңаенда без аларның Алашәһәрдәге өйләренә дә кереп чыктык. Аның әле беренче каты гына әзер — иркен залы, йокы бүлмәсе, ашханәсе, коридоры, бәдрәфе һәм ваннаханәсе инде матур гына җиһазланган. Баскычтан икенче катка күтәрелдек — анда әле төзелеш мәйданы

гына иде: диварның арматура чыбыклары, моржа һәм вентиляция торбасы югарыга дәвам итүне көтеп, идәннән шактый калкып тора. Беренче катта исә кайнар суга чаклы бар, яши бир!

— Исән булсак, быелгы йөзем акчасына тагын кирпеч алачакбыз,— диде Баһаветдин.

Алар керемнәрен тиененә кадәр исәпләп, башта җир сатып алырга мая туплаганнар, аннары — нигез салырга, беренче катны өяргә, аның түшәмен түшәргә, бүлмәләр бүләргә... Ел саен әнә шулай өлешләп башкаралар эшне. Икенче катны җиткереп бетергәндә кызларны кияүгә бирер, улларын өйләндерер вакыт якынлашыр — туй ясарга әзерләнергә кирәк булыр. Гаилә тормышы көйле аксын өчен, хезмәтне кызганмау, тапканны саклап тоту хаҗәт.

— Безнең Гайнелхәят әби Төркиягә Идел буендагы Керкәле авылыннан күчеп килгән, бабабыз Мостафа да шул яктан. Кайтып күрәсе килә ата-баба җирен, әмма бик кыйбатка төшәчәк шул ул сәфәр,— диде Баһаветдин.

Гөрсудагы җылы һава, уңдырышлы туфрак, озын җәй, әгәр явымтөшем дә мулрак булса, рәхәт һәм иркен яшәргә тулы мөмкинлек бирер иде. Дым җитми. Артезиан коесы казыткан булган Баһаветдин, тик хәзер аннан су чыкмый башлаган. Күршеләрнеке дә корыган. Авылда хәзер ике кое гына эчәргә яраклы су бирә икән. Алардан сугарып кына теләгән кадәр яшелчә үстерү мөмкин түгел. Тирәнрәк яңа коелар казыту исә шактый чыгым сорый.

Үлия безне авыл кырыендагы якын бакчага, ашар өчен җиләге махсус җыелмый тотылган йөземлеккә алып китте. Юл уңаенда без йәнә бер оҗмах җимеше — кыргый хөрмә белән сыйландык. Ул — баллы, әмма бик коры, авызда он кебек таралып аңкауларга ябыша — тиз сусата.

Йөземлек куе, чук-чук тәлгәшләре кошлар чүпләмәслек итеп яфраклар ешлыгында, аскы ботакларда калдырылган икән. Бер табак йөземне Хәмзәгә тоттырып кайтарып җибәргәч, Назмый миңа Гөрсуны күрсәтүен дәвам итте. Аркылы урамнан бераз бардык та тыкрыктан басуга атладык. Монда йөзем бакчалары, терлек кермәсен өчен, тирән чокыр белән киртәләнгән иде. Авыл башына чыккач, бер тар басмадан без иясен белмәгән йөземлеккә аяк бастык. Аның юл кырыендагы тарафында алмагач шикелле биек агачлар үсә, аларның өске ботакларында алсу җимешләре дә хәтсез иде. Назмый аларны үрелеп өзеп, берсен миңа сузды да:

— Авыз ит, инжир бу,— диде.

Кипкәнен беләбез, күз алдында агачтан өзелгәнен татып карау бәхете күпләргә эләкми. Пешкән армуттан да йомшаграк, искиткеч татлы, гел шикәрдән генә тора диярлек икән. Бераз гына әчкелтем тәме дә бар.

Шулчак яныбызга бер абзый якынлашты. Кечкенә авылга кунак килү, җитмәсә, шундый ерактан килү хәбәре сәгате-минуты белән таралып өлгерә, бу абзый да безнең белән аулакта танышырга ашыккандыр инде, дип уйлыйм. Назмый күңелле исәнләште, мин дә аңа кушылдым. Аннары хуш күңеллелек, юмартлык күрсәтеп:

— Әйдәгез, абзый, сез дә сыйланыгыз! — дидек.

Абзый кеше тыйнак кына көлемсерәп:

— Сыйланыгыз, сыйлан, минем агачлар бу! — диде.

Колхозның күмәк малына күнегеп, Татарстан авылында үскән сәяхәтче аны-моны уйлап торамыни инде? Ә Назмыйга ваемлау кирәк иде, ваемлау!

Бөккән ботакларыбыз үзеннән-үзе ычкынды, кулдагы җимешләрне кая куярга белми, бала-чага кебек:

— Юл буенда үскәч, без аны...

— Без аны уртак малдыр дип уйлаган идек! — дидек.

— Зыян юк. Кем агачы икәнен белсәләр дә, аскы ботакларын балачага үз итте инде аның. Безгә өстәге җимешләре бераз калыр әле.

Бурның олысы ни дә, кечесе ни? Гафу үтенеп, ят биләмәдән чыгып китәргә туры килде!

Өйгә кайтканда ике гөнаһлы бәндә мәчеткә кагылырга булдык. Әле намаз вакыты җитмәгәнлектән, ул бикле иде. Акычы шунда гына эленеп тора икән, ачып эченә кердек. Иркен, салкынча гыйбадәт залы. Идәненә паласлар, келәмнәр түшәлгән, түрендә Коръәннәр, төрле догалыклар тезеп куелган шүрлек тора. Диварына мөселман календаре ябыштырылган. Тыныч, таза, пакь бина. Төркиягә күчеп киткән милләттәшләребезнең бер өмете акланган — алар диннән язмаганнар. Моның игелекле йогынтысына шикләнмәскә мөмкин — мин Госманлы җирендә гел әхлаклы милләттәшләребез белән генә очраштым.

Кичен Баһаветдиннәргә мөсафир белән күрешер өчен күршеләре керде — мин мондагы, алар Татарстандагы тормышны сорашты.

— Әтием Хәйрулла Төркиягә үндүрт яшендә килгән,— диде Хәйретдин Кыяк.— Аның атасы — Насыйбулла, Насыйбулла атасы — Мотыйгулла Иштирәк авылыннан чыкканнар. Әткәй бер ел урысча да укыган булган. Күчмән татарларны монда хөкүмәт хезмәткәрләре дә, күрше төрек авыллары халкы да яраткан, без дә тату яшибез. Салымнарны вакытында түләгәнгә, һөнәрле булганга, безне «дөрес фигыльле, күркәм гадәтле» дип, ошатканнар.

Өлкәннәр белән гәп корып утырганда, бүлмәгә шәһәрчәрәк киенгән ике егет килеп керде. Аларның өлкәне үзен:

— Мәхмәт Вәли Аксу,— дип таныштырды.

Без инде элегрәк хат алышкан булганлыктан, кочаклашып күрештек. Мәхмәт (Мөхәммәт) Анкарада, Хаҗитәпә университетының химия факультетында өченче курста укый, ул былтыр редакциябезгә «Казан утлары»на Төркиядә язылу тәртибен сорашып мөрәҗәгать иткән иде. Хәзер ул авылда каникулда икән. Хатындагы адрес буенча, мин аны Күтәһия шәһәрендә яшидер, дип уйлаган, аңа дип татарча китаплар да алып килгән, Мөхәммәтне әлеге калада эзләп табарга ниятләгән идем.

Мөхәммәт белән әңгәмәбез аеруча җанлы ялганып киткәч, бүтәннәр колак салып кына утырырга мәҗбүр булды. Бу, мөгаен, аларга ошап җитмәгәндер, шул ук вакыт алар алдында без дә әңгәмәдә бик тирәнгә кереп китә алмадык. Кунаклар сирәгәйгәч һәм төнге сәгать унбер тулгач, иркенләп гәп корыр өчен, Мөхәммәт мине үзләренә чакырды.

Аларда инде без киңрәк дөнья — Күтәһия, Анкара, Төркиядәге милләттәшләребез язмышы, Идел-Уралдагы хәлләр, милли матбугатыбыз, әдәбиятыбыз-сәнгатебез хакында гәпкә чумдык. Күбрәк Мөхәммәт сорашты, миңа җавап бирергә туры килде. Баһаветдин әллә ничә мәртәбә мине алырга килеп тәрәзә чиртте, әмма Аксулардагы әңгәмә таң сызылганчы өзелмәде. Үз милләте белән шулкадәр тирән кызыксынган егетне минем Татарстанда инде күптән очратканым юк иде. Аңлашыла ки, үз халкың арасында яшәгәндә кызыксыну ансатрак басыла — күп нәрсәне күреп, белеп үсәсең, матбугаты, радио-телевидениесе, театрлары да ярдәмгә килә. Ә чит илдә үскән татарга боларның берсе дә эләкми. Җитмәсә, Төркиядәге татар авылларының өлкән буыны — укымышсыз, хәзер инде өлкән саналганнарның да, шушында туып-үскәнлектән, ватаннан да, туган мәдәнияттән дә хәбәрләре чамалы. Шунлыктандыр, Мөхәммәт Аксу егерме биш яше тулганчы белә алмаган, әмма белергә теләгән байтак нәрсәне миннән ачыклап калырга ашкына иде.

Татарстанга ничек барырга? Кесә такырлыктан, энесе университетта укуын өзәргә мәҗбүр, очкыч белән Казанга юл тотуны уйлыйсы да юк. Мөмкин булса, Казанда белгечлеге буенча практика узар, бәлки әле яшәп тә калыр иде. Татарстанда туган телдә югары белем алырга мөмкинме? Милли театрыбыз шулай данлымыни? Рәссамнарыбыз, композиторларыбыз да бармы? Бөтен татар журналларын алып торасы иде, ул инде хәзер кирилл хәрефләрен дә таный ич...

Эре гәүдәле, киң маңгайлы, тарихи ватаны, туган халкы белән шулкадәр тирән кызыксынучы бу егет мине Төркиядәге татар яшьләренең дә киләчәктә төрек диңгезендә эреп бетмәячәгенә, милли аңы уянагына өметләндерде. Ләкин бу эшнең кочәюенә Татарстанның ныклы өлеш кертүе кирәк. Татар диаспорасы вәкилләрен Казанга чакыру, мәдәниятебез эшлеклеләренең чит мәмләкәтләргә барып, милләттәшләребез белән аралашуы башланды, бу эшкә «Ватан» җәмгыятенең алынуы сөендерә. Ләкин әлегә бәйләнешләребез бик-бик зәгыйфь.

Илдән күчеп килгән беренче буын Гөрсуда инде күптән дөнья куйган. Авылның иң өлкән кешесе Зәүҗан әби белән мин монда килүемнең икенче көнендә очраштым. Без җилкапканы ачып кергәндә ул болдырда утыра, йон җебе эрләп әвәрә килә иде. Яланбаш, ситса күлмәктән, озын балаклы ыштаннан, киез катадан. Чәче — көлсу, маңгае — җыерчыклы, әмма хәтере әйбәт икән. Теле — саф татарча. Кәефе барда шаяртып алырга да булдыра.

— Исәнме, әби? Картлыкка бирешмибезме?

— Шөкер, балам, картлыгым яшьлеккә тиң,— диде ул көлемсерәп.— Яшьлектәге көчем картайгач та тулысынча сакланып калды.

— Бәрәкалла! Ә син моны исбатлый аласыңмы соң?

— Алам, бик алам. Әнә тегендә, лапаста, бер зур таш киле тора. Яшьлегемдә ничек кенә тырышсам да, мин аны урыныннан кузгата алмый торган идем. Хәзер дә шулай — никадәр маташсам да, аны борып та куя алмыйм. Димәк, көчем һаман элеккечә калган инде, шөкер.

Аның шундый көр күңелле булуына сөенеп, мин сорауларымны бирергә, бик еракта калган елларны ачыкларга керештем.

— Мин, балам, 1904 елда Күтәһия шәһәрендә туганмын,— дип дәвам итте ул сүзен.— Ул чакта ук шәһәрдә татарлар күп иде инде. Идел буеннан күчеп килүчеләр. Алар башта авылларга барып урнашкан, аннары әкренләп Күтәһиядә тупланырга керешкәннәр. Әнкәем Зөбәрҗәт белән әткәем Миңлекәй — Чүти авылыннан. Әнкәемнең әнисе Җәүһәр, әтисе Миңлехәер, әткәемнең әтисе Мияссәр дә төп Чүти кешеләре... Әнием ягыннан әби-бабам җиде бала үстергәннәр. Аларның нәселе илдә әле дә яши торгандыр. Чүти (хәзер Татарстанның Кайбыч районына керә.— Т. Ә.) авылында аларны беләләрдер, әтием Миңлекәй заманында анда кибет тоткан. Төркиягә диңгез аша Миңлекәй белән Зөбәрҗәт күчеп килгән, әүвәл Мәрсиндә тукталганнар, аннары шуннан ерак түгел Адана шәһәренә барып сыенганнар. Төркиянең дә көньягында, Ак (Урта — Т. Ә.) диңгез буенда, Кибрис утравына яп-якын икән болар. Җылы як. Әмма монда борчаклары пешмәгән, ахры, Күтәһия тарткан үзләрен. Бәлкем татар күп җирдә яшиселәре килгәндер. Минем яшьлегем Күтәһиядә узды инде. Аннары егерме тулганда Әфәнде Күпере егете Миңнехаҗига кияүгә чыктым. Каенанам Вазифа белән каенатам Миңнәхмәт Шөгердән иде, алар монда Кырым аша килгән булган... Чикләр ябылганчы, илкәйдән туганнарыбыз өзелмәгән. Әти-әни, каенатам белән каенанам да туган-үскән җирләрен сагыналар, безгә шуны гел искә төшереп сөйлиләр иде. Әмма, бердән, тормыш басты, икенчедән, юл ерак, чыгымлы, күпме сагышлансалар да, Чүтине бер кайтып күрә алмадылар. Урманлы, болынлы, чишмәле як булган икән... Әткәем монда тегү тектте, әнкәем дә кул эшенә оста иде. Татар халкы һөнәрле бит ул. Ике күчәрле арбаны Төркиядә «татар арбасы» диләр, аны монда безнекеләр алып килгән. Элек Төркиядә зәйтүн үсә, сәнагать (промышленность) юк иде. Әфәнде Күперендә без борчак, бодай, ясмык, солы, тары, бүтән игеннәр игә идек, төрле яшелчәләр дә үстерә башладык, гомер буе шушында яшәгән төрекләрне шундый эшләрдә узып киттек, хәлләндек. Бәрәңге, кишер, чөгендерләр чәчтек, мал асрадык. Күрше авыл төрекләре кырларыбызны-бакчаларыбызны, йорт-кураларыбызны таң калып карап йөриләр иде. Аннары, бездән күреп, алар да игенчелек, яшелчәчелекне күбрәк фәһемли башладылар... Ирем Миңнехаҗи Кумҗы зиһенле, хәтер-

ле кеше иде. Тату яшәп, җиде бала үстердек, аларның алтысы бүген дә исән, һәркайсының үз гаиләсе бар. Өлкәне алтмыш алтыда, Искешәһәрдә гомер итә. Берсе — Измирдә, икенчесе — Согуд Гарәбестанында, Мәдинә шәһәрендә яши. Ире татар, өч балалары бар, өчесе дә — Төркиядә. Оныкларым да күп, җәйләрен монда каникулга кайталар, балаларым да хәлемне белешеп китә. Утыз ел гомерем Әфәнде Күперендә узды, кырыкка якыны — Гөрсуда үтте. Миңнехаҗием үлгәнгә җиде ел, тик мин аның нигезен беркая да ташлап китмим...

Гөрсу үзе Төркиядәге бер татар утравы булса, Зәүҗан әби биләмәсе — аның милли йортыдыр шикелле тоелды миңа. Чөнки өй, каралты-кура анда нәкъ бездәгечә урнашкан — ишегалдын өч яктан урап корылган. Шуңа күрә, көннең теләсә кайсы вакытында ишегалдына күләгә төшә, яшел чирәм дә көйми-корымый. Моңа машина, арбалы ат кермәве дә сәбәпчедер инде, ләкин мин бу хакта нигәдер уйламаска тырышам, бүтәннәр белән чагыштырганда, Зәүҗан әбинең татарчарак сөйләшүе дә мөһим роль уйныйдыр, дип фараз итәсем килә бугай! Билгеле, әби монда хәзер ялгызы гына яшәгәнлектән, каралты-кура искерә, туза бара. Кызганыч, чөнки шулай татар йорты искерә, туза, татар рухы юкка чыга лабаса. Бер Зәүҗан әби биләмәсе генә түгел, бөтен Гөрсу шундый хәлдә. Күңелемнән бер минутка да чыкмаган Идел-йортым да милли тормыш белән яшәү ягыннан шатландырмый әлегә. Анда җырларыбыз туа, китапларыбыз языла, туган мәктәпләребез бетмәгән, ләкин халкымның сулыш алуы әле һаман кыңәю, ныгу юнәлешендә түгел, ул үз тарихи ватанында азчылыкка калган. Ниндидер явыз көчләр газиз балаларын төрле тарафларга кысрыклап чыгарып, Идел-йортымны зәгыйфьләндергән. Аерылганны инде аю ашый, бүленгәнне бүре ашый...

Зәүҗан әби белән болдырда утырганда шуларны уйлыйм. Нинди могҗиза белән бу чәчелгән-сибелгән татарны яңадан тарихи ватанына җыеп, Идел-йортка җиңелмәс рух өрергә, дәрт-гайрәтен терелтеп, мәңгелек сәламәт тормыш тәэмин итәргә? Шагыйранә уйчыбыз Дәрдемәнд, ялкынлы көрәшчебез Исхакый вә йөнә бүтәннәр шушы максатка хезмәт итәр өчен тапкан малларын да, казанган сәләт-белемнәрен дә багышлаган, ләкин болар гына татарны упкыннан йолып калырга җитмәгән. Әмма җан сакларга булышкан! Димәк, милләтебезгә тагын да куәтлерәк, тагын да гайрәтлерәк фикер ияләре, көрәшчеләр кирәк...

Әнә шулай үз уйларыма бирелә башлаганда, капкадан мине эзләп Әхмәт Зәки Атасевар килеп керде.

— Сөйләшкән сүз онытылырга да мөмкин, мин менә бер кәгазьгә адресымны язып тапшырам,— диде ул.— Авылдашларыбызның күбесе кичә сезнең килүне ишетеп өлгермәгән, бүген кичен очрашырга өметләнәләр. Ватандашыбызны күрер өчен Алашәһәрдән кайтырга җыенучылар да бар икән.

Аерым кәгазьгә исә ул латин хәрефләре белән түбәндәгеләрне язган иде: «Сак белән Сок» бәетен вә җырларыбыз мәҗмугасен җибәрә алмассызмы? Идел-Уралдагы бөтен татарларга исәнлек-сәламәтлек телим. Безгә киләчәктә дә күрешеп яшәргә язсын!».

Без 24 сентябрьдә Алашәһәргә барып, кечкенә каланың бик зур базарын тамаша кылдык. Тик минем хәтердә бу базар малы белән генә түгел, аның ачык күк астындагы бер чәйханәсенә җыйналган милләттәшләрем белән дә хәтердә калды. Түгәрәкләнеп утырганнар да нечкә билле бокаллардан чәй эчә иде алар. Җәйге челләдәге кебек бөркү булса да, башына бүрек, өстенә сырма кигән картлар да, шакмаклы бумазый күлмәгенең изүен ычкындырып, кара эшләпәсен башына кырын салган урта яшьтәгеләр дә, тагын да җинелрәк киенгән егетләр дә бар. Гади киемнәре, сөялле куллары әллә кайдан кычкырып тора: болар туклыктан, житешлектән арыган, кызык-тамаша күреп азган-тузган халык түгел, эш арасында бер мөһим хаҗәтен үтәргә килгән игенчеләр, һөнәрчеләр иде. Кайсы — шәһәрнеке, кайсы — авылныкы, базарның бер почмагына алар-

ны туган тел, татарлык тамыры җыйган. Тирә-якта төрек теле мөхите шау килә: ала, сата, бәхәсләшә... Ә монда унбишләп җан казанча гәп корып утыра. Ничәмә дистә елдан соң ата-баба нигезеннән мосафир килү алар өчен зур вакыйга булганлыктан, һәммәсе беравыздан дәррәү кыстап, мине түгәрәкнең түренә утыртырга тырыштылар, карашлары белән капшап, үзләрен аеруча кызыксындырган сорауларын биреп, ерак илкәй хәбәрләрен тыңларга әзерләнделәр. Кыска-кыска җавапларым аларны канәгатьләндереп җиткермәде, кичен Гөрсуда күрешергә сүз куештык. Ләкин мин Төркиянең үзем күрергә теләгән бүтән шәһәрләренә һәм авылларына барырга вакытым җитмәячәгеннән хәвефләнеп, ахыр чиктә вәгъдәмне боздым — Гөрсуда икенче кичкә калмадым һәм моның өчен соңыннан байтак үкенеп йөрдем. Чөнки мондый зур илне бер сәяхәт вакытында гына барыбер күреп бетерергә мөмкин түгел иде.

Алашәһәр базарында бергә җыйналган милләттәшләремнең кайберсе миннән «Сак-Сок» бәетен сорарга өлгергән иде. Тикмәгә булмагандыр бу, үз язмышларын да шул бәет, риваять каһарманнарыныкына тиңләүдән, тарихи ватаннарын, Идел-йортны юксынудан телгә алганнардыр Сак-Сокны. Юк, аларны ата-аналары каргап читкә таратмаган, кайчандыр ватаннары үги иткән. Мин бу милләттәшләремнең күңелен юатырга, Идел-йорт белән Төркия, Әбиавылы, Иштирәк, Керкәле, Чүтиләр белән Әфәнде Күпере, Гөрсулар арасында да ныклы бәйләныш урнашуга ышаныч уятырга, шул бәйләнышның гәүдәләнеше рәвешендә монда тагын бер кич мәҗлес корып утырырга тиеш идем. Әмма язмыш мине вәгъдәмнән чигендереп, аларны бу юлы да Сак белән Сок хәлендә калдырып моңландырырга теләде, күрәсең. Бу очракта мин Идел-йорт чагылышы идем ич!

* * *

«Сөйләшүең, чыннан да, татарчаны хәтерләтә». Бу сүзләрем Мәҗит Сүзәрнең мин-минлегенә шактый ук нык тигән булган, ахры, авылга кузгалыр алдыннан ул абыйсына:

— Кайту уңаенда кунакны Әхмәт Шәриф белән дә очраштыр. Әхмәт абый да шатланыр, Татарстан вәкиле дә Төркиядә саф татарча сөйләшүчеләр барлыгын күреп китәр,— диде.

Менә хәзер без Гөрсудан кайту юлына чыктык. Тургутлы шәһәрендә Анкара асфальты икегә аерылды — «Дуган»ыбыз уңга, Манисага таба борылды.

Юл буенда ике яктан да йөзем бакчалары сузылып китте — Гәдиз үзәнлеге бөтен Төркиядә нәкъ менә шул йөземе белән атаклы. Әмма куе караңгылык кинәтрәк төшкәнлектән, тиздән без аны җете аера алмый башладык.

Маниса — Измир кебек үк вилаят үзәге, әмма аннан күпкә кечерәк шәһәр. Ут алгач кына килеп кергәнлектән, без аның чинар, пальма, магнолияләр үскән ямьле урамнарын иркенләп тамаша кыла, чәчәкле яшел скверларында хушланып утыра алмадык, әмма якты мәйданнарында, мал тулы кибетләрендә һәм ризыкка бай каһвәханәләрендә тормыш кайнап торуын, яшь-җилкенчәкнең кала мәркәзендә ваемсыз гына сәйран чигеп рәхәтләнүен карап уздык.

Кирәкле өйне үзбаш кына табу кыен булачагын чамалагач, туктап, узгынчылардан юл сораштык. Төрекләрнең үзара ярдәмчеллеген мин менә шунда йәнә бер кат сынадым — мөрәҗәгать иткән ир-атларыбызның берсе, «әйдәгез, күрсәтәм», диде дә, машинабызга утырып, Лаләле мәхәлләсенә кадәр килде һәм, без эзләгән йортны төртеп күрсәткәч кенә, гаип булды.

Яңа кеше белән очрашуга әзерләнеп:



*Маниса шәһәре.*

— Әхмәт Шәриф немесләргә әсир төшеп, монда Алманиядән килеп урнашты инде алайса? — дип сорадым.

— Әйе, — диде Назмый. — Тик без хәзер Дәмирәл Ниязиләргә килдек. Ул да — үзебезнең егет, Әхмәт абзыйны табышмый калмас.

Безне бусагада озын буйлы, төп кебек таза-нык, киң җилкәле баһадир каршылады. Юкка гына Дәмирәл (тимер кул) исемен кушмаганнар икән, кысып та карый кулны! Танышып сөйләшә башлагач, мине гаҗәпсендергән тагын бернәрсә беленде: иллесен генә тутырса да, быел пенсиягә чыккан. Озак еллар автомобиль төзәтү остаханәсендә хезмәт иткән. Төркия гадәтенчә, хатыны өйдә генә кыштырдаган. Дүрт бала үстергәннәр: кызлары инде университет тәмамлаган, улларының берсе — солдат, икенчесе сәүдә эшен өйрәнә. Фатирлары — күп бүлмәле, уңайлы, матур җиһазланган, табыннары мул. Аптырыйм: шәһәр җирендә ялгызы эшләп алты җан асраган кеше ничек мондый тормышка ирешә икән? Балалары әле мал табарга керешмәгән диярлек, пенсия акчасына да шушылай иркен яшәү мөмкинме икәнни? Һәм, ниһаять, типсә тимер өзәрлек ирне пенсиягә чыгара торган нинди акылсыз ил бу? Алмания әнә алтмыш бишкә кадәр эшләтә, аннары гына пенсия түли башлый. Илледән ялга чыгаргач, дәүләт халыкның күпме өлешен үз кайгыртуына алырга тиеш, яңа тернәкләнеп килүче Төркия бюджетенә бик авырга туры киләдер болай?

Миңа аңлаталар: әйе, пенсионерлар дәүләткә бик кыйммәткә төшә, әмма хөкүмәткә әлегә шулай файдалырак. Илдә халык бик тиз арта, хәзер хезмәт базарына ел саен бер миллионга якын егетләр, кызлар өстәлә, аларга кирәк санда эш урыны булдыруга илнең капиталы, ягъни сәрмаясы җитенкерәми. Эшсезлек социаль шартлау барлыкка китермәсен өчен, өлкәннәрне вакытыннан элек хезмәттән бушатырга туры килә. Кызганыч, билгеле, чагыштырмача тәҗрибәлерәк һөнәр осталары әле җимертеп эшләр чакта пенсиягә китә. Ләкин бу — вакытлы хәл. Төркия күтәрелә, көчәя, яңа эшханә-фабрикалар салу, төзелешне, туризмны үстерү, көнкүреш хезмәте күрсәтү тармагын киңәйтү өчен аның көч-кодрәте арткаdebtannan-арта бара, шунлыктан якын арада ук инде пенсиягә чыгу яшен ирләргә илле биштән хәл итү карала. Илдә гомер озынлыгы арту да шуңа этәреп тора.

Әлбәттә, бездәгедәй социализм тәртипләрен кертсәң — колхозлар оештырып, анда дистә еллар буе кешене бушка эшләтсәң, фабрика, төзелешләрдә җан сакларлык кына хезмәт хакына бил бөктерсәң, Төркиягә дә эшсезлек янамас иде. Әмма монда көчләү бездәгедәй канат җәя алмаган, төрек мондый тәртипләргә шунлыктан риза булмаячак, аның тормышка үз мөнәсәбәте бар: эштә күз буяу — әхлаксызлык; эш өчен һәрвакыт лаеклы түләнергә тиеш!

Алашәһәрдә Гариф Йылмаз, телефоннан чакыргач ук килеп җиткән Әхмәт Шәриф — Төркия пролетарийлары миңа үз тормыш-көнкүрешләре турында шактый нәрсә сөйләде. Тик безнең әңгәмә, әлбәттә инде, иң әүвәл мөһаҗир татарның язмышын, аның туган теленә, мәдәниятенә, тарихи ватанына бәйләнешен ачыклаудан, күңелләрендә утырган сагыну юшкынына кагылудан башланып китте.

Тарихи ватанында туып-үсү әллә кайдан сизелә шул: Әхмәт Шәриф абзыйның теле саф татарча булуы бер хәл, аның сүз сөреше дә шагыйранә иде әле. Күрешеп бераз хәл-әхвәл сорашкач ук, үзен аңлап бетермәгән ят мөхиттән йончыган, үзе шикеллерәк тәрбия күргән затларга сусаган төсле:

Белмим,
Әллә күпкә,
Әллә бик озакка,
Ахры, мәңге оныта алмамын
Тамбов урманнары уртасында
Усак яфраклары шаулавын... —

дип сөйләп алып китте ул. Бүлмәдәгеләр һәммәсе тынып калды, Дәмирәлнең буй җиткән Асиясе белән Вәлие гаҗәпсенеп, күзләре очкынланып киткән Әхмәт абзыйга төбәлделәр. Ә ул сөйли дә сөйли:

Бер җирдә юк андый ак каеннар,
Бер җирдә юк андый урманнар,
Бер җирдә юк камыш сабаклары —
Андагыдай шаулый торганнар...

— Әллә сез дә Такташ якташымы? — дидем мин елмаеп.

— Юк, энем, Зәй буеннан, Карабаштан мин. Такташны балачагымнан яраттым, әле дә әсәрләре хәтеремнән чыкмый.

Әхмәт абзый 1923 елда туган. Авылында буй калкыткач, ФЗОга киткән, шуннан әле кавырсыны да катмаган унбиш-унҗиде яшьлек малайларны шахтага җибәргәннәр. Нужа шулпаларын эчеп, инде мондагы авыр хезмәткә ияләнеп килгәндә генә сугыш гарасаты кабынган. Шахтер егет, кулына корал алып, фронтка киткән. Канлы бәрелешләрдә катнашкан, әмма 1942 елның башында әсир төшеп, лагерь фаҗигаләрен татырга мәҗбүр булган. Польша, Алманиядәге тоткынлык газапларын башыннан кичергән, сугыш беткәч, исән калса да, әсир даны белән ватанына әйләнеп кайтырга җөрьәт итмәгән, Бавариядә теләсә нинди кара хезмәткә риза булып, җан сакларга тырышкан. 1949 елда инде Төркиягә килеп урнашкан. Монда төрек кызына өйләнеп, малай белән кыз үстергән. Дәмирәл шикелле, бер автомобиль төзәтү фирмасында хезмәт итеп, пенсиягә чыккан. Әмма ул үзе болар турында сөйләргә дәртсенми, йә Татарстанны сораша, йә тагын яттан Такташ шигырьләрен сиптерә башлый.

— Гомер ничек тә уза инде ул, энем, — ди Әхмәт Шәриф. — Алманиядә немесчәне, монда төрекчәне өйрәндек, әмма берсе дә үз телеңә җитми. Монда татарлар да бар барын, тик алар Тукайны да, Такташны да белми. Төреккә аралашып, сеңеп бетәрбез, ахры. Үз балаларымны да әниләре төрекчә тәрбияләде әнә.

Көнбатыш әдәбиятында, матбугатында мөселман хатын-кызларының хокуксызлыгын тасвирларга яраталар. Йәнәсе, ул ире кушканны гына үти, кол хәлендә, бичара. Ләкин мин Дәмирәл хатыны Зөлхиҗәне

дә, Әхмәт абый хатыны Һаҗәр ханымны да хокуксыз бәндәгә охшата алмадым. Киресенчә, мәҗлестә алар сүзе сүз иде! Укымышлы Асия Татарстан хәлләре белән кызыксынып, мине игътибар белән тыңлап утырса, әллә татарчаны төшенеп бетермәгәнлектән, Һаҗәр ханым әңгәмәбезне кырыкмаса-кырык мәртәбә бүлеп, сүзне кабат-кабат Маниса яңалыкларына күчерде. Шуңа күрә аны хәтта әдәпле генә туктатып, әз генә мине дә тыңлап торуын үтенделәр.

«Хокуксыз» хатын-кызларына төрекләр үзләре ничек карый соң?

Дусларының берсенә бер агай хатыныннан зарлана икән.

— Әллә син аның үлүен телисеңме?— дигән тегесе.

— Юк, теләмим,— дигән агай,— ул чагында мин үзем дә үләчәкмен ич. Шатлыктан!

Бервакыт Мәхмәттән танышы:

— Бүген күршеңне күмгәндә кайгысын уртаклашып елашырга барасыңмы?— дип сораган.

— Баруын барам,— дигән Мәхмәт.— Тик мин елый алмаячакмын: бүген хатыным үлде.

Бу мәзәкләрдән төрек хатынының гаиләдә муен гына түгеллеген бик яхшы күрәбез.

Чынлыкта да төрек хатын-кызлары язмышларыннан зарланмый шикелле. Чөнки алар, безнекеләр сыман, ике камыт кимәгән — күпчелеге өй эше, гаиләсен тәрбияләү белән генә мәшгуль. Аналарның абруе бик югары, апа-сеңелләргә дә хөрмәт, ягымлы мөнәсәбәт күрсәтү гадәткә кергән. Ир-ат эчкечелеккә, уйнашчылыкка бирелмәгән, алар гаиләне матди тәэмин итү белән мәшгуль. Нык, тату гаиләдә атаның яхшы үрнәге балалар сәламәт үсүгә шифалы йогынты ясый. Гаиләләр Төркиядә күп балалы булганлыктан, ир-атка, көчемне кая куйыйм икән, дип аптырыйсы юк — дөнья куарга туры килә.

Соңрак татарча гәбебезгә күнегәрәк төштеме, Һаҗәр ханым колагын шомрайтып, мосафирларны игътибар белән тыңлап кына утырды, юлга чыгарга урыныбыздан купкач, мине үзләренә килеп кич кунарга кыстый башлады. Әхмәт абыйны да уздырып!

Әмма арада ватаны хәбәрләрен тыңлап, эчендәге моңын бушатып туймаган кеше, әлбәттә, шушы Әхмәт абый Шәриф булды сыман. Бүтәннәр монда туган, монда үскән, аларга ата-баба нигезе турында ишетү кызык, әмма йөрәкләрендә ятимлек тойгысы, сагыну сызлануы юк дәрәҗәсендә иде. Әхмәт абый исә күңеленнән: «Бер җирдә юк андый ак каеннар...» дип кабатлаган саен, туган, газиз Карабашын, шуның тирә-ягын, Зәй буеның болыннарын, талларын, җил-яңгырын һәм карбураннарын күзаллап сыкрана иде. Күрешүнең үтә кыска булуына уфтанып:

— Энем, болай ярамый ич инде, кун инде бездә һич югы бер кич! — дип өзгәләнде.— Измирдә, минем шикелле, алман әсирлегеннән монда качып котылган Закир Ялмас якташыбыз бар, иртәгә аны да барып табар идек, илдәге кардәшләренә бәлки ул да хәбәр җибәрер иде.

— Ә сезнең Карабашта туганнарыгыз исәнме соң?

— Алты кыз кардәшем яши анда.

— Аларны кайтып күргәнегез бармы?

— Әлегә юк. Ходай кушса, дөнья эшен белеп булмый, бәлки кайтырмын да.

Сизәм, Әхмәт абзыйда шик-шөбһәләр әле һаман җуелып бетмәгән икән. Әсир төшүе өчен илдә җәзага тартулары бик ихтимал, дип икеләнүе текәнмәгән иде әле. Алгарак китеп әйтим: Казанга кайткач, Төркиядә яшәүче милләттәшләргә мин байтак бүләк, шул исәптән, шигырь сөюче Әхмәт абзыйга якташы Гамил Афзалның «Сайланма әсәрләр»ен һәм «Сөембикә» журналын юлладым. Манисадан озакламый җавап хаты да килеп җитте. «Җибәргән мәҗмугалар өчен бик күп рәхмәтләр яусын! Үз

телемдә күп еллар китап укыганым юк иде. Шатланып укыдым, шигырь китабы күңелемне бигрәк тә оста ачты. Журналны да укып туя алмадым, икешәр кат укыдым. Безне онытмыйча шуларны җибәрүегезгә инде нинди яхшылык итәргә дә белмим!» — дигән иде анда Әхмәт абзый.

«Әҗәлгә дару юк диләр, сагынуларга бар микән?» — дип җырлыйлар бездә. Минем «бар!» дип җавап бирәсем килә. Әллә соң ялгышам микән? Сагынучыларга юаныч бирергә омтылуым аларның әлеге хисләрен дөрләтүгә генә хезмәт итмиме соң?!

Төн уртасында Манисадан Измиргә кайтып барганда бу уй кабат-кабат күңелемә килде. Юл безне тирән тар үзән буйлап өскә, Маниса тавы түбәсенә алып менде, аннан инде икенче күңелле дөнья — Измир шәһәре җемелдәп күренә башлады. Ике каланың арасы — утыз чакрымдыр, аларны биек тау сыртлары гына аерып тора икән. Ә «Сак-Сок»лар тарихи ватаннарыннан бик еракка, меңләгән чакрымга килеп адашкан, ике арада тау сыртлары да, үзәннәр һәм упкыннар да бик-бик күп, далалар һәм диңгезләр дә, чәнечкеле тимерчыбык киртәләр дә бар. Ул араларны узу ай-һай кыен, ай-һай михнәтле. Тарихи ватан галәмәт ерак, күңелләрдә ул еллар буе сагыну булып кына яши. Сагыну — кешене кешелекле итә торган илаһи тойгы. Ләкин шулай да ул тойгы йөрәгеңне өзгәләмәсә яхшырак. Моның өчен исә ата-бабаларың нигезендә гомер итү кирәк.

## ИЗМИР. КАРДӘШЛӘР КОЧАГЫНДА

Измир — Төркиянең иң борынгы шәһәрләреннән берсе. Ул безнең эрага кадәр унынчы гасырда нигезләнгән, дип санала. Шәһәрнең исеме хуш исле чәчәккә бәйле рәвештә кушылган, дип фараз ителә. Билгеле, атаклы каланың кайчан барлыкка килүе һәм ничегрәк исемләнүе хакында фаразлар бик күп, тарихчылар бүген дә өзлексез бәхәсләшә, һәркайсы милли мәнфәгатеннән, зәвыге һәм укымышлылыгы дәрәҗәсеннән чыгып фикер йөртә.

Җылы һәм саф һавасы, тау буйларының калын урманнары, фирүзә диңгез култыгы белән бу төбәк иң борынгы заманнарда ук адәм балаларын кызыктырган, шушында төпләнеп яшәр өчен күп кенә кабиләләр һәм халыклар көрәшкән, үзара бәрелешеп, алар монда берсен-берсе алыштырган. Измир шулар тарафыннан кат-кат җимерелгән, әмма һәрвакыт хәрабәләр арасыннан яңадан калкып чыккан. Күп кенә атаклы шәхесләрнең дә тормыш юлы шушы шәһәргә бәйләнгән. Борынгы заманның бөек шагыйре Һомер Измирдә туган, дигән риваять бар. Безнең эрага кадәр (Б. э. к.) дүртенче гасырда мәшһүр җиһангир Искәндәр Зөлкарнәй (Александр Македонский) бу шәһәрне, нәүбәттәге тар-мар кылынуыннан соң, кабат яңарткан. Тагын өч гасыр узгач, монда атаклы Цицерон дәртле нотыкларын сөйләгән. Гүзәл шәһәр христиан дине таралу дәверендә яңа диннең элгәреге гыйбадәтханәләрен корган, иман яңарту көрәшләренең эчендә кайнаган. 440 елда исә Измирне төрки халыкларның даһи юлбашчысы Атилла буйсындырган. Моннан соң аңа әле гарәпләр, әле византиялеләр алмаш-тилмәш ия булган, аннары 1084 елда шәһәр сәлҗүк төрекләре кулына төшкән. Тик тынычлык бу юлы да озакка сузылмаган. Вакытлар алмашып, монда госманлы төрекләре солтаны Баязит та, Төркестан хакиме Аксак Тимер дә гайрәт күрсәткән. Бары 1413 елда гына гүзәл кала тәмам госманлы төрекләре биләмәсенә кертелгән.

Шәһәрдә шул көннәрдән алып, ниһаять, иминлек канат җәйгән: һөнәрчелек үскән, сәүдә киңәйгән, мәчетләр, кәрвансарайлар, матур-матур торак йортлар корылган, халкы ишәйгән. Соңгы дәвердә аның күпмилләтле халкы түбәндәгечә арткан:

| Милләте: | Саны (мең белән) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 1717 | 1837 | 1872 | 1900 | 1927 |
| Барысы | 28,1 | 110,0 | 155,0 | 225,0 | 184,0 |
| Төрекләр | 15,0 | 50,0 | 45,0 | 60,0 | 178,0 |
| Греклар | 10,0 | 40,0 | 75,0 | 100,0 | 0,5 |
| Яһүдләр | 1,5 | 5,0 | ... | 20,0 | ... |
| Әрмәннәр | 0,2 | 10,0 | 6,0 | 15,0 | ... |
| Бүтәннәр | 1,4 | 5,0 | 4,0 | 15,0 | 5,0 |

Шәһәрнең халык саны 1945 елда — 276 мең, 1970 елда — 521 мең, 1990 елда 1763 мең тәшкил итә һәм моннан соң тагын да кызурак тизлек белән үсә бара. Бераз көрдләр һәм гарәпләр яшәвен искә алмаганда, тулаем — төрекләр!

1914 елда шәһәр 85 мәхәлләгә бүленә, аларда 1100 урам була. 40 мәчет, 17 грек чиркәве, ике әрмән, дүрт католик гыйбадәтханәсе һәм тугыз синагога эшли. Монда унатлы илнең консуллыклары ачыла, Измир сәүдә һәм дипломатия үзәге рәвешендә таныла. Европа дәүләтләре шушы шәһәр аркылы шактый күләмдә мамык, йон, тире, ефәк, келәм, кипкән җимеш, зәйтүн мае һәм бүтән товарлар сатып ала. Унтугызынчы йөздә Измир вилаяте эченә ике юнәлештә мең чакрым чамасы озынлыкта тимер юл салынгач, көньяк-көнбатыш Төркия тормышы тагын да җанланыбрак китә. Яңа мәгъдән ятмалары ачыла, фабрикалар корыла, авыл хуҗалыгы экспорт маллары җитештерүне арттыра. Мәсәлән, Ушак шәһәрендә өч мең кеше эшли торган келәм фабрикасы барлыкка килә. Измир, Истанбулдан кала, илнең иң куәтле сәнагать (промышленность) мәркәзенә әверелә.

Егерменче йөз башында Измирдә бер йөз иллеләп башлангыч һәм урта мәктәп-мәдрәсә эшли. Арада грек, әрмән, инглиз, немес, француз, яһүд уку йортлары да күп була. Дистәдән артык кинотеатрның берсендә спектакльләр дә уйнала. Егермеләп клуб, утызлап казинода биючеләр һәм җырчылар һөнәрләрен күрсәтә. Әмма шәһәр халкының күпчелеге 1914 елда саны 550 гә җиткән каһвәханәләрдә ял итә һәм сәяси бәхәсләр куерта.

Измир төрек матбугатының бишеге исәпләнә. Монда беренче гәзит 1824 елда французлар тарафыннан француз телендә барлыкка китерелә. Төрекчә «Айдын» («Якты») гәзите 1881 елда нигезләнә. Гасырыбыз башында инде төрекчә гәзит-журналлар саны дистәдән артып китә.

Шифаханәләргә, табипларга фәкыйрьрәк булса да, кибетләре белән Измир дөньяның теләсә кайсы шәһәре белән ярыша ала. Инде узган йөзнең җитмешенче елларында ук монда 6250 сәүдә ноктасы эшли. Гасырыбыз башында кунакларга һәм илгизәрләргә алтмыш кунакханә хезмәт күрсәтә.

Беренче Бөтендөнья сугышына Төркиянең Алмания ягыннан катнашуы һәм җиңелүе Измир язмышына да кара күләгәсен төшерә: шәһәр грек гаскәрләре тарафыннан басып алына. Төрек халкының 1919 — 1922 еллардагы милли-азатлык сугышы нәтиҗәсендә, империалистик мәмләкәтләрнең Төркияне үзара бүлешеп юк итү омтылышы нәтиҗә бирми, илбасарлар Измирдән дә куып чыгарыла, әмма шушы кискен бәрелешләр вакытында шәһәр рәхимсез рәвештә яндырыла һәм җимерелә, греклар һәм бүтән христианнар моннан бөтенләйгә күчеп китә.

Төркия җөмһүрияте корылгач кына, Измирне чын-чынлап аякка бастыру башлана, моннан соң инде ул чын төрек шәһәренә әверелеп үсә. Бу аның архитектурасы һәм халкының милли составы ягыннан бертөрлегә әйләнүендә дә күзгә ташлана. Илнең яңа башкаласы Анкара аны күп яктан узып китсә дә, Измир бүген дә кайбер тармакларда икенче урынын

бирми — тышкы сәүдәдә ул бары Истанбулдан гына калыша. Чит илгә сатыла торган тәмәкенең өч чиреге, мамыкның яртысы шушыннан төяп җибәрелә.

Тире, сабын кайнату, тукыма, май җитештерүен дәвам иткән хәлдә, шәһәр эшчәнлеге хәзер күбрәк тармаклыга әйләнгән. Пластик матдә һәм тимер кою, станоклар, машиналар ясау елдан-ел арта бара. Измир хәзер автомобильләр һәм велосипедлар, суыткычлар һәм кер юу машиналары, авиация техникасы, күп төрле төзелеш материаллары һәм механизмнары җитештерә. Йөзләгән төр тукыма, кием-салым, мебель, дарулар, азык-төлек шушы шәһәрдән бөтен илгә һәм чит мәмләкәтләргә тарала. Заманча җиһазланган, алдынгы технология кулланылган байтак фабрикалар хәзер көнбатыш илләре белән ярышырлык дәрәҗәгә күтәрелгән. Моны Измир кибетләренә кереп йөргәндә бик тиз тоясың: күпчелек товарлар Төркиядә, шул исәптән, аларның байтагы шәһәрнең үзендә җитештерелгән.

Төркиядә башка төбәкләрендәгегә караганда әйбер арзанрак җир Истанбул шәһәре икәнлеген алдан ук ачыклаганлыктан, мин Измирдә кибетләргә кереп йөреп вакыт әрәм итәргә һич тә теләмәгән идем. Илнең икътисади үсеш, баю дәрәҗәсен шунда күргәч тә бик җитә ләбаса. Әмма Мәҗит Сүзәр дә, мондагы башка милләттәшләрем дә бу ниятемне, сөерсенеп, хупламадылар. Татарстаннан кадәр кил дә халыкара ярминкәләр үткәрә торган мәшһүр каланың ничегрәк яшәвен күрми кит, имеш. Бу санга санамау измирлеләрнең мин-минлегенә, горурлыгына тия иде, ахры, шунлыктан ниятемне үзгәрттеләр, йөзләгән-меңләгән эреле-ваклы кибетләр тезелеп киткән базарларына, витриналары әйбер күплектән аллы-гөлле елкылдап торган зур-зур сәүдә сарайларына алып бардылар. Күзләрне камаштырырлык малдан сыгылып торган шүрлекләрне күргәч, башыма ирексездән: «Ничек шулай баеган икән соң бу Төркия?» дигән уй килде. Очы-кырые күренмәгән саф-саф, урам-урам төзелгән сәүдәханәләрен карап йөрү әүвәл мине сокландырды, аннары арыта, йончыта башлады. Әйбер чамасыз күп, сиңа ошаган һәм хаҗәт булганнары да әллә ничаклы. Вак-төяк товарларны күтәреп сатып йөрүче кырык тартмачылар да җитәрлек. Шул исәптән, Советлар иле кәсепчеләре дә! Мәҗит Сүзәр аларны әллә ничек чамалап:

— Әнә сезнекеләр йөри! — дип, төртеп үк күрсәтте.

Яннарына барып, кайдан нинди йомыш белән килүләрен сорадым. Алар урысча белүче «төрек» очрауга сөенеп:

— Алматадан без, спорт ярышына килдек, — диделәр. — Вакыт тар, әйберне тизрәк биетергә дә таярга кирәк, сатулашырга булышыгыз әле!

Сумкалары тулы бинокль, электр товарлары. Фабрикасы Казанда булса да, аларны үзебезнең кибетләрдән таба алмаячаксың. Ә монда, рәхим ит, ал гына. Ләкин долларга, маркага һәм лирага. Төркиядә инде кайсы ил туристының нәрсә сатуын беләләр, ил базарлары совет бинокльләре белән туенган, башта егерме доллар бәяләнсә, хәзер унбишуналты долларга төшергәннәр. Әмма «бартер» сәүдәсе тукталмый, бер бокал кока-кола алып эчәрлек тә валюта белән тәэмин ителмәгән совет илгизәрләре, мең мәшәкать чигеп, әнә шундый кәсепкә керешергә мәҗбүр.

Сәүдә мәркәзендә йөргәндә, Тәлгать паша бульварындагы «Татарлар» кибете хәтердә калды. Хуҗалары кырымлы кардәшләребез икән. Кибетләре өч катлы, диварлары эчтән зәңгәр постау белән тышланган, идәнендә — коңгырт киез-келәм. Кием-салым, тукыма, бизәнү әйберләре белән сату итәләр. Кайдан килүемне белгәч:

— Боерыгыз, бәй-әфәндем, нә алачаксыз? — дип хезмәт күрсәтергә әзерләнделәр.

Теләгемне үтәргә атлыгып торулары, әлбәттә, татар булуым өчен генә түгел. Алыш-биреш әйбәт барсын өчен алар Африка негрына да ягымлы мөнәсәбәт күрсәтә. Әмма сатучының якты чырай белән ил-

тифатлы мөгамәлә ясавы, кулыма ялтыравыклы реклама буклеты китереп тоттыручы мине бүтәнчә уйлата: үз татарың шул болар!

Кибетләрендә затлы маллар өем-өем, сәүдәләре кыйбатчылрак булгангамы, керүчеләр артык күп түгел, урамдачыга ыгы-зыгы юк. Күпчелек халык арзанлы мал эзли. Алар исә мондый затлы кибеттә түгел, бар хәзинәсен ачык мәйданда җыелмалы өстәлләргә җәеп салган яки бинага беркетелгән элгечләргә элеп куйган, товарын кычкырып-кычкырып мактауга бер дә иренмәгән сәүдәгәрләрдә сатыла.

Төркия соңгы вакытта безне күн кием белән тәэмин итүче төп илгә әйләнде. Мода шуңа күчкәнлектән, Истанбулга яки Батумидан ерак түгел Трабзонга бару омтылышы әнә шул «күн бизгәге» аркасында да кызып китте. Самолетта, Румыйния, Болгария аша поездда, Кара диңгез аша корабта, Кавказ юлларыннан үз машиналарында яки чик буеннан төрек автобусларында көн саен меңләгән илгизәр көньяк күршебезгә агыла. Бездәге илчелеге һәм консуллыгы теләүчеләргә виза биреп өлгерә алмаганлыктан, Төркия Русия илгизәрләренә визасыз гына кунакка килергә рөхсәт бирде — тамгачыларга ун долларыңны түлә дә рәхим ит. Үз хакимнәрегез дә шуңа риза булса!

Агыла халык. Күн куртка алырга йөз доллар юнәтә алса, буш кайтмаячак. Долларлы булу ансат түгел, ләкин ил зур, шунлыктан чаялар, үткеннәр бездә дә шактый җыйнала, бартер алыш-бирешенә яраклы товарлар ничек табыладыр, тамгачылар иләгеннән иләнеп чик аша ничек алып чыгыладыр — анысын бер Алла гына белә.

Нуретдин Шамданлы әфәнденең күн киемнәр кибете. Зур түгел, әмма кием белән туп-тулы. Иллесе тулмаган ялтыр маңгайлы, хәрәкәтчән хуҗа сатып алучыларына кием сайлашу белән мәшгуль. Яшүсмер кыз белән малай — ярдәмчеләре узгынчыларны кибетләренә рәхим итәргә өнди. Мәҗит Сүзәрне күреп алган Нуретдин әфәнде бөтен йөзе белән балкып:

— Боерыгыз, бәй-әфәндем, даими мөштәрием! — ди.

— Рәхмәт, әфәндем!

— Хәлегез яхшымы? Өегездә иминлекме? Боерыгыз, утырыгыз! — дип дәвам итә хуҗа.

— Әйе. Кәндегез сагмы? Сәүдәләр барамы? — дип гәпкә көч өсти Мәҗит. — Кунагым бардыр, Советлар Берлегеннән килгән Казан төрегедер.

— Чук гүзәл! Боерыгыз, утырыгыз, бәй-әфәндем. Илегездә иминлекме? Сәяхәтегез күңелле узамы?

— Әйбәт. Тәшәккер идәрем, — дим мин тыйнак кына.

— Кунагыбыз тире куртка сайлаячакмы? Иң шәбен табып бирәчәкбез. Сезнең өчен, Мәҗит бәй, даими мөштәриебез өчен, әлбәттә, хакын төшерәчәкмен, — ди хуҗа юлдашымның колагына. — Сезнең кунак — минем кунагымдыр!

Төрек теленең безгә ят сүзләре дә шактый: мөштәри — алучы, тәшәккүр — рәхмәт, саһиб — хуҗа, эйе — яхшы, кәнде — үзе... Нуретдин әфәнде ул арада үсмер малайга безнең өчен чәй китерергә боера, бүтән сатып алучыларга сүз кушарга онытмаган хәлдә, аннары тагын безнең белән гәп кора башлый.

Мәҗит Сүзәр канәгать. Ул шушы кибеттән әле быел гына берьюлы ун куртка сатып алган, сәүдәгәр бу хәлне онытмаган, димәк, эшләр уңар. Киемнәргә ишек төбеннән, еракттан гына күз салып торуымны Мәҗит килештерми:

— Әйдәгез, берәрсен киеп карагыз инде, — дип мине үгетләргә керешә.

Сатучыларның мондый ягымлы, кунакчыл мөгамәләсенә без күнекмәгән. Кесә дә такыррак булгач, сәүдәгәр алдында үземне әллә ничек гаепле кеше сыман тоя башладым. Ул әнә ничек бөтерелә, алдыма төрле-төрле өч-дүрт куртка тотып килде дә:

— Кайсы төс ошый? Кайсы таманрак? Әллә башканы эстисезме?— дип, бер-бер артлы аларны миңа кигезә, чабу-җиңнәрен тарткалап, аркаларын сыйпаштыргалап, мине күзгә алдында әйләндерә-тулгандыра башлады.

Йөз долларлык курткалар. Ә минем кесәдә — әлеге дә баягы «Йени Форум» биргән илле генә. Аннары Измирдә кием сатып алырга теләмим дә ич мин, бу хакта Мәҗиткә алдан ук әйтеп куйдым. Ул моны әллә оныткан, әллә сату-алу дәртеннән исергән, һаман мине үгетли:

— Икенчесен киеп карагыз әле, борчылмагыз, акчаның җитмәгәнен мин үзем түләрмен,— ди. Аннары ризасызлыгыма игътибар итеп, өсти:— Киеп караган өчен монда берәү дә акча сорамый.

Анысы шулай шулаен, әмма ләкин кибет хуҗасы, безнең татарча сөйләшүебезгә колак салып, яныбызда гына бөтерелә бит. Ул инде киеп карарга бишенче куртканы алып килде. Шулкадәр ярарга тырышып хезмәт күрсәтүен, билләһи, кызгана башладым инде. Алырга чамаң юк килеш, аны бушка мәшәкатьләү уңайсыз да. Болай ярамый дип уйлап, ниһаять, мин курткадан баш тартыр өчен, әдәпле бер сәбәп табам:

— Бәй-әфәнде, киемне улыма сайлыйм мин. Яшьләргә күп кесәле, шылтыр-мылтыр тимер йозаклары ялтырап тора торган куртка ошый. Ә моның түшендә йозагы...

— Бәй-әфәндем, төшендем. Биш минуттан түш кесәсе әзер булачак...

Кибет хуҗасы, җавабымны да көтеп тормастан, мин яраксызга чыгарган куртканы тотып, бинасының икенче катындагы ательесына йөгерә-йөгерә менеп тә китте. Минем заказ буенча кесә ясаткан, аңа йозак куйдырган була ич инде ул, менә килеп каптым!

Мәҗит исә күңелле елмаеп, чәй эчәргә керешкән иде.

— Борчылмагыз, сез куртка киеп маташканда, Нуретдин әфәндегә хәлне аңлаттым инде,— диде ул.— Минем янә күпләп курткалар алуыма өметләнә, шуңа күрә кунагыма да унбиш доллар төшәргә риза булды. Моннан арзанракны сез Истанбулда да таба алмассыз!

Биш минуттан инде кибет хуҗасы баягы куртканы яңартып төшеп тә җитте. Саубуллашканда ул безне тагын килергә чакырды һәм «Әлиф антилопа» кибетенең адресы, базар картасы басылган реклама буклетын да бүләк итәргә онытмады. Кунакларын буш кул чыгарып җибәрмәвенә ул, әлбәттә, бик канәгать иде.

* * *

Измир шәһәре мәгариф һәм мәдәният үзәге буларак та ил тормышында күренекле урын били. Дистәләгән китапханәләрендә йөз меңнәрчә том китап, журнал тупланган, Археология, төрек сәнгате, Ататөрек музейлары бөтен илгә мәгълүм. Музей ныгытма Кәдифәкала (Хәтфәкала) — тау башындагы урта гасырлар архитектурасы һәйкәле, анда менгән илгизәрләр бөтен Измирне уч төбендә шикелле күреп тамаша итә ала. Йөздән артыграк мәчет арасында Хисар (1597), Шадырван (1636) исемлеләре борынгылыклары белән атаклы.

Измирнең үз радио үзәге, йөзләп типографиясе бар, соңгылары кырыклап гәзит, унбишләп журнал, күп санда китаплар баса. Исемнәре Татарстанда да мәгълүм Самим Куҗагүз, Тарык Дорсын, Атилла Илхан кебек язучылар шушы вилаяттә туганнар. Унбер роман һәм күп кенә хикәяләр язган С. Куҗагүз, аңардан яшьрәк, әмма шулай ук байтак роман, хикәя һәм әкият иҗат итәргә өлгергән Т. Дорсын бүгенге төрек әдәбиятында мәртәбәле роль уйный. Башка язучыларның китаплары белән бергә, С. Куҗагүзнең «Ун меңнәрнең кайтуы», Т. Дорсынның «Диңгез каны» романнарын уку да миңа заманында Төркияне күзалларга ярдәм иткән иде. Без озак еллар дәвамында СССРда сул карашлы, ягъни

изүче сыйныфларга каршы булган төрек язучылары әсәрләрен генә тәрҗемә иттек, романнары урыс телендә басылган С. Кужагуз белән Т. Дорсынның да төрек «тәнкыйди реализмы» вәкилләре булуын чамаларга мөмкин иде. Әллә шуның өчен өнәмәгәнгәме, Измир укымышлылары белән әңгәмә корганда, аларның берсе дә әлеге язучыларны телгә алмады. «Бездә атаклы каләм ияләре юк, Истанбул белән Анкарада тупланган алар»,— дип аңлаттылар.

Соңрак миңа СССРда әсәрләре еш тәрҗемә ителгән башка язучылар, шул исәптән, Газиз Нәсин, Сәбахетдин Гали, Орхан Кәмал, Йәшәр Кәмал, Фәкыйрь Байкорт һәм бүтәннәргә карата да шундыйрак салкын карашны тоярга туры килде. Ләкин алар хакында мин Анкара, Истанбулда кызыксындым...

1987 елда Болгариягә барып, анда яшәүче төрекләр һәм татарлар белән танышып, сәяхәтем һәм әлеге күрешүләрем тәэсирләрен «Гөлчәчәкләр илендә кара болыт» исемле әсәремдә чагылдырган идем. Укучылар хәтерлидер: мин анда төрек-татар язучылары белән очрашуларымны сурәтли алмадым — алар ул чакта барысы да төрмәләргә җыеп ябылган, сөргеннәргә сөрелгән иде. Измирдә йөргәндә мин шулардан берсенең — Болгарстанның Разград округы Шәрәмәт авылында дөньяга килгән шагыйрь Шабан Калканның, 1989 елда туган иленнән сөрелгәч, шушында яши башлавын белмәдем.

Әсәрләре болгар, македон, поляк, украин, урыс телләрендә дә басылган, Болгарстанда төрекчә һәм болгарча шигъри җыентыклары нәшер ителгән, төрекчәдән һәм урысчадан — болгарчага, болгарчадан һәм урысчадан — төрекчәгә әдәби тәрҗемәләре белән дә танылган Шабан туган илендә озын хезмәт юлы узган. Солдат, эшче, укытучы, журналист, Болгарстан Язучылар берлеге Разград бүлеге рәисе, шигырь бәйгеләрендә әллә ничә мәртәбә бүләкләр казанган каләм иясе ул. Аның Измирдәге Алсанҗак дәүләт шифаханәсендә дәвалаучы доктор булып эшли башлавын вакытында белсәм, Болгарстанга һәм Төркиягә бәйле күп кенә вакыйгаларны мин аннан сорашкан булыр идем. Кызганыч, мин аның хакындагы хәбәрне, каләмдәшемнең шигырьләрен Төркиядән өйгә әйләнеп кайткач кына, Измирдә чыга торган «Кардәш әдәбиятлар» журналыннан укый алдым.

Измир шәһәрендә ун футбол командасы бар. Монда баскетбол, көрәш һәм спортның бүтән төрләре дә киң таралган. Стадионнар, йөзү бассейннары һәм бүтән спорт корылмалары елдан-ел арта бару ил күләмендәге һәм халыкара ярышларда «Алтай», «Алтынай», «Алтын Урда», «Гүзтүбә», «Каршыяка» һәм бүтән Измир командаларының еш кына призлы урыннарга чыгуына мөмкинлекне киңәйтә. Югарыдагы исемнәрне санаганда мин ирексездән: Татарстан командалары ни өчен «Динамо», «Синтез», «Рубин» һәм башка ят кушаматлар белән атала икән?— дип баш ватам. «Алтай», «Алтын ай»лар ярамаса, безгә бәлки «Алтын Урда»сы Төркиягә караганда да күбрәк килешер иде? Ни әйтсәң дә, бу дәүләт төрекләрнеке түгел, татарныкы булган ич!

Измирнең мәдәни тормышын җанландыруга сурәт галереясе, Дәүләт театры, консерватория җитди өлеш кертә. Әмма культура эшенең башы да, нигезе дә — мәгариф челтәре.

Хәзер Төркиядә мәктәп яшендәге барлык балалар укуга тартылган. Күпчелеге, әлбәттә, башлангыч белем генә ала. Анысы исә — биш сыйныфлы. Аннан соң укучылар өч сыйныфлы урта мәктәпкә күчә. Шуннан соң белем алу өч ел буе лицейләрдә дәвам итә. Лицей тәмамлаучыларны югары уку йортлары көтә. Аларына керү, бездәге шикелле, конкурс нигезендә, 1991 елда, мисалга, 975 мең дәгъвачының 185 меңе генә кабул ителә. Ягъни бер урынны якынча биш кеше дәгъвалый.

Мәгариф челтәренең бүтән тармагы да бар. Башлангыч мәктәптән соң һөнәр-техника урта мәктәпләренә кереп, берьюлы гомуми белем һәм һөнәр үзләштерергә мөмкин. Югары һөнәр-техника мәктәпләре исә кол-

леджга тиң — аларда урта һәм югары белемле һөнәр ияләре әзерләнә. Әйтик, хатын-кызлар педагогия институты, туку сәнәгате техниклары мәктәбе шундыйлар исәбенә керә.

Милләттәшебез Надыйр Дәүләт әйтүенчә, Төркиядә дәүләт мәгариф челтәре Татарстанныкыннан күчлерәк түгел. Бер сыйныфта кайбер җирләрдә 60 — 70 укучы белем алу сыйфат ягына сукмый калмый. Илдә халык бик тиз арта — күп балалы гаиләләр ишле. Үсеп килүче ил булган Төркия мәктәпләр өчен биналар төзеп җиткерә алмый, төпле әзерлекле укытучылар, мәктәпләрне заманча техник әсбаплар белән тәэмин итү дә аксый. Мондый аксауны хосусый мәктәпләр киметергә булыша — аларда укыту сыйфаты бермә-бер югарырак. Ләкин аларда укыту — түләүле.

Дәүләт мәгариф челтәрендә белем алучылар университетка кергәндә түләүле хосусый курсларда өстәмә әзерлек үтәләр — бу аларга көндәшләре белән уңышлы ярышырга булыша.

Измир шәһәрендә, югарыда телгә алынган мәгариф учакларыннан тыш, Ислам институты, Икътисад һәм сәүдә академиясе, Тугызынчы сентябрь һәм Эгей университетлары да бар әле. 1955 елда ачылган Эгей университеты аеруча мәртәбәгә ия. Аның яхшы җиһазланган лабораторияләре, зур клиникасы, 1100 урынлы шифаханәсе, бай китапханәсе, куәтле типографиясе яхшы белгечләр әзерләргә, киң күләмдә тикшеренүләр алып барырга мөмкинлек бирә. Эгей университетының медицина, авыл хуҗалыгы, техника, археология, чит тел, халыкара бәйләнешләр факультетларында меңләгән студент белем ала.

Әмма минем игътибарымны җәлеп иткәне — нәкъ менә шушы Измир университеты галимнәре тырышлыгы белән барлык төрки халыклар рухи байлыгын төрек укучысына тәкъдим итүче «Кардәш әдәбиятлар» журналы чыгарылуы иде. Советлар Берлегендәге «Дружба народов» шикелле басма ул. Билгеле, «Кардәш әдәбиятлар» әлеге Мәскәү журналыннан күпкә юкарак һәм өч айга бер, чынлыкта исә елга бер-ике мәртәбә генә дөнья күрә, тиражы да аз. Ләкин аны Төркиянең башкаласы Анкара да, илнең иң зур шәһәре, аннан да бигрәк, илнең иң атаклы һәм күпсанлы мәдәни көчләре тупланган Истанбул да түгел, ә гадәти вилаят үзәге чыгара. Шуңа тагын бер өстәмә бизәк: идеологик каршы торулар йомшара төшкәч, Төркиядә ике кеше (Алмания аша алдыру чарасын күргән милләттәшебез Надыйр Дәүләтне санамыйк) «Казан утлары» журналын рәсми төстә алдыра башлады. Шуларның берсе — Измир университеты профессоры Фикрәт Төрекмән.

«Кардәш әдәбиятлар»ның күләме 32 бит, сирәк очракта гына — 48 бит. Европа бизмәне белән үлчәсәк, Төркиядән тышта яшәүче төрки халыклар әдәбиятын танытучы берданбер басманың университет укытучылары тарафыннан җәмәгать башлангычында гына нәшер ителүе һәм әҗәл даруы сыман әз таратылуы гаҗәпсенү һәм канәгатьсезлек уята. Алтмыш миллион (1993 ел) халкы булган илдә бит бу! Төркия бик әз укый дигән сүзме бу? Әллә ул кардәшләре белән кызыксынмыймы? Үзеннән башка төркиләрдә игътибарга лаек әдәбият барлыгын белмиме?

Төркияне һәм төрекләрне яхшы яктан гына сурәтләргә никадәр тырышсак та, югарыда куелган сорауларга: «Әйе. Әз укый. Әз кызыксына. Белми»,— дип җавап бирергә туры килә. Халык саны уникe мәртәбә артыграк булуга да карамастан, ул журналлар һәм китаплар чыгару буенча Финляндияне куып җитә алмый. Төрекләрдә бүген малкуарлык бар, ләкин уку культы, басма сүзгә табыну юк. Моны саннар да бик ачык күрсәтә: 1991 елда Төркиядә 17 миллион тираж белән 6031 исемдә китап басылды (төрек китабының уртача тиражы — 2819 данә). Ягъни дүрт кешегә — бер китап, җан башына чирек китап туры килә. Җан башына исәпләсәк, Румыйния — 3, Польша 5,4 китап баса. Халык саны бер чама илләр белән чагыштырсак, басылган китап исемнәре буенча Төркия Италиядән — 2,8, Франциядән — 6,5, Англиядән 8 мәртәбә калыша. Шунысын да искәртергә кирәк: төрек китабының байтагы — дини эчтәлекле;

руханыйлар, дини вакыфлар матбага эшендә үтә актив — басмаларын зур тираж белән басып, чагыштырмача арзанрак бәягә сата, хәтта бушлай да тараталар. Төрекләргә матбага өлкәсендә алдынгы Көнбатыш һәм Төньяк Европаны куып җитү өчен озак еллар дәвамында бик нык тырышырга туры киләчәк әле, чөнки алар укымышлылык буенча татарлардан да шактый түбән тора.

Әмма югарыдагы саннар һәм фикерләр Төркиядә фән һәм мәдәният гомумән түбән тора икән, безгә аңардан өйрәнерлек һәм алырлык бернәрсә дә юк икән, дигән ялгыш уйга китерергә тиеш түгел. Күпсанлы халыкның нисби яктан азчылыгы гына укымышлы булса да, ул укымышлыларның абсолют саны миллионнарны тәшкил итүе табигый, шуннан төрекләрнең югары үсешкә ирешкән матур әдәбияты, музыкасы, сынлы һәм театр сәнгате, гуманитар фәннәрне алга җибәргән күренекле галимнәре бар. Аларның кайберләре турында алдарак сүз булды, моннан соң да танышуны дәвам итәр өчен мин бер көнне Измир университетының төрек теле һәм әдәбияты бүлегенә киттем.

Измир университеты — яңа корылган иркен һәм матур бер аерым шәһәрчек. Гөлчәчәкләр утыртылган скверлары, ак ташпулатлар ансамбленнән гыйбарәт модерн бизалары аңа күркәм төс бирә. Билгеле, меңләгән студент укытуны күздә тотып төзелгән биналарда купшы архитектура бизәкләре юк диярлек, монда барысы да максатка яраклы рәвештә гади бетон, мәрмәр, пыяла — һәммәсе исәп белән файдаланылган. Төрек теле һәм әдәбияты кафедрасында да шундый ук гадилек — бездәгечә үк сары өстәлләр, шкафлар, пластмасс урындыклар.

Кафедрада мин байтак галим белән таныштым, шулардан аеруча истә калганнары доцент Явыз Акпынар белән әле аспирантураны яңа гына тәмамлап килүче Мостафа Өнәр булды. Икесе дә «Кардәш әдәбиятлар» журналында татар әдәбиятын төрекчәгә тәрҗемә итеп, рухи байлыкларыбыз турында мәкаләләр язып бастыручылар. Алар шкафларындагы өч томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н чыгарып:

— Бу китаплар — Измирдә бердәнбер нөсхәдә,— диделәр.— Алты җилдле «Татар әдәбияты тарихы»н да мең бәла белән алдырабыз. Классикларыгыз әсәрләре дә ярым-йорты гына тупланган. Татарстан белән хезмәттәшлек итүебез юк дәрәҗәсендә, журналларыгыз безгә гомумән очраклы рәвештә генә килеп эләккәли, ярый әле беребез Суоми татарлары белән бәйләнешкә керде...

Суоми — Финляндия, Мостафа шунда барып татар кызына өйләнгән икән. Ул кыпчак төркеменә кергән төрки телләрне өйрәнә, татарча инде хәзер үк иркен сөйләшә. Чем-кара чәчле, калын кашлы, озынча йөзле, эре сөякле. Сөйләшү манерасы, үз-үзен тотышы белән миллионлы шәһәр укымышлысыннан бигрәк авыл егетен хәтерләтә. Ләкин ул инде «Кардәш әдәбиятлар»да Гәрәй Рәхим шигырьләрен, кайбер язучыларыбызның мәкаләләрен төрекчә тәрҗемә итеп, аларга аңлатмалар биреп бастырырга өлгергән. Шул аңлатмаларны әзерләр өчен байтак әдәбият карап чыккан.

Явыз Акпынар «Кардәш әдәбиятлар»ның Тукайга багышланган махсус санына сүз башы язган. Ул әдәбиятыбызны тагын да тирәнрәк өйрәнергә, төрек-татар мәдәни багланышларын барларга тели икән, әмма кирәкле китапларны — галимнәребезнең тикшеренүләрен, язучыларыбызның әсәрләрен кулга төшерүдән гаҗиз.

Мин дә шундый ук кыенлыкка тарыган идем ич. Төрек әдәбиятын, киңрәк алганда, мәдәниятен һәм тарихын яхшырак, киңрәк белергә теләдем. Еллар буе тырыша-тырыша төрек язучыларының, галимнәренең китапларын җыярга омтылдым — әмма урысчага тәрҗемәләрен генә таба алдым. Төркия белән СССР арасында мөнәсәбәтләр шактый салкын булганлыктан, төрекчәдән тәрҗемәләр дә аз басылды.

Менә хәзер мин (ышанасы да килми) рәхәтләнеп Төркиядә йөрим. Кибетләре тулы китап, әмма... безнең валютасыз кесә белән аларның янына да килә торган түгел: иң юкасы да — ике доллар тора!

Университетка бару китаплы булу ягыннан ифрат та файдалы булды. Без Явыз Акпынар әфәнде белән ярты сүздән үк аңлаштык: мин Казанга кайту белән аңа кирәкле басмаларны табып җибәрәчәкмен, ә ул...

Мәҗит, сүзебез тәмамланганны да көтмәстән, безне якындагы гыйльми китаплар кибетенә алып китте.

Баскычтан түбәндәге катка төштек. Эче җыйнак, якты икән, дивар буйларында да, уртада да китапханәдәге шикелле тезелеп киткән киштәләр. Калын-калын томнарның яңа чыкканнары да, күптән дөнья күргәннәре дә бар. Төркиядә китапның озак сатылуы миңа ярап та куйды — мин монда исемнәрен библиографик чыганаклардан күптән укып белгән басмаларга да юлыктым. Кулга тотып карарга да хыяллана алмаган күпме китап күзгә чалынды монда!

— Явыз бәй, ничә долларлык сайларга мөмкин?

— Кирәген һәпсен алыгыз!

Сайлыйм: Шөкран Курдакул. «Чагдаш төрек әдәбияты»; Фарук Тимурташ. «Тарих эчендә төрек әдәбияты»; Зыя Бакырчыуглы. «Төрек романы»; Мәхмәт Каплан. «Шигырь тәһлилләре»; Ибраһим Кафәсуглы. «Төрек милли культуре»; өч автор әзерләгән «Хикәячелегебезнең 100 елында йөз үрнәк» антологиясе...

Йә Хода, күпме тансык хәзинә монда. Кайсылары саллы-саллы ике томлык. Вак-төяк хезмәтләргә сузылмыйм, түләүче барында калын-калын томнарга үреләм. Хуҗа да «өметле» кешеләр килеп керүен күреп, яныбызда бөтерелә. Үзе сораша:

— Кайдан килдегез? Насыл мәүзуг мираклandыра? — ди.

Нинди темалар кызыксындыра, янәсе. Күзем төшкән китапларны шундук дымлы чүпрәк белән тузаннан арындырып миңа суза. Ул арада нечкә билле касәләрдә кайнар чәй дә китертеп җиткерә — унике яшьләрдәге бала аны әйләнмәле баскыч буйлап икенче каттан алып төшә. Тартынмагыз, ерактан килгән кунакны хуҗа үз исәбенә сыйлый! Ә бәлки китап бәясенә кушып җибәрәдер? Көне буе кем генә кермәс монда! Әлбәттә инде, исеме, кибетенең адресы язылган визиткасын тәкъдим итәргә дә онытмый, кирәкле басмаларны почта белән җибәреп тору мөмкинлеге барлыгын да искәртә. Аның банктагы исәбенә валютагыз гына килеп җитсен.

Китап кибетенә алучылар ишелеп керми, аларны кунакчыл каршыларга хуҗа иркен өлгерә. Сәүдәгәрлек сатучыларга уртак сыйфатлар өстәсә дә, монда тирече-күнче түгел, китапчы эшләве сизелеп тора: мөгамәләсе затлырак, нәзакәтлерәк!

— Йосыф Акчураның «Төрекчелег»ен күрдегезме? Түнҗәр Байкараның «Зәки Вәлиди Туган»ы да бар. Әгъдәс Нигъмәт Куратның «Төркия вә Русия»сен карадыгызмы?

Чамалап алды бу минем кызыксыну даирәсен, берсеннән-берсе күңелне ныграк тарткан басмаларны табып кына тора. Кайбер хезмәтләрне Явыз бәй дә тәкъдим итә, әмма мин хәзер шактый биек өемгә кыенсыныбрак күз салам: Акпынар әфәндене уңайсыз хәлгә куймаммы, кесәсе чыдармы икән боларга?

Янәшәмдә Мәҗит бәй дә кайнаша ич әле. Көтмәгәндә аның кунагын баетырлык кеше табылуына сөенеп, ул да кирәкле санаган китапларны тотып килә. Шул арада миннән күреп, сорашып, үзенә дә сайлый — инженер тарих, әдәбият гыйлемен ялгыз башы кайдан белсен?

Күз бик кызган булса да, кат-кат актаргалап караган бүгенге төрек прозасы үрнәкләрен мин кире шүрлеккә илтеп куйдым. Газиз Нәсин, Кәмал Таһир, Рәшит Нури Гөнтәкин, Сәет Фаикъ һәм тагын кайберәүләрнең урысчага тәрҗемәләрен укып канәгатьләнеп торырга туры килер әлегә. Шөкер, йөз том чамасы шундый әдәбиятым бар. Алар янына менә хәзер антологияләр, гыйльми хезмәтләр өстәләчәк. Сиксән долларлык! Ягъни минем өчен бер күн курткалык сәрмая калдыра кибеткә Акпынар

бәй. Берәүләр бездә шуны алып кайтып сатып, керемәнә илле түгел, биш йөз китап алыр иде. Бездә китап арзанрак. Ләкин кайсы галимнең, язучының андый бизнес белән баеганы бар соң? Табигый ки, мин дә Төркия-Татарстан дуслык багланышларын үстерүгә хезмәт итәчәк кадерле басмаларның Казанга кайтып ирешәчәгенә сөенечемнән балкыйм!

Чәченә чал төшә, маңгай өсте шәрәләнә башлаган түгәрәк йөзле, йомры гәүдәле Акпынар бәй, сөйкемле елмаеп, үзенә нинди китаплар кирәк булачагын миңа янә бер кат искәртә дә безнең белән саубуллаша.

— Укулар башланмаган әле, студентлар белән очраштыра алмадык сезне, яренгә тагын килегез,— ди ул.— Татарстан галимнәренә чук сәлам! Бәлки әле Казанга Тюркология конференциясенә бара алырмын.

Мостафа Өнәр белән бүтән көнне янә бер очрашырга сүз куешканлыктан, бу юлы университет мәхәлләсендә озак мавыкмыйбыз — Мәҗит әшенә ашыга. Ул өйлә вакытында гына мине шушында алып килер өчен тәнәфес ясап алган иде. Китаплары белән кунагын өенә җилдереп кенә кайтарып куйды да тагын ширкәтенә чыгып чапты. Югары хезмәт хакын Төркиядә көч түкми генә казанып булмый шул!

Ә кичен без Мәҗитнең төрек дуслары белән очраштык. Сәүдәгәрләр, университет укытучылары, адвокат, врач, инженер һәм башка һөнәр ияләре — Өмәр Каплан өенә унбиш-егермеләп кеше җыйналган иде.

Мәҗитнең аңлатуынча, Төркиядән тыштa яшәүче төрки халыклар язмышы өчен җан атучылар икән болар. Өй хуҗасы — шушы төрки берлек төркеменең рәисе икән. Күренеп тора: җәмгыятьтә инде үз урынып тапкан утыз-кырык яшьләрендәге укымышлылар. Кем киләсен алдан белеп җыйналганлыктан, алар сүзне баштан ук миңа бирделәр һәм Татарстан, татар халкы, аның бүгенге хәле, көрәшләре хакында сөйләвемне үтенделәр.

Мәҗит минем тылмачым булырга теләгән иде, әмма мәҗлес кунакны үз шивәсендә тыңларга теләк белдерде. Билгеле, мин белгән кадәр төрек сүзләрен дә кулланырга тырыштым.

Бераздан мәҗлесебез хәйран кызып китте — мине сораулар белән күмеп ташладылар. «Татарстан бүген аеруча нәрсәгә мохтаҗ? Төркиягә нинди өметләр баглыйсыз? Сез үзегез шәхсән гыйбадәт кыласызмы? Татар халкын мөселманлыкка кайтару өчен ниләр эшлисез?..»

Бүлмәдә хатын-кыз заты күренмәде, ашны бусагадан хуҗа үзе генә ташыды. Табын ризыкка мул, мәҗлес сүзгә юмарт — очрашу бик җанлы, ихлас дәвам итте. Тугызынчы сентябрь университетының илаһият (дин) факультеты укытучылары да катнашкангамы, әллә монда барысы да диндар кеше булгангамы, бераздан дин, иман мәсьәләләре гәбебезнең үзәген тәшкил итә башлады.

— Казанда һәм тулаем Татарстанда яңадан-яңа мәчетләр салына, искеләре халыкка кайтарып бирелә һәм төзәтелә хәзер,— дидем мин.— Моңа чит илләрдән, бигрәк тә мөселман илләреннән килгән кунаклар да игътибар итә һәм шатлана. Күптән түгел шул кунакларның берсе мәчеткә килгән дә аның буш икәнлеген күреп, урамга чыккан һәм шул тирәдән узып барган бер карттан: «Намаз беттемени инде?» дип сораган. «Беткән булырга тиеш», дигән тегесе. «Ә син укыдыңмы соң?» «Ничек инде укымыйсың ди!» «Күптән укыдыңмы?» — дигән илгизәр. «Кырык еллап элек... әтине җирләгәндә», дигән әлеге карт.

Мәҗлеснең бер өлеше аһ итә, калганнары, әллә кунакны дөрес аңламадыммы, дип бер-берсеннән нидер ачыклап ала. Ә мин сүземне болай дип дәвам итәм:

— Хәзер бездә дин турында язу, сөйләү модага әйләнеп китте. Хөррият! Гомер буе алды — әдәп, арты тәһарәт күрмәгән уйнашчылар Мәккәгә хаҗга бара, форсаты чыкканда, вата-сындыра дога укый, шул исәптән, дини бәйрәмнәр уздыруда да катнаша. Яңа байларыбызның берсе, үзенең әхлаклы икәнлеген исбатлар өчен, рамазан бәйрәмендә мәҗлес җыйган. Табын янында сүз ураза тотуга да кагылган. Мулла

кунакларның һәммәсеннән йоланы ничә көн тотуын сораган. Хуҗа кеше: «Рамазан аенда юлда булганлыктан, мин бары шәһәремә кайткач кына, бер генә көн уразага керә алдым», дигән. Кунакларның берсе: «Мин уразаны хөрмәтле хуҗадан бер генә көн ким тоттым», дигән. Аңа бүтән кунаклар кушылган: «Мин дә бер генә көн ким», «мин дә бер генә көн ким!..»

Измирлеләр шаккатты: мәзәктер бу дип көлерләр иде, мин бик җитди кыяфәттә сөйлим, шул ук вакытта казан төрекләренең шул кадәр бозылуларына ышанасылары да килми. Мин исә тагын дәвам итәм:

— Дин — халыкны әхлакый тәрбияләүдә әһәмиятле чара. Без ислам динен тотабыз, әмма аны гарәпләр нигезләгән. Бәлки төрки халыкларга үз дини тәгълиматын булдырырга кирәктер? Исламны файдалану шуңа кадәр генә акланырга мөмкиндер?

— Бу нә дигән сүз, бәй-әфәндем? — ди мәҗлестәгеләрнең берсе.

— Тагын шунысы да бар,— дим мин аңа җавап биргән сыман,— диндарлыкка бирелү генә төркиләрне алдынгы халыклар сафына илтеп чыгара алмас. Без дөньяви белемнәрне үзләштерүгә, фәнни-техник казанышларны эшкә җигүгә күбрәк әһәмият бирергә тиеш.

Шушы фикерләремне әйткәч, бүлмәдәгеләр бер-берсенә карашып, бер мәлгә тынып калды. Гүя, Сүзәрне: «Кемне алып килдең син монда?» дип сүзсез генә шелтәлиләр иде. Мәҗит хәвефле тынлыкны өзеп:

— Әйди бәй «Казан утлары» дәргесендә Коръән аятьләрен әзерләп бастыра килә. Ул — язар, төрек айдыннары нә уйлавы илә миракланыюр, шуны белмәк эстәюр,— дип ачыклык кертергә ашыкты. Татар язучысы төрек укымышлылары нәрсә уйлавы белән кызыксына, кылларыбызны тартып карый, янәсе.

Буа ерылды. Китте бәхәс, бер-берсен бүлә-бүлә фикер кылычларын уйнату, сүз ташкынын хәтта кайнар аш килү дә туктата алмады.

— Бәй-әфәндем, динсез төрекне гарби Европаның байлыгы дәгел, бозыклыгы әсир итеп юкка чыгарачак.

— Христиан динендәге Европа белән йөзгә-йөз килгәндә Төркиянең төп таянычы — ислам.

— Ислам гарәпләрдән керсә дә, аны гасырлар буе таратучы вә үстерүчеләр — без, төрекләр.

— Төркия гареп илләрен куып җитәм, көчәям, дип аурупалаша, чын диненнән яза икән, андый Төркия безгә кирәк дәгел!

— Президентыбыз Тургут Үзал, илне икътисади яктан тиз үстерәм, дип туризмга сәрмая салуны арттырды. Бакың: иркәкләр белән хатын-кыз бер пляжда ауный хәзер, шуннан соң нинди әдәп-инсаф турында сүз алып барырга мөмкин? Мондый тәрәкъкый, инкишаф безгә нигә?!.

Мин бу очрашуга үзем дә бик кызыксынып килгән идем. Измирнең дипломлы зыялылары Көнбатыш Европаның үкчәсенә басып үсеп килгән Төркия турында карашларымны баетыр һәм киңәйтер, илдә чакта белә алмаган байтак серләрне ача алырмын, дип өметләндем. Өметем акланды да, юк та. Чөнки монда чыннан да, бер яктан, бездәгечә фикер йөртмәүче затлар җыйналган иде. Шунлыктан, аларны күрү үзе бер кызык. Әмма, икенче яктан, алар Төркия яңарышының сәбәпчесе — аңа этәргеч бирүче һәм тизләтелгән үсешне гамәлгә ашыручы көч түгел, ә бәлки яңарыш чабуына ябышкан сырганаклар сыманрак тоелды. Монысы инде һич тә күңелемә ятарлык нәрсә була алмый иде. Теләгем — Төркияне алга этәрүче Алып батырларны очрату иде ләбаса! Таң калдым Төрек берлеге әгъзаларына һәм, кайнар бәхәскә кереп, президент Үзалның егетлекләрен исбатларга тотындым.

Ерактан, Каф таулары артыннан, килгән «казан төрегенең» башкан Үзалны үз госманлылары тәнкыйтеннән сакларга ашкынуы мәҗлестәгеләрне тагын бер мәртәбә аптырашка калдырган вакыйга булды.

1980 елда халык саны буенча Болгариядән биш мәртәбә өстен Төркия электр энергиясен аның өчтән икесе кадәр генә җитештерә иде.

Т. Үзал җитәкчелек иткән ун ел эчендә Төркия экономикасы сокланырлык тизлектә күтәрелде. Илдә чуен һәм корыч коюю, электр энергиясе җитештерү ике мәртәбә, бөртекле ашлык үстерү өч мәртәбә, техник үсемлекләр тулай уңышы дүрт ярым мәртәбә артты. Башка тармакларда да еллык үсеш сигез-ун процентка җитте. Төркия, ниһаять, электр энергиясе җитештерү буенча Болгарияне ике тапкыр узып, шуны күршесенә сата башлады. Хәзер, боларның берсен дә игътибарга алмастан, гаҗәеп үсешләр баш конструкторына тел озайтып, «затсыз пляж, әдәпсез телетапшырулар безгә кирәкми!» — дип ыгы-зыгы кил, имеш. Дөрес, әдәп-әхлакны сакларга кирәк, әмма... «Төркиядә 72 мең мәчет эшли, шуларга ел саен тагын йөзләбе өстәлеп тора», дип күпме юанырга мөмкин? Биш вакыт намаз укып, ураза тотып, дини йолаларны төгәл үтәп кенә тамак туярмы, өс бөтәерме соң? Мөселман бәхетен матди нигездән аерып карарга шулай ук ярамыйдыр лабаса?

Тик мин дингә бәйле тәнкыйть фикерләремне чамалап кына белдердем. Чөнки бу мәҗлес аларны сыйдырмас төсле тоелды. Аннары сүземне төрки кавемнәрнең бай мәдәнияте булуына, госманлы төрекләренең башка төрки кардәшләре телләрен дә, мәдәниятләрен дә тиешенчә өйрәнмәүләренә һәм белмәүләренә, шулай яшәгәндә төркиләр бердәмлеген ныгыту уңышлы гамәлгә ашмаячагына борып җибәрдем. Мәҗлестәгеләрне бу фикер янә гаҗәпләндерде. Арадан берсе:

— Нигә сез, казан төрекләре, гел үз хосусиятләрегезне калкытырга тырышасыз? — диде.

— Монда укымышлы ир-егетләр җыйналган, — дидем мин. — Сезгә Йосыф Акчура, Садрый Максуди Арсал, Рәшит Рәхмәти Арат, Хәмит Зөбәер Кошай, Әкъдәс Нигъмәт Курат, Габдулла Баттал Таймас, Закир Кадыйри, Әхмәт Тимер исемнәре таныштыр. Алар — Төркиядә гуманитар фәннәргә европача нык нигез салган казан татарлары. Без башка төрки кавемнәрне үстерүгә дә күп кенә кабилиятле, көчле галимнәр, әдәбият-сәнгать эшлеклеләребезне биреп булыштык. Шундый талантлар үстергән халыкның үзенә илтифат өмет итүе гөнаһмыни?

Мәҗлестәшләремнең кайберләре, иманым камил, мин санаган олуг шәхесләрнең һәммәсе казан татарлары булуын беренче ишетә иде. Бу хәбәр аларга шундый көчле тәэсир итте ки, берсе дә миңа ризасызлык белдерергә ашыкмады. Моннан соң инде сүз «казан төрекләренә» ничек ярдәм итү турында бара башлады, ә мин «гүнәй» (көньяк) татарлары», ягъни Төркия төрекләре тормышына бәйле сорауларымны тездем.

Мәҗлес, үзара киңәшеп алганнан соң, «шушында җыйналган укымышлылар исәбенә Татарстаннан биш бала китереп укытырга, урта мәктәп программасын узганнан соң, аларның Тугызынчы сентябрь университетында белем алуларын да тәэмин итәргә», дигән карар чыгарды. Бу эшне күз уңында тоту әлеге университетның дин факультеты укытучыларына йөкләнде. Һәрхәлдә, мин шулай аңладым.

Татарга бүген икътисад, хокук, чит тел, компьютер белгечләре кирәгрәк дип уйлаганлыктан, мәҗлестәгеләрнең исә бездә шәригать сакчылары җитмәвенә аһ орuларын сизгәнлектән, димәк, безгә руханилар әзерләргә комарлануларын чамалаганлыктан, Татарстанга кайткач, мин төрек кардәшләр карарын һәм тәкъдимен «оныттым». Аларның бу ниятләре әлегә гамәлгә ашмаса да, без барыбер хәерхаһ җаннарга рәхмәт укырга тиеш: хәл итәсе үз мәсьәләләре дә бинихая күп булуга карамастан, алар ят дин, ят телләр диңгезенә батып йотылу хәвефе астында калган татарга ярдәм итәргә талпынуларын ап-ачык күрсәтәләр ич.

Төрек кардәшләрнең күңелләренә ятмаган фикерләремне тыңлаганда да кызып китмәүләрен, аларга кызыксынып колак салуларын, кунакчыллыклары һәм хөрмәтләре зурдан булуын, алдагы сәфәрем уңышлы дәвам итсен өчен башка шәһәрләрдәге дусларының адресларын язып бирүләрен, шуларга таянырга мөмкин икәнлеген искәртүләрен дә рәхмәт

хисе белән искә алмый булмый. Мин алар арасында утырганда татарның зарын да, дәгъвасын да белдерергә, шатлыгын да, кайгысын да икеләнми уртаклашырга мөмкин икәнлеген, бу гамәлләремнең теләктәшлек белән каршы алыначагын тойдым. Мондый мөнәсәбәт инде һич тә вак, әһәмиятсез нәрсә түгел. Дөньяда синең белән кызыксынучылар, сине аңларга тырышучылар барлыгын тою гына да кешене юата, тынычландыра һәм рухландыра, аны бәхетле итә ала. Капланнар өендәге мәҗлес исә сүздә генә теләктәшлек күрсәтү белән чикләнеп калырга теләми иде. Шундый ир-егетләре күп халыкка — безне үз хисаплаучы туганнарга бары кайнар мәхәббәт белән генә җавап бирергә мөмкин.

## ГҮНҖӘЛӘ НАЗЫ. ФИН БЕЛӘН ЧИН УРТАСЫНДА

Измир. Сентябрь азагы. Сәгать төнге унберенче. Диңгез култыгының шәһәрне икегә ярып кергән яры буенда — Каршыяка бульварында сәйран кылып йөрибез. Уң якта — кара кучкыл дулкыннарда тирбәлгән көймәләр, яхталар, эреле-ваклы кораблар, Каршыяка порты, кораб кору верфе. Сул якта — яктыга коенып утырган киосклар, хуш исле гөлчәчәкләр, йонлач юан кәүсәле, купшы озынча яфраклы пальмалар. Бу тирәдә култыкның киңлеге ике-өч чакрым чамасы, каршы якта — шәһәрнең тарихи үзәге, Ататөрек һәйкәле, банклар, кунакханәләр, шул исәптән, мин бер кич кунган «Марла» отеле, Измирнең символы булган сәгатьле манара, атаклы мәчетләр. Аллы-гөлле реклама утлары ике яктан да култык суында чагылганлыктан, дулкын шадралары фантастик төсләргә кереп ялтырый. Җылы — күпләр кыска җиңле күлмәктән, юка ак чалбардан яки шорттан. Хатын-кыз заты сирәк, ирләр, ирләр...

Каршыяка бульварында да, ярты төн якынлаша дип тормый, сәүдә кайный. Тәгәрмәчле мичләрдә кукуруз, каштан чикләвеге, тагын әллә нәрсәләр кыздыралар, җимеш, каһвә исләре борыныңны ярып керә. Нур чәчеп торган киоскларда — дистәләгән төр салкын эчемлек, сигарет, сагыз, акча тозагы булган бүтән вак-төяк. Мин шуларга кызыксынып күз сала-сала Мөслах белән Мәҗит уртасында атлыйм. Шулай бераз баргач, кунакчыл хуҗам миңа:

— Йә, әйт, нәрсә белән сыйлыйм үзеңне? — ди.

Яңа гына табын янынннан торып чыкканлыктан, тамак тук. Киоск витриналарына мин товарның матур капларына, этикеткаларына, төсле язуларына һәм сурәтләренә алданып кына карыйм — алар төнге утлар яктысында аеруча сокландырып, игътибарны үзләренә җәлеп итә.


Кинәт башыма бер сәер шаяру уе килә һәм мин Мәҗиткә:

— Әйдә бер тамаша ясыйк әле: ал шуннан бер сыра! — дим.

Гүя, мине бөтенләй ишетмәгәндәй, хуҗам ваемсыз гына атлый бирә. Нур сибеп, шаулап-гөрләп торган сәүдә нокталары артта кала. Ихтимал, Мәҗит тәкъдимемне ишетмәгәндер дә, бульварда гәп сатып сәйран чигүчеләр ишле, көймә-кораблардан җыр-музыка, һавадан акчарлаклар кыйкылдавы, якындагы асфальт юлдан автомобильләр гөрелтесе яңгырый — төрле авазлар бер дә тынып тормый. Мәҗит көне буе эшендә йончыган, бары хәзер генә киеренкелектән бушанып йөрүедер.

Диңгез буе бульварларында сәйран чигү хозур — халкы өч миллионга якынлашкан шәһәр сулышы монда аеруча ачык сизелә — кала якты тәрәзәләре белән өч яктан Измир култыгына карап утыра. Диңгездән салкынча-дымсу һава агымы исә — суүсем, йод, тагын бүтән тозлар эрегән нәни тамчылар шул һава агымы белән килеп бөтен бульварны тутыра, шәһәр тирәсендәге таулардан ишелеп төшкән ылыс исләре үпкәләргә янә дә тансыграк шифа бирә. Бу тылсымлы һава ваннасын төнге сәгатьләрдә — транспорт хәрәкәте, фабрикалар эшчәнлеге тыйлыккан чакта алу хәерле. Бульвар буйлап иплән кенә гизгәндә юлдашларың сиңа


шушы тирәләрдә моннан ике-өч мең еллар элек яшәгән халыклар, төрле риваятьләргә, дини кыйссаларга кергән мифик каһарманнар һәм тарихи шәхесләр, миллионнар хыялын биләгән вакыйгалар хакында сөйли. Колагыңны торгызып тыңла: шушыннан ерак түгел Халкапынар төбәгендә Измирне су белән тәэмин итеп тора торган чишмә һәм күл бар. Шуның яры буенда мәшһүр Диана — мәңге яшь сылу, гүзәл алиһә мунчасы урнашкан. Диана иптәшләре белән күңел ачарга, сунарга йөрергә, салкынча мәгарәләрдә — кеше күзе төшмәгән җирләрдә хәл алырга, сунардан соң мунча керергә һәм су коенырга яраткан. Мәңге яшь Диана коенган күл икәнлеген белгәч, бу шифалы чишмә һәм су буена чирләреннән арынырга, яшәрергә теләгән христианнар агыла башлаган. Хәзер бу күлдә, суын пычратмас өчен, коену тыелган — күл киртә белән әйләндереп алынган. Хәзер аның шифалы суын мөселманнар — Измир халкы эчә, аны авыз итеп мин дә бераз яшәрмәдемме икән әле?!



*Әфәстә Мәрьям ана йорты.*


Шәһәрне чыгып, көньяктагы Аладаг тавы түбәсенә күтәрелсәң, Иисус Христосның анасы Мария яшәгән өйгә тап буласың. Улы һәлак булгач, Мәрьям-ана Кече Азиягә христианлыкны таратырга киткән һәм шушында дөнья куйган, имеш. Изге бина хәзер меңләгән христианнар төрле гозерләре белән табынырга, өмет белдерергә килә торган җиргә әйләнгән. Мөселман төрекләр бүген дә ят диннең бу тарихи һәм риваяти һәйкәлләрен кайгыртучан саклый, христианнарның монда килеп гыйбадәт кылуына уңайлы шартлар тудыра. Әлеге корылманы, аның янындагы изге чишмәне, аңа алып килә торган юлны даими тәзек хәлдә тоталар, илгизәрләрне шунда сәйран чиктерү өчен заманча сервиз — менә дигән хезмәт күрсәтү белән тәэмин итәләр.

Тагын да көньяккарак, ягъни Измирдән сиксән чакрым чамасы китсәң, безнең эрага кадәр салынган атаклы Әфәс шәһәре хәрабәләрен күрәчәксең. «Диалектика атасы» Гераклит шунда туган, дөньядагы җиде могҗизаның берсе — Артемида сарае шунда салынган. Әфәслеләр аны сунар алиһәсе хөрмәтенә, риваятьләр раслаганча, 120 ел дәвамында мәрмәрдән корганнар. Аны күрүчеләр заманында сарайның гүзәллегенә сокланып туймаган. Герострат дигән бер тинтәк, үз исемен шулай тарихта калдырыр өчен, нәкъ менә шушы сарайга безнең эрага кадәр 356 елда ут төрткән. Сарай янган, тик аны яңадан торгызганнар. Ләкин тарихи бәрелешләр бу сарайны шуннан соң да аямаган — архитектура могҗизасын гасырлар дәһшәте ишкән-җимергән һәм комы, ләме белән күмеп



*Әфәс шәһәре хәрабәләре.*

киткән. Аның хәрабәләрен эзләп табу һәм замандашларыбызга ачып күрсәтү өчен 1863 елда археолог Вуд тарафыннан башланган казыну эшләрен егерменче гасыр башына кадәр дәвам итәргә туры килә. Нәтиҗәдә борынгы Әфәс шәһәре кешелек дөньясының гаять әһәмиятле цивилизация мәркәзе төсендә күз алдына килеп басты. Андагы биналарны, археологик табылдыкларны илгизәрләр, гадәттә, көне буе тамаша кыла,



*Пәргам. Борынгы театр.*

аннары шунда алган тәэсирләрен Измир археология музеена кереп тагын да тулыландыра.

Әгәр Измирдән йөз чакрым чамасы төньякка китсәң, Бергам шәһәренә килеп керәчәксең. Шуның янәшәсендә, тау башында борынгы Пергам каласы хәрабәләре белән танышырга мөмкин. Заманында шушында атаклы Искәндәр Зөлкарнәй талап җыйган хәзинәләр күмелгән, имеш. Безнең өчен тагын да кызыграгы — борынгы заманның «кәгазе» — пергамент нәкъ менә шушы шәһәрдә уйлап табылган һәм житештерелгән. Мисыр патшалары көнчелектән папирус бирүне туктаткач, пергамлылар бозау, кәҗә һәм сарык тиреләрен известь белән эшкәртеп, аны йонынnan арындырып һәм киптереп, акбур белән агартып, язар өчен яңа нәрсә барлыкка китергәннәр. Пергам китапханәсендә шул заман өчен (Б. э. к. 30 елда) гаять зур байлык — ике йөз мең данә кулъязма китап тупланган. Моның өчен ничә миллион тире кулланылды икән? Ләкин Измирнең диңгез буе бульварында йөргәндә бу хакта уйлап азапланасы килми!

Без инде хәзер кирегә — өйгә таба атлыйбыз. Аллеянең гөлчәчәкле ягына чыктык — чатыр шикелле пальмалар ябалдашы астыннан барабыз. Нур сибүче киосклар хәзер сул ягыбызда. Шуларның тагын берсе белән тигезләшкәч, Мәҗит миңа янә эндәшә. Бу юлы тәкъдиме, кыставы инде анығрак:

— Йә, кайсы белән сыйлыйм үзегезне: фанта алыйммы, кока-коламы?

Төшендем: бая ул минем җавабымны бик әйбәт ишеткән икән ләбаса! Әмма... хак мөселман башы белән, ничек инде ул хәмер саналган сыраны алып гөнаһка батсын? Хәмерсез эчемлек дисәгез, рәхим итегез!

Шушыларны уйлап алам да елмаеп кирелэнгән булам:

— Эчәсе килми әле, Мәҗит бәй.

Әмма хуҗам, тыштан беркатлы күренсә дә, чынлыкта үтә сизгер.

— Бервакыт, хәмер эчү катгый тыелган заманда, бер дәрвишне дөммә-дөм исрек хәлендә тотканнар,— дип сүз башлый ул,— аннары шундук казый алдына китереп бастырганнар. «Карале, син хәмер эчү катгый тыелуын белмисеңмени?!» — дигән аңа казый. «Ә мин — тиле»,— дип мыгырдаган дәрвиш. «Тиле икәнсең, нигә әйрән генә эчмәдең?» «Әйрән белән шәрабне бутарлык дәрәҗәдә үк тилермәдем әле мин»,— дигән дәрвиш.— Шулай,— дип елмайды Мәҗит,— без исә — бөтенләй аек, фанта белән сыраны да аера алачакбыз!

Мөслах дәшми. Чин иленнән — Кытайдан килсә дә, ул да динле. Чөнки алар Кытайның уйгырлар, казакълар, кыргызлар, үзбәкләр — мөселманнар күпчелек тәшкил иткән төбәгендә, төрки халыкларның ана ватаны Көнчыгыш Төркестанда гомер иткәннәр. Андагы татарлар да иманыннан аерылмаган, гореф-гадәтләрен әле дә кадерләп саклыйлар икән. Дин нигезләрен белү ягыннан хәтта андагы җирле мөселманнарны да уздырып җибәргәннәр. Шуңа күрә Мөслах үзе генә түгел, аның җиде-сигез яшьлек улы да табын яныннан киткәндә дога кыла.

Нәни Әсгать — полиглот, ягъни күп телләр белүче: Кытайда чакта уйгырча һәм кытайча аңлашкан, бер җәйне Алматада яшәгәндә урысчаны үзләштергән. Измирдә инде төрек мәктәбенә укырга кергән. Өйдә һәрвакыт татарча гына сөйләшәләр. Тик шунысы кызганыч: яңа телләр өйрәнә башлагач, ул элек үзләштергәннәрен оныта икән. Чөнки ата-анасы, белгәннәрен оныттырмау өчен, аңа тиешенчә булышмый — моңа ни вакытлары җитми, ни максатлары нык түгел. Бәлки әле моның өчен белем хәзинәләре дә чамалыдыр, әйтик, алар урысчаны Әсгать дәрәҗәсендә белми, чөнки Рәсәйдә яшәгәннәре юк, өйрәнү ихтыяҗы тумаган.

*(Ахыры киләсе санда.)*

# ШИГЪРИЯТ

**Әхмәт**

**Гадел**



## Казан белән серләшү

Төнге Казан зеңли, чыңлый, сыкрый Казан.
Кемдер кемнедер чакыра сыман төштә.
Гаҗиз тавыш. Газиз Казан. Ниләр язган?!
Йоклый кеше. Тик адашкан аваз күктә.

Юрган төсле җир өстендә шәмәхә күк.
Сакта торган сакчы кебек ай, йолдызлар.
Яши өмет: кеше торыр иртән иртүк,
Җәйрар, агар дулкынланып шат авазлар.

Килер дуслар, дусларының хәлен белер,
Нур сибәрләр урамнарга тәрәзәләр...
Гел шатлыкта кичсен иде безнең гомер!..
Тик әҗәлләр аша киләдер әзәлләр...

И, Казаным! Әгәр миңа бәла орса,—
Кем белә бит тәкъдиренә ниләр язган?! —
Зиндан эчен нурга күмеп иман кунсын,
Ислам нурың булып синең, Бөек Казан!

Таңгы Казан зеңли, чыңлый — сыкрый Казан.
Кемдер сәлам юллый сыман илаһ күккә.
Газиз тавыш. Газиз Казан. Ниләр язган?!
Ниләр бүләк итәр безгә яңа иртә?!

---

Әхмәт ГАДЕЛ (1942) — *шагыйрь; «Чаң», «Яшьлек урамы», «Көмеш кылган җыры» һ. б. китаплар авторы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

* * *

Тимер йөрәк булса иде,
Безне алга куса иде
Юллар буйлап, еллар буйлап...
Тимер йөрәк булса иде!

Үтәр идек җилләр аша,
Үтәр идек җирләр аша.
Агар иде безнең тормыш,—
Ап-ак сөтле елга булмыш!

Тимер йөрәк булса иде!
Уй-фикерне куса иде...
Алга-алга, туктамыйча,
Бер мизгелгә йокламыйча!

Без башкарган эш — тау кадәр.
Безнең җиңеш! Күрсәң әгәр!
Тимер йөрәк булса иде!

Тимерне дә тормыш изде...

*1993.*

* * *

Көз коя алтыннан мул итеп урманга,
Бар җирне төрә ул шул алтын юрганга.

Нигә соң, нигә соң юк аның җылысы?!
Йөрәгем җылысын ничек соң дөньяга юллыйсы?!

Хак икән, хак икән: җир өши, йөрәкләр суынса,
Кояш та елмая, кешеләр яшәү дип куанса.

Сагыну-сагышлар кимесә, җир йөзе — гөлләнә,
Хәрәкәт тизләнә, җир исә ятерәк әйләнә.

Йә, нигә кешеләр шуларны аңламый?!
Көз инде. Күк елый. Кешеләр нигәдер еламый...

*1992.*

## Кан

Мәскәүдәге вәхшилекләрдән соң.

Асфальтта ут-балан...
Юк!
Тамчы-тамчы кан!
Әрнегән кемнең җан?!
Нинди рух тәненнән вакытсыз аерылган?!

Асфальтта тамчы кан...
Тамчылап, тамчылап түгелгәнме заман?!
Тамчылап, тамчылап югалганмы иман?!

Асфальтта кызыл кан...
Бу илдә «утлы су» һәм шайтан хөкеме.
Күзләрдән моң качкан —
сәрхүшлык тәтене.
Рух авыру, иманны бастырыклый авыр хач:
Йә арын яшәүдән, йә илдән чыгып кач!!!
Асфальтта кыйммәт кан...
Һай, күп тә тамчылар!..
Ничә яшь пакь йөрәк хаинчә чәнчелгән!
Өметләр шартлаган, күкләргә очканнар,
Шайтаннар туй итә!
Мәләкләр качканнар!..

Асфальтта изге кан...
Гөнаһлар юыла...
Шайтаннар бер заман тәмугка убыла!
Кан аша — ут аша оча рух, китә җан...
Асфальтта мөкатдәс, бәһасез кыйммәт кан!

*1993.*

## Татар — һәйкәл

Бөтен татар иле —
Хаҗи Тарханнан алып, Обь ярларындагы Меңгазыйга тикле
кабер!!!
Буҗактан Татар Бугазына кадәр — кабер!!!
Әйтерсең лә биредә татар сөякләре тота бөтен җирне...
Татар биргән исемне йөрткән урыс авыллары,
чиркәүләре белән,
татар сөякләре өстендә!!!
Әйтерсең лә Яратучы — каберләргә күкне күпсенә.
Туна буйларында, Идел, Җаек, Ука,
Ерак Себердәге Зөя ярларында
Төннәрен, кабер ташларыннан корылган диварларны аерып,
Без оныткан мәетләр якты дөньяга, рухларын эзләп,
чыга.
Алар Хачлардан торган читәннәрне кичә алмый иза чигә.
Рух — җан бер якта, тән — икенчедә...
Әгәр иртән үләннәрдә, чәчәкләрдә көмеш чык күрсәгез, алданмагыз!
Бу — чык түгел, үлгәннәрнең кайнар күз яшьләре...
Дүрт йөз елдан артык Казан — шәһит киткәннәргә һәйкәл!
Исән калган әби-бабалар — һәйкәл.
Без — һәйкәл.
Балаларыбыз — һәйкәл!
Һәй, син, мескен, хәтере урланган татар баласы!
Каян гына табыйм чарасын,
Ничек кенә уятыйм син былбыл баласын?!
Үзең дә, нигә икәнлеген белмичә, җыр ишетсәң моңланасың,
һушыңнан язасың...

Беләсеңме соң изге Ибраһим каласын?/
Ак Тураны?!
Тотма Ныгырны?!
Таш Кирмәнне?!
Бал Тавын?!
Бел һәм яшен булып камчыла күкне, гөлт кабын!
Күңелләрдән юасы иде яла карасын...
Килмешәкләр астында калган тарихны ничек йолып аласы?!
Башкаларга нигез булган безнең тарих!
Ә без — татарлар — татарларга һәйкәл!!!

*1993.*

## Юлчы җыры

Сер тулы тормышның юллары,
Күңелнең түрендә башыгыз.
Хисемнең давыллы уйлары
Ташкандай киң җәйрәп, ташыгыз.

Ташландым хыялга — диңгезгә,
Упкыннар әзер юк итәргә.
Яшьлеккә кайтам мин — нигезгә
Тырышам ничек тә җитәргә!

Юлдашлар — минем чын дусларым
Чәчелеп калдылар елларда...
Бар микән ашасы ашларым
Ямь-яшел бакчалы гөл-ярда?!
Аллага тапшырдым үземне:
Тәкъдирдә ни язган шул булыр?

Сабырны бир, ходам, түземне...
Дәһшәткә юлларым ыргылыр!...

*1994.*



## Ләйсән

* * *

Һаман әле хыялыңда гизәсеңме?
Җаның инде таштай каткан, сизәсеңме?
Язың үтте, җәең җитте, беләсеңме?
Ә син әле көләсеңме?! Көләсеңме?

Мәңге язда үтәр минем еллар, дидең.
Көзең җитте — елар идең, елар идең.
Яңгырларың тутыктыра җан келәсен.
Һаман әле көләсеңме? Көләсеңме...

Ап-ак бәстә инде дөньяң — күрәсеңме?
Кышыңа да көлә-көлә керәсеңме?
Беләсеңме җаннан карлар көрәсеңне?
Өмет сула — сулышыңны өрәсеңме?

Гомер буе сине көттем — беләсеңме?
Әллә һаман көләсеңме? Киләсеңме...

* * *

... Елар әле, дидегезме,
Үксеп-үксеп, үкенеп —
Белдегезме, сиздегезме,
Көттегезме бу көнне?!

Инде көтәсездер, ахыры,
Мескен башын игәнне.
«Җүләр булдым. Гөнаһларым
Ярлыкагыз»,— дигәнне.

---

ЛӘЙСӘН — *яшь шагыйрә. Шигырьләре көндәлек матбугатта, шул исәптән журналыбызда да дөнья күрде. Казанда яши.*

Үксеп-үксеп елауларым
Үкенүдән түгел лә —
Ачы яшем җуләрлекне
Юксынудан түгелә.

* * *

Аңгырайдым — яңа гына... Яңа гына
Язмыш сукты яңгыратып яңагыма.
Яңгырлардай шыбырдады күз яшьләрем.
Өлешемнән көмеш көтеп күп яшәдем.
«Күп сорама — аз алырсың»,— диде аллам.
Ярар, ярар... Синнән башка яши алам.

Күңелләрем йодрыкланды. Күкне каргап,
Басып торам балбал сыман алга карап.

* * *

Учлап-учлап, ашыкмыйча, уйчан гына
Яңгыр сибә тамчыларын учагыма.
Утырам мин җиде юлның бер чатында,
Җиде төннең, җитмеш уйның кочагында.

Бер җилкәмнән җиде җилнең кулы какты.
Басып торам — җиде илнең җиде яты.
Бер узгынчы мин дөньяда — кемдер атым?
Җитмеш күзгә, җитмеш җанга барып бактым.

Җиде йозак күңелләрдә, җитмеш тозак.
Дәрвиш сыман йөрим Җирдә, бер ялгызак.
Җиде юлда адашканмын, кай чырак?
Җидегән йолдыз күктә дә соң... Йолдыз ерак.

## Көзге этюд

Тагын килдем, кайткан сыман үз ягыма,
Алтын моңнар, кызгылт-сары сагыш иле.
Мин ят түгел монда — әнә, аягыма
Килеп ятты, чиный-чиный сукбай җилең.

Синең балаң, җанда саклыйм сагышыңны.
Язмышымның җиле тисә әз генә дә.
Синең соңгы сары ертык яфрагыңдай
Бәргәләнәм, теткәләнәм, өзгәләнәм.

Елыйм әле, яңгырларга бер иш булып.
Бушанганчы, ышанганчы бушлыгыма.
Шундый рәхәт елый синең яңгырларың,
Дөнья елый әкрен генә, кушылып кына...

Исергәнче сулап калыйм салкыныңны.
Озак тормам, тора алмам кунак булып.
Кошлар киткән якка таба, алгысынып,
Томырылып-томырылып китте болыт.

Торсын шулай агачларың мине көтеп.
Алып китәм күңелемдә сары көзне.
Озатырга чыккан юеш сукбай җилең
Саклап калды яңгырлардан минем эзне.

## Шигырь-шыгыр

Шыгыр-шыгыр —
ачык ишек.
Шыбыр-шыбыр —
түбә тишек.

Яраларда
ярсый җилләр.
Яңгыр елый:
җуләр, җуләр...

Җилләр түгел,
җеннәр түгел —
Яши монда
ялгыз күңел.

Шыгыр-шыгыр
ватык йозак...
Шыгыр-шыгыр —
вакыт тозак.
Шыгыр-шыгыр —
ишек ачык...
Тик шигырьдән
булмый качып.

## Шунда...

...Таң көтә-көтә
кич житкәннәрем,
Ашыгып барып
кичеккәннәрем...

Булган икән бит
югалтканнарым —
Шунда икән бит
бар тапканнарым.

* * *

Тормыш ярып барам,
Язмыш ертып —
Йолдызыма таба ашыгам.
Офыкларсыз дала булып, әнә
Җәелгән бит гомер
Каршыга.

* * *

Мизгел булып өзелеп төште сары яфрак —
Гомеремнең сары көзе җиткән икән.
Усал җилләр йөрәгемне үтә тырнап,
Бәхет кошы киткән икән, читкә киткән.

Мизгел кебек тынып кына тамды тамчы —
Күрмәгәнмен, болыт сарган тормыш күген.
Кояшымның соңгы нуры, ашыкмачы!
...Яңгыр булып елый икән күңел бүген.

...Мизгелләрдәй җемелдәшеп карлар ява.
Юлларыма ап-ак бәхет салган икән,
Күктән иңгән шатлык ала күзнең явын...
Сабыр кошым китмәгән шул, калган икән.

## Чәчмә әсәрләр



## Локман Закир

# ГӨРГӨРИ

(ГЫЙБРӘТЛЕ ХИКӘЯТ)

**Тимерче Фатыйх улы Локман Закир, офицер буларак, хәрби хезмәттә шактый гомерен үткәргән. Туган ягыннан читтә яшәсә дә үз телен-денен онытмаган, әмма русча язарга күнегеп киткән. «Мин элеккеге халык укытучысы, элеккеге коммунист»,— ди ул ярым шаяртып.**

**Локман Закир яшьтән үк үзе өчен генә әсәрләр язган. Цензура балтасы кайраулы елларда аның кыю фикерле, «чәчәк аткан» социалистик җәмгыять аһәңенә туры килми торган язмалары, әлбәттә, дөнья күрә алмый иде. Хәзерге көндә тарихка, милләт язмышына караган төпле язмалар еш басыла, дистә еллар буена җиде йозак астында яткан хакыйкый документлар калкытыла, социаль фикер үсеше көнләп-сәгатьләп кешенең аңын били бара. Локман Закирның да соңгы елларда саллы язмалары газета-журналларда күренә башлады.**

**Журналга без аның 1975 елда язылган «Гөргөри» дигән гыйбрәтле хикәятен тәрҗемә итеп, бераз өлешен кыскартып бирергә булдык. Үз вакытында чыкса, бомба булып шартлыйсы кайбер фикерләре, бәлки, бүгенге күзлектән караганда гадәтигә әйләнгәндер. Әмма барыбер әсәр әдәби җирлеген, үткенлеген җуймаган.**

**Локман Закир дәррәү ачылып китми торган, тыйнак шәхес. Ул журналист яки язучы исемен дә дәгъвалап йөрми. «Фикерләрем башыма сыеп бетмәгәнгә, баш мием шартлар дип куркып язам»,— ди ул.**

**Укучым, әсәр синең алда, һич үкенмәссең, бисмилланы әйтеп кулыңа ал...**

**Хәерле сәгатьтә!..**

**Марсель ГАЛИЕВ.**

•

«Житмәсә көне эссе... Бу чыпчыклары тагын туктаусыз чыркылдаша...»

Чәчәк түтәле янында эскәмиядә утырган взвод командиры Вадим Сергеевнең бүген бер дә кәефе юк иде. Фуражкасын салып, ул тирләгән маңгаен сөртте дә куаклар күләгәсенәрәк күчеп

утырды. Бу ел да үз кул астына эләккән яшь солдатлардан уңмады, ахрысы. Былтыр бер үзбәк егете белән изаланган иде. Сүгенүдән кала ник бер авыз сүз русча белсен теге. Быел тагын взводка урыс булмаган ике егет эләккән. Берсе — Казан тирәсеннән, укытучы, русча бик яхшы белә белүен дә... холкы үҗәт, тыңлаусыз, киребеткән, кече командирларның бер генә әмерен дә телләшү-әрсез үткәрми. Аның күкшел, буйсынмас күз карашы һәр командирның ачуын кабарта, сәбәпсез дә шелтә белдерүне үзеннән-үзе сорап тора. Инде күпме җәза алды югыйсә, юк, игә килми, нәкъ менә рапорт вакытында башын боргалап сафта басып тора бит күсәк. «Смирно!» командасына ике минут та үрә катып тора алмаган солдат солдат мени ул!

Өлкән лейтенант Сергеевка шул Хөсәен Исмәгыйлов аркасында командирларыннан күпме эләкте, бүтән ротага күчереп котылырга иде дә ул күсәкне... Юк шул, ансат кына ычкындырып булмый, взводта икенче бер имгәге бар бит әле аның. Анысының телен белеп, тәрҗемә итә алган да шул ук Исмәгыйлов. Менә шул Григорий Степанов дигәне тагын да сәеррәк. Армиягә кадәр ул Каманың Иделгә кушылган төбәгендәге бер авылда, дөнья күрмичә йомыкый гына яшәгән. Русча ник бер кәлимә сүз белсен, ул гынамы, сафта барлау вакытында, Степанов, дип дәшкәнгә дә илтифат итми. Бала чактан ул исемен Гөргөри дип әйткәнгә генә күнегеп үскән икән ул. «Әгәр взводта шул сәер татар Степанов булмаса, мин татар Исмәгыйловтан җиңел генә котылыр идем. Туктале! Нинди татар инде ул, йә?! Степанов Григорий Иванович. Үзе зәңгәр күзле, сары чәчле. Муенына тәре тагып килгән иде. Өздереп ыргыттым анысын. Бәлки, ул ялган докуметлар юнәткәндер? Булыр да. Мондый татарны минем гомеремдә күргәнем юк иде. Мин генә түгел, хезмәт дәверендә Россияне иңләп-буйлаган карт офицер — комбатның да күргәне булмаган, белми андый татар барлыгын. Хикмәт нәрсәдә? Бәлки, ул солдат икейөзләнәдер. Махсус бүлеккә әйтергә туры килер. Тикшерсеннәр. Алар өчен менә дигән табыш булып чыкмагае... Юк, юк! Башта үземә ачыкларга кирәк. Мәскәү университеты ромбигы тагып йөргән башым белән җүләргә калыйм тагын. Бәлки, ул чынлап та милләте белән татардыр, урыс фамилиясе генә алгандыр. Нигә соң ул алай булгач Исмәгыйловка бер дә охшамаган, ә икенче взводтагы Петров белән ике тамчы су кебек. Суйган да каплаган Петров инде!»

Шундый уйлар белән гаҗизләнеп йөргән өлкән лейтенант Сергеев бер көнне рядовой Степанов белән Исмәгыйловне рота канцеляриесенә әңгәмәгә чакыртты.

Менә ул — тәмәке төтененнән ысланган бүлмә. Снаряд гильзасыннан кисеп эшләнгән көлләвечтә нинди генә сигарет һәм папирос төпчекләре юк. Өлкән лейтенант Сергеев рота командирының иркен урындыгына утырып, алдына кәгазь битләре куйды, ручкасын алган булды. Ярдәмчесе — мәҗбүри хезмәттән соң яңа срокка калган сержант Васильев өстәлнең уң ягына утырды. Рядовой Исмәгыйлов белән Степанов стена буеннан урын алдылар.

— Татарга һич тә охшамаган бу,— дип сүз башлады командир,— чын-чынлап рус егете, күр инде. Моңа караганда татарга син охшаганрак,— дип, сержантка бармак төбәп алды ул.

— Шулайдыр,— диде сержант.— Рус телен белмәвенә ышанырлык түгел. Симулянттыр ул... үзе — Григорий Иванович. Кирәк бит, ә!

— Гөргөри мин, Чипанов мин,— дип нидер аңларга тырышып мыгырдана башлаган Степановны Хөсәен җиңеннән тартып туктатты.

— Менә ычмасам Исмәгыйлов татар тек татар! Моңа бераү дә шикләнә алмас,— дип сөйләнде сержант.— Кап-кара чәч... Менә, менә, иптәш өлкән лейтенант, карагыз әле! Нәкъ менә Исмәгыйловка охшашлар! — дип, ул «Огонек» журналының тышлыгын күрсәтте. Анда орденлы Татарстанның алдынгы нефть чыгаручылары төшерелгән иде.

— Дөрес әйтәсез. Мин — чын татармын. Ә Гөргөри — керәшен. Бездә алар хәтсез... Ике ел элек минем апам керәшен егетенә кияүгә чыкты да... Мин аларның авылына кунакка бардым. Аңа кадәр мин дә керәшеннәр барлыгын белми идем,— диде Хөсәен.— Ислам динендәге чын татарлардан аермалы буларак, алар Христоска табыналар. Авылларында, фәкыйрь генә булса да, чиркәү бар. Рус исемнәрен кушсалар да, берсе дә рәтләп рус телен белмиләр алар.

Керәшеннәр — Иван Грозный варислары, мәктәптә укыгансыздыр инде?

— Белмәскә,— диде командир.— Әйе, кайчандыр Иван Васильевич яшәгән...— Офицер башы белән солдаттан күбрәк мәгълүматлы булырга тиешлекне искәртергә тырыша иде ул.

— Паспортка керәшеннәрнең милләте татар дип язылган. Исемнәре русныкы булса да, керәшеннәр аны үзләренчә үзгәртеп әйтәләр,— диде Хөсәен,— мисал өчен: Яков — Җәкәү, Евдокия — Аудрый, Тимофей — Теми, Григорий — Гөргөри.

— Шулай! Дөрес, кап дөрес! — дип, таныш сүзләр ишеткәч кыбырсып куйды Гөргөри.— Чипанов, Чипанов Гөргөри мин. Ул алдашмый.

— Әгәр сез керәшенгә кайчандыр элек мөселман булгансың, сине Иван Грозный чукындырган, дисәң, чынлап әйтәм, бугазыңа ябыша. Мин моңа үзем шаһит булдым. Менә сез юри, сынар өчен генә, Гөргөридән сорап карагыз әле...

Өлкән лейтенант белән ярдәмчесе тоташтан тартып утырган җирдән сигаретларын басып сүндерделәр дә Хөсәенгә ым кактылар. Хөсәен, Гөргөригә борылып, татарчага күчте:

— Синең борынгы мөселман бабаларың Аллага болай табынганнар бит, әйеме? — дип, учларын кушырып, дога кылгандай, битенә якын китерде.

— Булмас! Булмас! — дип Гөргөри урыныннан калкынып куйды. Күзләре ут янып чыкты.— Сүләмә юкны! — дип ул, гөнаһлы сүзләрне үз тирәсеннән куарга теләгәндәй, ашыгып-ашыгып чукынырга тотынды.

— Кызык бу! — дип, өлкән лейтенант Сергеев башын кашып куйды.— Йә, тагын ниләр?!

Командирының әсәренеп китүен күреп, Хөсәен тагын да илһамланыбрак фәлсәфәгә бирелде:

— Керәшенне киредән мөселманга кайтарам димә. Кайчандыр Иван Грозный мөселманнарны, явызлык кылып, христианлаштырган бит. Шуның кебек, коточкыч көч кулланып кына керәшеннәрне кабат мөселман итәргә мөмкин. Куркытып буйсындыруның хикмәте нәрсәдә? Һәммә бәндә яшәргә тели. Кеше физик һәм рухи сызлануга түзә алмый. Яшәү теләге көчле булганга күрә, бәндә физик һәм рухи җәзага түзә алмыйча, үз асылын алыштырырга мөмкин. Иван патша моны яхшы белеп эш иткән. Ул татарлардан Чыңгыз хан өчен үч алган, әлбәттә, христианлашкан татарның яңадан беркайчан да мөселманлыкка кайтмасларына ул чакта Иван Грозныйның ышанычы булмаган.

— Иван Васильевичның усал патша булуы тарихта билгеле, әлбәттә. Ул хәтта үзенең малаен да сөңге белән кадап үтергән,— дип сүзгә кушылды өлкән лейтенант.— Тик менә... Татарларга карата шундый явызлык кылуы хакында гына беренче тапкыр ишетүем. Бер генә китапта да бу хакта әйтелмәгән ич.

Гөргөри бу мәлдә сүзсез генә утыра, әңгәмәнең ни турыда баруын ул сизенә, әмма ни сәбәптән кузгатылуын гына төшенә алмый иде. «Командирга минем милләт-чыгышым нигә кирәк булды икән? Керәшеннең кайчандыр мөселман булганлыгын тануы — ул үзеңнең ихтыярсыз, көчсезлегеңне тану, борынгы ата-бабалар рухын рәнҗетү дигән сүз. Эчке оят турында кычкырып әйтмиләр. Әнә бит безнең авылда күптән түгел генә Минкәш улы Теми өйләнгән иде. Шәп! дигән була. Ә үзенең шәп дигән чакта ирене тартышып куйды. Аудинең (Авдотья) кем икәнен мин бел-

мимме?! Теми солдатта чакта минем кочактан чыкмады. Чак бала тапмыйча калды. Бу хакта белсә дә, ир кеше тешен кысып булса да түзә шул. Шәп диган була. Нәкъ менә шундый хәлдә шул без керәшеннәр дә. Мөселман булмаганбыз, дидем дә... Иренем тартышып куйды... Әгәр мин куркаклыгым аркасында христиан Гөргөри булганмын дисәм, нинди кыз миңа карар иде микән? Куркак, сатлык, диячәкләр алар. Кыз-кыркын батырларны ярата. Иң дөресе — бу хакта дәшмәү. Заманалар үзгәреп китәр дә ни татарың, ни керәшенең калмас әле. Ул чакта безгә, керәшеннәргә, чын татарларга караганда җиңелрәк тә булачак. Чөнки безнең исем-атларыбыз русныкы кебек үк. Кыяфәткә дә охшашлар. Паспортка «русский» дип тамга чәписе дә... Телне өйрәнеп аласы да... Әйе, чын татарларга кыенга киләчәк. Аларның бит күз төсләре дә чем-кара, кайберләренең монголныкы кебек кысык та әле җитмәсә, күбесе, безнең кебек үк, русча начар сукалый. Миңа калса, руслар үзләре дә татарларны руслаштырып, үз милләтенең канын бозарга теләмәсләр...» Әнә шулай эчтән уйланып утырган Гөргөри үзаңы белән бүген беренче тапкыр керәшеннәрнең асылына төшенергә тырышты.

Сержант Васильев сүзсез генә утыра, университет белеме алып чыккан командирының да керәшеннәр тарихын белмәвенә, үзенең җиде класс очлаган авыл гыйбаты, сержант дәрәҗәсендә генә калуына сөенеп, эчтән канәгатьләнеп, төкереген ләззәтле йотып утыра иде.

Үз милләтенең тарихын белүдә танылып өлгергән Хәсәенгә командир, үз тиңе итеп, сигарет сузды, сержант исә ялагайланып диярлек, ут элдерде. Гөргөригә дә тартырга рөхсәт иттеләр. Тик ул өстәлдә яткан зажигалканы кыюсыз гына үрелеп алып, үзе кабызды. Хәсәен тәмәке өчен рәхмәт әйтте, тәтенне эчкә суырып, бер мәлгә оетып торгач, рәхәт исереп киткән кебек булды һәм үзен командир белән бер дәрәҗәдә итеп тойды. Бераздан соң гына фәлсәфәгә кереште:

— Керәшеннәр хакында ишетмәвегез дә бар. Ә менә Казан татарларының килеп чыгышын беләсезме? Безнең борынгы бабаларыбыз болгарлар булган, диләр.

— Беләсезме дип...— Өлкән лейтенант Сергеев тәмәкесен сүндергән булып әвәрә килде. Шул арада сүзгә сержант Васильев кушылды:

— Аны җүләр дә белә! Безнең изге Русебыз ничәмә гасыр татар кул астында иза чиккән. Башымны кисмәгә бирәм: татарлар Чыңгыз ханнан яралган. Моны белү өчен академия бетерүнең һич тә кирәге юк!

— Миңа калса, сержант Васильев дөрес сукалый кебек,— дип, взвод командиры яңа сигарет алып кабызды.— Болгарлар православие диненда, телләре дә русчага якын, тылмачсыз да аңлашырга була, исемнәре дә безнеңчә.

— Дин башка мәсьәлә,— диде Хәсәен.— Менә мин татарларны ничек чукындырулары турында ишеткәнем бар. Аларны Идел-Кама буйларына куалап китергәннәр дә суга тутырганнар. Поп әмере буенча, суда билдән торган татарлар чукынырга тиеш булганнар. Кем карыша — шуны батырып үтергәннәр. Барысын да, балаларына кадәр... Идел төбендә мәңгегә ятып калырга теләмәгәннәр христиан динен кабул итәргә мәҗбүр булганнар. Чукындыруны мулладан башлаганнар. Әгәр мулла риза икән, бөтен авыл диярлек аның артыннан ияргән. Ә инде мулла каршы килсә, авылның ирләре урманнарга, тауларга качып киткәннәр. Иван Грозныйның гаскәриләре үз хезмәтләрен тирәнтен аңламыйча гына башкарганнар. Хатын-кызларны чукындыру белән күбрәк шөгыльләнгәннәр. Рухи чукындыру процессы исә күпкә катлаулырак... Хатын-кызларны корал белән куркытып, көчләп чукындырганнар. Якларга ирләре янда булмагач, алар үзләрен гөнаһ кылган итеп санамаганнар. Ә инде күңелдән, эчке иманыңны үзгәртеп чукынмагач, Алла каршында үзеңне рухи чиста калам дип исәплисең. Моның нәтиҗәсе шуның белән бетә: татар рухлы, рус чырайлы яңа буын татарлар туа... Шулай дип сөйләгән иде миңа бер бабай.

Хөсәеннең бу гыйбрәтле хикәятен тып-тын калып тыңладылар. «Менә сиңа фәлсәфә: рухыңны бирсәң, тәнеңне саклыйсың, тәнеңне бирсәң — рухың сау кала... Иван Васильевич күрмәгәнен күрсәткән икән татарларга. Менә шуның тере бер мисалы инде бу! Тeленнән, рәсми документыннан кала, бер генә дә татарлыгы юк бит бахырның»,— дип уйлаган өлкән лейтенант керәшен егетенә тагын сынап-текәлеп карады.

— Иван Васильевич хакында мин дә кайбер нәрсәләр беләм,— дип, ул Хөсәеннең тәмәкесенә ут бирде дә, тавышына ниндидер сер төсмере биреп, салмак кына сөйләп китте.— Син Иван Грозныйның яшерен хәзинәсе турында ишеткәнең бармы? — дип Хөсәенгә төбәлде. Аның өчен бу мизгелдә гүя сержант та, Гөргөри дә юк иде.— Мәскәү университетында укыган чагында моны безгә карт бер ассистент сөйләгән иде.

Әмма өлкән лейтенантка тәмләп сөйләргә насыйп булмады, ишектән каударланып рота старшинасы килеп керде. Ул кичке барлауның нәтиҗәсе хакында үрә катып рапорт бирә башлауга, бөтенесе дә торып бастылар.

* * *

Өлкән лейтенант Вадим Сергеев, өенә кайтып ашап-эчүгә, Валерий Костылевның өч томлыгын кулына алды. Кайчандыр икенче дәрәҗә Сталин премиясе алган язучының бу китабын ашыгып актара башлады. Укыды-укыды да, ах, шайтан алгыры! дип сүгенеп куйды, тарихи китап санала, бер генә урында да вакыйгаларның еллары күрсәтелмәгән. Толстойның «Сугыш һәм дөнья»сында әнә вакыйгаларның минуты-сәгате төгәл бирелгән.

Аптырагач, Сергеев кухня якта табак-савыт юып маташкан хатынына дәште:

— Галя! Костылевның «Иван Грозный»ын укыганың бармы синең?

— Көләсеңме әллә, Вадим?! Ул бит тарихчыларның өстәл китабы. Минем диссертация темасы да Иван Васильевич эшчәнлеге белән бәйле ич. Бик дефицит китап ул! — дип Галя килде дә, шелтәләгән сыман итеп, иренең беләгеннән чеметеп алды.

— Моның бернинди дә тарихи кыйммәте юк! Бу вакыйгаларның кайчан барганын төгәл генә әйтеп бирә аласыңмы, йә?!

— Иван Грозный яшәгән чор буенча чамалап... 1530—1584 еллар диярга була... Син, Вадим, шедевр әсәр турында алай җиңел генә хөкем чыгарма.

— Бәгырькәй, керәшен татарлары хакында ни дә булса беләсеңме син? Әллә минем кебек бихәбәрме?... Синең Иван Васильевичың аларны көчләп чукындырган икән бит.

— Нинди татарларны әйтәсең? Казаннныкылар бар, Себер татарлары... Алтын Урда калдыклары... Каян чыккан ди ул керәшен татарлары?! Россия халыклары тарихын, һәрхәлдә, мин синнән яхшырак беләм дип уйлыйм...

— Диссертация язып маташсаң да, тарих буенча мине узып әллә ни сикерә алмыйсың әле. Бу очракта белемең бигрәк тә сай күренә. Син Кырым татарлары турында да белмисеңдер әле. Илне сатканнар, дип аларны Сталин, Берия ялчылары Себергә, Төркестанга сөргәннәр. Кырым автономияле республикасы шул чактан бирле өлкә итеп үзгәртелгән... Бер караганда, керәшеннәр турында белмәвебезгә гаепле дә түгелбездер, чөнки ул хакта ВУЗ дәреслекләренә кертелмәгән.

— Бәлки Зур совет энциклопедиясендә бардыр?..— дип Галина китап шкафына үрелде, калын фолиантны алып актарырга тотынды.— Менә таптым! «Керәшеннәр Казан татарларыннан чыккан этнографик группа. XVI—XVII гасырларда православиегә күчкәннәр. 1926 елда аларның саны йөз мең булган...» Әйе, бу минем өчен яңалык. Ләкин керәшеннәрне

көчләп чукындыру турында монда берни дә әйтелмәгән. Бәлки алар үз теләге белән православиегә күчкәннәрдер?.. Казан ханлыгын Россиягә кушу уңай күренеш булган кебек, татарлар бәлки чукынып бәхеткә ирешкәннәрдер?..

— Арттырасың, бәгырькәй! XVI гасырда татарга үз теләге белән бүтән дингә күчү үлем белән бер булгандыр. Хәтта XX гасырда да бу бик авыр эшләнә. Денен, иманын сату бирәүгә дә җиңел бирелми. Бигрәк тә үзсүзле, үҗәт татарларга... Әнә мин ротада бер татар солдаты белән ике ай чиләнәм инде, «смирно!» командасына кыл кебек торырга һаман да өйрәтә алмыйм. Әмма бүген егет белән нидер булды. Бәлки, минем якыннан торып сөйләшүем ярап куйгандыр. Икенчесе — керәшен татары Степанов, киресенчә, шулкадәр күндәм, тыңлаучан. Төн уртасында уятып бәдрәф чистартырга куш — бернинди ризасызлык белдермәс, ни өчен җәза бирелүен дә сорап тормыйча эшкә ябышыр. Әйе, әйе! Шушы ике татарның ике төрле холкына карап мин, тарихчы буларак, гадел хөкем чыгара алам. Димәк, гаярь холыклы татарлар ислам өчен җанын биреп, христиан диненә күчәргә теләмәгәннәр. Рус теленә: «упрямый как татарин» дигән гыйбарә юкка кермәгәндер. Ә инде юаш, күндәм татарлар үзгәртү шаукымына тиз бирешеп, керәшен булып киткәннәр. Минем ротадагы Хөсәен әйтә, Казаннан йөз илле чакрымнар ераклыкта чукындырудан качып киткән татарлар яшәгән мәгарә бар, ди.

Ни хикмәт, өлкән лейтенантның уй сөреше бүген гел шушы тирәдә кайнаша иде. Алтын Урда, Казан ханлыгы турында язылган бүлекләрне ул дикъкать белән укып чыкты.

«Алтын Урда таркалганнан соң, Урта Иделдә башкаласы Казан булган феодал дәүләт — Казан ханлыгы оеша (1436—1552 еллар). Казан ханлыгы 1236 елда татар-монголлар яулап алган Болгар, Идел-Кама территорияләрен били. 1445 елда Алтын Урда ханы Олугъ Мөхәммәт улы Мәхмүт тәхеткә утырган дәвердән Казан ханлыгы чоры башлана. Бу ханлык оешу килмешәк татар-монголлар тарафыннан Идел буе болгарларын ассимиляцияләүне көчәйтеп җибәрә. Татар-монгол изүе астында Казан ханлыгының хуҗалык-көнкүреш үсеше тоткарлана».

— Күр әле, Галя, парадокс монда! Казан ханлыгы татар-монголлар тарафыннан оеша, ди үзе. Бәс, шулай булгач, үз-үзләрен изеп торалар булып чыга түгелме?!

— Тарих буталчык инде ул... Укы әйдә...

— Монда тагын аермалык килеп чыга! 310 биттә, 1236 елда татар-монголлар яулап алгач, Казан ханлыгы Болгар, Идел-Кама территориясендә оеша, диелә. Ә менә 313 биттә болай ди: «... XIII гасырда, Бату яуларыннан соң монда Болгар шәһәрчекләре калка...» Хатамы бу, ялгыш басылганмы? — дип Вадим Сергеев ары таба укып китте:

**«...В 1551 году вблизи Казани была создана русская крепость Свияжск. 16 июля 1552 года Иван IV во главе большого войска выступил из Москвы в новый поход на Казань. В результате быстрого искусного похода (30 км в сутки) все русские военные силы (около 150 000 человек и 150 орудий) были уже к 13 августа у Свияжска. К 23 августа Казань была окружена кольцом русских войск. После отказа казанцев сдаться, город был 2 октября 1552 года взят после ожесточенного штурма. С взятием Казани закончилось самостоятельное существование Казанского ханства. Вслед за этим 1552—1557 г. г. были присоединены к русскому государству Среднее и Нижнее Поволжье и Башкирия, свою зависимость признали Ногайские мурзы, северокавказские владетели, Сибирский хан.**

**Казанское взятие произвело огромное впечатление на современников. Подвиг этот воспевался в песнях и описывался в литературе. В честь победы был построен великий памятник русского зодчества — храм Василия Блаженного. Завоевание Казанского ханства имело большое историческое значение.**

**Присоединение Поволжья к России было глубоко прогрессивным явлением для народов Среднего Поволжья и Приуралья. Оно спасло их от угрозы порабощения турецкими ассимиляторами «наиболее жестокими из всех ассимиляторов»** *(И. В. Сталин, Соч., т.* II, стр. 347).

— Әйдә әле, булачак фән кандидаты, кил яныма, укып җибәр әле Иван патша хакында!

— Үзең укы! Иван Васильевичның бөтен гомер юлын яттан сөйли алам мин сиңа,— дип, Галина горур гына үз бүлмәсенә кереп китте. Сергеевка, берьялгызына хозурланып, тарих төпкеленә төшәргә калды. Казан, Әстерхан, Себер ханлыкларының Россиягә «кушылуы», Кабардин һәм черкәс кенәзлекләренең дә вассаллыкны тануы хакында укып килде дә ныклап Иван Грозныйга тукталды:

«Иван IV атаклы тарихи шәхесләрнең берсе. Көчле ихтыярга ия буларак, ул алга куелган максатына ирешү өчен бөтен көчен җигә торган була. Тарихи әдәбиятта Иван Грозныйның шәхесенә һәм эшчәнлегенә карата сәяси-классик позициядә торган авторлар тарафыннан төрлечә караш яшәп килде. Самодержавиенең реакцион идеологиясен яклаган Н. М. Карамзин Иван Грозныйга карата тискәре караштa тора, «коточкыч террор», канлы чорларның сәбәбен патшаның «явыз рухыннан» күрә. Иван Грозный эшчәнлегенә асыл бәяне бары тик марксизм классиклары гына бирә алды. ВКП(б) Үзәк Комитетының «Олы тормыш» исемендәге кинофильмга карата чыгарган карарында (4.09.1946 ел) Иван Грозный «көчле рухлы шәхес» диелә».

Өлкән лейтенант Вадим Сергеев кирпеч калынлыгындагы энциклопедия томнарын йотылып укыды да укыды. Төн уртасы авышканда күрше бүлмәдән хатынының ягымлы-мут тавышы ишетелде:

— Вадим, йокларга вакыт!.. Бер утыруда бөтен тарихны айкап чыга алмассың барыбер...

* * *

Йомшак мендәргә башын төртүгә, Вадим Сергеев хәрбиләрчә каты йокыга талды... Берничә минуттан ул, ике солдат ияртеп, Мәскәүнең үзәгендә, патруль сыйфатында йөри иде инде. Зур-зур тәрәзәле магазин витриналарында карабин тотып «на караул!» баскан манекен солдатлар күренә. Кремль курантлары төнге уникене сукканда, тып-тын Кызыл мәйданда хәрбиләрнең үзара татарча сөйләшеп килгәннәре ишетелде. Хөсәен белән Гөргөри дә, патруль җитәкчесе өлкән лейтенант Сергеев та алар белән татарча сөйләшә иде. Кремль дивары яныннан барган вакытта хәрбиләр бик нык яктыртылган урында туктап калдылар. Якты уртасында борынгы киемнән, кулына чукмар башлы бик затлы таяк тоткан ир кеше басып тора иде. Якынрак килеп карагач, Сергеев аны танып алды. Бу кеше — Иван Грозный үзе иде! Каушап калган Хөсәен белән Гөргөрине өлкән лейтенант, татарча эндәшеп, үз янына чакырды.

— Здравия желаю, Иван Васильевич! — дип, ул җәһәт кенә честь бирде. Әмма кырыс чырайлы Иван патша тешләрен генә шыкырдатты.

— Миңа эндәшергә ничек батырчылык итәсең, көчек! Хәзер үк каршымда тезлән, маңгаеңны ташка ор! — дип, падишаһ таягын шакылдатты.— Иван Васильевичыңны күрсәтермен мин сиңа! Мин — падишаһ галиҗанәбләре, Русиянең олугъ кенәзе! Җитмәсә үз кешеләрең белән татарча сөйләшеп киләсең — моның өчен үлем дә аз сиңа! Эшемә кирәксезгә тыгылган өчен мин хәтта үз малаемны да дөмектердем...

Иван Грозный алтын җепләрдән тукылган чапаннан иде, аның һәр әйткән сүзе шулкадәр кодрәтле чыга иде, хәтта Сергеев үзенең коралы барлыгын да, патруль башлыгы икәнен дә онытып җибәрде. Падишаһ боерыгына буйсынып, ул тезләнде һәм маңгаен ташка орды. Хөсәен

белән Гөргөри дә командирны кабатладылар. Күпмедер вакыттан соң падишаһ, таягын шакылдатып, боларга торырга боерды:

— Сине һәм дә синең адәмнәреңне теге дөньяга олактырырга өлгерермен әле, хәзергә сез миңа кирәк. Менә дүрт йөз ел инде җир йөзендә ниләр барганын шушы төштән күзәтәм мин,— дип сүз башлаган падишаһ диварында шәмнәр янып торган тарлавыктан хәрбиләрне ияртеп алып китте.— Күпме еллар инде адәми затларның күзен ачарга телим, әмма барып чыкмый.— Падишаһ аягына уралып комачаулаган чапан итәген җыебрак тотты.— Мин сезне үзем патшалык иткән чакта төзеткән яшерен мәгарәмә алып барам. Берәү дә белми анын кайда икәнен. Бер мин генә беләм...

— Ничек алай, галиҗанәб падишаһ?! — дип көтмәгәндә бүлдерергә җөрьәт итте Сергеев.— Бу кадәр зур мәгарәне берүзегез төземәгәнсездер ич, анда күп кешеләр катнашкандыр?

— Юк инде, угланым! Әгәр син төзетсәң, бер рота солдат китерттерер идең, мөгаен. Алар соңыннан синең сереңне дөньяга сибәрләр иде. Ә мин синнән акыллырак. Дөрес, башта мин да шулай иттем: Костромадан утыз оста чакыртып, сарай яраны күзәтчелегендә эшләттем. Мәгарә төзелеп беткәч, һәр остага бер бүрек алтын биреп Мәскәүдән төнлә чыгып китәргә боердым... Аларны озаткач, яраным колагыма: «Мәгарә хакында утыз адәм белгәч, анын нинди сере калсын. Аларның хәтерен алырга кирәк, падишаһым...» — дип пышылдады. Яранның сүзендә хаклык бар иде. Шунда ук гаярь өч солдатны чакырттым да теге осталарны куып җитәргә, урманда дөмектереп, алтыннарын тартып алырга боердым. Солдатларым әмерне җиренә җиткереп үтәп кайтып кергәч, мин аларның һәрберсенә икешәр бүрек алтын бирдереп өйләренә җибәрдем. Тик алар...ызбаларына кайтып җитә алмадылар шул... Яраным берәм-берәм юк итте бахырларны һәм дә миннән өч бүрек алтын алуга ирешге. Үз чиратымда мин аны бер тамчы кан чыгармыйча, агулап та мәшәкатьләнмичә чәнчелдердем... Мендәренә каплап тын гына буып үтердем. Шулай итеп, минем мәгарәм артык чыгымнарсыз гына төзелде. Иң мөһиме шул: анда дәвернең кыйммәтле кәгазьләре, бәһасез хезмәтләр саклана. Менә алар, карагыз! — дип Иван патша хәзинә сандыкларына, китап киштәләренә ымлады.— Соңгы елларда бу байлыгыма карап күңелем төшә башлады. Чөнки минем христиан галәме һәм дә Бөек Русь өчен кылган күпме хезмәтләрем тәк ята, югала бара. Хәзерге елъязмачылар минем хакта бик саран, буталчык язалар. Хәтта мине денсез Петр Беренче, уйнашчы Екатерина Икенче белән чагыштырырга җөрьәт итәләр. Оят кирәк! Мин христианлыкны ныгыттым, ә алар таркаттылар... Чыраеңа караганда син да христиан булырга охшыйсың, ә нишләп соң солдатларың белән Бату телендә сөйләшәсең? Аңлат! — дип ул таягын тукылдатып алды.

— Алар татарлар бит, падишаһым. Берсе анын бөтенләй дә русча белми,— дип, өлкән лейтенант патша тәхете каршындагы эскәмиядә утырган Гөргөригә күрсәтте.— Әнә ул, кайчандыр сез чукындырган татар нәселенең дәвамы — Степанов Григорий Иванович, Христоска табына...

— Гөргөри йә, Гөргөри Чипанов,— дип куркынып кына мыгырданды керәшен солдаты.

— Күзләрем күрә, колагым ишетә, хәзерге заман елъязмачылары сезнең башларны тәмам бутап бетергән икән. Мин бер татарны да чукындырмадым. Алла шаһит, елъязмачыларым шаһит... Мә, укы! — дип Сергеевның аяк астына калын тышлы китапны ыргытты падишаһ.— Татарларны чукындырып мин христиан дөньясын пычратмадым, һәрберсен кырырга гына боердым. Үтерелгән бер татар башы өчен — картмы ул, сабый баламы — уңдырышлы җирләр бирдердем. Татарны кырырга бөтен рус ирләре кузгалды, чөнки өч йөз ел элек татарлар нәкъ шулай русларны кырганнар иде. Әгәр Бату үзе кебек үк кансыз варис калдырган

булса, хәзер инде рус милләте хакында истәлекләр генә торып калыр иде... Минем дә үземә охшаган варисым булмады, татарларны юк итеп бетерергә иде югыйсә. Явызлык кына җиңү китерә. Бу һөнәргә мин Чыңгыз ханнан өйрәндем. Татарларның гайрәте нәрсәдә икәнен миңа кадәр берәү дә ача алмады. Аларның көче — кансызлыкта иде. Шулай да... минем лаеклы укучыларым бар,— дип, падишаһ дивардагы Гитлер, Сталин сурәтләренә ымлады. Алар Чыңгыз хан һәм Иван Грозный сурәте белән янәшә торалар иде.— Болар белән горурланам! Минем хакта Джуга-Сталинның нинди шәп фикерләре бар,ә! Мәскәүнең сигез йөз еллыгын үткәргәндә ул мине Русьнең иң прогрессив патшасы дип атады... Ләкин ул очракта да минем Казанны алуымны үзәкләшкән Русь дәүләтен ныгытуга гына кайтарып калдырдылар, дөрес бәя бирә белмәделәр. Казанны алуның төп сәбәбе — Чыңгыз хан золымлыгы өчен үч алу иде. Татарларны кырып бетереп кенә Русь дәүләтен ныгытып була иде. Мин аларның динен алыштырырга һич тә тырышмадым. Моны миннән соңгы патшалар, императорлар гамәлгә ашырды. Ул максатка ирешү өчен берничә гасыр кирәк иде. Ә мин татарларның төп өлешен нибарысы 30—35 ел эчендә хәл иттем... Яугирләрем миңа хәбәр китерә иде: татарларны Иделгә куып китереп батырганда, кайберләре, исән калыр өчен, чукыналар икән. Әмма мин аларның берсен дә исән калдырмаска дип әмер бирдем. Әнә, әнә, ул, басурман, Бату калдыгы! Ах син Чыңгыз мордасы! — дип Иван патша Хөсәенгә төбәлеп таягын болгады.— Теге чакта минем яугирләремнең берсе шәфкатьлелек күрсәткән дә, менә хәзер бу, күзләрен тасрайтып, каршымда утыра инде. Әлегә мин сиңа кагылмыйм, минем хакта кешеләргә сөйләрсең. Аннары инде эт хөкемендә дөмегерсең. Бәхет язмаган сиңа! Менә минем лаеклы дәвамчыларым,— дип Иван Грозный янә Гитлер белән Сталин сурәтенә ымлады.— Алар хәтәр дошманны «ике куян» алымы белән юк итә белделәр. Бер дошманны җиңү өчен икенче дошманны файдалану, аннары үзен дә юк итү дигән сүз ул. Дошманны кырудан да зур ләззәт юк бу дөньяда. Рухың күтәрелә, кан йөрешең шәбәя, тәнеңә сихәт-көч иңә... Бигрәк тә корсакка узган татар хатыннарын эзәрлекләргә ярата иде минем яугирләрем. Бәһаләү ягыннан, андый һәр хатын-кыз бәлигъ булган өч татарга тора иде. Ә бу мәхлукка! — дип Иван Грозный Степановка таягын төбәде,— чукынган өчен генә минем яугирләрем тормыш бүләк иткәннәр.

Коты ботка киткән Степанов урыныннан калкып чукына башлады:

— Мин Гөргәри Чипанов.— Мин — керәшен. Керәшен мин!..

— Сезгә аңлатып бирим әле, бөтен Русьның олугъ кенәзе,— дип өлкән лейтенант Сергеев үрә катты, аннары, патшаның каты куллы икәнен искә төшереп, тезләнде,— ул керәшен татары Степанов, русча бик начар белә. Чырае нишләптер татарга охшамаган. Бәлки ул сездән соңгы патшалар хезмәтенең нәтиҗәседер. Ләкин бу хакта хәзерге заман әдәбиятында бер кәлимә сүз дә юк. Сез, бөтен Русиянең олугъ кенәзе, Наполеонга нинди бәя бирер идегез? — дип сүзен дәвам итте Сергеев.— Дөнья әдәбиятында Чыңгыз ханга караганда аны күбрәк беләләр бит. Ә менә сезнең диварда Чыңгыз хан, Иван Грозный, Гитлер һәм Сталин сурәтләре. Болар янәшәсендә нигә Бату хан, Наполеон юк. Мин үзем тарихчы, хатыным да сезнең хакимлек иткән еллар турында диссертация яза. Шунлыктан мин сезгә берничә сорау бирергә җөрьәт итәм. Сезнең эшчәнлегегез Казан ханлыгы белән бәйле. Менә сезнең каршыгызда Казан татары басып тора. Ул әйтә, имеш, Казан татарлары татар-монголлардан түгел, ә болгарлардан чыккан, ди.

Әллә инде бу сорау, әллә Хөсәен ошамады падишаһка, ул, кинәт тетрәп китеп, аягы белән җиргә тибеп куйды. Аның бу кыланышыннан барысы да тынсыз калдылар.

— Мин үземнең җуелган данымны кире кайтарганчы сезне бу мәгарәдә тотачакмын. Бу минем өчен генә түгел, ә Русь өчен дә кирәк. Телдән әйткәннәрем генә канәгатьләндермәсә, китапханәм белән файдалана ала-

сыз. Сурәтләргә килгәндә... Миндә күп алар. Әмма бу дүртесе — иң даһилары. Без, дүрт шәхес, бер үк холыклы, иң мөһиме — чиксез кодрәткә ия без. Бату Чыңгыз ханның оныгы гына. Шуңа күрә мөгаремдә Чыңгыз үзе булгач бик җиткән. Наполеон Бонапарт исә бөтенләй башка камырдан. Даһилар белән янәшә мин аның сурәтен куя алмыйм. Ул, сезнеңчә әйтсәк, либерал... Ул император Александрга үз көчен генә күрсәтергә теләде. Әмма соңына кадәр барып чыга алмады. Мәскәүне алгач, ашадылар-эчтеләр, өелештеләр дә... качтылар. Урыс мажигын французларга эшләтә алмады Наполеон, каты куллы була алмады. Авылларны талау француз өчен пычрак, авыр эш булып тоелды. Ач, ялангач килеш, чабатадан үзләренең Парижларына таба йөгерделәр! Юк, юк, мин Наполеонны Сталин белән янәшә куя алмыйм. Сигез йөз еллык юбилеемны шәп үткәргән өчен генә мактамыйм мин Джуганы. Хикмәт шунда: Гитлер бүтән халыклар өчен генә явызлык кылса, Сталин бүтәннәр өчен дә, үз халкы өчен дә залим иде. Шуңа күрә җиңеп тә чыкты ул. Сугышта штраф батальоннарын кем гамәлгә кертте? Джуга! Кем халыкны Сталин өчен үләргә өйрәтте? Джуга! Сез, гади бәндәләр, залимлыкның асылын белмисез. Явыз патшалар хакында пышылдап кына сөйләнгән буласыз. Чынлыкта сез залим хәкимнәрнең аягын үбәргә тиешсез. Чыңгыз хан дәверендә күпме рус адәмнәре, куркып, татарча сөйләшә башлаган иде. Телебезгә керә барган татар сүзләреннән котылу өчен мин яшерен указ чыгардым. Әгәр дә рус кешесе ялгыш кына бер кәлимә сүз ычкындыра икән — колагын, тулаем татарча сөйләшкәннең телен кисәргә боердым. Күрәсезме, рус теленең чисталыгы өчен ничек көрәштем мин! Джуга да рус телен сафландыруда күп көч куйды. Әлбәттә, ул пычак тотып, тел-колак кисеп йөрмәде, халыкларны нигезеннән кубарып яңа алымнар кулланды... Казанны алганда бернинди дә болгар очратмадым мин. Әгәр анда болгарлар яшәгән булса, яу сәфәренә чыкмаган да булыр идем. Татарлар аркасында Казанга яу чаптым мин. Ул көчле ханлыкны җимерми торып Себер, Кырым, Әстерхан ханлыкларын яулап булмаячак иде. Әгәр Идел буенда кайчандыр болгарлар яшәгән икән, аларның бөртеген дә калдырмыйча Бату һәм Сүбүдәй баһадир кырып салгандыр. Шуңа күрә мин ышанып әйтәм: Казан татарлары — Чыңгыз һәм Батуның турыдан-туры варислары. Әгәр минем Казан каласын алудагы данлы җиңүләрем турында төпле мәгълүмат аласыгыз килсә, әнә теге, өченче киштәдәге китапны укыгыз... Тик бу Казан басурманнарын каршымнан ал! Биш адым арткарак чигенеп тезләнсеннәр. Юкса, үз-үземә хисап бирмим. Укшыта мине алар. Боларны исән калдырып үрчеткән яугирләремне буып үтерер идем хәзер!

Хәсәен, командирның әмерен көтеп тормыйча, падишаһтан биш адым арырак китеп тезләнде, Гөргөри дә нәкъ шуны кабатлады.

Өлкән лейтенант Сергеев падишаһның һәр сүзен йотып утыра бирде. «Их, Галинаны алып килергә иде монда,— дип уйлады ул, әллә никадәр китап тезелгән шүрлекләргә карап.— Боларны кулга төшерсәң, шунда ук академик дәрәҗәсе бирәчәкләр. Картны бәйләп ташларга да бөтен китапларын җыеп алып Ленин китапханәсенә илтергә иде. Сакчылары юк, без өчәү җиңел башкарып чыгачакбыз моны. Өстәвенә, минем уналты патроным, пистолетым да бар. Юк, моңа тияргә ярамый. Ул бәһа биргесез, даһи эшлекле. Андый шәхескә кагылып төрмәгә башны тыгаргамы...»

Чыраен сыткан Иван Грозный, тәхетеннән торып, өлкән лейтенант катына килде:

— Көчек, ни уйлаганыңны белми дисеңме! Татарлар белән бер сүздә икәнсең! Христианлыкны сату бу! Сине дар агачы көтә!

Берни дә кыра алмаячаксың, көчек! Мин — үлемсез. Йә, уеңны тормышка ашырып кара, атып карарга рөхсәт итәм сиңа... Йә, әйдә, шыр җибәрмә! Тиз бул, таяк белән сылаганчы! Йөрәгемә турылап төзә, куян кебек калтырама, якыннан төзә!

Падишаһ әмеренә буйсынып, Сергеев кобурасыннан пистолетын чыгарды, калтыранган кулы белән йөрәгенә төбәп атып та җибәрде. Бер мәлгә күзен йомып торды, ачса... Иван Грозный нәкъ шул урында үлемсезлеген раслап басып тора. Бераздан ул тәхетенә барып утырды.

— Сез кара халык, безне аңлар дәрәҗәдә түгел шул. Кайбер елъязмачылар, шагыйрьләр патшалар усаллыгын тәнкыйтьләгән булалар. Мин андыйларның телен кистереп, зинданнарда череттем. Ә минем лаеклы укучыларым мине дә уздырдылар... Хәзер инде сезгә китәргә боерам. Арыдым. Икенче вакыт очрашырбыз. Хәбәр бирермен. Алла ярдәменнән ташламасын,— дип, падишаһ сүзен төгәлләде дә күздән гаип булды.

...Өлкән лейтенант Сергеев уянып киткәндә, таң аткан иде инде. Ул, кайда, нинди халәттә калуын аңлый алмыйча, күзләрен ачты. Йокы бүлмәсендә, хатыны кырыенда ятуын аңлагач кына бераз тынычланды. Гасырлык вакыт кичелгән сыман иде. Ул шашынып, хатынын үбә, иркәли башлады. Иң ләззәтле мизгелдә дә ул падишаһны төштәме, өндә күрдемме, дигән уйдан котыла алмады.

Иртәнге чәй вакытында хатынына төнге маҗараларын тәфсилләп сөйләде. Галина үзенең дә шундый «фәнни-популяр» төш күрмәвенә үкенеп куйды.

Хәрби киемнәрен киеп, көзге каршына баскач, Вадим Сергеев сагаеп, чыраен тотып-тотып карады. Төн эчендә чәче әллә тагын да караебрак киткән инде. Күзләре дә кысылыбрак тора шикелле. «Бәлки, мин үзем дә керәшендер?.. Ә бәлки чиста татармындыр?.. Татар белән рус язмышы шулкадәр чәбәләнеп беткән, кем белә... Юк, юк, Аллам сакласын...» — дип, ул Иван Грозныйның шомлы карашын искә төшереп, калтырап куйды.

Казармада өлкән лейтенант Сергеев Степанов белән Исмәгыйловка күренмәскә тырышты. Төнлә Иван Грозный мәгарәсендә булуы турында беркатлыланып сөйләп ташлаудан курка иде ул. Ни хикмәттер, җыелып торган бер төркем солдат аңа честь бирүне кирәк тапмадылар. Ул, искәрмәскә тырышып, үтеп киткәндә сәер елмаеп калган кебек булдылар.

«Әллә соң Степанов белән Исмәгыйлов та нәкъ минем кебек үк төш күреп, шуны солдатларга сөйләп өлгергәннәр инде,— дип уйлады өлкән лейтенант.— Бер үк төш төрле урында яшәгән берничә кешегә берьюлы керә ала микән? Юктыр ла...» — дип үзен тынычландырып, ул взводы урнашкан кубрикка керде. Анда Степанов белән Исмәгыйлов, бау сузып, ятаклар рәтен тигезләп йөриләр иде. Взводный килүен күргәч, Хөсәен тиз генә «Смирно!» командасы биреп, нәкъ устав кушканча, рапорт бирергә кереште. Разгильдәй саналган Исмәгыйловның бүгенге иплe-тәртиплелеге гаҗәп иде, янәшәдәге солдатлар да мыскыллы көлмиләр иде.

* * *

Кичкә таба өлкән лейтенант Сергеев Хөсәенне ияртеп шәһәр китапханәсенә китте. Алар 1973 елда басылып чыккан «Татарстан АССР тарихы» китабын алып уку залына керделәр. Китапны күпмедер караштыргач, Сергеев фәлсәфәгә бирелде:

— Болар язуынча, Дунай һәм Идел болгарлары бер халык булып чыга. Нинди сәбәп аркасында халык икегә аерылып, капма-каршы якка киткән? Анысы — билгесез. Менә монда бер болгар исеме китерелә: Аспарух. Мондый исем татарда бармы, Исмәгыйлов?

— Аспарух дигәнне ишеткәнем юк. Батудан үзгәртелгән Батыев бар. Ул Татарстанның Югары Советы президиумы председателе. Галим дә санала бугай... Михаил Калининга килгән кебек, аңа да күпләр гозер белән килә, әмма ул да беркемгә дә ярдәм итә алмый, диләр. Безд

Чыңгыз исеме дә күп очрый, Казан янында Чыңгыз поселогы да бар. Тик менә... Аспарух исеме юк...

— Бу китаптан шул аңлашыла: Казан татарлары болгардан килеп чыккан. Ә Себер, Әстерхан, Кырым, румын татарлары татар-монголдан... Ни өчен алай? Синең өчен моның аермасы бармы, Хөсәен? Әгәр башка төбәк татарлары сезне татар-монголдан чыккан дип исбатларга керешсә... Төп көч Казан ханлыгында булган бит. Иван Грозный беренче чиратта Казанны яулауны юкка гына максат итеп куймаган. Шулай итеп, синең Чыңгыз хан нәселеннән икәнлегең исбатланса...Ха-ха-ха. Сиңа бу ошар идеме, йә?!

— Мең ел элек булган хәлләр миңа кагылмый, иптәш өлкән лейтенант. Ярый инде, хәзер дәүләтләр сугыш теленнән дипломатик телгә күчә баралар. Аерым алганда, кеше дигән зат гасырлар дәвамында тамчы да үзгәрмәде. Яхшы якка дим... Чөнки бүгенге көндә Алладан курку юк. Изге мәгънәдә курку... Алласыз бәндәне күпме тәрбияләп кара, үз асылына кайта да төшә. Бервакыт, армиягә кадәр, операциядән соң шифаханәдән кайтып барам. Трамвайда. Вагонның алгы өлешендә бер буш урын табып утырдым шулай. Бераздан халык кереп тулды. Урыннар бетте. Минем адреска шелтәле сүзләр яудыра башламасыннармы! «Оятсыз... Яшь башы белән... Кырыенда карчыклар басып бара!..» Тагын әллә ниләр. Мин шифаханәдән генә чыкканымны, хәлем юк икәнне кычкырып аңлата алмыйм ич инде. Янәшәдә бер олы гәүдәле, кызмача адәм басып тора иде, җитмәсә, минем иңгә таянып-таянып ала, сасы тәмәке пыскыта. Берәү дә дәшмәгәч, мин җүләр, трамвайда тартырга ярамаганын искәртеп куйдым моңа. Ул миңа тозсыз күзләре белән акаеп карады да, урынымнан кубарып алып, ишеккә таба томырды. Бушаган урынга теге карчыкларның берсен утыртып куйгач, салондагы халык и мактау сүзләре яудыра башлады моңа. Бер чибәр генә туташ, журналист иде бугай, бу «игътибарлы, әдәпле» адәмнең исем-фамилиясен сорап яза башлады. Ә минем тәндәге ныгып өлгермәгән ярам җөе ачылып китте, канга батып сөялгәнмен, ник бер кеше хәлемә керсен. Шул көнне мине тагын операция өстәленә салдылар. Менә шундый хәлләр... Мин шуңа шаккатам: күпме акыл иясе ничә гасырлар буена кешене яхшы якка бору турында үлмәс хезмәтләр язганнар, ә барыбер явыз кешеләр, явыз дәүләтләр арта тора. Аллага ышану бетте, бөтен хикмәт шунда... Американың айга төшкән астронавтлары, уйсигезе дә, куркыныч мизгелдә Алланы искә төшергәннәр. Әмма мин аларның күк иясенә чын-чынлап ышануларына шикләнеп карыйм. Шуңа иманым камил: Аллага табынганнар гына көндәлек тормышта шәфкатьле була, бүтән табыну ысулын кешелек әлегә уйлап чыгара алмаган.

— Син, Хөсәен, бик каты кычкырып сөйли башладың бит әле. Уку залында, гадәттә, пышылдап кына сөйләшәләр. Бар, болгар, илтеп тапшыр китапны, кичке барлауга кайтып җитешергә кирәк. Хәзер инде син тарихлы булдың, армиядән соң, паспорт алганда, милләтеңне болгар дип яздыра аласың. «Татарстан АССР тарихы» моңа нигез була ала. Күпләр синеңчә эшләсә, республикагызның исемен дә үзгәртергә мөмкин. Бар, Болгарстан улы!

* * *

Кичке барлаудан соң, казарма тынып калгач, Хөсәен белән Гөргөри күпмедер вакыт шыпырт кына сөйләшеп яттылар. Аларның ятаклары янәшә, төнгә яндырып куелган сүрән лампа чырайларын да яктырта иде.

— Мин бүген командир белән китапханәгә бардым. Безнең республика тарихын укыдык. Гөргөри, син йокыга китмәдеңме? Анда керәшеннәр турында бер кәлимә сүз дә язылмаган,— диде Хөсәен.

— Кирәкми дә. Миңа ул тарихның бер хаҗәте дә юк! Безнең авылда тарихсыз да менә дигән тормыш итәләр... Берәү дә үз тарихын белми, башкадан ким дә яшәми. Кем ничек тели, шулай яза бит ул тарихны. Мин аны беркайчан да укымаячакмын,— диде Гөргөри.— Әйдә, якташ, спат! Спат нады! — дип русчалатып та өстәде. Әкеренләп ул «өлкән туган» телендә ипи-тозлык кына булса да сукалый башлаган иде.

* * *

Кичен өлкән лейтенант Сергеев кафе-барга кереп йөз грамм аракы, бер кружка сыра эчте. Өенә кайтканда хатыны әле йокларга ятмаган, өем-өем кәгазьләр арасында диссертациясен язып утыра иде. Вадим сүзне бүген укыган тарих китабыннан башлады:

— Син безнең өйнең иң укымышлы иясе, Галя, Россия халыкларының килеп чыгышы хакында күп белергә тиешсең. Шулай да, каян килеп чыккан соң бу татар кавеме, ә?! Бигрәк тә Казан татарлары? Синең Иван Грозныйга багышланган фәнни эшең бу мәгълүматсыз тулы булмаячак бит.

— Син, җанашым, башта әйт әле, нинди бәйрәм хөрмәтенә эчтең, ә?! Казан сабантуе хөрмәтенәме? Нәрсәгә кирәк булды сиңа татарлар?! Шулар белән тәмам саташасың бугай инде. Беренчедән, минем диссертация җитәкчем тарафыннан расланган, икенчедән, Казан татарлары хакында бихәбәр булсам да, барыбер яклыйм мин аны. Аларны Әстерхан, Кырым, Себер татарларына нигә аерып карарга. Татар-монголдан яралган бер халык ич алар. Син беләсең бит инде, кайчандыр хәзерге Россия, тагын Әдрән диңгезгә кадәрге Көнбатыш җирләре татарлар кулында булган. Нәрсә син, аларны инглизләрдән килеп чыккан дияр иденме әллә! Башыңны ватма, кайчан гына әле Уралдан Камчаткага кадәрге җирләр Татария дип аталган.

— Кил әле, Галя, бер үбим әле үзеңне. Юкка гына без бер ВУЗ бетермәгәнбез. Син дөрес фикерлисең дә бит... Татарстан тарихын инкарь итеп, күпме фән докторларына каршы бармыйсың микән. Шәп булыр иде, ә! Алар бит Казан татарларының борынгы балалары болгар дип язалар. Чагыштырып кара кыяфәтләрен бүгенге Дунай болгарлары белән, туры киләме, юк бит! Болгарлар чат славяннарга охшаганнар, шулаймы, Галя?! Карап-карап торам да... Әгәр син чын галим булып китсәң, минем белән санлашмый да башларсың, мөгаен... Мин кем инде, җә, гап-гади бер взвод командиры. Ирең кем дип сорасалар, ни әйтерсең. Комдив яки батальон командиры булсаң бер хәл әле... Безнең комбатның югары белеме дә юк әнә, кичке мәктәпкә йөргән була. Бер карасаң, Чапаевның да белеме сай булган. Әй, ташлыйк сана! Ятыйк әйдә. Син галим булып өлгергәнче, бер одеал астында ятып калырга кирәк.

Иренең бу сүзләрен Галя елмаеп тыңлады да җылы ятакка, ире куенына чумды. Көтеп алынган наз-ләззәт бишегеннән дөнья гамьнәре артка чигенде.

* * *

Вадим Сергеев йокыга китеп гырлый гына башлаган иде, тылсымлы көч аны тагын Иван Грозный мөгарәсенә китерде. Бусында инде ул тезләнеп тормыйча, падишаһ тәхете кырыеннан ук урын алды. Кәефе яхшы иде хакимнең.

— Мин Иоан VI үзе түгел, рухы гына. Шуңа күрә теге чакта син кесә пушкасы белән йөрәк турыма атып та мине үтерә алмадың. Чордашларың арасында җан-рух барлыгына сирәкләр ышанадыр. Әмма ул бар... Күзгә күренми торган нурлар тибрәнеше. Ул бик аз урынны били.

Тәрбия-шартлар аңа мөһим түгел. Кирәк чакта югала, кирәк чакта тагын барлыкка килә. Күптән үлгән кешенең җаны бүгенге тере бәндәнең җанына корылырга мөмкин. Менә бу очракта минем җаным синекенә тәңгәл килде, һәм дә без гапләшеп утырабыз. Үлгәннәрнең җанын сыйдыру өчен галәм чиксез итеп яратылган. Кояш, Җир, Ай һәм дә башка җисемнәр — барысы да җанлы, туалар, үләләр, бер-берсе белән бәйләнештә торалар. Җан гелән үсештә, янарып тора. Менә шуңа күрә дә инде мин синең белән борынгы рус телендә түгел, ә бүгенге заман телендә сөйләшәм. Тәнем үлгәннән соң дүрт гасыр эчендә ниләр булганын да әйтеп бирә алам. Сөякләремне күпме галим-голәмә тикшереп карады, әмма үлемем сәбәбен тәгаен генә берсе дә ачыклый алмады. Бервакыт мин үз җанымны бер галимнең җанына кордым да үлемем сәбәбен әйтеп бирдем. Шунда ул болай диде: «Аны белү мөһим түгел, без, галимнәр, бөтендөнья коммунизмы мәсьәләсенең идеологик ягын өйрәнәбез». Мине тынычлыкта калдырыгыз, дип үтендем галимнән. Хәйләкәр елмайды да, борчылмагыз, галимнәр сез падишаһ файдасына эшли, диде. Алар минем сөякләрдә терекөмеш тапканнар, имеш. Янәсе, мине агулап үтергәннәр икән. Чепуха! Яраннарым мине агулау турында уйларга дә җөрьәт итмиләр иде. Сезнең бу хәсрәт галимнәрегез мине гадәти бер бәндә хөкеменә куеп карыйлар бугай. Минем, падишаһ буларак, тәнемдә, терекөмеш бәлки тумыштан ук булгандыр. Наполеоннан да таптылар әнә. Ләкин ул минем белән чагыштырганда әнчек кенә!.. Син үзең дә, укыган кеше буларак, рәсми тарихны гына беләсең. Ә мин сиңа рәсми булмаган мәгълүмат бирәм. Бәлки, минем казанышларымны күтәреп чыгарсың. Галимнәрнең тарихны үз файдасына боруларына мин каршы чыга алмыйм. Чөнки мин — җан, бары тик җан гына.

— Кодрәтле галиҗанәб, сезнең әйткәннәрдә хаклык бар, әлбәттә. Казанышларыгызга асыл бәя бирү өчен тарихка рәсми карашны үзгәртергә кирәк. Аның өчен сезнең иңгә ябышып үскән йөзләрчә галимнәрне, язучыларны себереп түгәргә кирәк... Сез, Иван Васильевич, минем хатын белән әңгәмә корсагыз икән. Ул сезнең турыда фәнни эш яза, аның да төгәлсезлекләре китәргә мөмкин.

— Җиңел уйлыйсың, угълан! Мин үземнең җанымны теләсә кемгә юнәлтә алмыйм. Югыйсә, күпләрнең башын дөрес якка борыр идем. Һәр бәндә белән ешлык, тибрәнеш туры килми. Әгәр хатының хакыйкатьне генә язса, эшен якларга куймаслар иде. Син шуны онытма, тарихта мин калыкмасам, Русь татар башмагы астында калачак иде! Кызганыч, җир йөзендәге бөтен татарларны да кырып салырга вакытым җитми калды, миннән соң инде җыен селәгәй хакимлек итте. Указларымны үзгәрткән булып, ассимиляция белән шөгыльләнеп... Чукындыру белән булашып... Ә татарлар отыры үрчи тордылар. Керәшен дигәннәре пәйда булды. Үлгәннән соң да мин дүрт гасыр буена галим-голәмә, сәясәтчеләр кавеменә шактый мәшәкать тудырдым, күпме шатлык-куаныч-борчу китердем. Минем җан тибрәнеше туры килгәннәр бер син генә түгел, андыйлар — меңнәр. Син мине яхшы аңлыйсың, хезмәтең дә татарлар белән бәйле... Бар, угълан, бүгенгә җитәр, минем дә җаным арды. Алла юлдаш булсын сиңа! — дип, Иван Грозный офицерның маңгаеннан үпте.

* * *

Өлкән лейтенантның иртәнге әйбәт кәефен казарма ишеге төбенә килеп җитүгә үк боздылар. Иртәнге күнегүләр вакытында керәшен татары Степанов белән ефрейтор Иванов сугышты, дип бәян итте сержант Васильев. Тәртип бозган өчен Степанов кухняга чираттан тыш нарядка җибәрелгән. Взводтагы гадәттән тыш хәлне яшереп калдыру мөмкин булмаган. Хәбәр өстәгеләргә барып ирешүгә, комбат тарафыннан Сергеевка кичекмәстән шелтә бирелде.

Бер тәүлектән соң рядовой Степанов белән ефрейтор Иванов канцеляриедә, взвод командиры каршында басып торалар иде инде.

— Сержант Васильев докладыннан шул билгеле: сугышны Степанов башлап җибәргән. Рядовой Степанов, сез башлап кул күтәрдегезме? Беренчедән, ефрейтор Иванов сезнең иптәшегез, взводташыгыз. Икенчедән, ул хәрби дәрәҗәсе буенча да сездән югарырак, отделение командиры. Җавап бирегез, рядовой Степанов! Закон буенча без сезне трибуналга бирергә тиеш...

— Ан скасал мяне: «уан утсюды татарин! Я ошол ут ниго и вис узвод хухотал... Нучали мяне дуразнить устальные. Тогда я русослился и узтукнул яму... Ан мяне туже и пушол кров у нуса... Пучля я вдарил гласам... Путом ефритор скасал: «Путомок Чингис-хана, сря тебя Грозный не сaресал...»

— Ничек сез, ефрейтор Иванов, шундый сүз әйттегез? Кешене мыскыл итәргә берүнең дә хакы юк. Рядовой солдатка сез үрнәк күрсәтергә тиеш идегез. Русмы, украинмы, татармы — безнең илдә һәр милләт тә тигез хокуклы. Ул болай да рус патшаларыннан рәнҗетелгән милләт вәкиле, фамилиясе Степанов, ә русчасы ташка үлчим... Сез нәрсә! Степанов, тукта хәзер үк!

Сергеев өстәл артыннан чыгарга өлгермәде, рядовой Степанов авыр мәрмәр пресс-папьены эләктереп алды да, алагаем кизәнеп, Ивановның башына орды.

Ул арада казармада паника купты. Сергеевтан кала монда бер генә офицер да юк иде. Солдатлар арасында башланган ыгы-зыгыны кече командирлар тиз генә туктата алмадылар. Җитмәсә, санитар частькә чылтыратырга телефон да эшләми иде. Егерме минутлардан соң гына өлкән лейтенант Сергеев казарманы кулга алды һәм гадәттән тыш хәл килеп чыгуы турында югарыга җиткерде.

Чуалыш вакытында якташы Гөргөрине якларга ташланган Исмәгыйловны бик каты кыйнап ташладылар. Ефрейтор Ивановның канлы мәете белән ярымүлек Хөсәенне санчастька озаттылар.

Комбат тарафыннан махсус оештырылган кичке барлау вакытында Гөргөринең казармадан югалганы билгеле булды. Аны, дөнья бетереп, төне буе эзләделәр. Өенә качып китмәдеме икән дип ике телеграмма суктылар. Телеграмманың берсенә — Григорий Степанов дип, икенчесенә Гөргөри Чипанов дип яздырдылар.

Болары артык мәшәкать булган икән, бер атнадан соң, шәһәр чүплегендә Гөргөринең күсе җәнлекләре кимереп бетергән гәүдәсе табылды.

* * *

Рядовой Исмәгыйловны өлкә хәрби госпиталендә ярты ел дәвалаганнан соң психик авырулар шифаханәсенә күчерделәр. Әгәр ул, госпитальдән чыккач, Болгария башкаласы Софиягә китәргә виза сорап рапорт язмаган булса, аны бәлки сары йортка тыкмаган да булырлар иде.

Шунда берничә ай ятканнан соң аны, санитар озатуында, туган ягына кайтарып җибәрделәр.

Казармада чыккан җәнҗал өчен иң авыр җәза өлкән лейтенант Сергеевка төште. Ул хәрби трибунал тарафыннан биш елга ирегеннән мәхрүм ителеп, каты режимлы хезмәт белән төзәтү лагерена җибәрелде. Әгәр ул беркемгә кирәге булмаган керәшен татары — кыйнап үтерелгән Гөргөри исеменнән чыгыш ясамаган булса, бәлки бер-ике еллык шартлы җәза гына алган булыр иде. Ләкин Сергеев биш елдан соң да, ун елдан соң да өенә әйләнеп кайтмады. Психик авыруларны төзәтү шифаханәсендә гомерлек ябылуда икән, дип тә сөйләделәр аның турында.

Әлеге вакыйгалардан соң ике ел үтүгә, Сергеевның хатыны Галинә әйбәт кенә кияүгә чыкты, диссертациясен яклап, институтның тарих кафедрасында эшли башлады. Иренең лагерьда ике елдан соң үлүе хакында хезмәттәшләренә сөйләп, үз-үзен аклап куя иде ул.

Хөсәен Исмәгыйловка исә язмыш гомерлек елмаю бүләк итте. Тымызык яңгырлы көздә авылына әткәсен җирләргә кайткач та ул кабер өстендә дә елмаюдан туктамады. Гел бертөрле сузып гыйбадәт кылган мулла да аның туктаусыз елмаюына игътибар итте, үзе дә елмаеп куюдан чак тыелып, мөселманга ят тарафка башын борып алгалады.

Әтисен җирләгәннән соң Хөсәен тагын теге шифаханәдә ятып чыкты. Аннары паспортсыз-нисез төрле җирләрдә көн күреп, әле товар складында, әле берәр кибеттә вакытлыча йөк төяүче булып эшләштереп алгалый иде. Электәге укытучылык эшенә аны якын да җибәрмәделәр.

Ул Казан шәһәренең үзәк урамыннан йөрергә ярата иде. Якыннан күреп белмәгәннәр аны тормыш сөючән, бик ачык күңелле адәм икән бу, дип калганнардыр. Күпләр Хөсәенне танып беләләр, урамда туктатып: «Син татар түгел, син — болгар, милләтең болгар!» дип ышандырырга ябышса да аңа рәнҗемиләр иде.

Үзәк кинотеатр янында Хөсәен еш туктала, каешланып беткән бүреген баш астына салып асфальтта йоклап ала иде. Авызыннан хәмер исе килсә дә, тәртип саклаучы милиционерлар аны күрмәмешкә салышалар, чөнки ул алар «кунакханәсендә» билгеле кеше санала, аңа пычрак бер дивана дип карыйлар иде. Ямьшәеп беткән кирза итек, киндер җилән кигән, тишелеп, кыршылып беткән хуҗалык сумкасы тоткан Хөсәенне алдынгы эшче класс вәкиле дип тә алданырга мөмкин иде. Шуңа күрә урамнан үзалдына сөйләнеп баруына да каршы сүз әйтмиләр иде. Казан татарларына хас булганча, мөһим дип санаган фикерләрен Хөсәен русча гына белдерә иде: «Казан — Болгарстан башкаласы! Дунай һәм Идел болгарларын кичекмәстән кушарга кирәк... Болгарлар йә Балканда, йә Идел буенда бергә яшәргә тиеш. Юк, мин югалмыйм!.. Мин болгар Аспарух... Пред-во-дитель!..»

Ул кыю атлый, рядовоймы, полковникмы — каршы килгән милиция хезмәткәренә честь биреп китә. Тукталышларда кешеләр ташкынына каршы барып, кулын селки-селки, төкереген чәчә-чәчә ярсып нотык сөйли. Аның кыяфәтеннән чирканып читкә тайпылалар. Урам шавында тавышы күмелеп кала, елмаеп ачылган авызы кыймылдавыннан гына аның нидер сөйләп торуына төшенәсең.

Бервакыт аны үзәк гастроном директоры күреп алды да складына эшкә чакырды. Рябой кушаматлы йөк төяүче фаҗигале төстә үлеп киткән икән. Хөсәенгә бер атна буена йөк төяү-бушату бәхете эләкте. Көнгә биш тәңкә чумара эләктерү уен эшмени! Менә ул бүген башын чөеп, шешә авызыннан гына аракыны голт-голт эчкәләп, сасы эчәге колбасасын кабыгы-ние белән капкалап урамнан бара. Хәмер тәэсире белән бергә аңарда горурлык хисе дә көчәя. «Юк, югалмыйм әле мин, андый камырдан түгел мин! Мәктәп директоры булып эшләячәкмен... Татарныкында гына түгел, болгар мәктәбендә! Миңа укытучы дипломын кайтарып бирәчәкләр әле... Я — предводитель Аспарух!»

Аракыны соңгы тамчысына кадәр «сыккач», ул шешәсен тапшырды да, унике тиенен учына кысып, фәлсәфи уйларга бирелде. Аның хәзер биш сум унике тиен акчасы булды. «Моңа «Экстра» алып эчәргә дә мөмкин ич. Киләчәк турында нигә баш ватарга. Рябой юк хәзер, өч кибеттә дә эш тәэмин ителгән. Юк, бетерә алмыйлар мине! Рябой әнә өч урында эшләп күпме акча туплаган булды. Мотоцикл ала, имеш, әрҗәләр арасында күсе кебек җан тәслим кылдымы! Нәрсә миңа арзанлы хәмер генә эчәргә дигәнме әллә!»

Хөсәен «Экстра» сатып алды, калган бер тәңкәсен шоколадка сарыф итте. Булгач байларча кыланып калсын әле. Аның даими торыр урыны юк иде, йә вокзалда, йә кочегаркада — кая туры килә шунда баш төртә иде.

Хөсәен бүген, яхшы киенгән халык арасында сәләмә икәнен онытып, яңа модалы бостон костюм, очлы башлы туфли кигән кебек хис итеп йөрде. Галстугы бар кебек ара-тирә аны рәтләп куйгандай итә иде. Кешеләрне туктатып ул күңелендәгеген әйтергә тели, ләкин бар да аңардан җирәнеп, тизрәк китү ягын карыйлар иде. Хөсәен үз-үзе белән дә тәмләп сөйләшә ала, ләкин аны нигәдер кеше күп җыелган урыннар тарта иде.

— Менә хәзер дөньяның иң шәп аракысы — «Экстра» белән сыйлыйм үзеңне,— дип сөйләнде ул кочергакада көн-төн эшләүче, ничә яшьтә икәнен дә чамалап булмаслык бирчәйгән кыяфәтле хатынны иска төшереп.

Хөсәен урам аркылы чыкты, тукталышта троллейбус көтүләр шактый иде. Ул моңа сөенеп, галстугын «рәтләп» куйды, сәхнәгә чыгасы актер шикелле, гәүдәсен җыебрак куйды, уң кулын нәзакатьле селкүгә, халык тып-тын калды. Һәрхәлдә, аңа шулай тоелды. Көчле тавыш белән нинди дер шигырь сөйли башлады...

Никадәр шәп сөйләсә дә, аңа кул чабучы табылмады. Янә Хөсәен кул селкеде дә, үпкәләгән сыман, каядыр китеп барды.

Иртән, шул тукталышка якын гына урында, иске йорт җимерекләре арасыннан Хөсәеннең гәүдәсен табып алдылар. Баш сөяге яньчелгән бу гәүдәне танып алучы булмады. Атна-ун көннән мәетне моргтан мединститутның патологик анатомия кафедрасына күчерделәр. Биредә ул, һичбер авырту тоймыйча, тәнен кисәкләп-кисәкләп фән казанышлары өчен бирергә мәхкүм ителде.

Казан, 1975.

**Шаһинур Әхмәтсафа**

# Сез — хөкемдар!

Дөньякүләм танылган шагыйрь, азамат ир Муса Җәлилнең һәм аның көрәштәш дуслары Гайнан Кормаш, Фоат Сәйфелмөлеков, Абдулла Алиш, Фоат Булатов, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Абдулла Баттал, Зиннәт Хәсәнов, Әхәт Атнашев, Сәлим Бохаров кебек фидакарь затларның Алманиядәге Плетцензее төрмәсендә җәзалап үтерелүләренә быел 25 августта 50 ел тулды.

Исән калган җәлилчеләрдән Кыргызстанның Ош шәһәрендә яшәгән Рушад Хисаметдинов (1992 елның 29 августында ул 81 нче яшендә йөрәк өянәгеннән вафат булды — авыр туфрагы җиңел булсын...), Үзбәкстанның Каршы шәһәрендә гомер кичерүче Фәрид Солтанбеков, Ташкенттан Гарәф Фәхретдинов, Казаннан Әмир Үтәшев һәм башкалар яшерен оешмадагы иптәшләре турында чын дөреслекне чагылдыруда, аларның рухи ныклыкларын раслауда, намуслы исемнәрен халыкка, якыннарына кайтаруда үзләреннән бинилаяа зур өлеш керттеләр...

Ниһаять, мәңге эремәс булып тоелган торгынлык бозы кузгалды. Җәлил белән бергә фашист гильотинасы пычагы астында гомерләре өзелгән ун батырның һәммәсе дә 1990 елда 1 дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнде, үлем алдыннан алар үпкән изге Коръән Казанга әйләнеп кайтты. Инде менә хәзер — мәңгелеккә күчүләренә нәкъ ярты гасыр тулган көндә — Җәлил һәйкәле янәшәсендә ун каһарманның һәркайсы барельефтагы сурәт рәвешендә торып басты!..

Түбәндәге шигъри юлларны җәлилче шул баһадирларга багышлыйм.

Сынаулары белән сыный Тормыш —
Җиз иләктән кат-кат үткәрә...
Рух вә җаны көчле булганнарны
Йолдыз итеп күккә күтәрә!
Йолдыз итте Сезне дә ул, Җәлил,
Алиш, Кормаш, Гарәф, Рушад,
Әмир!..
Йолдыз итте
Тиңсез батырлыкка таң калып:
— Аяк-кулга зынҗыр салынса да,
Көрәшә, көлә белә бу халык!
Җырлый белә!
Кырык яктан үлем янаса да,
Алмаз кебек нык сез, бөгелмәс! —
Иманына тугры күңелләрдән

Үлемсезлек җыры өзелмәс!
Ургыла җыр!..
Зинданнарың, дошман,
Туктаталмый хисләр
ташкынын...
Ургыла җыр юллар, еллар
аша,
Кайта Илгә, кайта
ашкынып!
«Җырың белән дусны иркәли бел,
Җырың белән җиң син
дошманны!» —
Сезгә көч һәм гайрәт бирде Җәлил,
Үтәр өчен халкым кушканны —
Көлеп җиңәр өчен дошманны!..
Без беләбез:
Төп хөкемдар
тик фашизм түгел,
Гильотинада башлар чапса да,
Сезнең рухи ныклык,
җырга көчеп,
Меңнәр күңеленә кайтканга,
Сез — ХӨКЕМДАР!!!..
Каныгыз белән язган һәр җырыгыз
Гаепләү акты булды фашистка,
Гаепләү акты булды хаиннарга! —
Карарыгыз кискен һәм кыска!
Сатлык җаннар — яла-этдиновлар
Сезне гестапога чакса да,
Җыр тылсымы белән, сез алардан
Алданрак басып чакмага,
Җиңү яуладыгыз шул «дуэль»дә! —
Хаклык сүзен кайтардыгыз
Илгә!
(Сезне һәркем белә,
башын ия —
Алдыгызга, зурлап, чәчәк сибә!..)
...Сынаулары белән сыный Тормыш,
Моабитлар аша үткәрә...
Рух вә җаны көчле булганнарны
Йолдыз итеп күккә күтәрә!
Йолдыз итте сезне дә ул, Җәлил,
Фоат, Баттал, Саттар, Әхәт, Сәлим,
Гариф, Әхмәт, Зиннәт, Фәрид,
Әмир! —
Йолдыз итте
Күңел күкләрендә кабызып!..
Көрәшчеләр рухы көч-дәрт бирә —
Без яшибез Сезгә табынып!..



**Казан Кремле каршындагы Муса Җәлил һәйкәле янына һәр елны 25 августта герой-шагыйрьнең көрәштәш дуслары, Польша, Германия, Франция, Бельгия кебек чит илләрдә фашизмга каршы көрәшкән ветераннарның Идел буе төбәгендәге «Кызыл ромашка» берләшмәсе әгъзалары, аларның якыннары, тол хатыннар җыела. Фотохәбәрче А. Биктимеров төшергән әлеге рәсемдә сез шул берләшмәнең рәисе — җәлилчеләрнең Франциядәге яшерен оешмасы җитәкчесе, Совет Армиясе офицеры, французларның Каршылык күрсәтү хәрәкәте капитаны, татар һәм рус партизаннарының (макизарларының ) беренче группасын оештыручы Әмир Үтәшевны (уңнан — икенче) үзенең фикердәшләре Ибраһим Айнатуллов (Буа), Якуп Фәйзрахманов (Казан), инде вафат булган макизар Мөбәрәк Хәсәновның хәләл җефете — Марзия ханым (Әтнә) һәм Ризван Мөхетдинов (Казан) янәшәсендә күрәсез (1993 ел).**




**Рәсемдә — Нәҗип Нәкъкаш иҗат иткән «Бүләгем» дип аталган шәмаил-миниатюра. Анда Муса Җәлилнең тоткынлык газапларын бергә кичергән бельгияле дусты Андре Тиммерманска багышланган шигыренең соңгы дүрт юлы тасвирланган.**

# БҮЛӘГЕМ

...Үзем үлсәм — исмем, җырым үлмәс,
Ул яңгырар илнең кырында.
Сөйләп илгә тоткын көннәрдә
Чәчәк аткан дуслык турында.

Бу шәмаил-миниатюраның беренче варианты 1991 елда Татарстан Үзәк дәүләт музееның әдәбият бүлеге үтенече буенча иҗат ителгән иде. Әдәбият бүлеге аны М. Җәлилнең хатыны Әминә ханымның Бельгиягә, Андре Тиммермансның хатыны янына кунакка җыенуын искә алып ясаткан иде. Һәм ул Әминә ханымның Казанга килгән вакытында, музейда очрашу мәҗлесендә аңа бүләк итеп бирелгән иде.

Гарәп язулы миниатюра исә М. Җәлилнең Моабит дәфтәрләрендә нәкъ менә шул гарәп язуын куллануына ишарә. Безнеңчә, ул татар халкының борынгыдан килгән мәдәни мирасын һәм аның милли төсмерен чагылдыра.


Күп төсле беренче варианттан аермалы буларак, «Казан утлары» журналының мөмкинлекләрен искә алып, бу миниатюра бер төс белән генә башкарылды.

**Нәҗип НӘКЪКАШ.**

---



Менә ул — Муса Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен җәзалау урыны булган Плетцензее (Көнбатыш Берлин) төрмәсе залы. Герой-шагыйрь һәм җәлилче каһарманнар хакында күп язган, киң колачлы эзләнүләр алып барган танылган язучы, Татарстан яшьләр оешмасының М. Җәлил бүләге лауреаты Рафаэль Мостафин (уңнан беренче) чыгыш ясый. 25 март, 1976 ел.



# Гарәф Фәхретдинов

# КАЙДА МИНЕМ ИЛЕМ?!

**Гарәф Фәхретдинов 1920 елны Бөгелмә өязе, Карабаш авылында туып үскән. Аның әтисе Кашафетдин агай, бөтен гаиләсен алып, 1937 елда Урта Азия якларына күченеп китә. Гарәф Фәхретдинов шуннан хәрби хезмәткә алына. Сугыш башлангач, Киев чолганышында ул каты яралана. Әсир төшеп, нимесләрнең нинди генә лагерьларын күрергә туры килми аңа. Кыю йөрәкле егет бернечә тапкыр кача, тагын тотыла.**

**«Идел-Урал легионы»нда ул Муса Җәлил, Гайнан Курмашлар белән аралаша. Татар халкын мөстәкыйль дәүләтле итеп күрергә теләгән Шәфи Алмаз белән дә таныша. Соңыннан ул француз партизаннары сафында фашистлардан Францияне азат итүдә катнаша. Сугыштан соң Италия, Мисыр, Төркия аша ул, татлы өметләр белән, туган илгә кайтып егыла. Әмма монда да аның кешелеген изеп, гомер буе рәхәт күрсәтмиләр.**

**Бүгенге көндә Гарәф Фәхретдинов Үзбәкстанда яши. Кансыз совет җәмгыятендә ни генә күрсә дә рухын сындырмаган бу шәхеснең язмасын тетрәнмичә уку мөмкин түгел. Бу хәсрәтле истәлекне без кыскартып, тел ягыннан Марсель Галиев эшкәртүендә, журнал укучыларына җиткерергә булдык.**

**Әйе, азатлык Гарәф Фәхретдиновка бик соңлап килә шул. Аны 1989 елның 29 июнендә генә аклап, ветеран киңәгәсе бирәләр.**

**Редакциядән.**

БЕРЕЗАНЬ САЗЛЫГЫНДА.— Тор, улым, тор инде! Озак йокладың, кайнар тары коймагы белән чәй эч, укырга барырга соңга каласың!..

Әнкәйнең ягымлы тавышына иркәләнеп, уяныр-уянмас кына, урынымнан торырга теләмичә ятам, имеш. Чү! Каядыр еракта шартлау авазлары. Аратирә мылтык-автоматтан аткан тавышлар ишетелә түгелме?! Үлем ачысы белән кемдер «За Родину!» дип кычкырган кебек була. Сискәнеп күземне ачып җибәрәм. Баш очымда төпсез зәңгәр күк йөзе. Шул зәңгәрлекне томалап, вакыт-вакыт күз алдымнан аклы-каралы томан йөзеп үтә. Әллә нинди ямьсез тавышлы каргалар, киң канатларын җәеп, минем өстә әйләнә-тулганалар. Җылы кан исен сизенепме шулай шомлы карылдыйлар алар?

Ерактан килгән тавышлар да тынды. Нишләп соң әле мин монда ятам? Булып узган вакыйгаларны хәтерләргә тырышам. Ике мәртәбә атакага ташланып та чолганышны өзә алмадык. «Рама» дип аталган ике койрыклы немец

самолетлары бертуктаусыз бомбага тоттылар. Мин машинадан сикереп төшкәндә дошман самолетлары бер-бер артлы сызгырып, дәһшәтле үлем йөкләрен безнең өскә коя иде инде. Мин җиргә йөзтүбән капландым. Гәүдәм белән бергә җир тетри — мәхшәр башланды. Аннары... самолет гүләүләре тынгач, тирә-якта яралы солдатларның инәлеп ялварган тавышлары ишетелә башлады. «...Мама... Мама... помогите... воды, братцы, воды...». Башымны күтәреп карасам, миннән ике-өч адымда гына хәрби киемле бер хатын ята, ике аягы да бот төбеннән өзелгән, бөтен җире канга баткан, үзе күккә карап тирән сулыш ала, үзе кычкырмый да, су да сорамый. Янына барып ярдәм күрсәтим дип урынымнан тормакчы булам, юк, кымшана алмыйм, гәүдәмә авыр таш бастырып куйган шикелле. Терсәгемә көч-хәл белән таянып күтәрелгәндәй итәм, йә Хода, яткан җирем кан гына. Аяк-кулларымны капшап карыйм — исән шикелле, каян, нишләп кан ага соң әле?! Тагын хәлем китә: «Братцы, помогите... воды... әни!..»

Күпмедер вакыттан соң мин машина әрҗәсендә аңыма киләм. Янәшәмдә яралы солдатлар. Безне каядыр алып баралар. Берничә хәрби кеше яралыларга су бирә, тәмәке кабызып каптыра. Кемдер җан бирсә, машинаны туктатып, юл кырыенда сай гына чокыр казып күмәләр дә ары кузгалалар. Өметсез хәлдә дә кеше дигәнең нидер уйлый, борчыла икән. Мин политрукны үз яныма дәшеп китерәм:

— Мин үлгәч, чокырны тирәнрәк казып күмегез, дим. Күземне каргалар чукырлык булмасын, дип ялварам. Кесәмдәге комсомол билетын, заем кәгазьләрен, өйдән килгән хатларны биреп, шул адрес белән языгыз, дип үтенәм дә аңымны җуям.

Кабат аңыма килгәндә караңгы төшкән иде инде, мине куаклар арасыннан каядыр күтәреп алып баралар иде.

Менә хәзер мин сулы сазлык кырыенда, шәп-шәрә килеш плащ-палаткага төренеп ятам. Иртәнге салкын һава мине үлем исереклегеннән айныткан. Аяк-кулларым бинт белән бәйләнгән, алардан кан саркый. Тирә-ягымда сарык көтүе, йөзләгән сарыклар йөзтүбән ятканнар. Бу көтүне нигә монда куып китергәннәр, көтүчесе кая китеп олаккан? Тагын каргалар төркеме, шомлы аваз белән тынлыкны кисә...

Кабат күземне ачканда кояш баеп бара иде инде. Янәшәмә шактый тирән кабер казыганнар. Күмәр алдыннан миңа су эчерәләр. Менә мин кабер эчендә. Йомшак булсын дипме, суык тимәсен дипме, аска-өскә берничә кат шинель салалар. Каберем кырыенда яралы ике солдат. Берсе хатын-кыз. Алар миңа карап тордылар да:

— Прощай, братец! Мы еще вернемся,— дип китеп бардылар. Кабер эчендә күпме ятканмындыр, таң беленгән иде, аяк бармакларымны нидер кимергәнгә уянып киттем. Аяк бармакларын кыймылдаткан идем, колак яфрагын кимерә башлады.Карасам, бәләкәй генә тычкан баласы икән. Нишләп соң әле бу тычкан баласы миңа тыныч кына үләргә ирек бирми? Кабер эченнән күккә багып, җем-җем килгән йолдызларга карап ятам. Малай чакта мин төн ката ат сакларга баргач, урман аланыннан шулай күккә карап ята идем. Бәлки шушы мизгелдә авылымда кемнәрдер йолдызларга текәлгәндер. Кычкырсам, тавышымны ишетмәсләрме?.. Бәлки су бирерләр...

— Коткарыгыз мине моннан! Су бирегез! Братцы, помогите!..

Тавышымны ишеттеләрме, иртән янә теге ике солдат килеп мине чокырдан күтәреп алдылар, шинельләрдән урын көйләп, кырыема ике-өч котелок су куеп, минем белән хушлаша башладылар.

— Нигә мине ташлап калдырасыз, бармакларымны тычкан кимерә... Үлсәм кем күмәр?! — дип аларга карап ялварам.

— Тычканны үтердек, безгә китәргә, сазлык аша чыгып үзебезнекеләргә кушылырга кирәк. Без сине кечкенә генә утрауга чыгарып куйдык, монда сиңа куркыныч янамый инде... Ярый, прощай, братец! — дип китеп тә бардылар.

Соңыннан белүемчә, әллә кай ераклыкларга сузылган сазлык уртасындагы утрауда ятам икән. Шулай итеп көннәр-төннәр үтте, котелоктагы су да, азык-төлегем дә бетте. Көннәр суыта, иртә белән ап-ак кырау төшә башлады. Ә мин һаман үлем көтеп ята бирәм. Яралар тәмам сасып, тәнем бетләп чыкты. Тирә-як тып-тын. Көнчыгыш якта күк күкрәвенә охшаш гөрелте авазлары гына ара-тирә колакка чалынып куя. Сазлыкта бихисап сарык көтүе һаман ял итеп ята. Көтүченең чыбыркы шартлатканы да ишетелми.

Ә минем ашыйсым-эчәсем килә. Менә бит, янәшәмдә генә каберем әзер, үлем һаман көттерә. Ашыйсым килә икән, димәк, мин яшәргә телим. Яшисең

килә икән, димәк, хәрәкәт итәргә кирәк. Котелогымны кулга алам да, мүкәләп, ташбака кебек урынымнан кузгалам. Үзем яп-ялангач, муеныма бәйләгән плащ-палаткам җирдән сөйрәлеп бара. Су кырыенда солдат капчыклары ята, эчендә укмашып каткан сохарилар. Шул сохариларны саз суына чылатып, тәмләп ашап утырганда күзем төште дә сискәнеп киттем. Сарык көтүе дип уйлаганым сазлык өстендә үлеп калган меңләгән солдат мәетләре икән ләбаса! Суда талгын гына чайкалып яткан кеше гәүдәләре...

Шулай итеп бу утрауда мин Робинзон кебек үз-үземне туйдырып яши башладым. Ашарыма бетсә, ауга чыккан иясез эт кебек утрауны тикшерә башлыйм. Солдат капчыкларында ни генә юк, эчке киемнәр дисеңме, өр-яңа бинт төргәкләре дисеңме... Мин хәзер җылы киемнәр киеп алдым. Салкынга түзәргә була.

Бердәнбер көнне, тәмам батыраеп, бөтен утрауны барлап чыгарга уйладым. Бу бит минем утрау, мин — яралы «Робинзон» хуҗа монда! Үрмәләп, шуышып, мүкәләп бара торгач, куак арасында яткан тере солдатка юлыктым. Ике аягы да гөбе кебек шешенгән. Моның хәле минекеннән мөшкелрәк иде шул.Янына килеп: «Нихәл, братец?!» — дигәч ул, иренен көчкә кыймылдатып: «Воды... воды...» дип кенә әйтә алды. Үрмәләп барып мин аңа котелыгымны тутырып саз суы алып килдем. Мәетләр чолганышында калган бу шыксыз утрауда иптәш табылуга сөенеп тә куйдым. Әмма аның исемен әйтерлек тә хәле юк иде. Шулай итеп мин — «Робинзон», ул — «Җомга» булдык хәзер.

Утрауны берничә сәгать эчендә үрмәләп карап чыгарга була. Противогаз киеп, мәетләр арасында йөрсәң җан асрарлык кирәк-яраклар табып аласың. «Җомга» янына көн дә бер мәртәбә үрмәләп барып кайтам. Ашарына бирәм, су калдырам. Янәшә генә ятасы иде дә бит, ул коточкыч сасыган, якын килмәле түгел.

Су кырыйлары юка боз элпәсе белән каплана башлаган бер көндә урман ягыннан, агач көймәгә утырып, кара сакаллы бер бәндә утрауга килеп туктады. Мин аңардан «Җомга» белән икебезне сазлык аша урман ягына чыгаруын үтендем. Ул төксе генә:

— Мин монда барахло җыярга дип килдем, шуларны чыгарып куйгач, сезне алмага килермен,— диде. Мин аның сүзләренә ышанып үземнең аска җәелгән шинельләремә хәтле биреп җибәрдем. Ләкин ул әйләнеп килмәде. Әллә алдады, әллә немесләр кулына эләкте — Алла белсен.

Төннәрен бик суыта башлады. Суны да яр читендәге бозны ватып ала башладым. «Җомга» да бирешми әле, һаман үлем белән көрәшеп ята. Вакытны чамалыйм, 1941 елның октябрь азаклары җитте булса кирәк.

Бер иртәдә уянып китсәм, каршымда су үткәрми торган комбинезон кигән бер тап-таза солдат басып тора. Пистолетын төбәгән дә: «Руки вверх!» дип кычкыра. Минем чарасызлыктан битарафка әйләнгән җанымда кинәт ачу кабарды:

— Төкерәм мин синең пистолетыңа! Миңа хәзер барыбер. Бүген-иртәгә боз каткач, урманнан ач бүреләр чыгып безне ботарлап ташлаячаклар! Ат, әйдә, ат! — дип ярсып кычкырам. Солдатның пистолетлы кулы салынып төште. Кешечә сөйләшә башлады. Ул монда кием-салым җыеп кайтырга дип килгән икән. Җыйган нәрсәләрен хутор халкына илтеп ашамлыкка алыштырмакчы икән. Мин аңардан «Җомга» белән икебезне дә бу утрау әсирлегеннән коткаруын үтендем. Ул риза булды. Миңа комбинезон кидереп, сазлык аша култыклап алып чыкты. Аяклары бөтенләй йөрмәү сәбәпле, «Җомга»ны алып чыга алмыйм, хутор кешеләренә әйтермен, килеп алырлар, диде.

Урман эчендә аны иптәшләре көтеп тора икән. Һәммәсе пистолет белән коралланган. Чолганышта калган офицерлар ахрысы. Мине болар үз араларына утыртып җылы аш ашаттылар. Соңыннан мине хутор кешеләренә калдырып киттеләр. Хәрбиләр биргән кием-салымны арбага төяделәр дә болар, шуның өстенә утыртып алып киттеләр. Әмма миңа җылы өй күрү насыйп булмаган икән. Мин моны Березань стансасы янындагы әсирләр лагерының капка төбенә барып җиткәч кенә аңладым. «Нигә мине концлагерьга тапшырасыз? — дигәч, «Безгә шундый приказ бирелгән, кем дә кем совет солдатын хатасында яшереп тота, шуның бөтен гаиләсе атарга хөкем ителә», диделәр.

И Аллам! Нигә мин теге утрауда Робинзон булып кына калмадым икән... Нигә үз вакытында үлмәдем икән!.. Нинди юл сайлады миңа язмыш...

Әй, энем, энем... кайда минем Илем?!.

* * *

ҮЛЕМ ЛАГЕРЫНДА. Бу лагерь тимер юл буенда, «Березань стансасы» дип атала. Зур ябык сарайның эчендә дә, тышында да тезелеп яткан яралы әсирләр. Көнгә бер литр чөгендер суы (баланда) бирелә. Немецләр лагерь эченә бөтенләй кермиләр, авыру йоктырудан куркалар, этләр белән тышта, чәнечкеле чыбык сузылган койма артында гына саклыйлар иде. Лагерьның үз кануны — комендант, полицайлар, табип, поварлар барысы да үз арабыздан иде. Аягына басып тора алган әсирләрне немецләр капка төбеннән эшкә алып китәләр. Лагерьда «ярдәм итә» алырдай бер генә төркем бар, аны «капут командасы» дип йөртәләр. Аягын сузганнарны болар лагерь тышындагы тирән чокырга ташып торучылар.

Бердәнбер көнне аягында басып тора алган әсирләрне кызыл вагоннарга төяп, Киевтән ерак түгел бер шәһәргә алып киттеләр. Кырык беренче елның кышы иде бу. Хәрби аэродромнан калган баракларга урнашып без лагерь тормышын башлап җибәрдек.

* * *

БОРИСПОЛЬ ЛАГЕРЫ — рәттән салынган дүртәр катлы кирпеч бараклардан тора. Әйләнәсе икешәр катлы тимер чыбык киртәләр белән тотылган. Монда тәртип үзгәрәк икән. Аягында йөри алганнар котелогын тотып баландага үзләре баралар. Йөри алмаганнар исә үлемгә дучар ителгән. Теге лагерьда урында яткан авыр яралыларга баланданы үзебезнең санитарлар китерәләр иде. Монда ул нәрсә юк.

Минем дә ачлыктан хәлсезләнгән тәнемдә яралар ачыла башлады. Хәрәкәттә бәрәкәт, дигән Әфлатун хәким. Юк, болай ятып булмый, сазлык уртасындагы утрауда «Робинзон» булып, үрмәләп йөреп исән калганны, монда, кешеләр арасында... Яшәргә булгач яшәргә! Кулыма таягымны алдым, таш баскычлардан артым белән шуып төштем дә, сөйрәлеп киттем кухня тарафына. Анда черегән бәрәнге, чөгендер өйгәннәр икән. Якынрак килеп бераз эләктердем дә кесәмә салдым, комсызланып, шатыр-шотыр чәйнәп, үрдәк кебек авызны югары күтәреп йотып та җибәрдем. Шулай кесәмне һәм бүксәмне тутырып торганда ике әсир яныма килеп үзара сөйләшә башлады. Йә Хода! Саташаммы әллә?! Авылыма кайткан кебек булдым. Теге әсирләр нәкъ безнеңчә, чын татарча сөйләшә лабаса! Алар кырыена ук сөйрәлеп килдем дә, таягыма таянып бастым.

— Якташлар түгелме, кордашлар?

— Без Әлмәттән булабыз.

— Бәрәкәч! Мин дә шуннан ерак түгел Карабаш авылыннан инде...

Әнә шулай бер-беребезгә сораулар яудыра-яудыра гапләшеп киттек. Баксаң, якташларым повар булып эшлиләр икән. Сиңа хәзер әйбәт ашарга кирәк, шул чакта гына яраларың төзәлер, безнең янга килгәләп йөр, диләр.

Шул көннән соң ашау ягыннан минем эшләр хутка китте. Мин поварлар бүлмәсендә дневальный булып тора башладым. Өске катта санитар хатын-кызлар яши, күбесе минем кебек яралы. Алар белән дә дуслык урнаштырдым. Янга калган бәрәңгеләремне бирәм дә, алар минем яраларымны юып, чиста марля белән бәйлиләр. Лагерьның базары кайнап тора. Әсирләр ду килеп алыш-биреш итәләр. Бәрәңге-әпәен булса, хәтта яңа солдат киеме дә сатып алып була. Ике зур бәрәңгегә бер яңа гимнастерка тия. Сигез-ун бәрәңгегә — кирза итек. Минем монда тәмәке тартмавым зур бәхет иде. Күпләр бер төргәк тәмәкегә баландасын алмаштыра килеп, соңыннан шешенеп, дөнья куйдылар.

Инде мин таякка таянып, шаплап йөри башладым. Якташларыма рәхмәт. Мин аларны үлгәнче онытмам. Аларның бүлмәсен сакладым, әкиятләр сөйләп, җырлар җырлап, күңелләрен ачып бергә яшәдем. Ләкин монда да озак яшәргә мөмкинлек бирмәделәр. Кем аягында йөри ала, этле сакчылар шундыйларны җыйнап барладылар да, кызыл вагоннарга төяп, Киев аша, Днепрның сул ягына алып киттеләр. Соңыннан, йөри алмаган әсирләрне бер чокырга тутырганнар дип ишеттек.

* * *

ДАРНИЦА ЛАГЕРЫ. Монда да ике кат чәнечкеле киртә белән уратып алынган мәйданда, элек яшелчә сакланган сарайларда яшибез. Такта сарайларның берсендә авыр яралылар, икенчесендә җиңел яралылар, өченчесендә — авыр һәм җиңел яралы офицерлар. Тәне сау әсирләр исә ачык һавада, йомран кебек

чокыр казып шунда яшиләр. Чокырларның бер кешелеге, икс-өч кешелекләре бар... Полицайлар әсирләр арасыннан куела, күбесе — хохоллар. Иртә-таңда полицай һәм немесләр, ярсу этләрен өрдерә-өрдерә, әсирләрне чокырларыннан чыгарып тезәләр дә, барлап, каядыр эшкә алып китәләр.

Минем өстә офицер киеме булганлыктан, яралы командирлар белән бергә такта сарайда ятам. Имеш мин кече лейтенант. Монда да уңдым: комсоставка бер литр баландадан кала туксан грамм ипи белән чөгендер мармеладды бирәләр. Бүтән сарайдагы гадәти әсирләргә бер литр баланда — вәссәлам. Әле ул баланда да санитарлар кулы аша кипә-киле шактый сыекланып бетә...

Тышта суык. Сарай эчендә әлегә түзәрлек. Өч катлы нарларда таралышып ятабыз. Аста — иң авыр яралылар. Эт белән куа башласалар, мин «авыр яралы»га әйләнәм, кирәк чакта өске каттан урын алып «җиңел яралы» булам.

Меңнәрчә әсирләр тупланган бу лагерьда көненә өч йөзләп кеше үлә диләр. Аларны «капут команда» чокырга ташып тора. Әгәр төнлә үлә-нитә калсаң, балтыр итеңне кисеп алып ашап куярга мөмкиннәр. Әгәр кеше ите ашаганыңны сизсәләр, полицай-немесләр ул әсирне строй каршында асып куялар. Мондый хәлләр дә була: яңа гына үлгән әсирне ике яклап култыклыйлар да ашханәгә алып баралар, мәетнең муенына асылган котелокка баланда салдырып алалар. Кирәдән алып кайтып сөяп куялар да баландасын бүлешәләр. Үлек тәмам тораташ катканчы шулай кабатлыйлар.

Полицайларның кулында кургашлы чукмар таяк, шуның белән бер бирсә, гарипләнүеңне көт тә тор. Әнә, оберполицай чукмарын күтәреп җикерепә:

— Ахтунг! Шнурайтесь! (Тезелегез!)... Сталинские соколы... С... вашу мать...— дип команда биргәннән соң ул сафларның алгы рәтен ике адым алга атлаттыра да авызын ачтырта. Кем алтын тешле, шул турыда туктала, инструменты белән тешне каерып ала да кырыеннан барган полицайның әрҗәсенә сала. Бу мәрәкәне камчылы немес үткер күз белән күзәтеп тора.

Әйткәнемчә, лагерь ишегалдында йөзләрчә чокыр. Шул чокырлардан, йомран шикелле, әсирләр баш калкытканнар. Әгәр инде чокыр-өннән ялкын-төтен күренә калса... немесләр кисәтеп тормыйча ата башлыйлар яисә граната ыргытып, чокырны тигезләп куялар. Әсирләр барыбер үзенекен эшлиләр, чокыр төбенә ут ягып җылыналар, әмма шылт та төтенен чыгармыйлар. Моның сере нидә икәнен мин белә алмадым.

Минем хәлләр мөшкелләнә башлады бит әле. Күн итегемне салдырып алып, агач башмаклар кидерделәр. Мин шинель чабуын кисеп алдым да пилоткага колакчын, кулга бияләй, аякка оеклар тегеп кидем. Күпләр шулай эшләде. Койрыгын кискән әтәчләргә охшап калдык, нәләт төшкере!

Бер көе генә яшәп ятканда баракны бет басты. Яралы офицерлар көннән-көн азая бара. Җитмәсә санитарлар аларны машиналарга төяп, каядыр озатырга тотындылар. Туктале, нишләп мин командир булыйм ди, русчаны да юньләп белмәгән килеш... Торам да хәзер гади солдатлар барагына чыгып китәм. Анда инде мин «кече лейтенант Федотов» түгел, ә рядовой солдатка әвереләм. Язмыш тагын ниләр күрсәтер икән миңа. Үзалдыма җырлыйм да җылыйм...

Мин китәрмен туган илгә,
Урман эчләре белән.
Бәйләп куйсалар да тормам
ефәк очлары белән.

Әй, энем, энем... Кайда минем Илем?!.

* * *

МИНЕМ ИЛЕМ — як-ягын куе әрәмәлек баскан ямьле Зәй буенда иде. Бөгелмә белән Әлмәт арасында, «патша юлы» өстенә урнашкан авылымның исеме — Карабаш булыр. Утызынчы елларга кадәр анда биш йөзләп хуҗалык яшәгән. Бер таш, бер агач мәчете, алты кибете, биш күпере, бер мәктәбе булган. Гаҗәеп матур табигатен җырларга гына салырлык иде. Карал тавы итәгенә урнашкан авылыбыз Олы урам, Түбән урам, Төбәк, Түбән оч дигән өлешләргә бүленеп йөртелә иде. Түбән оч Әлмәткә китә торган юл өстендә, язгы ташу вакытында өйләрнең билләренә кадәр су баса торган урын. Ташу сулары тәмам тенкәсенә тигәч, икенче якка, әрәмәлеккә күчеп утыручылар төбәген Котылдык дип йөртә башлыйлар.

Баттал бабайның улы Ягъфәр, аның улы Фәхретдин, аның улы, ягъни, минем әти Кашафетдин, 1889 елны шунда туган. Әтием мич чыгару, калай-тимер, агач эше кебек һәммә төрле һөнәрне белә иде. Баш авыртса да, теш алдырырга дип тә тирә-яктан аңа киләләр иде.

1914 елгы сугышта әти гражданнар сугышында катнаша. Самара шәһәрендә кызыл гвардиячеләр сафына эләгә. Шунысын да әйтергә кирәк: безнен Карабаш авылыннан иң хәтәр «сәнәкче»ләр чыккан. Кызылгвардияче әти авылга кайтып төшкәч, бабай аңа тиз арада күздән югалырга куша. Икенче көнне сәнәкчеләр өйгә кереп тулалар, «Малаеңны кая яшердең?!» дип мич башыннан бабайны сөйрәп төшерәләр дә, әйтмәгәч, сәнәк белән кадап үтерәләр.

Ул елларда сәнәкчеләр «Бетсен коммунистлар!» дип активистларны ат койрыгына тагып йөрткәннәр, бәкегә салганнар, баганага бәйләп җәзалаганнар. Балалар укытучысы буларак, минем әни дә сәнәкчеләрдән авылдан-авылга качып йөргән. Әнием Габдерахман авылында затлы гаиләдә туган. Кышның озын кичләрендә әнкәй китап яисә Коръән укый башласа, әти авызын ачып, исе китеп карап утыра иде. Әнинең тәэсире миңа да йоккан күрәсең, мин бәләкәйдән үк көйләп догалар укырга өйрәнгәнмен. Үсә төшкәч инде җырлый, бии, такмаклар әйтә идем.

Литтер-литтер литтата,
Чуар тавык кем сата?
Кил, апаем[1], кәнфит бирәм,
Тутаң кемне ярата?

Әткәйнең Бөгелмә базарына киткән чаклары аеруча истә калган. Ишегалдында җигүле ат тора. Арбага ул бакчабызда үскән кыяр, кавын-карбызлар төйи, үзе ясаган чиләк-комган, тас, соскы ише әйберләрне дә җайлап урнаштыра. Без әткәйне озатып калабыз һәм тизрәк кайтуын көтә башлыйбыз. Әллә нинди хуш исләр ияртеп әткәйнең базардан кайтып керүе үзе бер бәйрәм була торган иде. Әнкәй шакмаклы ашъяулыкка базар күчтәнәчләрен тезеп куя, табынга җырлап торган самавыр килә. Әткәй олы шакмаклы шикәрне алып вата башлый, аннары һәммәбезгә берәм-берәм өләшеп чыга:

— Мә, улым Гарәфетдин, бусы сиңа, ә менә бусы Нәфис улыма, иң матуры — Әгъдәс улыма, бусы инде әнкәгезгә, ә бусы...— дип ул ашъяулыктагы вак шикәр комын учына ала да, башын чөеп, авызына каплый...

Без, өч малай, шикәрнең төмен саркытып кына, озаграк сакларга тырышып, аны тел астына кыстырабыз. Әмма озак түзеп була димени, шикәр эри дә бетә... Күзләрне елтыратып тагын әткәйгә киләбез.

— Чоланда тәпәне белән кәрәзле бал тора, шуны ашагыз,— дип әти битәрләгән сыман итә. Ә безгә шикәр тансык, балдан туйганбыз.

Онытырлыкмыни: төнге ат саклаулар, Зәй буеның карлыганлыклары, ярышып йөзә-йөзә су коенулар, төнбоеклы күлләр, каз-үрдәкләрне йотарлык чуртан балыкларның сикереп уйнавы... Безнең яктагы кебек итеп кошларның ярсып сайрауларын бүтән бер җирдә дә күрмәссең.

Менә мин хәзер туган илдән еракта, ачка киселеп, әнкәйнең майда йөзгән тары коймакларын сагынып утырам. Йә хода, никләр мине болай каһәрләдең икән? Нигә дип кенә миңа мондый язмыш юрадың икән? Югыйсә бит үз гомеремдә берәүне дә рәнҗеткәнем, кимсеткәнем булмады, әткәм-әнкәмә һәрчак тыңлаулы булдым, олыны олыга, кечене кечегә санадым. Чит җирләрдә кол булырмын дип үскән идеммени!

* * *

— Ахтунг! Шнурайтесь, погание!

Нимеслардән дә явызрак полицайлар, этләреннән талата-талата, безне плацка чыгарып тезделәр. Балык кебек шыплап машиналарга төяделәр дә каядыр алып киттеләр. Каядыр дигәнебез Киев лагеры булып чыкты. Салкын җилекләргә үткәнче туңып, яңа урынга килеп төштек. Без Киев белән Житомир арасында канау казып, кабель сузарга тиеш икәнбез. Бу шартларда ике генә юл бар: йә эшләп үләсең, йә булмаса качып котыласың. Ә нигә качмаска?! Бу җирләрнең һәр карышы миңа таныш ич. 1940 елны Бохарадан хәрби хезмәткә алынуга мин шушы Украина якларына эләктем. Киевны калдырып чигенгән чактагы күренешләр әле дә күз алдымда. Магазиннарның тәрәзәләре ватык, ишекләре ачык, эчтәге әйберләре таланган, урамда трамвайлар аударылган, китаплар өеме төтәп

[1] Апаем — кече туган, эне йә сеңелгә әйтелә.

ята, кәгазьләр очып йөри — мәхшәр. Днепрның сул ягына чыгар өчен бер генә күпер калган иде. Без чыгуга, аны да үзебезнекеләр шартлаттылар. Ярның аргы ягында калганнар инәлеп җылый башлады, йөзә белгәннәр күпләп суга ташландылар. Бу вакытта инде Киевкә немесләр ике яклап бәреп керә башлаган иде (1941 елның 18 сентябре).

Мин рота командирының элемтәчесе һәм тән сакчысы идем. Кулымда немес автоматы, билемдә дүрт граната һәм немес хәнҗәре — кыскасы, бу корал белән мин яу кырында үземне юлбарыс кебек хис итәрлек идем. Әмма безнең полкларны немесләр җирдән дә, һавадан да туктаусыз тупка, бомбага тотып, боткага әйләндереп бетерделәр. Березань сазлыгына җитәрәк мин тугыз җирдән бомба ярчыгы белән яраландым һәм контузия алдым. Яраларымны бәйләп машинага салганнары исемдә, аннары инде аңымны югалтканмын.

Мондагы һәр сукмак, һәр агач миңа таныш булгач нигә качып китмәскә, әсирлек тозагында барыбер көн күрсәтмәячәкләр... Шундый уйлар белән эшләп йөргәндә якындагы бер йортның капкасы кысылып кына ачылды, аннан кул күренде, «бире кил» дигән кебек ишарәли иде ул. Ни буласын уйлап та бетермәстән, мин ашыгып килеп шул капкага «чумдым». Минем арттан тагын ике ачыгавыз йөгереп килеп җиттеләр. Эчтә ни күрик: ике немес офицеры безгә карап тыныч кына басып тора. Аннары тиз генә капканы яптылар да чәнечкеле тимер чыбык белән уратып алынган бер сарайга безне бикләп куйдылар. Монда немесләрнең комендант взводы икән, үзләренә утын кисеп әзерләр өчен утызлап әсир тоталар икән. Шул әсирләрнең икесе үлгән, берсе качып киткән. Менә шулар урынына без, өч әсир, үз аягыбыз белән килеп кердек тә капкын эчендәге капкынга эләктек.

Яраларым ачылуы сәбәпле мине утын кисү эшеннән азат иттеләр. Минем вазыйфам — мич ягу иде. Бер немес офицеры буш вакытларында кече калибрлы мылтыктан чыпчыклар кыра, мин аларны җыеп алам да, пешекләп, йонын йолкып, шулпа пешерәм. Баландага кушып ашарга чыпчык шулпасы да ярап тора икән...

Җәрәхәтләрем бөтенләй ачылып, утын да китерә алмый башлагач, карап эшләтүче немес офицеры, мәрхәмәте килепме, мине шәһәр лазаретына илтеп тапшырды. Табибларга: «Әгәр качырсагыз, аның урынына сезне алып китәрмен» — диде. Әмма миңа әйбәт шартларда озак ятарга туры килмәде. Ул чакта кулдан-кулга күчеп торган Харьков шәһәреннән бик күп немес яралыларын шушы лазаретка китереп тутырдылар. Шулай итеп мине әсирләр лазаретына китереп ташладылар. Савыгып килгән тән яраларым монда тагын ачылып, коры сөяккә калдым. Янбаш сөякләрем тирене тишеп чыкты. Күпләр шундый иде. Ишегалдына һава суларга чыгарсалар җирдә эскәк белән чүпләрлек тә үлән калмый, тамырына кадәр корытып бетерәләр иде. Кичләрен, тәрәзәгә карап:

И, Ай туган, алтын булсаң
Алкалар ясар идем.
Ай булганчы икмәк булсан,
Туйганчы ашар идем —

дип эчемнән генә җырлый идем.

* * *

1942 елның июнь башында лазаретта үлем алалмаган әсирләрне бер көнне машинага төяделәр дә янадан Дарница лагерына китереп ташладылар. Без инде өметне кисеп, «туганнар каберлегенә» дип уйлаган идек.

Ни гаҗәп: иң әүвәл безне сафка тезеп, ашарга алып бардылар. Пычкы оны кушылмаган өч йөз грамм ипи, бәрәңгеле, куе тәмле аш бирделәр. Мондый «сый-хөрмәт»кә хәйраннар да калдык. Әллә соң «Кызыл хаҗ» безгә кулын суздымы, «минем әсирләрем юк, сатлыкҗаннар гына бар» дигән Сталин бабабыз йомшаганмы әллә?

Ашап чыкканнан соң милләтне милләткә аеру башланды. Урыслар, Дон казаклары, кавказлылар, фин-мордвалар — һәммәсе аерым. Мин азиятлар төркеменә эләктем. Безне Ровны лагерына китерделәр. Монда инде тәртип башка... чәнечкеле чыбыктан уратылган киртәләр дә күренми, автоматлы немес сакчылары да юк. Лагерь капкасы янында беләкләренә яшел бәйләгән үзебезнең әсирләр кизү тора. Элеккеге командирларны яңадан түрә итеп куйдылар. Хәзер инде без аларга «сугфюрер», «компанейфюрер» дип кенә эндәшәбез. Хәер, ком-

панейфюрерлар безнең белән бик вакланып тормыйлар, нимес офицерлары белән генә сөйләшәләр. Әллә каян гына ак чалмалы, яшел чапанлы мулла да пәйда булды. Ашау байдан, үлем Ходайдан, дигәндәй, көненә өч мәртәбә шәп кенә сыпыртып куябыз. Мулла моңлы тавыш белән дога укып җибәргәндә без дә кулны кушырып амин тотабыз. Гүя без үлеп терелгәнбез дә оҗмах аланнарында истирәхәт кылып йөрибез. Ризык үзгәртә шул кешене, күпләрнең эчке асылы ачылды да китте, эчке һәм тышкы төсләр үзгәрде...

Мин күбрәк ашау ягын кайгыртам. Тән-тазалыкны ныгытып, тизрәк качарга кирәк моннан. Үзем кебек ирекке ыргылган бер мишәр егете белән дуслашып алдым. «Хәйдәр Кадыйров, бывший учитель-биолог» — дип таныштырды ул үзен. Ә мин Дим Алишев булып алдым.

— Димка, кайгырма! Бераз тынабыз да, потом сызабыз,— дип ул зур соры күзләрен уйнатып, сары чәчен сыпырып мишәрчә әйтеп куя. Мин аның сәләмә өс-башына карап үземнекен күз алдымнан кичерәм: өстемдә керләнгән, умырылган хатын-кыз бәйләм күлмәге, теткәләнгән чалбар... Икебезгә бер «параш» (кечкенә чиләккә охшаган), баланданы шуңа салдырып алабыз. Менә шулай, суярга әзерләгән мал кебек ашатып яткан бер вакытта безне, Идел-Урал төбәгендә яшәүчеләрне аерып алдылар да шәһәрнең икенче ягына илтеп тупладылар. Бу — «Идел-Урал легионы»на хәзерли торган «карантин лагеры» икән. Монда инде милләтләр чуарлыгы алай ук күп түгел: татар-башкортлар, чирмеш, ар, удмурт, чуваш һәм тагын башка халык вәкилләре иде. Командирлар, әлбәттә, татарлардан иде. Лагерь башлыгы «сугфюрер» Волков фамилияле татар, нимесчәне дә су кебек эчә, гел тегеләрнең офицерлары белән сөйләшеп йөри иде.

Беркөнне полицай Волков барыбызны да сафларга тезде дә көтелмәгән сорау бирде:

— Арагызда мулла бармы?

Каккан казыктай катып калдык. Саташамы бу әллә?.. Монда күбесе социализм төзегән яшьләр, нинди мулла булырга мөмкин. Мин үзем коммунист булып атакага барган сугышчы.

Теге нәләтнең тавышы тагын да катырак яңгырады:

— Кем мулла, ике адым алга, марш!

Сафлар дәшми, бер-беребезгә аптырап карашабыз. Хәйдәр колагыма жуылдый:

— Димка, син сказкаларны яхшы сүлисен, может азанны да беләсеңң? Вота ул чакта ашап күрсәтер иек, муллага өстәмә пурсы бирәчәк тә бирәчәк инде...

— Кем вакытлыча мулла эшен башкара ала?!

Шул мәлдә тоттым да алга чыгып бастым. Сәләмә киемнән, яланаяк, кыяр түтәлендәге карачкы сыман басып торам. Кара күн перчаткалы, камчылы нимес офицеры, җир кортына караган шикелле чирканып кына миңа күз атты да, полицайга нидер мыгырдады. Полицай әшәке калын иренен җәеп елмайды да миңа дәште:

— Син чынлап та мулламы, дога укып күрсәт әле!

— Мин мулла түгел, әмма мулла укыган чаклы гына беләм,— дидем. Һәм шикләнеп тә куйдым. Әгәр бу җүнсез бәндә Коръәнне белсә, әнә нимес тә камчы сабын елтыр итек кунычына суккалый башлады. Рәт-рәт тезелгән әсирләр тын да алмый карап торалар. Дустым Хәйдәрнең карашы «бетерделәр малайны...» дигән шикелле кызганулы... Шалишь, брат! Әнкәй миңа малай чагымнан ук күп нәрсәгә өйрәтте. Кирәге булмады тормышта, ләкин аз-маз булса да кайбер догалар истә калган. Нишләп әле мин бу мокытлардан куркып торам. Боларның берсе дә гарәп телен белми ич. Мин үзем дә укыганымның нәрсә аңлатканын белмим... Маршировкаларда җырлап чарланган тавышым белән укып җибәрдем агай...

— Бисмил-лаһир-рахманир-рахим. Әл-хәмдү лил-ләһи Раббил галәмин. Ир-рахманир-рахим. Малики яумиддин. Иййакә нәгъбүдү вә иййакә нәстәгыйн. Иһдин әс-сирател мөстәкыйм...

Полицай авызын ачкан, нимеснең күзе челт-челт йомыла, әсирләр чүгеп калдылар. Шулай бер-бер артлы укыйм белгән догаларымны, әмма белүем чамалы гына. Полицай тагын, тагын укуымны сорый, нишләргә, белмим дип туктап калуы да унайсыз... Әһә... Туктап калырга ярамый, мин сүзләрен үзем дә аңлап бетермәгән төрле сурәләрдән алынган өзекләрне тезәм генә...

— «Әл-хәмдү лил-ләһи раббил гәләмин, Әр-рахманир рахим. Сталин умер, Гитлер карт мөртәтин,— дип кулны кушырып күтәрдем, әлбәттә соңгы юлларны авыз эченнән мыгырданыбрак тәгәлләдем, шулай итеп «Аллаһу әкбәр» — дип амин тотам, йөзләгән әсирләр дә, миннән күрмәкче, кулларын күтәреп амин

тоталар. Бу мәрәкә тәмам булгач, полицай нимес офицерына борылып алман телендә нидер ләңгелдәде дә, безнең якка карап:

— Бүгеннән башлап менә бу (миңа төртеп күрсәтә) мулла булыр. Үзеңә ярдәмче ал. Баланда аңа ике порция бирелергә тиеш.

Соңыннан мин Хәйдәр янына килеп:

— Син минем ярдәмчем булырсың,— дидем. Мишәрем күзләрен тасрайтып карады да:

— Анаңны орган нәрсә! Азанчы икәнеңне белгән булсам, якын да килмәгән булыр идем! — дип ярып салды.

— Авызыңны яп! — дим тегеңә.— Мулла абзаң белән әдәпле генә сөйләш... Баланданы кешеләрдән күбрәк ашап, аякка баскач, моннан тайганда миңа рәхмәт әйтерсең әле...

Хәйдәрем бу сүзләрдән соң йомшап калды. Ярдәмче буларак мин аннан бернинди дә файда күрмим, баланда чөмереп бүксәсен тутыра да: «Әйдә, поп, кәртле уйныйбыз», дип кенә тора.

Иртәнге намазга соңга калынган. Монда бит әтәчләр кычкырып уятмый, каян беләсең вакытны. Барактан чыктым да нидән башларга белмичә торам. Кран янына килеп үземчә тәһарәт алган булдым. Башка әсирләр дә нәкъ минемчә кыланалар. Шуннан соң мин ташландык әберәкәй башына мендем дә көйләп җибәрдем:

— Аллаһү әкбәр... Аллаһү әкбәр... Әшһәдү әл-лә иләһә илләллаһү...

Түбәнгә карыйм, йөзләрчә әсирләр, учларын кушырып, авызларын кыймылдатып нидер укынган булалар. И Хода бәндәләре, болар кичәге коммунизм төзүчеләр бит инде югыйсә...

Көннәрдән бер көнне яныма олырак яшьтәге бер әсир килде дә:

— Син, иркәм, муллалык эшен белеп бетермисең, күрәм,— диде.— Баланданнан өлеш чыгарсаң, өйрәтергә була...

— Нигә соң алай булгач башта ук үзең мулла булмадың?!

— Теләмәдем...

Шулай итеп минем хәзер нахлебникларым икәү булды. Берсе дин гыйлеменә өйрәтә, икенчесе авыз турында кашык уйната.

Беркөнне лагырь кайный башлады. Әсирләрне мунча кертеп, нимес киеменә киендерәләр икән, димәк чын легионерларга әйләнәбез. Чукынып китсен мунчасы, мулласы, төкердек барысына да. «Кырык ел тавык булып яшәгәнче, кырык көн әтәч булып яшә!» дигән Әфләтүн хәким, безгә ирек кадәрлерәк. Шушы мәхшәрдән файдаланып сыпырттык без Хәйдәр белән. Урман-кырлар аша Көнчыгышка — үзебезнекеләр ягына... Әмма без ачлык белән азатлык төмен бергә кушып озак бара алмадык, хохол полицайлар тиз эләктерделәр. Йә Хода, миңа тагын Хорол шәһәрендәге лагерьны да күрергә язган икән әле. Качып китеп, әллә ни кадәр юл үткән кебек булабыз, юк, һаман шул Украина җирләреннән ычкынып булмый. Бераздан язмыш безне Белая Церковь лагерына китереп ташлады. Монда инде урта һәм югары белемле әсирләрнең исем-фамилияләрен язып алдылар. Германиягә эшкә алып китәләр икән дигән сүзләр дә таралды. Ә безнең иреккә сусаган җанда гел качып котылу кайгысы.

Беркөнне ССчылар килеп әсирләрне тезделәр дә, егерме биш-утызлап әсирне машинага төяп алып киттеләр. Болар арасына мин дә эләктем. Хәйдәрем моңсуланып: «Прощай, браток!» дип озатып калды.

Урман читенә килеп җиткәч, безне машинадан төшерделәр дә чокыр казырга куштылар. Тирәнлеге бер метр булгандыр, шулай казыгач, барыбызга да чишенергә куштылар. Нимесләрнең «юда» юда!» дип җикеренүләреннән мин бер нәрсәне аңлап алдым. Яһүдләр арасына эләккәнмен лабаса. Борыным да аларныкына охшаган, сөннәтем дә бар... менә сиңа «капут» сәгате сукты... Безне чокыр кырыена тезеп бастырдылар, мин ни кылырга да белмим, чарасыз калдым. Мишәр дустым әйтмешли, вота, Гарәф Фәхретдинов, синең өчен дөнья бетте... Нинди суык көн иде югыйсә, анадан-тума басып торабыз, гүя кар түгел, ә кайнар көл ява, бөтен тән ут эчендә.

Минем кырыйда басып торучы бөтен тәнен кара бөдрә йон баскан әсир кычкыра башлады:

— Их нихт юда, их бин әрмән, Кавказ!

Әрмәнне сафтан тартып алдылар да, киендереп, кире машинага утырттылар. Минем дә юкка үләсе килми бит, каһәр төшкере! Нишләп болай иманга оеп торам соң әле... Мин дә җан ачысы белән кычкырып җибәрдем:

— Их нихт юда, их бин мугаметан!.. Татариш!

Арырак торган офицер-полицайлар төркеме арасыннан чалма ураган казахмы-кыргызмы калыкты. Бер полицайның җиңеннән алып, миңа төртеп күрсәтә: «Осы бәндә нугай гуй, мөселман гуй!» — дип офицерларга да төшендерә башлады. Ул арада мине чакырып алдылар, киемнәремне биреп, арт ягыма шап итеп тибеп, машинага мендереп утырттылар. Теге әрмән янына утырып киенгәч, кенә эчкә суык төшә башлады. Калганнарны атып, чокырга ташлаганны күрмәс өчен мин күземне каплап, башымны түбән идем.

Кичен минем кайтуымны зарыгып көтеп торган Хәйдәр белән лагерьда күрештек. Икенче көнне безне, урта һәм югары белемле «интеллигентлар»ны яшел вагоннарга утыртып, Польшаның Кельце шәһәренә алып киттеләр. Бу җыйнак кына шәһәрдә яу кырыннан кайтарылган немес яралылары, лазаретлар бик күп икән. Безне кирпеч заводыннан ерак түгел бер бай йортының ишегалдына машина китерде. Тора торган урыныбыз «секция» дип аталачак икән. Ике катлы нарлар, салам белән тутырылган матрацлар, хәтта одеал-мендәрләр дә бирделәр. Лагерь чәнечкеле тимер чыбыклы киртә белән әйләндереп алынмаган, капкада безнең кебек үк әсирләр дневальный булып тора, «старшина» да үз арабыздан. Җиңенә свастика билгесе таккан ике немес көн аралаш килеп, тикшереп китәләр. Ашау яхшы. Көн саен лекцияләр тыңлыйбыз.

Монда Россиянең бик күп милләтләре «укып» ята. Без, ачык авызлар, большевикларга имеш кол булганбыз. Милли байлыкларыбызны яһүдләр талап яткан икән. Әнә шулай, кинофильмнарга кадәр күрсәтеп безгә милли тәрбия бирәләр. Безгә нәрсә, «бүрене күпме генә ашатма, барыбер урманга карый...». Без бит Ленин-Сталин фанатиклары, якты киләчәк төзүчеләр, алай гына туры юлдан тайпылдыра алмассыз!..

Без мишәр дустым Хәйдәр белән «юнга» сигаретын төтәтеп, тәмле ашап, урысларга «господин», татарларга «әфәнде», немесләргә «хиер» булып, милләт сыбызгысын сызгыртып, качарга план корып ятабыз.

Безнең татар секциясендә дә төрле кеше бар. Бик наданнарны немесләр чүпләп алып, каядыр озата торалар. Без Хәйдәр белән бик белемле кыяфәт чыгарып йөргән булабыз. Көнгә бер сигара, өч сигарет бирсеннәр дә... сигара төтенен буржуйларга охшатып, түшәмгә өреп ят та... ничек инде әфәнде булмыйсың.

Көн дә стенага зур карталар элеп, лекторлар сандугач кебек сайрыйлар: «Идел-Урал җөмһүрияте — берләшкән татар мәмләкәте... Дон елгасыннан алып Тын океанына, Татар бугазына чаклы җирләр синең туган илең. Синең бар мөлкәтең, байлыгың большевиклар кулында. Совет дәүләтендә большевиклар һәм яһүдләр генә рәхәт яшиләр. Калганнар — кол...»

Милли тәрбия озакка бармады. Беркөнне ач яңаклы, пеләш башлы, елтыр күзлекле, бик зыялы, русчаны әйбәт сөйләшә торган немес килде. Моның яраннары да Берлинның үзеннән иде (берсе дә хәрби түгел). Боларга яхшы билгесенә имтихан тапшырганнарны шәп киендереп, портфель тоттырып каядыр алып китәселәр имеш...

Хәйдәр сүгенеп: «Мин большевик булып тудым, большевик булып үләчәкмен! Имтиханда шуны ярып салам!» — дип кызышып йөри.

Имтиханга кергәч миннән: «Син интернатта тәрбияләнгәнсең, димәк, большевик тәрбиясе алгансың. Партиядәме?» — дип сорадылар. «Элек комсомол идем, аннары одеал урлап тотылгач, комсомолдан чыгардылар», дим. «Анысы әйбәт икән», диләр болар.

Икенче көнне минем кебек «ачыгавыз»ларны чыгарып тезделәр дә вокзалга алып киттеләр. Тагын кызыл вагоннарга төяләр икән безне.

Вагон идәненә җәелеп утырган Хәйдәр көлә:

— Бире кил, браток Димка! Утыр янымa... Хәзер син әфәнде түгел инде... Йомшак вагон да, эшләпә-галстук та, фашист паспорты белән портфель дә тью-тью!

Икенче көнне без Польшаның Висла елгасы буена урнашкан Демблин кальгасына килеп җиттек.

Әй энем, энем... Кайда минем Илем?!.

* * *

ДЕМБЛИН КАЛЬГАСЫ Екатерина II заманында корылган диләр. Дивары биек, кызыл кирпечтән төзелгән, өстән ток уздырылган чәнечкеле чыбык үтә. Кальганың тышкы әйләнәсенә тирән канау казылып, эченә су җибәрелгән. Тимер капкасы каршында биниһая калын чылбырлар белән күтәрелә торган күпер. Моннан качып чыгу турында уйларга да куркыныч...

Борынгы таш җәелгән ишек алдында агач башмаклар белән дагалы ат кебек шыкы-шыкы йөрибез. Тәртип бик каты. Әз генә кыек бассаң да сине карцер көтә. Бөтен тирә-юньдә чисталык, бер генә чүп заты да күрмәссең. Бу да «Идел-Урал легионы»на хәзерли торган «карантин лагере» булып чыкты. 1943 ел башыннан монда Казан, Әстерхан, Төмән, Оренбур татарларын һәм башкорт, мари, чуаш, удмуртларны җыйганнар икән. Яңа килгән әсирләр төркеме арасыннан немесләр комиссар, яһүд, чегән кебекләрне чүпләп алалар да теге дөньяга озатып торалар.

Буш вакытларында әсирләр ни генә эшләмиләр: агачтан яисә ак тимердән шәп тәмәке савытлары дисеңме, саламнан яисә агачтан шкатулкалар, уенчык елан-балыклар, чәчәк бәйләмнәре дисеңме — тагын әллә нәрсәләр! Боларны нимескә биреп әпәйгә алмашалар. Безнең халыктан да һөнәрле, юкны бар итә белгән халык тагын бар микән, дип уйлап мин хәйраннар кала торган идем. Шәхсән үземнең күзгә күренеп торган һөнәрем юк та... әмма миндә әкият, шигырь сөйләрлек тел бар, киерелеп җырларлык моң бар.

Нарга ятып җырлый башлыйм да... янымa әсирләр җыелыша башлый, «тагын берне, әйдә, тагын берне генә», дип һаман-һаман мине җырлаталар.

Бервакыт яныма кечерәк буйлы, коңгырт йөзле, аскы ирене бераз очлаеп, алга чыгыбрак торган әсир килде. Ул да агач башмактан иде, сул иңенә противогаз сумкасы аскан (анда котелок белән кашыгы булса кирәк). Миңа елмаеп карады да бу:

— Иркәм, тагын нинди җырлар беләсең? — диде.

— Күп көйләр беләм дә, тик сүзләре онытылган.

— Алай булгач, менә бу шигырьне ал әле, берәр көйгә сала алмассыңмы? — дип ул латин хәрефләре белән язылган, «Висла» дип исемләнгән шигырьне кулыма тоттырды.

Висла! Синең көчле агымыңны
Борып булса иде кирегә.
Дулкынына төреп бу гәүдәмне
Илтер иде туган Илемә.

Шигырьне азагынача кычкырып укып та чыктым. Яңа танышым шулчак үзен «Гумеров» дип таныштырды. Кәгазь-каләме булганнар шигырьне тизрәк күчереп калырга ашыктылар. Бераздан мин шигырьне «Эшче» операсындагы ария көенә шыңшып карадым, аннары Гумеров алдында җырлап та күрсәттем.

Мин теләдем тормыш дулкынында
Колач җәеп иркен йөзәргә.
Тик чикләнде гомрем коллык белән,
Бу хурлыкка ничек түзәргә...

Мин Гумеровка ошап киттем ахрысы. Ул үзенең Казаннан икәнен әйтте. «Мин Үзбәкстаннан, Дим Алишев. Казанда бер дә булганым юк», дидем. «Сүзләрен белмәгән җырларыңа мин үзем язып бирермен», дип ул янымнан китеп барды. Шул көннән соң миңа баланданы тутырыбрак бирә башладылар. Хәтта поварлар да «Казан артисты» дип эндәшәләр иде.

Гумеров көн дә диярлек минем янга килә. Мин җырлаганны тыңлап сагышланып утыра, кайбер җырларны үзе сорап җырлата иде. Ләкин аның белән күп аралашырга туры килмәде, бер атнадан аны каядыр алып киттеләр. Соңыннан поварлар аның хакында «Казанның танылган шагыйре» диделәр. Алар һәр һөнәрле кешене югалтмаска, саклап калырга тырышалар иде бугай. Поварлар Гайнан Курмаш белән Зиннәт Хәсәнов алдан ук олы максатка әзерләнгән булганнар күрәсең.

Һөнәр дигәннән... Унбиш яшемдә мине әти-әниләр Урта Азия якларына алып киттеләр. Әткәй анда калайчы булып, вагон түбәләрен ямауда эшләде. Мине дә үз һөнәренә өйрәтмәкче иде, теләмәдем. Бохарада педучилище бетереп, мөгаллим булып, үзбәк балаларын укыттым. Бар иде яшь чаклар, кесә тулы борчаклар... Әткәйнең тальяны кулда... Үзем уйныйм, үзем җырлыйм, кирәк чакта биеп тә җибәрәм — тирәмдә кызлар бөтерелеп кенә йөри. Мөгаллим булгач почет та бар, ул чакта гади укытучы да профессор кимәлендә иде. Табында беренче касәне миңа сузалар, ашның өрелесе, урынның түрдәгесе иде. Менә бит әле каһәр төшкән лагерьда да ким-хур түгелмен...

— Азанчы булдың, әфәнде булдың, артист булдың, инде хәзер тагын кем булырсың микән! — дип көлә Хәйдәр.

1943 елның яз башында номер-исемнәребезне әйтеп мәйданга чыгарга куштылар. Хәйдәр артымнан «Прощай, браток!..» дип калды. Без, унөч әсир, маши-

нага төялдек. Стансага алып килделәр дә безне пассажир вагоннарына утырттылар. Башта без Радом шәһәрендә тукталдык. Аннары безне ике-өч чакрым ераклыктагы Едлино лагерена алып киттеләр. Табигать хозурында утырган бу лагерьның урам һәм барак тирәләре матур бизәлгән, пөхтәләп чәчәкләр утыртылган иде. Барак дигәне дә икешәр кешелек бүлмәләрдән тора. Уртада — солдат ашханәсе, аның ишек башына «Зольдатенхаем» дип язылган. Татарга сүзне бозарга гына булсын, без аны «солдаткаем» дип йөртә башладык. Шуннан ерак түгел генә радио бүлеге бар, аннан көне буе татарча тапшырулар бара. Мәйдан уртасында озын колгага яшел байрак күтәрелгән. Байракта сары ука белән чигелгән ук һәм җәя билгесе. Байракны югары күтәргәндә «Идел-Урал гимны»н («Тукай маршы») оркестр уйный, «солдаткаем» янәшәсендә культвзвод барагы, аның бер ягында муллалар, икенче ягында артистлар тора. Без урнашкан барактан ерак түгел генә зур клуб бар, анда кино-концертлар була, төрле милли уеннар, кичәләр үткәрелә. Лагерьның көньягында нимес һәм татар офицерларының казиносы, шунда ашап-эчеп, кәеф-сафа коралар.

Едлинодагы «Идел-Урал легионы»ның башында нимес майоры, җитмеш яшьлек фон-барон Зеккендорф тора иде. Ул 1937 елга кадәр Мәскәүдә Германиянең хәрби атташесында хезмәт иткән, шуңа күрә рус телен әйбәт белә иде. Аның ярдәмчеләре нимес офицерлары, аларның ярдәмчеләре татар офицерлары иде. Легионерлар бар да нимес киемендә, җиңгә сары укалы ук белән җәя төшерелгән яшел бәйләнгән иде. Эмблемага «Идел-Урал легионы» дип язылган.

Шулай итеп безнең хәлләр мондый: командалар нимесчә, ашау-эчү нимесчә, яшәү рәвеше нимесчә, калганы — татарча.

Культвзводны озын буйлы, кәкре борынлы, күзе эчкә баткан нимес фельдфебеле җитәкли, аның урынбасары — Түмән татары, старшина Гәрәев. Ул элек укытучы булып эшләгән, аккордеонда шәп уйный, чибәр егет иде. Тора-бара ул нимес фельдфебелен тәмам үзенә буйсындырып бетерде.

Без, «яңа артист»ларның мондагы «иске артистлар» белән танышуы гадәттәгечә «син кайдан? Мин шуннан» кебегрәк булды. Арабызда шагыйрь һәм язучылар Гайнан Курмаш, Зиннәт Хәсәнов, Абдулла Баттал да булгач, «иске артистлар» бик тә куандылар. Танышып алуга безгә нимес солдатларына бирелә торган блюда китерделәр. Каяндыр поляк «бимбер»е (самогон) дә табылды, аның янына «шнапс» килеп утырды. Шулай кызышып утырганда берәү:

— Кайсыгыз филармония артисты? — дип сорады. Чыраена кызыллык йөгергән Гайнан Курмаш, күзләрен кысып елмайды да, миңа төртеп:

Менә ул егет — Дим Алиш,— диде. Әлеге егет минем янәшәмә килде:

— Казаннан күптәнме? Син чын артистыр инде?!.. — дигәч, мин:

— Мин Казанда гына түгел, мич башында да артист булып җырлаганым бар,— дидем.

— Сез чын артист икәнсез, күренеп тора,— дип ул миңа маймылга караган кебек исе китеп төбәлде.

Бераз кызып алгач, китте сөйләп Абдулла Баттал шигырь һәм мәзәк хәлләрне. Ул Казан зыялылары дөньясын якыннан белә икән. Ул кызлар, рестораннар, артисткалар, Маркиз утраулары турында китте тезеп...

Бер почмакта музыка кораллары өелеп тора икән. Тотындык боларны сайратырга... «Баламишкин», «Барыня», «Каз канаты», «Әпипә» — берсе дә калмады. Әмма мин шуны сизеп алдым, бу музыкантлар әле «аксаклабрак» уйныйлар, шомармаганнар. Аккордеон, баян, скрипка, гитара, мандолина кебек кораллар монда җитәрлек. Башкорт егете Салаватов хәтта үз кураенда башкорт көйләрен дә гыж-гыж китерә.

Мәҗлес кыза төшкәч, кул чабып, минем җырлавымны сорадылар. Мин урынымнан кубып, баш иеп, чыгып бастым. Күпме татар-башкорт көйләрен әйтеп карадым, әмма җөрьәт итеп уйнап торучы музыкант табылмады. Ниһаять, скрипкасын тотып Кәрим чыкты һәм минем арттан уйнап торырга булды. Мин төрле спектакльдән җырлар, опералардан арияләр («Наемщик», «Зәңгәр шәл», «Бишбүләк» һ. б.) җырладым. Бара торгач «Кара урман» да, «Җирән кашка» да калмады. Кайчандыр музыкадан дәрес биргән Шакир абый белән Галимә апага үзем эчтән генә рәхмәт укыйм. Менә бит, артист иткәннәр малайны...

Җыр арасында Абдулла Баттал чыгып шигырьләр укый. Соңыннан инде дәртле биюләр башланды. Аяк табаннарыннан ут чәчелә. Гүя без үлем алдыннан дөньясын онытып, бер күңел ачып калабыз. Җырлап үлә торган халык шул без татарлар...

Икенче көнне безгә француз киемнәре китерттеләр, аннары мунчадан соң, нимес киемнәре өләштеләр. Шулай итеп мин «Идел-Урал легионы»ның баш

жырчысы һәм баш биючесе булып киттем. Без зур концерт куярга ду китереп әзерләнә башладык. «Артистлар»ым алай ук профессиональ булмасалар да бик ипле, тәртипле егетләр иде. Болар бәлки яшерен оешма өчен кирәкле кешеләр булганнардыр, Ходай белсен. Чөнки конспирация бик көчле, «кая бардың, ни эшләдең?» дигән сорау бирәүгә дә бирелми иде. Без мәчеткә йөрмибез, баракның үз мулласы бар, форточкадан башын тыгып кына азан әйтә. Капельмейстерыбыз Рушад Хисаметдинов аңа:

— Суликов, к...ә бармагыңны тыгып кычкырсаң чебеннәргә (нимесне «чебен» дип атыйбыз) яхшырак ишетелмәсме! — дип үрти иде. Без одеял астыннан шаркылдап көлешәбез.

Легион муллалары элеккеге партия органнарында эшләгән кешеләр иде, сәдакадан кергән акчаны «бимбер»гә җибәреп, кәефләнеп яттылар.

Легиондагыларга без марш, төрле җырлар өйрәтергә тиеш идек. Совет илендә җырланган җырларның да «партия, комсомол, колхоз, коммуна» кебек сүзләрен алыштырып кулланышка кертә идек. Һәр эштә башлап йөрүчеләрнең кайберләре исемдә калган: ике мулланың берсе — Сабирҗан, баш пропагандист Мичурин, аның ярдәмчесе Сәйфелмөлеков, баш рәссам Шамбазов. Тагын әле музыкантлар арасында Киевтән Борис Попов, Ленинградтан Розенштейн дигән яһүдиләр бар иде.

Легионның башка батальонына концерт белән барганда безгә нимес күзәтчесе тагыла. Хәтта ялга чыгарып каядыр барганда да «чылбыр»сыз йөрмәдек. Фәкать Берлинда яшәп, «Миттельштелле»да («Идел-Урал» комитеты) эшләүчеләр генә нимес паспорты белән ирекле йөргәннәр, диделәр.

Бервакыт, «Идел-Урал легионы»ның бер батальонын большевикларга каршы сугышка озату тантанасы уңаеннан зур концерт бирергә тиеш идек. Берлиннан комитетның «культура министры» килүен көтәбез. Олы түрәләр килеп төшеп, казинода ашап-эчеп ял иткәннән соң гына безгә күренделәр. Министр дигәнебез Демблин кальгасында танышкан Гумеров әфәнде булып чыкты. Бу юлы инде аның кыяфәт башка иде. Өстендә шәп костюм, ак күлмәк, яшел галстук, фетр эшләпә, аягында ялтырап торган туфлиләр. Янәшәсендә сәркатибе — яхшы портфель тоткан яшь егет, фамилиясе Фәтхуллин икән. Алар килеп керүгә, без урыныбыздан кубып, үрә катып «Ахтунг!» командасы астында каршы алдык. Команданы нимес офицеры бирә иде. Гумеров барыбыз белән дә күрешеп чыкты. Гайнан Курмаш белән Зиннәт Хәсәновка ул бик җылы караш ташлаган кебек булды. Минем турга җиткәч: «Ә, Казан артисты, нихәл, иркәм»,— дип кенә куйды. Гумеров әфәндене мин Муса Җәлил икәнен ул чакта белми идем әле...

Болар килгәч безнең эшләр җанланып китте. Репетицияләргә дәртләнеп йөри башладык. Нинди дә булса бирәр көйне белмичәрәк торсак, Гумеров әфәнде мандолинаны кулына алып, үзе уйнап күрсәтә, онытылган сүзләрне дә тиз генә кәгазьгә язып, кулыбызга тоттыра иде. Сәркатибе дә яхшы гына җырлый икән.

Ашыгабыз. Репертуарны баету өстендә эшләп ятканда Берлинның үзеннән олы түрәләр килеп төште. Шул ук көнне «солдаткаем»да кунаклар катнашында «камрадшафт» (дуслык кичәсе) уздырылды. Мәҗелестә Көнчыгыш («Ост») легионнары командиры фон-барон Хэйкендорф та катнашты. Ул озын буйлы, пеләш башлы, алтын кысалы күзлек кигән, русчаны яхшы белгән илле бишләр тирәсендәге генерал иде. Янында — тәбәнәгрәк буйлы, түгәрәк йөзле, сап-сары нимес (хәрби түгел) фон Менде — Көнчыгыш эшләре буенча Гитлерның киңәшчесе. Болар янында «Идел-Урал дәүләте»нең беренче президенты Шәфи Алмаз-Габдерахман ага, аңа илле ике яшьләр булыр, уртача буйлы, чандыр гәүдәле, озынча йөзле, шадралары беленеп тора, чәче сирәкләнгән, бик затлы киенгән. Хатыны Гайшә ханым тулы гәүдәле, түгәрәк битле, алтын кысалы күзлектән. Ул ун-унике яшьлек кызын култыклаган. Киләчәк дәүләтебезнең «тышкы эшләр министры» Гариф Солтанов чибәр, римлән кыяфәтле, нимесчәне яхшы белә. Түрдән урынны әлбәттә фон-барон Зеккендорф алды. Үзе җитмешләрдә булса да хатыны яшь күренә, утыз-утыз бишләрдә булыр, алгы тешләре чыгыбрак торган юка иренле ханым. Болар янында «культура министры» Гумеров, аның сәркатибе Фәтхуллин һәм легионның башка татар офицерлары, баш мулла, пропагандистлар, мәдәният-идеология хезмәткәрләре һәм арырак без — культвзвод капелласы әгъзалары.

Тәүге сүзне баш пропагандист, тамада Мичурин «тышкы эшләр министры» Гариф Солтановка бирде. Ул туган илебез — «Идел-Урал»ны большевиклардан азат итү, үз байлыгыбызга хуҗа булу хакында нотык тотты. «Мөстәкыйльлек өчен, ур-ра!» — дип сүзен бетерүгә, гимн уйналды. Барыбыз да тост күтәрдек. Аннан соң генерал Зеккендорф торып басты, алдан язып бирелгән кәгазьдән

карап, ватып-җимереп булса да, татарча укыды. «Сез большевикларны җинеп, үз илегезгә үзегез хуҗа булырга тиешсез!» — дип сүзен тәмамлады. Кулына фужер тотып баскан башка кунаклар да «Идел-Урал» халкының киләчәге, аның сәләтле интеллигентлары, кодрәтле солдатлары хакында тост әйтеп, кызыл авызлы большевикларны бетереп, үз илегезгә хуҗа булырга тиешсез, дип теләк теләделәр. Өстәлдә ром, шнапслар агыла гына. Шул чак үзебезнен түрә-офицерлар арасыннан бер селәгәе яныма килеп, кулымны кысып: «Илемдә дә мондый «камрадшафт»ны күргәнем юк иде, менә кайда икән Казан» — дип мине кочаклый ук башлады.

Кунак нимесләр үз казиноларына киткәч тә әле без хәтсез күңел ачтык. Ашау байдан, үлем Ходайдан, бер типтереп калыйк ичмасам! Какча, авыру йөзле Мичурин, тамада буларак, табынны шәп тота, русча да, татарча да сайрата гына. Чират җиткәч, мин дә җырлап җибәрдем:

Урал таулар, биек таулар,
Ерак таулар, кар таулар.
Ир-егетләр корал алып,
Мәйданда ирек даулар.

Бусы беткәч, кул чабып, сорап, «Карурман»ны җырлаттылар. Шуннан соң китте биюләр, уеннар... Бераздан президентыбыз Габдерахман ага мине үз янына чакыртты. Кыза төшкән, мине кочаклап, үбеп алды, кул аркасы белән күкрәгемне чәбәкләп:

— Әй энем, синең күкрәгенә Урал таулары сыйган икән,— диде.— Шул кызыл чүпрәклеләрне юк итеп, илебезне азат итсәк, Урал байлыклары безгә генә түгел, бездән соңгыларга да җитә әле,— дип балавыз сыгып алды. Фрау Гайшә ханым дәшми, затлы сигарет капкан, помадалы иреннәре арасыннан төтен алкалары чыгарып елмая гына.

Татар-башкорт көйләренә дәртләнеп биедек ул төнне, аяк тузаннарын кагып алдык, күңелдәге юшкыннарны хәмер белән эретергә тырыштык.

Икенче көнне легионның тагын бер батальонын сугышка озаттык. Берлин кунаклары да кайтып киттеләр. Культура министры Гумеров белән сәркатибе генә оештыру эшләре белән калдылар. Атна-ун көн эчендә концерт әзер булды. Тукайның «Шүрәле» интермедиясен дә сәхнәләштердек. Мин — Шүрәле, Кәрим утын кисүче егет ролендә, Курмаш вакыйганы сөйләп тора. Гумеров әфәнде сәркатибе белән Берлинга барып-кайтып йөри. Кай көннәрдә казинога китми, безнең янда куныл кала, төннәр буе сөйләшеп ятабыз. «Алтын чәч» либреттосын ничек язганы, ничек сәхнәгә куелуы турында сөйләгәне хәтердә калган. Сугыштан соң мин ничә мәртәбәләр Казанда булдым, бик теләсәм дә «Алтын чәч»не күрергә насыйп булмады, форсат чыкмады. Ул язып биргән җыр өчен сүзләр — «Таң маршы», «Кайту маршы», тагын бик күп шигырьләр хәтеремдә ятланып калган. Мин аларны соңыннан Татарстан Язучылар союзына, Гази Кашшафка тапшырдым. Моабит дәфтәреннән тыш, мин алып кайтканнарыннан җиде шигырь «Совет әдәбияты» журналында 1957 елда басылып чыкты. Янә 1974 елны «Кругозор» журналында дүрт шигыре дөнья күрде. Шуның белән вәссәлам. Калганнары күренмәде.

* * *

БЕРЛИНДА «Идел-Урал легионы» декадасы. Гумеров әфәнде житәкчелегендә без бу декадага ныклап, ясканып әзерләнергә тотындык. Аурупаның олугъ шәһәрендә без Идел буе халыкларының тормыш-көнкүреш үрнәкләрен, культурасын һәм сәнгатен күрсәтергә тиеш идек. Монда инде артистлардан кала рәссамнар, макетчы осталар, төрле һөнәр ияләре, тегүчеләр — кыскасы, кемнәр генә тартылмады. Күргәзмә әсбаплары хәзерләнде. Легионда тамаша күрсәтеп чирканчык алганнан соң Гумеров әфәнде Берлинга кайтып китте. Ул анда безне каршы алырга тиеш иде.

Безне яхшы, йомшак вагоннарга утыртып Варшава аша Берлинның үзенә алып киттеләр. Башкалада Гумеров әфәнде житәкләгән бер төркем — комитет хадимнәре безне каршы алдылар. Аннары машинада «Александрплац»ка килеп төшеп, шуннан ерак түгел генә казинога урнаштык. Өс-башыбызны карап, бераз ял итеп алганнан соң, ресторанга алып киттеләр. Шуның алдыннан Гумеров әфәнде безне бер залга җыеп, декадада үз-үзебезне ничек тотарга тиешлегебез турында әңгәмә үткәрде. Як-якка каранмыйча салмак кына атларга... кулны

бутамыйча, шаркылдап көлмичә, тыныч кына сөйләшергә... кулны каты кысмыйча, күзгә туры карап күрешергә... Ресторанда туры утырырга, чәнечке-пычакларны тәртибе белән генә алырга... Авызны чәпелдәтмичә ашарга...

Алманнар безне культурасыз, кыргый халык дип уйлый. Сынатмыйк, алардан да өстен булыйк, диде Гумеров әфәнде. Без, әлбәттә, әдәп сакларга тырыштык... Берлинның музейларын күрдек, Рейхстагны, Бранденбургны тамаша кылдык. Күрмәгән җирләр калмады. Мондагы чисталыкка, тәртипкә ис китмәле иде. Безнең илдән матур ил юк, дип үскән безләргә шушы кадәр контрастны күрү күңелгә авыр иде...

Ресторан-кафетерийларында шпинат белән флэешьләренә (бака үләне белән бака ите) кадәр ашарга туры килде. Егерме-егерме биш яшьлек егетләр бит без, шәп ашап-эчеп алгач, кан кызыша башлый, күзнең ачылган чагы... Немкаларның ирләре фронтта... Кыюланып китеп алман хатыннарын да караштырырга туры килде.

Беркөнне без Берлинның аристократлары өчен зур бер казинода концерт бирдек. Монда нимес артистлары да катнаштылар.

Декаданы уңышлы гына уздырганнан соң безне Балтыйк диңгезе буена, Узедом дигән ял йортына озаттылар. Бу ял йорты бик матур урында, концерт һәм бильярд заллары бар, су коенырга, көймәдә йөзәргә була. Берлиннан комитет җитәкчеләре гел килеп-китеп торалар. Костюмын иңенә салып, ак күлмәктән Абдулла Алишның да берничә көн ял итеп киткәне күз алдымда тора. Башкала кунаклары күбрәк килгәндә милли концертлар биреп «камрадшафт» үткәреп алабыз.

Монда Шәфи Алмаз да үз гаиләсе белән ял итәргә килде. Габдерахман ага мине үз янына чакыртып алды. Өстәл төрле ризык һәм эчемлекләрдән сыгылып тора. Фрау Гайшә ханым кече кызы белән янәшә утырган, хуш исле сигарет төтенен алкаландырып утыра. Габдерахман ага борынгы халык көйләрен җырлавымны үтенде. Мин аккордеонны кулга алдым. Үзем уйныйм, үзем җырлыйм. «Карурман»ның искесе дә, яңасы да калмады, «Зиләйлүк», «Зәңгәр шәл», «Салкын чишмә», «Әллүки»ләрне дә җырладым. Ара-тирә шагыйрьләр үз шигырьләрен сөйләп куялар. Гумеров әфәнде дә монда. Аның «Сыра залында», «Томаулы гыйшык» кебек шигырьләре нәкъ менә шушы «Узедом»да язылды бугай.


Балтыйк диңгезендә үз суыбыз кебек итеп коенып (ни дисәң дә ул безнең илебез белән тоташа ич), ун көнләп ял итеп алганнан соң без тагын Берлинга юл тоттык. Моннан инде Алманиянең башка шәһәрләренә дә барырга тиеш идек. Әмма нимесларның каушап калган чагы иде бу. Инглизләр Берлинны бик каты бомбага тотканнар икән. Безне башкалага кертмәстән, юлны борып, тиз генә легионга кайтарып җибәрделәр.

Нимесләр безне «Идел-Урал интеллигентлары» дип йөртсәләр дә күбебезгә әле культурага ирешү өчен ай-һай күп кирәк иде. Совет илендә безне әдәпкә бик үк өйрәтмәгәннәр икән шул. Мәгънә белмәвебез кайда да үзен сиздерә: урамда сигарет төпчеген теләсә кая ату дисеңме, урынын белмичә төкерү, борын сеңгерү, алман хатын-кызларына аю кебек ябышу, шнапсны артык нык төшереп болагайлану — тагын әллә ниләр... Нимесләр безнең культура ягы түбән дәрәҗәдә икәнен һәрчак искәреп тора шикелле, шуңа эчке бер оялу кичерә идем мин. Аурупаның кайсы гына илендә булмадым, һәркайда үз милли культурасы. Кешеләренең әдәплелегенә, сәламәт рухына сокланып йөрдем.

*(Ахыры киләсе санда)*

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XII СЪЕЗДЫ МАТЕРИАЛЛАРЫ

**Матбугатта инде хәбәр ителгәнчә,
быелның 3 июнендә
Казан шәһәренең Актерлар йортында
Татарстан язучыларының чираттагы XII съезды
булып узды.
Бу олы җыенда идарә рәисе РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
идарәнең биш еллык
эшчәнлеге хакында хисап докладлары белән чыкты.
Аннары
әдәбиятның төрле жанрлары буенча
секция җитәкчеләреннән ӘХӘТ ГАФФАР** *(проза)*,
**ГАЗИНУР МОРАТ** *(поэзия)*,
**РӨСТӘМ МИНГАЛИМ** *(драматургия)*,
**РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН** *(балалар әдәбияты)*,
**ФӘИЗ ЗӨЛКАРНӘЙ** *(әдәби тәнкыйть)*,
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ** *(публицистика)*,
**ВЛАДИМИР КОРЧАГИН** *(урыс әдәбияты)*,
**КЫЯМ МИҢЛЕБАЕВ** *(әдәби тәрҗемә)*
**иптәшләрнең чыгышлары булды.
Съездда,
шулай ук, байтак кына каләм әһелләре
сүз алып,
үзләренең уй-фикерләре
белән уртаклаштылар,
теләк-тәкъдимнәрен әйттеләр.
Түбәндә
журналыбыз укучыларына
Татарстан язучыларының XII съездында
яңгыраган
кайбер чыгышлар
һәм документлар тәкъдим ителә.**



*Съездда Татарстан Республикасы Президенты МИНТИМЕР ШӘРИП улы ШӘЙМИЕВ тә катнашты һәм чыгыш ясады.*



# Ринат Мөхәммәдиев

## ЯЗМЫШЛАР ХӘЛ ИТЕЛГӘНДӘ

Хөрмәтле каләмдәшләр! Мөхтәрәм кунаклар!

Ике жыен арасындагы елларда без һәммәбез гаять зур колачлы, моннан элгәрге дәвердә төшкә дә керергә мөмкин булмаган катлаулы, каршылыклы вакыйгалар шаһите булдык. СССР таркалды. КПСС таратылды. Дистә еллар дәвамына торгызылган һәйкәлләр аударылды. Марксизм-ленинизм тәгълиматы хаким идеология вазифасын югалтты. Байтак еллар дәвамына тотрыклы рәвештә яшәп килгән канун, тәртип, структуралар жимерелде. Урам һәм мәйданнар кайнар митинглардан бушап тормады. Дәүләт һәм хөкүмәт даирәләрендә фетнәләр булып узды. Яңа мөстәкыйль жөмһүриятләр барлыкка килде. Күрше белән күрше якага-яка килде, мөстәкыйльлеккә ирешкән дәүләтләрнең үз эчләрендә дә хакимият өчен көрәш, сугышлар кабынып торды. Дәрья-дәрья булып кан һәм күз яшьләре түгелде...

Без — татар язучылары исә күбрәк үз казаныбызда кайнадык, республикабызда барган гаять кайнар һәм житди вакыйгаларның кыл уртасында булдык. Соңгы дүрт ел эчендә 440 ел дәвамына изерәгән, басылган, кысылган, жәберләнгән милли хис, халык рухы, гүя, фонтан сыман бөрөзлексез бәреп торды. Бәрмәслекме соң?!. Шул кыска гына вакыт эчендә Татарстанның дәүләт суверенлыгы турында декларация кабул ителде. Декларация ул нәрсә, халык ни әйтер, диделәр. Референдум узды. 60 проценттан артык татарстанлылар республиканың мөстәкыйльлеккә тоткан юлын кайнар яклады. Тарихта беренче тапкыр үз Президентыбызны сайладык. Жөмһүриятебезнен яңа законы — Конституция кабул ителде. Югарыдан йодрык болгау, масса-күләм дезинформация һәм янаулар да куркытмады күп милләтле Татарстан халкын. Чын мәгънәсендә сыналды, тарихи дәвер кичерде ул, провокацияләргә бирешмәде, иң мөһиме — милләтара низагларга юл куелмады. Татарстанның, шулай ук тарихта беренче мәртәбә, мөстәкыйль дәүләт атрибутлары — дәүләт гимны, дәүләт гербы һәм дәүләт флагы кабул ителде.

Республикабызның сәяси житәкчеләре һәм Югары Советы, әйтеп бетергесез кыюлык һәм каһарманлык үрнәкләре күрсәтеп, бердәм булды ул көннәрдә. Миңа, бу тарихи вакыйгаларны Казаннан гына түгел, Мәскәүдән дә торып күрергә һәм кичерергә туры килде. Һәм ничәмә-ничә тапкырлар Президентыбыз Минтимер Шәймиевка ачыктан-ачык басым ясау гына түгел, янаулар булганын беләм. Фәрит Мөхәммәтшинның Россия Югары Советы белән күзгә-күз калып тартышкан сәгатьләре, Мөхәммәт Сабировның съезд трибунасыннан сөйләнгән ялкынлы чыгышлары әле дә хәтердә. Молдова икегә бүленеп Днестр ярында сугыш башлангач та, Россия Югары Советының прогнозлар бүлегендә компьютерга салынган яшерен мәгълүматлар... әле дә күз алдымда. Чираттагы милләтара низаг Татарстанда кузгалырга, аннан соң Тажикстанда башланырга

тиеш, диелгән һәм бу низагларны кузгатырга тиешле берничә вариант күрсәтелгән иде аларда. Күргәнебезчә, Таҗикстан белән ялгышмадылар, ул заманнарда тыныч иде әле анда. Ә Татарстанны Алла саклады. Шәймиев, Мөхәммәтшин һәм Сабировларның фикер бердәмлеге һәм халык белән бергә булуы саклады.

Бу тарихи көннәрдә татар әдипләре, һичшиксез, төп әйдәүче көчне тәшкил иттеләр. Башкача мөмкин дә түгел. Чөнки халык һәм милли әдәбият, мәдәният, тел язмышы язучының канына сеңгән мәсьәләләр. Татарстанның халык депутатлары Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Фәүзия Бәйрәмова, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин һәркайсы уртак эшкә хәл кадәри өлеш керттеләр. Матбугатта бәхәсләр уяткан һәм митингларда башлап йөргән Әбрар Кәримуллин, Роберт Батулла, Айдар Хәлим, Әмир Мәхмүдов, Зәки Зәйнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Газинур Моратовларның да, үтә кайнарлык күрсәткән чаклары булса да, теләкләре изге булуда шик юк. Әдәбиятыбызның олпат аксакаллары Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники дә, гадәттәгечә, аек акыл һәм сабырлык белән өртелгән фикерләрен милләттәшләренә үз вакытында җиткерә тордылар. Гомумән, Татарстан өчен тарихи әһәмияткә ия булган бу көрәштән бер генә әдип һәм шагыйрь дә читтә торып калмады дияр идем мин. Анда һәркемнең үз урыны бар иде, һәркем изге эшкә хәл кадәри өлеш кертте. Милләт турында кайгыртканда дуамаллык, кайнарлык һәм мин-минлектән бигрәк, бер-береңне аңларга тырышу, үзара хөрмәт, олпатлык юлдаш булсын иде киләчәктә. Усаллык һәм янау-куркытулар белән хезмәт итеп булмыйдыр ул халкыңа...

Әмма милли дәүләтчелекне ныгыту, яңарыш процессы әле юл башында гына. Тынычланырга яисә күңел төшерергә урын юк. Россия белән Татарстан арасындагы килешү — ул кичектергесез зарурлык, минемчә. Киресенчәлекне алга таба дәвам итү Россиядәге бүгенге сәяси һәм икътисади тотрыксызлык, кризис, хаос чорында һич кенә дә Татарстан файдасына булмаячак иде. Республикабыз җитәкчелегенең халкыбыз иминлеге хакына кылган гамәле булды бу. Соң чиктә халык сайлаган җитәкчеләргә дә ышанырга, таянырга кирәктер... Президент Шәймиевнең дә башына тай типмәгәндер ләбаса... Ул да шушы җир баласы ич, халык җырларын көйләп, татар әдәбиятын укып татар авылында үскән. Тагы, җәмәгать, урыс белән булышуны көчләп такмаска иде халыкка. Ничек кенә булса да, без моны аңларга һәм урынлы-урынсызга каршылык, ыгы-зыгы уятудан тайчынырга тиешлебез. Халык һәм аның киләчәк иминлеге өчен җаваплылык язучы алдында һәрнәрсәдән өстен торсын иде. Шуны онытмыйк: Россия һәм рус халкы белән тарткалашу әлегәчә һичбер дәүләткә һәм шәхескә иминлек китергәне булмады. Әйе, тарихтан гыйбрәт алыйк, әмма мөстәкыйльлеккә тоткан юлыбыздан да тайчынмыйк...

Әүвәлге Советлар берлеге язмышы, табигый ки, әдәбият-сәнгать дөньясына да олы сынау, зур тетрәнүләр алып килде. СССР Язучылар берлеге таркалды. Ул да түгел, Мәскәүдә төрле милли һәм идеологик сәбәпләргә бәйле рәвештә Россия язучылары берлеге бүлгәләнергә керешге. Әнә шул шартларда, хәтерлисездер, без сезнең белән чираттан тыш съездга җыелдык һәм мөстәкыйль иҗат берлегебезне булдырдык. Ләкин бу милли рамкаларда чикләнүгә омтылыш түгел иде. Озак көттермичә, без үзебезнең күршеләр, туганлаш әдәбиятлар һәм рус язучылары белән дә хезмәттәшлек килешүләре төзедек. Алай гына да түгел, — бу җирен русча әйтәм — участвующие в работе нашего съезда писатели Сергей Владимирович Михалков и Тимур Исхакович Пулатов не дадут мне соврать, писательская организация Татарстана стала одним из инициаторов создания на руинах Союза писателей СССР Содружества писательских Союзов. Алай гына да түгел, Әнкарада Төрки әдәбиятлар берлеген нигезләү эшендә дә Татарстан Язучылар берлеге, аерым алганда, Гариф Ахунов, Зөфәр Фәтхетдинов һәм без фәкыйрегез вәкиллегендә, тулы хокуклы, мөстәкыйль иҗади оешма буларак катнашты.

Мөстәкыйльлек яхшы нәрсә, әлбәттә. Әмма вакыт-вакыт, эмоциягә чамадан тыш бирелеп китүдәнме, безнең оешмага да җимерү, таркату бацилллары кертергә омтылучылар булды һәм яшерен-батырын түгел, алар әле дә бар.

Аларның беренчесе — Татарстан язучылары берлеге урынына Татар язучылары берлеге яисә ассоциациясе оештыру идеясе. Оешмабызны милли нигездә бүлгәләү, бәхәссез ки, республикабыздагы милләтара тотрыклык файдасына булмас иде. Бу бер булса, икенчедән, Татарстаннан читтә яшәгән каләмдәшләребез һәм милләттәшләребез өчен безнең ишекләр болай да ачык. Бүген иҗат берлегебездә Мәскәүдән, Уфадан, Ташкенттан, Казахстан һәм Кырымнан әгъзаларыбыз бар. Соңгы араларда гына Башкортстанда яшәүче каләмдәш-

ләребез Рим Идиятуллин, Халисә Мөдәррисова һәм Рәшит Гатауллиннарны бертавыштан үзебезнең иҗат оешмабызга кабул итеп алдык. Татар шигъриятенең бу өч моңлы сазы бүген безнең арада. Талантлы милләттәшләребезне эзләү дәвам иттереләчәк. Димәк, бүлгәләнү өчен бернинди нигез дә юк.

Икенче берәүләр иҗат берлегебез урынына Париж, Нью-Йорклар үрнәгендә пенклуб оештыру кирәк диләр. Оештырып күрсәтегез иң элек, дип әйтүдән башка чарам юк аларга. Ә иҗат берлегенә тимәгез, аның язмышын съезд хәл итсен.

Язучылар берлегенең тыныч кына эшләп килүен өнәп бетермәгән кайберәүләр тагын Иҗади оешманы Әдәби фонд белән алыштыру хакында юк-юк та сүз кузгаталар. Әдәби фонд язучы өчен бик тә кирәкле структура иде, бәхәс юк. Әмма аның бар килере, белгәнегезчә, Мәскәү аша иде. Ә СССР Литфондын кычкыртып таладылар, ямаулыкларга тураклап бетерделәр. Мәскәүдә бүген татар әдәбияты кайгысы түгел, башлары үзара тарткалашудан бушамый. Ә инде «фондлар»ның, нинди генә изге максаттан төзелмәсеннәр, дәүләт бюджетыннан акча алып торуы мөмкин түгел, гайре табигый күренеш.

Литфонд дигән оешма бик күп республикаларда юкка чыкты. Ә Татарстанда ул — бар, бетерелмәде. Аның рәисе Әхсән Баян, директор вазифаларын җәмәгатьчелек тәртибендә Мансур Шиһапов алып бара, бухгалтеры да үз урынында. Клуб һәм китапханәне Язучылар берлеге күтәрде. Һәм башка барлык вазифа һәм мәшәкатьләрен дә санап тормыйм, сез аларны яхшы беләсез, Язучылар берлеге җилкәсенә салдык.

Шуның өстенә, Татарстан хөкүмәте, безнең үтенечләрне искә алып, ТАИС оештырды. Шулай итеп, Татарстанның авторлык хокуклары буенча бүген мөстәкыйль үз оешмасы бар. Аның җитәкчесе — язучы Рәфкать Кәрами.

Бүген, Халыкара Литфонд белән килешүләр нигезендә, безнең Переделкино, Гагра һәм Күктүбә иҗат йортларына барырга теләүчеләрне льготалы путевкалар белән җибәрү мөмкинлегебез бар. Үзебезнең иҗат йортыбызны булдыру мәсьәләсе көн тәртибендә тора. Бу мәсьәләнең җитдилеген аңлап, Минтимер Шәрипович Шәймиев Язучылар берлегенә ярдәм итәргә вәгъдә бирде. Һәм инде, күздә тоткан уңайлы объектлар да бар. Иншалла, иҗат йортлы булу бәхетенә дә ирешербез кебек. Әдәби тел, милли культура һәм сәнгатьнең барлык төрләре нигезен тәшкил иткән һәм соң чиктә милли аң һәм милли дәүләтчелекнең дә үзәк тамыры булган әдәбиятка кертелгән чыгымнар бере белән генә түгел, уны белән кайтачак соң чиктә. Республикабыз җитәкчелегенең моны аңлавы киләчәккә өмет белән карарга нигез бирә.

Иҗат көнкүреш шартларының гаять дәрәҗәдә кыенлашуына да карамастан, әдипләребез халык алдындагы җаваплылык тойгысын киметмәделәр, миңа калса, киресенчә, арттыра гына төштеләр. Әдәби хәрәкәт үзенең сыналган үзәненнән тулып агарга омтылды. Әдәбиятыбызның кайсы гына жанрына бакма, анда кызыклы ачышлар бар. Кризис һәм бер урында таптану кебек бәяләр — шигъриятебезгә булсын, драматургия яисә прозага булсын — хас күренеш булмады. Әдәбияттагы үсеш һәм хәрәкәтне, күңел тарлыгын онытып, күрә белергә дә кирәк.



*Татарстан Президенты әдипләр арасында*

Бу елларда татар прозасында шактый үзенчәлекле һәм гыйбрәтле эзләнүләр күзгә ташланды. Утызга якын роман, илледән повесть һәм йөзләрчә хикәяләр. Шунысы мөһим: прозаикларыбызның караш офыклары, сәнгатьчә осталыклары һәм фикерләү культуралары елдан-ел киңәя, күтәрелә бара.

Халкыбызның бөек улы, талантлы язучы, фидакарь сәясәтче Гаяз Исхакый мирасының әдәбиятыбызга әйләнеп кайтуы — соңгы елларның иң мөһим күренешләреннән берсе булды. Бу каһарманыбызның гаять бай иҗаты белән танышып, яшь буын әдипләр осталык мәктәбе уздылар, үзләре өчен көрәш үрнәгеи күрделәр, халкыбызның бәйсезлеге, дәүләтчелегебезне торгызу юлында Гаяз Исхакыйча батыр һәм фидакарь булырга өйрәнделәр. Гасырыбыз башында инкыйраз хәтереннән сакланырга өндәп сугылган чаң авазы, ничә дистә еллар буена хакимлек иткән коммунистик идеология тозакларыннан котылып, ниһаять, безгә дә килеп җитте.

Фатих Әмирханның «Шәфигулла агай» әсәре безнең күзләрне томалап торган пәрдәне алып ташлады. Гали Рәхимнең «Идел», Садри Җәләлнең «Дим буенда», Галимҗан Ибраһимовның «Адәмнәр» әсәрләренең бүгенге укучыларга ирештерелүе дә әдәбиятыбыз тормышында һәркайсы олы вакыйга. Ниһаять, Хәсән Сарьянның «Нокталы өтер»е укучы хөкеменә тәкъдим ителде.

Болар һәммәсе, әлбәттә, агымдагы прозаның да публицистик рух белән өртелүен тәэмин итте. Газиз Кашаповның «Гыйфрит», Фоат Садриевның «Таң җиле», Фәрит Гыйльминең «Зәйтүнәкәй, акчарлагым», Җәүдәт Дәрзаманның «Ник кирәсез төшләремә?», Аяз Гыйләҗевның «Балта кем кулында?», Гариф Ахуновның «Гомер юлы» һәм башка байтак әсәрләр якындагы үткәннәребезнең бик әчкә яшеренгән серле якларын уңышлы күрсәтеп бирүләре белән игътибарны җәлеп иттеләр.

Бер төркем язучыларыбыз, халык, бигрәк тә зыялыларыбыз өчен, афәттән гыйбарәт булган утызынчы-илленче еллардагы шәхес культы чорын тасвир иттеләр. Хакыйкатькә юлны бездә шушы тәмугъ газапларын үткән Е. Гинзбург һәм Ибраһим Сәлахов башлап җибәргәннәр иде. Алар укучыларга чынбарлыкның коточкыч вакыйгаларын җиткерделәр. Әгәр Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында», «Җимерелгән бастион», Габдрахман Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше» һәм Ибраһим Сәлахов әсәрләрен берсе артыннан берсен укысаң, кешегә карата кылынган вәхшилекләрнең немец фашизмы тарафыннан да, совет тоталитаризмы ягыннан да бер үк төрле булуын күрәбез. Чөнки аларның тамыры бер — кешене кыралмау. Аяз Гыйләҗевның «Йөгез, бер дога», Гурий Тавлинның «Афәт», Нәби Дәүлинең «Сталинга хат», Рәфкать Кәраминең «Каргышлы юллар» һәм Әнәс Галиевнең «Намус кушканча» әсәрләре ярдәмендә исә әлеге күзаллаулар тагы да тулылана төште. Газиз Кашаповның «Киек каз юлы» романын да шулар рәтендә карарга кирәк. Гасырыбызның олы шагыйре Хәсән Туфан язмышы — тулаем халык өстенә ябырылган фаҗиганең бер күренеше иде. Бу еллар М. Солтангалиев өстеннән тоталитар хакимият япкан кара япманың алынып ташлавы белән дә үзенчәлекле. Бу нык рухлы, милләтен азатлык юлына алып чыгу омтылышында гаять масштаблы каһарманлыклар кылган шәхес хакында укучыларыбыз мөмкин кадәр күбрәк белергә омтылдылар.

Хәзер үткәннәребезгә гаделл бәя бирер чак. Чөнки өстебездән, тегеләй яз, болай яз, дип, бармак селкеп торучы фирка юкка чыкты. Бүген цензор һәр язучының үзендә булырга тиеш. Төп цензор — ул намус. Дөрес, теге вакытларда да намусына хилафлык итмәгән әдипләребез күп булды. Әдәбиятыбыз аксакаллары Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗевлар шуңа үрнәк түгелмени?! Гомәр Бәширов «Гыйбрәт» исемле әр-яна әсәре белән моны тагын бер тапкыр раслады. Арпаяз авылында утызынчы елларда кулакларга каршы кылынган кыргыйлык һәм кешелексезлек тетрәндергеч картиналарда күрсәтелә. Каләм остасының сәнгатьчә камил буяулар белән эш итүенә, хакыйкатькә тугрылыгына сокланмый мөмкин түгел.

Тәлгать Галиуллинның «Замана балалары», Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ачы тәҗрибә» кебек әсәрләре дә кичәге көнебезне аңлау юлында кызыклы тәҗрибә булып кабул ителде.

Бүген үткәннәребезгә игътибар, тарихыбызны документальлек дәрәҗәсендә төгәл белүгә ихтыяҗ бермә-бер артты. Тарихи әсәрләрнең абруе гомер булмаганча үсте. Нурихан Фәттахка нәкъ менә быел тарихи проза өлкәсендәге фидакарьлекләре өчен Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге бирелү юкка түгелдер. Нурихан Фәттахның «Кырык дүртнең май аенда» повесте, «Кичү» романы да якындагы үткәннәребезне сәнгатьчә өйрәнүнең матур үрнәкләре булып торалар. Халык әйтмешли, аның кул-аягы җиңел булды, тарихи катламнарны ачуга башкалар да

ныклап тотынды. Мөсәгыйть Хәбибуллинның активлыгы игътибарга лаек. Аның «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный», «Хан оныгы Хансөяр» кебек романнары үз укучыларын тапты. Роберт Батулланың «Сөембикә» романын вакыйга булган әсәр дип искә алырга мөмкин. Шуны да хәбәр итим: бу көннәрдә әлеге әсәр төрек телендә Истанбулда нәшер кылына. Җәмит Рәхимовның «Батырша», Флүс Латыйфиның «Хыянәт» романнары тарихи прозабызның офыкларын нык киңәйтте. Сүз уңаенда әйтергә кирәк, Татарстан китап нәшрияты прозабызны күптомлыклар бастырып чыгаруы белән дә баета килә. Вакыйф Нуруллин һәм Әхсән Баяновның ике томлыклары, Әмирхан Еникинең өч томлыгы дөнья күрде инде. Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Мәхмүт Хәсәновларның да күптомлыклары укучыга барып ирешү юлында.

Прозада хатын-кыз язучыларыбыз Мәдинә Маликова, Кояш Тимбикова әүвәлгечә үк ныклы кул белән эшләүләрен дәвам иттерәләр. Зәки Зәйнуллин шактый нәтиҗәле иҗат дәвере кичерде. Бүген аның «Полковникны озату», «Галимулла бабай күгәрченнәре», «Сугыш алды малайлары» кебек әсәрләрен белмәгән укучы сирәктер. Мәгъсүм Насыйбуллин һәм Зөфәр Фәтхетдиновлар детектив жанрны үстерүгә елдан-ел зуррак өлеш кертә баралар. Сүз уңаенда шуны да әйтим, З. Фәтхетдиновның «Откровение XX века» хезмәте татар һәм рус дөньясында гына түгел, дөньякүләм вакыйга буларак кабул ителде. Атилла Расихның «Ишан оныгы» романы да укучыларыбыз тарафыннан җылы кабул ителде.

Мөслимдә тын гына, ипле генә иҗат итеп яткан тыйнак бер каләмдәшебез бар безнең — Фоат Садриев. Әмма аның кабатланмас прозаик һәм драматург булуын һәммәбез яхшы белсәк тә, еш искә алмыйбыз бугай үзен. Бу бишьеллык Фоат Садриев өчен аеруча бәрәкәтле булды. Аның «Таң җиле» романы бүгенге прозабызның иң гүзәл үрнәкләреннән.

Әхсән Баянов прозада җиң сызганып эшләвен дәвам иттерде. Миңа калса, аның татар прозасында һәм эчтәлек, һәм форма ягыннан зур яңалык булган «Җәй белән җәй арасы», «Урланган ай» повестьлары әлегәчә житәрлек дәрәҗәдә бәяләнмәде булса кирәк.

Прозада үз йөзен, үз урынын тапкан Нәбирә Гыйматдинованың «Сихерче»се укучылар тарафыннан 1993 елда аеруча яратып укылган әсәр буларак кабул ителде. Һәм бу очраклы күренеш түгел, минемчә.

Укучылар яратып кабул иткән әсәрләр арасында без Газиз Кашаповның «Убырут», Мөхәммәт Мәһдиевнең «Бәхилләшү», Роберт Батулланың «Юл буенда зәңгәр чәчәк», Миргазиян Юнысның «Европа ат сагына», Гәрәй Рәхимнең «Җәгүр дәдәй дәмәкләре», Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат», Рәисә Ишморатованың «Тормыш дәвам итә», Тәүфыйкъ Әйдинең «Елан угы», Зиннур Хөсниярның «Тәгәри китте язмышлар», Әхәт Гаффарның «Олы юлның тузаны», Әнәс Галиевның «Авылдашлар», Рашат Низамиевның «Кызыл кар яугач» әсәрләрен билгеләп үтәргә кирәк. Камил Кәримов, Зөлфәт Хәким һәм Фәнзаман Баттал — сатира, Вахит Имамов, Альберт Хәсәнов, Шамил Рәкыйпов, Шаһинур Мостафин публицистик прозада, Заһит Мәхмүди исә мажара һәм фантазия жанрларында уңышлы эшләп киләләр. Мәгъсүм Хужин, Марат Әмирханов, Әсрар Галиев, Индус Сирматов, Хәйдәр, Фәйзи Галиев һәм Радик Фәизов хикәя-повестьлары да укучыларның игътибарын җәлеп итте. Рахмай Хисмәтуллинның ихласлык һәм җан кайнарлыгы белән язылган «Кыйбла җиле» югары бәя — Г. Исхакый бүләгенә лаек булды.

Әйе, прозада зур эзләнүләр бара, кызыклы, мавыктыргыч әсәрләр языла. Ләкин шулай да бүгенге көнебезнең катлаулылыгын эстетик, фәлсәфи өйрәнү юлында ул безне канәгатьләндерә алмый әле. Кыюлык, масштаблылык юлдаш булсын каләмдәшләремә киләчәктә.

Татар әдәбиятының чишмә башы, авыр елларда һәм бәхет килгәндә халык күңеленең мәңгелек юлдашы булган шигъриятебезнең дөнья халыкларына мәгълүм абруе, югары аты бар.

Ике съезд арасында татар шигъриятенең дә ирешкән уңышлары муллан булды. Күпчелек шагыйрьләребез заман авырлыкларына бирешмичә, шигырь китаплары чыгаруның кыенлыкларына карамыйча, актив иҗат иттеләр. Иң сөендергәне шул: шигырьдә, шагыйрь әйтмешли, чын-чынлап уйланучылар күбәйде. Салих Баттал, Гамил Афзал, Илдар Юзеев кебек олпат шагыйрьләребезне дә, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат кебек яшьләрне дә халкыбызның фаҗигале тарихы, бүгенгесе, киләчәге турындагы борчулы гамь биләп алды. Әүвәлгерәк елларда шигърияттә очрый торган коры, купшы риториканы акрынлап конкрет хискә, фикергә корылган шигырь-поэмалар алыштыра башлады. Кыскасы, соңгы 4—5 елны шигъриятебезнең кызыл, идеологик шигырьләрдән тәмам арыну чоры

булды диярга дә мөмкин. Ләкин дөрес аңлашыла күрсен: күп шагыйрьләребез тоталитар система шартларында да ил, халык язмышы турында уйланудан туктамады, һич югында эзоп теле ярдәмендә булса да, халкыбызга үзенең бөек һәм фаҗигале үткәне, дәүләтчелеге хакында сөйләргә, язарга омтылды. Халкыбыз аңында азатлык, бәйсезлек, дәүләтчелек идеясе күпмедер дәрәҗәдә сакланып килгән икән, без моның өчен, һичшиксез, шагыйрьләргә дә бурычлыбыз.

Заманында шагыйрьлек пәйгамбәрлек белән янәшә йөргән. Шагыйрь әйткән сүз олуг сүз саналган, аңа колак салганнар.

Чын шигырьнең абруе бүген дә шул югарылыкта. Ышанмаучылар булса, Илдар Юзеев яисә Равил Фәйзуллин, Лена Шагыйрҗан яисә Кадыйр Сибгатуллин китапларына мөрәҗәгать итсеннәр. Нәрсә-нәрсә, әмма татар әдәбияты үзенең шагыйрьләре белән горурлана ала. Ренат Харис, Әхсән Баян, Марс Шабаев, Кави Латыйп, Рөстәм Мингалим, Роберт Әхмәтҗан, Әхмәт Гадел, Рәфыйк Юнысовларның фәлсәфи лирикасы, Әдип Маликов, Флера Гыйззәтуллина, Рәдиф Гаташ, Сафуан Муллагалиев, Харрас Әюпов, Шамил Маннапов, Эльмира Шәрифуллина, Рифкать Закиров, Нияз Акмалов, Фирдәвес Әһлия, Илсөяр Иксанова, Эдуард Мостафиннардагы эчкерсезлек һәм хис кайнарлыгы кемне генә әсир итмәс икән! Авылда яшәп, туган як гүзәллеген җырлап туймаган Гарифҗан Мөхәммәтшин, Илдус Гыйләҗев һәм Рафаэль Газизовлар да шигърият бакчасында янып иҗат итә һәм үз урыннарын таптылар.

Чәчәннәрдән килгән гайрәтле талантка ия Клара Булатованы тыңлап карагыз, туры Тукайлар рухын дәвам иткән Мөдәррис Әгъләмовны укыгыз, Такташ дәрте һәм кайнарлыгын сүрелдерми килгән Зөлфәткә мөрәҗәгать итегез, татар поэзиясенә тел-теш тидерергә теләгәннәр. Бар ул бездә шагыйрьләр, кадерләрен генә белеп бетермибез.

Ике съезд арасында әдәбиятыбызда сизелерлек эз калдырган поэмалар да дөнья күрде. Рәшит Әхмәтҗановның «Карачкы», Фәнис Яруллинның «Нәсел агачы», Зиннур Мансуровның «Хозыр галәйһес-сәләмне эзләү», Флера Гыйззәтуллинаның «Ирек юлы», Газинур Моратның «Ачлык», Ркаил Зәйдулланың «Матәм» поэмаларында татар халкының катлаулы язмышы, ирек даулап бүгенге бәргәләнүләре һәм өметләре. Әхмәт Рәшитовның «Колшәриф» поэмасы исә безне ерак тарихыбыз сәхифәләренә алып кайтты. Шагыйрьнең үз иҗаты өчен генә түгел, татар әдәбиятында күренекле вакыйга «Колшәриф»нең үз Казанына, халыкка әйләнеп кайтуы.

Ренат Харис исә укучыны гына түгел, үзен элек-электән яхшы белгән каләмдәшләрен дә хәйран калдырды. «Өч үбешү» поэмасы — татар әдәбиятында уникаль вакыйга һәм яңа сүз. Габделҗаббар Кандалыйның үзен «ух-ах» китерерлек мизгелләр бар...

Татар халкында җырга аеруча җылы мөнәсәбәт яши. Соңгы елларда «җырның ертыгы юк» ди торгач, талымсызланулар да ишәя төште кебек. Әмма җыр өлкәсендә шагыйрьләр башкарган эш аерым сүз һәм хөрмәтләүгә лаек. Гөлшат Зәйнашева иҗаты бу өлкәдә үзе бер кабатланмас дөнья — җыр-моң дәрьясы. Аңарга Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге бирелү ул шагыйрәне генә түгел, татар җырын да олылау булды.

Илдар Юзеев, Әхсән Баян, Клара Булатова, Резедә Вәлиева, Роберт Миннуллин, Разил Вәлиев, Марсель Галиев, Разим Вәлиуллин һәм Мансур Шиһапов әүвәлгечә үк тугрылык күрсәттеләр татар җырына. Ләкин минем татар җырына яңа, кайнар бер дулкын булып бәреп кергән шагыйрәләр һәм шагыйрьләр хакында сүз әйтәсем килә. Шәмсия Җиһангирова һәм Наил Касыймов, Фирая Зыятдинова, Бикә Рәхимова һәм Нур Әхмәдиев, Халисә Мөдәррисова һәм Илсур Хөснетдинов, Фәйрүзә Мөслимова һәм Фирдәвес Әһлияләр хакында. Эчкерсез һәм ихлас җырларыгыз сәхнә түрендә, халык күңелендә бүген. Хәерле сәгатьтә булсын, җырлатыгыз татарны, җырлатыгыз... Ул күп еллар инде болай да...

Театрларыбыз сүрелә төште, драматургия бик саекты, дигән сүзләр әледәнәле ишетелеп ала. Театр хакында әйтә алмыйм, ул өлкәдә зур белгеч түгелмен. Ә драматургиябез хакында исә аяк терәп бәхәсләшә алам. Моңарчы күрелмәгән идея-эстетик эзләнүләр, тематик киңлек төсмерләнә бүгенге сәхнә әдәбиятында. Моннан биш еллар элек кем яза иде сәхнә әсәрләрен? Туфан Миңнуллин, Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев, Ризван Хәмид, Батулла, Рөстәм Мингалим һәм Фоат Садриев, Юныс Сафиуллин исемнәре күренгәли башлаган иде. Моннан ун еллар әүвәл дә шулар. Унбиш еллар әүвәл дә...

Бу биш елда да Туфан Миңнуллин үз жанры һәм сәхнәсенә тугры калды. Аның соңгы әсәре булган «Хушыгыз!» тагы бер кат бу өлкәдә талантлы һәм ихлас олы әдип иҗат иткәнлекне дәлилләп килә. Т. Миңнуллин татар сәхнәсендә

үз буыны һәм заманыбызның җанлы энциклопедиясен тудырды дип әйтергә, ниһаять, вакыттыр инде.

Ә менә соңгы биш ел эчендә драматургиябезгә бер түгел, дистәдән артык яңа, яшь талантлар килеп керде. Мансур Гыйләҗев, Гафур Каюмов, Зөлфәт Хәким, Данил Салихов һәм Сәрия Вильдановалар иҗат иткән әсәрләр бүген татар сәхнәсе түрендә, тамашачыбызның иң яратып караган авторлары булып киттеләр.

Шуның өстенә, формалашып килүче кинодраматургия өлкәсендә дә җитди тәҗрибәләр күзгә ташлана. Гариф Ахунов, Ризван Хәмид һәм Рөстәм Мингалим иҗат иткән сценарий нигезендә Тукай турында күпсерияле фильм төшерелә. Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим һәм Әхмәт Гаделнең дә бу жанрда актив эшләве мәгълүм. Һәм, әлбәттә, драматургия хакындагы сүзне бүген арабызда утырган аксакал Риза агай Ишморатны олылап йомгаклыйсы килә.

Әйтергә кирәк, әдәби тәнкыйть заманы түгел бүген. Шулай да Нил Юзеев, Гариф Ахунов, Тәлгать Галиуллин, Рафаэль Мостафин, Азат Әхмәдуллин, Флүн Мусин, Фәиз Зөлкарнәев, Мөдәррис Вәлиев һәм Фәрит Хатиповларның тәнкыйтебезгә хәл кадәри өлеш кертә килүе куандыра. Әдәби тәнкыйть һәм әдәбият тарихы, библиографиянең академиклары (инде, ниһаять, туры мәгънәсендә) Мансур Хәсәнов, Миркасыйм Госманов һәм Әбрар Кәримуллиннар, гадәттәгечә, фундаменталь хезмәт башкардылар. Мансур Вәлиев, гәрчә үзенә вакыт-вакыт объективлык житенкерәмәсә дә, гадәттәгечә актив эшли. Мөгаен, бүгенге тәнкыйтьнең прозага караган өлкәсендә Фоат Галимуллин, драматургия һәм театр тәнкыйтендә Рәүф Игъламовның аеруча эзлекле һәм принципиаль иҗат итүләре съезд мөнбәреннән яд ителергә тиештер. Вакыт-вакыт Галимҗан Гыйльманов белән Фаяз Дунай да кызыклы мәкаләләр белән чыгыш ясадылар. Шуның белән бергә, тәнкыйть жанрының бүгенге хәле һәм киләчәк язмышы безне нык борчый торган мәсьәләләрнең иң җитдие булып кала бирә. «Казан утлары» һәм «Идел» журналы җитәкчеләре дә бу проблемага йөз белән борылсыннар иде.

Әдәбиятның киләчәге, ягъни яшьләр турында кайгырту — бездә элек-электән дәвам итеп килгән матур традицияләрнең берсе. Яшьләр белән эшләүнең классик дәвере Гариф Ахунов, Илдар Юзеев һәм Шәүкәт Галиев исемнәре белән бәйләнгән. Соңгы елларда исә бу эшне җанын әдәбият өчен фида кылырга әзер булган Рөстәм Мингалим алып бара. Аның җитәкчелегендә Пермь өлкәсенең Барда районында, үзебезнең Актанышта, Алабугада, Чаллыда, Яңа Чишмә һәм Питрәчтә, район иҗат берләшмәләре белән бергәләп, иҗат семинарлары уздырылды. Йөзләгән башлап язучының кульъязмасы рецензияләнде, иң лаеклылары матбугатка тәкъдим ителде. Дистәләгән яшь әдәпнең китаплары дөнья күрде. Ә иң куанычлысы, әдәбиятның матди престижы нык кимегән бер заманда иҗат берлегебез сан ягыннан кыскармады. Күпсенмәгез, җәмәгать, соңгы биш ел эчендә Татарстан Язучылар берлегенә җиде дистә талантлы яшьләр яисә гомерен әдәбиятка багышлап олыгая килгән фидакярлар кабул ителде. Идарә рәисе буларак, миңа һәм Кабул итү комиссиясе рәисе Аяз Гыйләҗевка кайбер каләмдәшләр әледән-әле, талымсызлык күрсәтәсез түгелме (?), дигән кинаяле караш ташлый килде. Күпсенмик, сигез миллионлы татар халкына һәм Татарстанга 250 каләм иясе һич кенә дә күп түгел ул. Аннан язучы яисә шагыйрьнең халыкка бәла-каза китергәнен белмим, рэкетерлар, бандитлар һәм талаучылар ничек үрчегәнне күрмисезме, шуңарга пошыныйк без.

Газета-журналлар чыгару өлкәсендә бай традицияләребез булуга да карамастан, совет чорында татар әдәбияты өчен бердәнбер мәйдан «Казан утлары» журналы булды. «Казан утлары» бүген дә татар әдәбиятының көзгесен хәтерләткән иң мәртәбәле, академик басма булуында дәвам итә. Соңгы биш ел эчендә генә дә аның сәхифәләрендә 24 роман, 37 повесть, 48 хикәя, 9 поэма, 7 сәхнә әсәре, тарих һәм әдәбият-сәнгать мәсьәләләрен яктырткан йөзләгән мәкаләләр дөнья күрде. Журнал үзенең 70 еллык юбилеен күркәм билгеләп узды.

Ике съезд арасында, ниһаять, әдипләребезнең күптәнге хыялы «Идел» журналы чыга башлады. Ул татар һәм рус телләрендә ай саен дөнья күреп килә. Кем ничектер, әмма мин үзем «Идел» журналына сокланам. Тулы булмаган биш ел эчендә, юктан бар булып, бу коллектив татар халкы яшәгән төбәкләрдә үз урынын, даими укучыларын тапты. Журнал кызыклы, оператив һәм актуаль. Бүгенге татар әдәбиятын «Идел»сез күз алдына китерү мөмкин түгел. Бу, беренче чиратта, әлбәттә, журналның беренче баш мөхәррире Римзил Вәлиев һәм гамәлдәге җитәкчесе Фәиз Зөлкарнәевларның һәм, гомумән, журналның талантлы, бердәм коллективы хезмәте нәтиҗәсе.

Чаллы төбәгендә чыга башлаган «Аргамак»ның да региональ журнал гына булмыйча, бөтен татар әдәбияты һәм татар халкын колачлап алачагына өмет зур. Һәрхәлдә, талантлы публицист һәм шагыйрь Айдар Хәлим житәкләгән бу журналның үз йөзе бар инде.

Татарстан Язучылар берлеге инициативасы белән нигезләнгән «Салават күпере» журналын исә озын гомерле булмас, көчебез житмәс дигән шик-шөбһә белән нәшер кыла башлаган идек. Сәләтле һәм кулыннан эш килә торган егетләргә тап булганбыз, баш мөхәррир Зиннур Хөснияр һәм Ләбиб Лерон, замана нинди генә проблемалар тудырмасын, һәммәсен мөстәкыйль хәл итеп, республикабызда гына түгел, әүвәлге Советлар берлеге мәйданнарында беренче булган журнал чыгарып киләләр. Сабыйларның рәхмәте төшсен үзләренә. Моннан 2—3 ел элгәре Мәскәүдә съезд мөнбәреннән Сергей Владимирович Михалков: «Я лучшего журнала для детей в руках еще не держал»,— дип, сокланып, реплика ташлаган иде. Татар әдәбиятына һәрчак хәер-хак булган олы әдипнең бәясенә лаек журнал балалар әдәбиятын үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә. «Ялкын» һәм «Сабантуй» белән янәшә, шул рәвешле, балаларыбыз өчен гел көтмәгәндә өченче могжиза пәйда булды. «Ялкын»ны балалар язучысы Җәүдәт Дәрзаман житәкләсә, «Сабантуй»да Андерсен дипломы лауреаты, балачак шагыйре Роберт Миңнуллин житәкли. Шушы урында соңгы биш ел эчендә татар балалар әдәбиятының шактый ышанычлы адымнар белән үсеш алуын да аерым билгеләп узу урынлы булыр иде. Олы талант иясе Шәүкәт Галиевнең бүген татар балалар поэзиясендә үз мәктәбе бар. Ләбибә Ихсанова, Энже Мөэминова, Җәвад Тәржеманов, Роза Хафизова, Җәүдәт Дәрзаман, Хәкимжан Халиков, Мәрзия Фәйзуллина, Резеда Вәлиева, Ләбиб Лерон, Әзһәр Габиди, Раушания Низамова һәм Рафис Корбан кебек дистәләгән шагыйрь һәм прозаиклар да балаларны яңадан-яңа әсәрләр белән куандырып килә. Безгә бу урында бер нәрсәне ассызыклап узарга кирәктер: балалар язучысы — ул бүгенге укучы алдында гына түгел, жәмгыять һәм милләтнең киләчәге каршында да жаваплы. Шуңа күрә бездән балалар әдәбиятына игътибарны икеләтә-өчләтә арттыра бару сораладыр киләчәктә.

Ике съезд арасында Язучылар берлеге үзенең атналык әдәби газетасы «Әдәби жомга»ның да берничә санын нәшер кылды. Бу очракта, дөресен әйтергә кирәк, арабыздан башлап йөрүче фанатик табылмады һәм, әлбәттә, акча мәсьәләсе. Һәрхәлдә, газета теркәлгән, заманалар яхшырып, матди мөмкинлекләребез табылса, аны дәвам итү мөмкин булыр, дип ышаныйк. Әлегә вакытлы матбугатта мәйдан юклыктан зарланучыны очратканыбыз юктыр. Чөнки хөрмәтле әдибебез Рафаэль Мостафин житәкләгән «Татарстан» журналы, күренекле тәнкыйтьче Флүн Мусин житәкчелегендә чыга башлаган «Мирас» журналы һ. б. басмалар язучыларны һәрвакыт көтеп ала.

Матбугат турында сүз чыккан икән, газета-журналларыбызның ишәюенә куану белән бергә, китап басу, язучы һәм шагыйрьләрнең әсәрләрен укучыга житкерү өлкәсендә килеп туган кыенлык һәм кысынкылыклар хакында да әйтми үтү мөмкин түгел. Татарстан китап нәшрияты татар әдәбиятын үстерүгә хәл кадәри өлеш кертә. Рәхмәттән башка сүзебез юк. Әмма, бүгенге әдәбият өчен жанын фида кылырга әзер торучылар саны анда сирәгәя төште кебек соңгы араларда, базар һәм коммерция түргәрәк үтеп керде. Хәер, эш китап нәшриятында гына да түгел, иң әүвәл китап сәүдәсе һәм полиграфиянең милли китап мәнфәгатьләреннән шактый читләшә баруында, минем карашымча. Үз вакытында матур гына эшләп килгән бербөтен нәшриятны кисәкләргә бүлгәләүдән түгел, эшне, киресенчә, Татарстан китап нәшрияты, Полиграфия комбинаты һәм китап сәүдәсен бер йодрыкка туплаудан башларга кирәк булгандыр. Бүген кайда барма — анда татар китабы юклыктан зарланалар. Чит өлкәләр турында әйтмим дә, Арчада да, Актанышта да, Мамадышта да юк татар китабы. Без — язучылардан: «Язудан туктадыгызмы әллә?» — дип сорыйлар. Авыл жирен китап белән тәэмин итәргә тиешле сәүдә оешмасы — Татпотребсоюз китап дигән рухи байлык барлыкны, гомумән, онытты, санга сукмый хәзер. Книготоргның акчасы юк. Полиграфкомбинат һәм нәшрият та акчасызлыктан зарлана. Бәлки, халыкның да артык акчасы юктыр. Әмма ул китап эзли, аңарга татарча китап юк, дип жавап бирәләр. Ә Казанда, әлеге дә баягы бер йодрык булып эшләргә тиешле булган өч оешма,— бер түбә астында бер-беренә бурычларын санап, «бетәбез... үләбез...» дип каравыл кычкыралар. Болай дәвам итсәк, ерак китә алмабыз, әлбәттә. Бик тә житди, үтә житди мәсьәлә бу.

Язылган китапларыбызны үз вакытында укучыга тәкъдим итә алмау — авыр эш. Әмма республика жәмәгатьчелегенә төрле төбәкләргә тузганактай сибелгән

халкыбыз белән элемтәдә торуның башка юлларын да эзләргә туры килә. Бу очракта газета-журналлар, әдәбиятка хөрмәтле караштa булган радио-телевидение ярдәмгә килә.

Әдәбият көннәре уздыру практикасы дәвам иттерелде. Соңгы араларда гына да Башкортстанда, Пермьда, Эстониядә, Ульяновскида, Әстерханда, Екатеринбургта татар әдәбияты көннәре уздырылды. Ә инде әле генә Балык Бистәсе һәм Балтач районнарында үткән әдәбият көннәре авыл эшчәннәре өчен дә, язучылар өчен дә, чын мәгънәсендә тарихи вакыйгага әверелде. Тукай туган көндә һәр елны шагыйрьләрне Арча районы колач җәеп, олылап каршы ала. Рәхмәт авыл хезмәтчәннәренә.

Тугандаш Төркия белән дә аралар көннән-көн якыная бара. Төркиядә татар поэзиясе һәм хикәя антологияләре басарга әзерләнде, китапларыбыз дөнья күрә килә, дистәләгән журналларда татар әдәбиятыннан үрнәкләр һәм әдипләребез хакында мәкаләләр басылды. Аерым делегацияләр составында һәм шәхси визит белән язучыларыбыз бары соңгы биш ел эчендә генә дә 40 тан артык чит илдә булып, юлъязма һәм истәлекләр белән кайттылар. Язучы Роберт Батулла һәм шагыйрь Ркаил Зәйдулла Истанбулда төрек телен өйрәнү курсын уздылар. Равил Фәйзуллин һәм Ренат Харис Бурса шәһәрендә үткән халыкара шигъри фестивальдә катнаштылар. Төркия һәм Татарстан Язучылар берлекләренең уртак килешүе нәтиҗәсендә, шушы айның ахырында Әнкарада һәм Истанбулда Тукай шигърияте атналыгы уздырылачак.

Татарстан җиренә дә каләмдәшләр бик теләп киләләр. Республикабызда эстон һәм фин, башкорт, молдован һәм удмурт әдәбияты көннәре зур уңыш белән узды. Тагы дистәләгән чит илләрдән килгән шагыйрьләр, әдипләр белән онытылмас очрашулар хәтердә уелып калды.

Мөхтәрәм каләмдәшләр!

Татарстан язучыларының XI-XII корылтайлары арасындагы әдәби-иҗтимагый һәм оештыру эшләре һәммәсе үзебез сайлаган Идарә тарафыннан алып барылды. Идарәгә 23 әдип сайланган иде. Ике-өч кешедән тыш, һәмма идарә әгъзалары утырышларга даими йөрделәр һәм үзләреннән гомуми эшкә хәл кадәри өлеш кертеп килделәр. Бүген аларга рәхмәттән башка сүз юк. Ә инде бу корылтайда яңа Идарәне сайлауга безгә бермә-бер җаваплырак килергә кирәктер. Идарәгә, биш ел дәвамына бармакка-бармак сукмый торып та, иҗат оешмасына яла ягып, аны таркату юлларын эзләгән эксперимент ияләре кирәк түгел. Яңа идарә әгъзалары — һәммәсе конкрет эш өчен җаваплы, сүз белән генә түгел, үзләрен эш белән дә күрсәткән, күрсәтергә сәләтле талантлы каләм ияләре булсын иде. Һәрхәлдә, заман таләбе шундый.

Чаллы бүлеге (җитәкчесе Рахмай Хисмәтуллин), Әлмәт бүлеге (Нур Әхмәдиев һәм Разим Вәлиуллин) шулай ук, безнең карашка, үз өсләренә салынган йөкне җигелеп тарттылар. Рәфкать Кәрами әйдәп барган Матур әдәбиятны пропагандалау бюросы Татарстанда һәм татар халкы яшәгән төбәкләрдә меңнән артык иҗади очрашулар, китап укучылары конференцияләре, әдәбият атналыклары үткәрде. Күренекле әдипләребезнең юбилей һәм иҗат кичәләре даими узып торды. Язучыларыбыз Бөтендөнья татар конгрессы эшендә катнашты, Язучылар йортында дөньяның 20ләп иленнән килгән милләттәшләр катнашында эчтәлекле әңгәмә оештырылды.

Базар мөнәсәбәтләренә керү чорында авыр хәлдә калган язучыларыбызның көнкүрешен кайгырту Идарә һәм җитәкчелекнең даими игътибары үзәгендә булды. 1992 ел ахырында Президентыбыз каршында оештырылган Мәдәниятне яклау фонды даими рәвештә зур ярдәм күрсәтә. Соңгы ике ел эчендә генә дә бу фондтан язучыларга 3 миллион 714 мең сум акча бүлеп бирелде. Идарә карары нигезендә, ул 144 әдипкә тапшырылды.

Шуның өстенә, безнең әдәбиятта Рәшит Ахунов дигән бер игелекле җан бар. Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов һәм әдибәбез Гөлшаһидә апа улы. Шушы соңгы өч ел эчендә татар әдәбияты өчен үз кесәсеннән 5 миллионга якын акча кертте Рәшит Ахунов. Аның 3 млн. 223 мең 810 таңкәсе 130 язучыга матди ярдәм буларак бүленде. Калганы исә Татарстан язучыларының Гаяз Исхакый исемендәге олы бүләге лауреатларына тәгаенләнде.

Җимерек харәбәләр урынында кафе бинасы торгыздык. Җырларда җырланган «Сарман» атлы бу кафе, «Петровский» агрофирмасы генераль директоры Сәлимҗан Әхмәтханов кебек игелекле кеше ярдәм кулын сузмаса, шулай ук эшләп китә алмаган булыр иде. Әлеге агрофирманың язучыларга ярдәме шулай ук 4 млн. чамасына тартты инде.

Язучылар берлегенә теге яки бу формада ярдәм итеп килгән «Итил» фирмасына (җитәкчесе Эдуард Минһаҗев) һәм 124 номерлы ПМКга (җитәкчесе Галимҗан Золотдинов) шулай ук рәхмәт белдерүне үземә бурыч дип саныйм. Башкача булмый, җәмәгать, базар мөнәсәбәтләре безне дә янача яшәргә, эшләргә мәҗбүр итә. «Заманалар авыр, еллар ябык, дус-иш кирәк гомер итәргә...» дигән сүзләр нәкъ менә бүгенгедәй шартларга туры килә булса кирәк. Ышандыра алам: татар әдәбиятының кадерен белгән олы җанлы җитәкчеләр һәм эшмәкәрләр җитәрлек, киләчәктә исә алар тагы да зуррак ярдәм күрсәтергә сәләтле.

Мөмкин кадәр тыныч, ипле рухта язарга омтылган докладым ахырында, шулай да, җанны рәнҗеткән бер мәсьәлә хакында әйтми булдыра алмыйм. Ул да булса — әдәп, әхлак мәсьәләсе. Әдәбиятны әдәп сүзеннән чыккан, дибез. Әдип сүзе дә шул ук тамырдан. Ә чынлыкта күпләребез моны онытта төште соңгы араларда.

Әйтик, Миргазиян Юнысның Язучылар берлеген — Сталин чорының эзәрлекләү аппаратларына тиңләве әхлаксызлык түгелмени? Фәнзаман Батталның Бөек җиңүнең 50 еллыгы якынлашкан көннәрдә фронтовикларга «Сез кемне яклап сугыштыгыз...» дигән мөрәҗәгате әдәплелекме? Мөсәгыйть Хәбибуллинның Татарстан һәм төрки халыклар хакына үз-үзен корбан иткән Солтангалиевне һичнинди документларга нигезләнмәгән җинаятьләрдә гаепләвен ничек бәяләргә?!

Мин инде Язучылар берлеге рәисе бакчасына ыргытылган ташларны байтак татыдым. Парламентка төбәп атылган снарядларың бер читтә торсын, ничек кенә итеп кешенең җанын, бәгырен рәнҗетим икән, ди-ди изаланалар. Чал чәчле агайлар бит үзегез, каян килә ул шулкадәрле вак җанлылык? Җәвад агай, Мөсәгыйть әфәнде, Миргазиян иптәш, каләмдәшләрегезне һәм укучыны хөрмәт итмәсәгез, үзегезне булса да хөрмәт итәр идегез, бәлки... Язучыларны гомер буе ихтирам итеп яшәгән укучыга сез газета-журнал сәхифәләренә чәчкән ваклыкларның берсе дә кирәк түгел бит. Шул исәптән, «Татарстан яшьләре», «Мирас» һәм «Казан утлары»н укучылар өчен дә.

Татарстанның халык язучылары Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиевләрне дә урынсызга рәнҗетүләр чамадан ашты... Ил агасы булган Нурихан Фәттахның халык каршысына чыгып иң элек Ренат Харисны, аннан Батулланы җәберләргә керешүе дә әдәбият файдасына түгел. «Иман» газетасының Роберт Миңнуллинны рәнҗетүе кемгә кирәк булган?! Эх, егетләр, дип дәшәсе килгән чаклар була, имансызлар «Иман» газетасы чыгарсын инде, ә?! Язучыларга гынамы соң, Президент өстенә, Югары Совет рәисенә, Министрлар Кабинеты рәисенә дә байтак чәчтеләр ул пычракны... Чама хисе югалды. Кеше хокуклары турында сөйләргә ярата идек югыйсә... Матбугат ирегең, плюрализмны дөрес аңламадылар кебек бездә, ул — һәр информация һәм факт өчен авторның юридик җаваплылыгы булырга тиешле дигән сүз. Хокук саклау органнарына мөрәҗәгать итәргә дә уңайсыз, ни дисәң дә каләмдәшләр ич... Матбугат министры киләчәктә бу күренешкә болай ук битараф булмас дип ышанасы килә. Үзебезгә дә, агай-энеләр, чама хисен югалтмау урынлы булыр иде. Бу дөнья... ничек тә түзәр, ахирәттә җавап тоту дигән төшенчә дә бар бит әле...

Хөрмәтле корылтай делегатлары, кунаклар!.. Үтә җаваплы һәм катлаулы дәвердә яшәргә насыйп булды безгә. Әмма, бер үк вакытта, кызыклы һәм иҗатчы өчен үтә гыйбрәтле замана бу. Татарстаныбызның милли дәүләтчелеге торгызылган, татар халкы яңадан уянган, өмет һәм хыялларга канат иңгән еллар... Җаваплы һәм тотрыксыз көннәр... Болар һәммәсе ил, халык язмышы өчен үтә җаваплы булган һәр язучы, шагыйрь, драматург алдына өстәмә бурычлар да куя. Халкыбыз тормышының иминлеге, аның рухи бөтенлеге, әхлакый сәламәтлеге өчен без — язучылар җаваплы. Әлеге корылтайда шушы олы миссияне тирәнтен тоеп, вак-төяк үпкәләрне онытып торып, әдәбиятыбыз каршында килеп туган катлаулы мәсьәләләр турында ихлас сөйләшүгә чакырам һәммәгезне.



# Газинур Морат

## ШИГЪРИЯТ — СӘЯСӘТ ТҮГЕЛ

Бу дөньяда рэкетерлар мыжгып торган талчуклар, колхоз базарлары гына түгел, шигырь базарлары да бар. Аларда елның бишенче фасылы нигъмәтләре белән сәүдә итәләр. Җыелган барлык керем исә Вакыт дигән комсыз рэкетерның исәп-хисап чутына күчә бара. Ә инде сатылмыйча калган сыйфатсыз, үтмәс товар иртәме-соңмы тарихның чүплек савытына ташлана... Бу җәһәттән ике корылтай арасы татар шигърияте өчен гаять уңдырышлы дәвер булды. Беренчедән, соңгы елларда шигъри продукциянең күләме бик нык артты. Әйтик, әвәлрәк «Казан утлары» татар язучыларының, шагыйрьләренең күз текәп торган бердәнбер әдәби журналы булып, анда әсәр бастыру гаять катлаулы һәм мәртәбәле эш саналса, хәзер аның белән тиңләшергә дәгъва иткән башка мәҗмугалар да барлыкка килде: «Идел», «Аргамак», «Мирас»... һәм алар һәркайсы, шөкер, моңарчы шигъриятькә хәерхаһ булдылар, кайбер гәжит мөхәррирләре кебек, шигырьгә үтмәс товар итеп карамадылар.

Икенчедән, шигъриятебездә байтак кына яңа исемнәр пәйда булды. Һәм моны да беренче чиратта татарча басмаларның арта төшүе белән аңлатырга кирәктер. Бу юнәлештә аеруча «Идел» журналы уңышлы эшләде. Журнал нәшер ителә башлаганнан бирле аның сәхифәләрендә дистәләгән яшь шагыйрьнең шигырьләре дөнья күрде.

Өченчедән, татар шигъриятенә моңарчы тарихта күрелмәгән сүз иреге бирелде. Ихтимал, мондый ук хөрлекне Тукай да күрсә шул төшендә генә күргәндер. Шуңа күрә ике корылтай арасы шагыйрьләрнең кыюлыкта алышу дәвере дә булды: Сүз ирегенә бәйле рәвештә шигърияттә публицистик накал бермә-бер көчәеп китте. Татар шигыре мәйданнарга чыгып, дистәләрчә мең халык җыйналган митингларда яңгырады, депутат шагыйрь, язучыларыбыз йөзендә хәтта парламент мөнбәрләренә дә күтәрелде. Әйе, безнең азатлык, бәйсезлек турында кыеп әйткән һәр сүзебез асылда Шигъри Сүз ул. Бүген безнең өчен хөр, ирекле булудан да югарырак поэзия юк. Икенче төрле әйткәндә, шигърият һәм азатлык — синоним төшенчәләр. Аны халыклар төрмәсе тоткыннары Тукай белән Дәрдемәнд тә, Моабит һәм Гулаг мәхбүсләре Җәлил белән Туфан да шулай аңлаганнар. Һәм шигырьгә иман китергән бүгенге көн татар шагыйрьләре дә шигъриятебезнең төп, асыл миссиясен бөек элгәрләре аңлаганча аңлыйлардыр дип беләм.

Мәңге алданган халыкта  
Икеләнү бар тагын:  
Куймас микән авызын ачкан  
Бүрәнәгә бармагын?! —

дип яза Рәшит Әхмәтҗан үзенең 1993 елда басылып чыккан «Ачлык мәйданы» дигән китабында. Әйе, шагыйрьнең шөбһәләнүе юкка булмаган икән: бүген без

тагын бүрәнә ярыгына бармагын кыстырган Шүрәле хәлендәрәк калдык бугай. Суверенитет дигән бөек омтылыш һәммәбезнең күз алдында отыры «сувенирит-тет» атлы тәти уенчыкка әверелеп бара. Югары даирәләр үзара ниндидер шикле килешүләр төзиләр, бәгъзе каләм әһелләре шул килешүләрне мактый-мактый матбугатта чыгышлар ясыйлар, икенче беришләре җилнең кайсы яктан искәнен чамалап алалар да, кичә генә язган әсәрләренә капма-каршы килеп, чәчләрне үрә торгызырлык кыю шигырьләр язалар. Инде мин торгынлык дип аталган дәвердә каләмдәшләренә милләтче ярлыгы тагып, обком, КГБларга шикаять язган һәм бүген милләтпәрвәр булып йөргән кайбер әһле каләм иляре турында әйтеп тә тормыйм. Аларны Вакыт үзе хөкем итәр. Кайбер рәсми мәгълүматларга караганда, элеккеге СССРда балигъ булган һәр ун кешегә бер жасус-осведомитель туры килгән. Шагыйрь, язучы жасуслыкка бара аламы? Юк, билгеле. Һәрхәлдә, мин ул исемлектә үз замандашларымның исемнәре булуын теләмәс идем.

Мине, шәхсән, беренче чиратта каләм иясенең ни-нәрсә язганы түгел, ә бәлки аның шәхесе кызыксындыра. Чөнки һәртөрле иҗат та шәхестән башлана. Вөҗүдендә ике-өч «мин» асраган кешенең яхшы шагыйрь булуына ышаныч аз. Бу җәһәттән XVIII гасырда яшәгән инглиз язучысы һәм дәүләт эшлеклесе лорд Филипп Честерфильдның гыйбрәтле сүзләрен искә төшереп үтәсе килә: «Уртача сәләткә ия булган теләсә кем бик тырышып, үҗәтләнеп эшләсә,— дип яза ул,— ни теләсә шуңа ирешә ала. Бу юнәлештә яшь кеше хәленнән килмәслек бары бер генә нәрсә бар, ул — яхшы шагыйрь булу».

Шөкер, бездә яхшы шагыйрьләр аз түгел. Шигъри сүзнең төмен белеп, җегәрен тоеп, шигырь тукымасына сабыр гына сүз-авазлардан җанга иш булырдай сурәтләр чигүче чын осталар алар. Дөрес, андыйларга бүген көн итүе шактый кыенлашты. Метрополиянең үз биләмәләрен саклап калу һәм кабалада тоту өчен уйлап чыгарган икътисади терроры әдәбиятны, шул җөмләдән шигъриятне дә тәмам күтәрәм хәленә калдырды. Ләкин бу әле һич тә җәмгыятьтә шигъриятнең абруе төшү дигән сүз түгел. Киресенчә, бүген безгә Кеше абруеның, намус, әхлак абруеның отыры төшә, гаип була баруын күзәтергә туры килә. Ә поэзия исә намус, әхлак кебек үк, беркайчан да үсеш-үзгәреш кичерми торган статик категория. Ул — барометр кебек. Җәмгыятьнең икътисади, сәяси, әхлакый саулыгы беренче чиратта аның шигъриятка, шагыйрьләргә булган мөнәсәбәте белән билгеләнә. Шагыйрьләрен эт типкесендә йөрткән җәмгыять үзе дә эт көнендә яшәргә мәҗбүр. Бу җәһәттән Советлар Союзы турында китап язар өчен моннан өч ел элгәре СССРга килеп киткән инглиз язучысы Сюзан Ричардзның күзәтүләре дә гаять гыйбрәтле: «Миңа калса, сездә булдыклы, талантлы, бәйсез рухлы кешеләргә тормыш итүе аерата авыр һәм газаплы,— ди ул.— Дөрес, мин китаплардан укып сездәге тормышны азмы-күпме өйрәнгән идем, ләкин чынбарлыкта хәлләр тагын да катлаулырак булып чыкты. Сездә талантлар гына түгел, ә бәлки барлык намуслы кешеләр дә туктаусыз көрәшеп яшәргә мәҗбүр. Тук, рәхәт, житеш яшәр өчен сездә гавәмнән бигүк аерылып тормаска кирәк».

Сүз дә юк, чын талантлар яңа шартларга, яңача яшәү рәвешенә бик зур авырлык белән җайлашалар, яки бөтенләй җайлаша алмыйлар. Конъюнктурага, гадәттә, фикер йөртү рәвеше белән «гавәмнән бигүк аерылып тормаган»нар тизрәк җайлаша. Кичә генә коммунистик системага мәдхия җырлап, бүген шуны сүгеп шигырь-мигырь язган шагыйрьне мин аңлый алмыйм. Әйтик, миңа милли сәясәттә ленинчыл принциплар бозыла дип оран салып, шуңа һаман да ышанып яшәүче Салих ага Баттал якынрак та, аңлаешлырак та.

Ләкин, дөрес аңлашыла күрсен, сәяси системаның, эстетик кыйммәтләрнең үзгәрүе каләм әһелләренең иҗатына да мәгълүм дәрәҗәдә йогынты ясамый кала алмый. Әйтергә кирәк, бу шигъриятта аеруча ачык чагыла. Шигърият үзенең табигате белән конъюнктурага чагыштырмача тизрәк җайлаша торган жанр. Теләсә нинди системада да уңга-сулга карамыйча хак сүзне әйтә килгән шагыйрьләр дә эстетик кыйммәтләр үзгәрү белән үз иҗатларына башкачарак күзлектән карарга, еш кына шигъри мәсләкләренә кайбер төзәтмәләр кертергә дә мәҗбүр була. Әйтик, соңгы елларда шигъриятта сүз ирегенең көчле йогынтысын кичермәгән бер генә татар шагыйре дә калмагандыр. Элек-электән кыю сүзле булулары белән аерылып торган Гамил Афзал, Мөдәррис Әгъләм кебек шагыйрьләр дә кичерделәр аны. Озак еллар житәкче урыннарда эшләп, алдын-артын уйлап кына язарга күнеккән Ренат Харис та үткән ел «Казан утлары»нда эротик поэмасын бастырып, шигъриятебезнең офыкларын киңәйтеп җибәрде. Заманында кызыл шигырьләрне шактый гына калыплаган Әхмәт Рәшит тә, «Колшәриф» поэмасын язып, үз иҗатында зур сикереш ясады. Берара, шаукымга ияреп дигәндәй, публицистик шигырьләр белән мавыгып алган Рәдиф Гаташ та кабат үз стихи-

ясенә кайтып төште һәм интим лириканың гүзәл үрнәкләрен бирде. Ә менә Харрас Әюп, Лена Шагыйрьҗан, Флера Гыйззәтуллина кебек шагыйрьләрнең, спортчылар теле белән әйтсәк, «икенче» сулышлары ачылып китте, алар тизлекләрен отыры арттыра баралар. Шулай да соңгы елларда нәшер ителгән һәм поэзиябездә үзләренә лаеклы урын алырдай берничә мәҗмуганы атап китәргә җөрьәт итәм. Сүз Рәшит Әхмәтҗанның «Ачлык мәйданы», Мөдәррис Әгъләмнең «Мин әйттем», Зөлфәтнең «Адашкан болыт», Марсель Галиевнең «Су буеннан әнкәй кайтып килә», Ркаил Зәйдулланың «Урыс кышын озату» дигән китаплары, Зиннур Мансуровның «Хозыр галәйһес-сәламне эзләү» поэмасы турында бара. Шул ук Мөдәррис Әгъләм иҗатының Тукай бүләгенә лаек булуы да чын талантлы шагыйрьнең шигъри һәм гражданлык батырлыгын тану белән бергә гомум шигъриятебезгә бирелгән югары бәя итеп тә кабул кылынды.

Ике җыен арасында татар шигъриятендә тагын бер мөһим вакыйга булды: озын-озак тоткарлыклардан соң, ниһаять, «Татар поэзиясе антологиясе»нең ике томлыгы нәшер ителде. Соң булса да, уң булсын, дигәндәй, әлеге мәҗмугаларны әзерләп дөньяга чыгарган мөхәррирләргә, Татарстан китап нәшриятына рәхмәт әйтәсе генә кала. Дөрес, совет чоры шагыйрьләренең иҗат үрнәкләрен эченә алган икенче томны әзерләгәндә мөхәррирләр беркадәр ашыгычлык та күрсәткәннәр. Әйтик, анда кайбер шагыйрьләрнең заманында классик саналып та, бүген үзенең эстетик кыйммәтен югалткан шигырьләре дә урын алган. Аннары кайсы шагыйрьнең ничәнче елда КПСС әгъзасы булуы турында мәгълүмат бирү дә беркадәр мәзәгрәк килеп чыккан. Яхшы шагыйрь булу өчен кесәдә партия билеты йөртү алай ук мөһим түгелдер ләбаса.

Алда әйткәнемчә, гәзит-журналларның ишәюе нәтиҗәсендә соңгы елларда шигъриятебездә күп кенә яңа исемнәр пәйда булды. Һәм иң сөендергәне шул: алар арасында югары профессиональ әзерлекле, шигъри сүзнең тәмен яхшы тоеп, белеп язучы яшьләр дә бар. Миңа калса, Габделнур Сәлим, Рөстәм Сүлти, Илсөяр Иксанова, Рифә Рахман, Фәйрүзә Исмәгыйлова әнә шундыйлардан. Гәрчә мин Габделнурны яшь шагыйрьләр рәтенә кертмәс идем. Ул инде күптән житлеккән; һәм, әйтергә кирәк, үзенең шигъри фикер йөртү рәвеше, талант куәсе белән бүгенге татар поэзиясендә лаеклы урын алырдай шагыйрь. Моңа ышану өчен аның «Аргамак» журналының 1993 елгы 10 санында басылган «Карлыгач балчыгы» дигән күләмле шигырьләр шәлкемен укып карау да җитә торгандыр дип беләм. Кыскасы, татар шигъриятендә берәүгә дә охшамаган, берәүне дә кабатламаган, хәтта әйтер идем, уникаль шигъри фикер йөртү сәләтенә ия булган Габделнур Сәлим дигән талантлы шагыйрь бар. Ләкин, ни кызганыч, аның бүгенгә кадәр бер генә китабы да дөнья күрмәде әле. Ә шагыйрьгә китабын чыгарырга бик тә кирәк иде. Ул чагында аның иҗаты бәлки әдәби җәмәгатьчелектә дә, шигърият сөючеләр арасында да киңрәк яңгыраш табар иде.

Әмма бүген шигырь китабын нәшер итү шигырьнең үзен язуга караганда күпкә кыенлашты. Күп чыгымнар сорый торган, файдасыз, хәтта ки кирәксез бер шөгыльгә әйләнде. Дөресен әйтергә кирәк, коммунистлар эш башында торганда шигъриятнең абруе күпкә зуррак иде. Баш очында цензура балтасы асылынып торганда, шигырьләрнең сәнгатьчә эшләнеше дә югарырак иде шикелле. Һәрхәлдә, ул чагында шагыйрь чыпчык томшыгы кадәр фикерен дә бик нык читләтеп, чәчәкле-чуклы образларга төреп кенә әйтергә мәҗбүр иде. Бу җәһәттән «Цензурага мәдхия» дигән шигырь язган Марсель Галиев белән килешмичә булмый. Шушы ук фикерне халкыбызның олуг шагыйре Гамил Афзал да куәтли:

> Эзоп теле белән сөйләшкәндә
> Мәгънәлерәк иде сүзебез,
> Әдәплерәк иде ходавәндә,
> Акыллырак идек үзебез,—

дип яза ул үзенең бер шигырендә. Ләкин бу әле һич тә цензураны кабат торгызырга кирәк дигән сүз түгел. Чын шигърият сагында торучы цензор шагыйрьнең үз башында утырырга тиеш. Әдәбиятка дәүләт контроле кирәкми — ул заманнарга берүк яңадан әйләнеп кайтырга язмасын. Шигърият — сәясәт түгел, ул иманлы затларны гына таный һәм икърар итә.



# Фәиз Зөлкарнәй

## ФИДАИЛӘР ЭШЕ

Татарстан Язучылар берлегендә тәнкыйтьче буларак кабул ителгән 30 дан артык каләм әһеле исәптә тора. Бары әдәби тәнкыйть жанрында гына эшли торганнары, саф тәнкыйтьчеләр генә аз. Күбесе, тәнкыйтьче булып башкаларга акыл өйрәтә-өйрәтә кыюланып, башка жанрларга күчә баралар. Мисалы күз алдыгызда: берлек рәисе Ринат Мөхәммәдиев, университет профессоры Тәлгат Галиуллин, «Казан утлары»ның төп тәнкыйтьчесе Мансур Вәлиев һәм хәтта кичә генә язучы билетын алган Галимҗан Гыйльмановның да прозага күчеп яткан көннәре.

Әмма бездә прозаиклар, шагыйрьләр үзләре менә дигән тәнкыйть яза. Һәм шулай булырга тиеш тә! Шушы җәһәттән немец акыл иясе, тәнкыйтьче Фридрих Шлегельнең бер фикере хәтергә килә. «Шигъриятне фәкать шигърият кенә тәнкыйтьли ала. Сәнгать турында әйтелгән хөкемнең, әгәр ул сәнгатьчә әйтелмәсә, сәнгать патшалыгында яшәргә хакы юк»,— ди ул. Ягъни андый тәнкыйть әдәбият булмый, бары тик мәкалә генә була ул. Шуңа күрә дә мин Матур әдәбият турында матур итеп яза белгән тәнкыйтьчеләргә «хөрмәт вә мәртәбә» дим. Әхмәт Рәшитов, Зиннур Мансуров кебек шагыйрьләрнең, Гариф Ахунов кебек прозаикларыбызның тәнкыйтьтә дә җиң сызганып эшләвен хуплыйм. Тәнкыйтьче эше ул, ни генә димик, барыбер дә әдәбиятның «кара эше», ул «неблагодарный труд». Ул фидакярләр эше. Минем әле бер генә язучының да үз әсәрләренә төпле тәнкыйть язган өчен рәхмәт әйткәнен ишеткәнем юк. Каһәр ишеткән бар анысы. Шуңа күрә дә мондый «кара эш»не уртага салып, бергәләшеп эшләү мәгькул.

Узган биш елда әдәби тәнкыйть, әдәбият тарихына караган 20 ләп китап басылган. Шуларның 10 сын һич курыкмыйча чын әдәби тәнкыйть китаплары дип була. Менә аларның исемнәре:

Мансур Вәлиев. «Каһарманнар кирәк» (1990 ел) һәм «Гасыр ахырында» (1994);
Фарваз Миңнуллин. «Затлылык» (1989);
Тәлгат Галиуллин. «Гомер учагы» (1991);
Зиннур Мансуров. «Юлың белгән арымас» (1989);
Әхмәт Рәшитов. «Иман яңарканда» (1991);
Без фәкыйрегезнең «Чакма чакмый ут чыкмый» дигән китабы (1991);
Азат Әхмәдуллин. «Дөреслеккә ирешү юлында» (1993);
Галимҗан Гыйльман. «Заман сүз сорый» (1991);
Әхмәт Сәхапов. «Алтын тамырлар» (1990).

Катгый әдәби тәнкыйть сүзе, никадәр генә кадерсезлектә йөрмәсен, барыбер кирәк товар булып кала бирә. Шуңа күрә дә мин әлеге тәнкыйтьчеләрне тәкъдир итү йөзеннән, исемнәрен аерым-аерым атап үтү кирәк дип саныйм.

Китап китап инде ул, тәнкыйтьче әдип иҗатын тиешле зурлыкта күрсәтү җәһәтеннән аңа тиңнәр юк, әмма әдәби хәрәкәт ноктаи нәзарыннан караганда,

көндәлек матбугат битләрендә дөнья күргән тәнкыйть әдәбиятка кирәклерәк. Китап, иң аз дигәндә дә 3-4 ел элегрәк булып узган әдәби вакыйгаларны тасвирлый. Ә көндәлек матбугаттагы тәнкыйть аларның шушы көндә булганнары турында сөйли, шуларга бәя бирә. Аның тәэсир көче зуррак. Менә шушы агымдагы тәнкыйтькә килгәндә, мин хәлләр бик үк шәптән димәс идем.

Татар әдәби тәнкыйте электән дә инде, турысын әйтик, әллә ни куәт иясеннән булмады. Ул, вакыты белән, ачлык елда күтәрмәгә калган арык атны хәтерләтә иде хәтта. Хәзерге дуамал замана аның өрлеккә бәйләп куйган арканнарын кисеп төшерүгә, ул идәнгә ишелеп төште. Әдәби тәнкыйтьне үлеп ята дисәк тә була.

Дөрес, аңа җан өрергә тырышучылар юк түгел. Анда-санда Ф. Галимуллин, Г. Ахунов, М. Вәлиев, Р. Игъламов, Р. Мостафиннарның исемнәре күренгәләп ала. Фәрит Хатипов активлашып китте. Ләкин барыбер дә агымдагы тәнкыйть әдәби барышны тоташы белән чагылдыра алмады. Бигрәк тә соңгы 2 елда бу шулай булды. Әдәбиятта, әдәбият тирәсендә вакыт-вакыт кузгалып ала торган кампанияләр нәтиҗәсендә генә пәйда булалар кебек тәнкыйть мәкаләләре. Кемгәдер премия бирү кампаниясе, кемгәдер дәрәҗәле исем бирү кампаниясе... Үгез кадәрле булырга азапланган бака көчәнүен генә хәтерләтә болар. Иртәме-соңмы барыбер шартлаячак ич.

Калын бер элпә, шифалы агынты сыман булырга тиешле әдәби тәнкыйть бу елларда анда-санда очраган нефть таплары шикелле генә күзгә ташланды, дияр идем мин. Эзлекле, ныкышмалы, киң колач белән иңләп бара торган әдәби тәнкыйть агымы юк хәзер. Рецензия жанры «Казан утлары» тырышлыгы аркасында гына юкка чыгып бетми әле. Әдәбиятны күзәтүләр, иҗат портретлары, проблемалы мәкаләләр аз, бик аз. Әдәби тәнкыйтьнең калган егермеләп жанры турында әйтеп тә тормыйм инде — юк алар. «Казан утлары» күпмедер дәрәҗәдә оештыру эшләрен алып бара, һәм дә «Идел» журналы белән «Ватаным Татарстан»ның «Әллүки» сәхифәсе вакыт-вакыт нидер эшләгән сыман итәләр.

Турысын әйтик, әдәби тәнкыйть — бүгенге көндә фидаиләр эше, Газинур Гафиятуллин кебек амбразура капларга сәләтле каләм ияләре генә тәнкыйть яза хәзер.

Берничә каләм әһеле әдәби тәнкыйтьче сыйфатында Язучылар берлегенә әгъзалыкка тәкъдим ителгән иде. Шушы чыгышны әзерләгән вакытта барлап караган идем, тәкъдим ителгәннәр арасыннан бары тик Назыйм Ханзафаровның гына ни өчендер әле һаман кабул ителмәгән булын күрдем. Соңгы биш елда кабул ителгән 75 язучыны күздән кичереп чыктым, чагыштырып карадым да бу миңа бик сәер тоелды. Бу бит — әдәбият тарихы томнарын язуда актив катнашкан алдынгы карашлы галим, драматургия тәнкыйтьчесе буларак, күптән өлгереп җиткән каләм иясе, әдәбиятыбызның, җәмгыятебезнең бүгенге хәлен мәдәният тарихы, рухи мирас белән тыгыз бәйләп, ел саен саллы-саллы мәкалә биреп килүче милләтпәрвәр зат. Һәм дә, ахыр килеп, республикабыз гербы итеп өтек әтәч-зилантны түгел, ә канатлы барсның сайлануында төп сәбәпче булган, гербның тарихи-нәзари нигезләмәсен эшләгән көрәшче шәхес.

Киләчәктә секцияләрнең статусы нинди булыр, белмим, әмма алар тагын шушы кәмит хәлдә калмасын өчен, минем бер тәкъдимем бар. Язучылар берлегенең журналлары редакцияләренә дә Берлеккә яңа әгъзалар тәкъдим итү хокукын бирергә кирәк. Чөнки кемнең ничек язуын, кемнең иҗатчы буларак ничек өлгереп җитүен редакцияләрдән дә яхшырак белүче юк. Авторлар белән редакцияләр эшли, алар белә. Алар яшь талантларны эзләп таба. Алар үстерә. Алар ук тәкъдим дә итсен. Бу бигрәк тә хәзер, китаплар бастыру мөмкинлеге кысылган, журналда басылып чыгуның әһәмияте арткан чакта аерата актуаль. Әйтик, «Идел» журналы янында абруйлы, таләпчән әдипләрдән экспертлар (остазлар) төркеме оештырыла. Бу төркем Идарәдә раслана, һәм шушы экспертлар хуплавына лаек булган яшь каләм ияләрен редакция Язучылар берлегенә тәкъдим итә. Бу эшләре өчен ул остаз әдипләргә күпмедер дәрәҗәдә түләү мәсьәләсен дә хәл итү кыен булмас иде.

Мәсьәләне болай кую, минемчә, берничә төрле файда бирәчәк. Беренчесе. Теләсә кемне сикерә-сикерә мактарга, әллә нинди Союзларга тәкъдим итәргә әзер торучыларга юл ябылачак. Икенчесе. «Идел», «Казан утлары» журналларының яшь каләм ияләрен өйрәтүдә мөһим эш башкаруын тану булыр бу, монарчы башкарып килгән шушы «кара» эшләренең кыйммәтен рәсми тану булачак. Өченчесе. Талантлы, каләме булган редакция хезмәткәрләрен «литературный негр» категориясеннән «остаз» дәрәҗәсенә күтәрәчәк бу. Иң мөһиме: редакцияләрнең абруен күтәрәчәк.



# Роберт Миңнуллин

## БАЛАЛАР ДӨНЬЯСЫ

Кадерле каләмдәшләр! Сүземне күренекле балалар язучысы Ләбибә Ихсанованың узган елны миңа язган бер хатыннан башлыйсым килә.

**«Роберт!»**

**«Шәһри Казан»да минем хакта язган мәкаләңне укыгач та рәхмәтемне әйтим дип, редакциягә кергән идем. Сине ялда диделәр. Шундый да җылы итеп, күкләргә күтәреп язган мәкаләңнән соң телефоннан гына шалтыратып, рәхмәтемнең зурлыгын киметәсем килмәде. Чөнки мин андый сүзләрне җитмеш яшькә җитеп, кырык еллап әдәбиятта эшләп, беренче тапкыр ишетәм бит. Син мине бик бәхетле иттең, чөнки безнең бик күп каләмдәшләребез үзләренә тиешле бәяне ишетмичә дә дөнья куйдылар. Шунысы кызык, синең һәм Гөлшатның (Зәйнашева) мәкаләләре турында Казаннан һәм Уфадан шактый хуплау сүзләре ишеттем, ләкин ник шуда бер татар язучысының (Шәүкәт белән Илдардан башка) игътибары булсын. Хәер, безнең халык шундыйрак бит инде ул. Тормышта үзенә кирәге булмаган каләмдәшенең язганнарын гади бер кызыксыну белән генә дә укып мәшәкатьләнми.**

**Ярый әле ул яктан безнең балалар язучылары бер башка өстен торалар... Алар кешелекле, игътибарлы, киң күңелле. Нәкъ шундый язучылар гына балалар өчен иҗат итәргә хаклы да шул. Монысы синең фикереңә һәм мин аңа бөтен йөрәгем белән кушылам. Кара син, нинди алтын кешеләр бит алар! А. Алиш, Г. Гобәй, Б. Рәхмәт, Ә. Бикчәнтәева, Ш. Галиев, Х. Халиков, гомерендә бер җылы сүз ишетми арабыздан киткән Абдулла Әхмәт, артык күп язмасалар да менә дигән хикәяләр остасы булган Ф. Шәфигуллин һәм Г. Сабитов, татар балалар әдәбиятына карашы матур булмаган, әмма үзе әйбәт кенә балалар шигырьләре язган Җ. Тәрҗеманов, Бөек Ватан сугышы батырлыгын данлаган Ш. Рәкыйпов һәм, шуларның барысы өстенә, аякка басып килә торган талантлы яшь авторларыбыз да бар бит әле. Шул хәтле осталар белән кайсы милләтнең әдәбияты мактана ала соң?**

**Бик кызганыч, жанр ягыннан да, сан һәм сыйфат ягыннан да, гомеренең озынлыгы ягыннан да зур булган бу әдәбиятның үз урынын алганы юк әле.**

**Нәшриятта безнең китапларыбыз зурлардан кәгазь калса гына чыга кебек. Җыелышта сөйләгән сүзләребез, матбугаттагы чыгышларыбыз өлкәннәр өчен язучыларның колагына керми, йөрәгенә барып җитми. Сүземне раслау өчен бер генә мисал китерми түзә алмыйм. Август аенда Президент белән очрашу вакытында мин дә сүз алып, балалар әдәбияты проблемалары, китап чыгару кыенлыклары турында сөйли башлаган идем, очрашуга килгән бер язучы «ардырмыйк инде», дип реплика бирмәсенме. Югыйсә, күбесе, татар теле бетәме, каламы, дигән глобаль мәсьәләләрне чәйнәп вакытны алганда, ярады бу кешегә. Үзе дә беренче булып сүз чиратын үткәргән иде шул.**

**Менә шундый усал кешеләр янында кыю гына түгел, усал да була белергә кирәк безгә, Роберт энем. Әлегә без татар әдәбиятының ишек төбендә йомышка**

**кергән бала кебек торабыз. Инсафлы булу гына житми хәзерге заманда, үзеңне күрсәтә белү дә бик кирәк. Еламаган балага имчәк бирмиләр дигән сүз бар. Ләкин без еларга тиеш түгел, сүзебезне горур яңгыратыйк. Моңар безнең мораль хакыбыз бар.»**

Бу сүзләрне гомере буе балалар әдәбиятында эшләгән, гомерен балаларга багышлаган язучы яза. Бу — язучының йөрәк авазы. Бу сүзләр — ачы хакыйкать. Әгәр дә Ләбибә апа хаклы булмаса, Ләбибә Ихсанованың 70 яшьлек олы юбилее кечкенә итеп булса да билгеләп үтелер иде. Юбилеена аның кечкенә булса да бер китабы чыгар иде. Томнары турында әйтеп тә тормыйм. Ә бит ул гади бер язучы гына түгел. Ләбибә апа бит ул! Ләбибә Ихсанова! Татар балалар әдәбиятының күренекле вәкиле. Әгәр дә Ләбибә апа хаклы булмаса, Тукай һәм Андерсен бүләкләре лауреаты, татар балалар шигъриятенең аксакалы, 65 яшьлек Шәүкәт Галиевнең һич югында «Татарстанның атказанган культура работнигы» дигән исеме булыр иде. Әгәр дә Ләбибә апа хаклы булмаса, 32 тәнкыйтьчебезнең ичмасам берсе булса да балалар әдәбияты турында, аның проблемалары турында хет бер мәкалә яисә монография язган булырлар иде. Әгәр дә Ләбибә апа хаклы булмаса, күпме талантлы яшьләребез балалар өчен 1—2 китап чыгару белән, якты чырай күрмәгәч, өлкәннәр өчен урта кул булса да әсәрләр язарга тотынмаслар иде. Шуңа күрә дә фәкать балалар өчен генә язучылар, балалар әдәбияты белән генә көн күрүчеләр союзның рәсми басмаларыннан күренгәнчә, бармак белән генә санарлык. Әйтик, 1974 елда 11 балалар язучысы булган, 79 елда да — 1, 84 елда — 6, бүгенге көндә җәмгысе — 7 бөртек балалар язучысы. Югыйсә, без ике съезд арасында гына да уннан артык яшь балалар язучыларын союзга кабул иткән идек. Кая булып бетәләрдер, шайтан белсен.

Фәкать балалар өчен генә язучы әдип бездә мохтаҗлыкка, акчасызлыкка, мескенлеккә дучар ителгән кеше. Балалар өчен язып тамак туйдырып булмады һәм булмый. Безнең мөхтәрәм язучы-шагыйрьләребез Ә. Бикчәнтәева, З. Туфайлова, Б. Рәхмәт, Г. Хәсәнов, Г. Галиев, Абдулла Әхмәт бу фани дөньядан шундый мохтаҗлыкта китеп бардылар.

Соң үзегез уйлап карагыз, ике-өч елга бер китапчык. Төсле рәсемлесе эләксә — 10—15 шигырь дигән сүз. Төссез, рәсемсезенә риза булсаң — 25—30 шигырьлек зур китап. Гонорары — машинисткага бирергә дә җитми. Аның каравы — китап! Анда да балалар шагыйре 10 шигырьлек төсле китапны сайларга тырыша. Балаларга матур булсын дип. Ике-өч елдан тагын шул ук хәл. Язарга бернинди стимул юк. Хет кычкырып ела.

Х. Халиковның катыргы тышлы, зур, калын китабын күргәнегез бармы? Яисә Зәкия Туфайлованың? Яисә Рәшит Бәшәрнең шундый китабын? Яисә Р. Мингалимнең бергә тупланган балалар шигырьләрен? Юк алар. Һәм тиз генә булмаячак та.

Узган атнада гына миңа Уфада булырга туры килде. Аларның нәшрият эшләре белән танышканнан соң, мин аннан көнләшү һәм гарьләнү хисләре белән кайттым. Язучылар союзы белән китап нәшрияты кулга кул тотынып эшли. Чөнки нәшрият тулысынча диярлек язучыларга хезмәт итә. Башкортстан хөкүмәте, мәсәлән, аларның китап нәшриятына 2 млрд. сум дотация биргән. Шуңа күрә дә анда балалар китабын чыгару проблемасы юк. Шунысы кызык, анда балалар китапларлары бары тик төсле рәсемнәр белән генә чыга. Киләсе елга 50 дән артык балалар китабы планга кергән. Бу да бит балалар әдәбиятына мөнәсәбәт. Ләкин әйбәт мөнәсәбәт!

Минем бер генә үтенечем бар. Мин моны хөкүмәт җитәкчеләренә дә, үзебезнең союз җитәкчеләренә дә әйтәм. Безнең балалар язучылары да — кеше. Аларның да башкалар кебек яхшы шартларда яшиселәре килә, башкалар шикелле китаплар чыгарасылары килә. Бу — табигый теләк.

Аннары шуны да онытмаска кирәк. Өлкәннәр өчен язучылар гафу итсеннәр, әмма балалар китабы, балалар өчен язылган әсәрләр сезнекеләргә караганда кимендә ун тапкыр күбрәк укыла. Хет әйбәт, хет начар булсын, хет матур, хет төссез булсын — барыбер укыла. Ни өчен дисәгез, кече яшьтәге балаларны рухи яктан тәрбияләү бездә, нигездә, әдәби әсәрләр аша алып барыла. Балалар бакчасында — шигырь, җыр, халык авыз иҗаты, әкият. Дәресләрдә — шигырь, хикәя, җыр. Бәйрәмнәрдә, кичәләрдә — җыр, шигырь, уеннар. Радио һәм ТВ тапшыруларында да — җыр, әкият, шигырь. Татарча мультфильмнар — юк. Радиоспектакльләр, телеспектакльләр — юк диярлек. Һәм тиз генә булмас та кебек. Шуңа күрә бердәнбер реаль таяныч — китап. Һәм, әлбәттә, балалар матбугаты: «Сабантуй», «Ялкын», «Салават күпере» һәм, ниһаять, «Сабыйга». Бөтен рухи

тәрбия балалар әдәбиятына нигезләнгән. Һәм балалар язучылары белән жанлы очрашуларга. Әле менә «Ике съезд арасында» дигән басманы карап чыктым. Әйтик, Ш. Галиевның исеме анда берничә урында гына күренеп кала. Әлеге китапка ышансаң, Ш. Галиев союз эшләрендә бөтенләй катнашмаган, өйдә генә утырган булып чыга. Ләкин мин моның алай түгел икәнен яхшы беләм. Ә безнең Шәүкәт абый төгәл кеше, барсын да теркәп бара. Шуңа үзеннән сорарга мәжбүр булдым. Очрашуларда ничә тапкыр булды икән? Белмәсәгез, белегез: ике съезд арасында ул мәктәпләрдә 100 тапкырдан да артыграк чыгыш ясаган, балалар белән очрашкан, дәресләр үткәргән, кичәләрдә булган. Бу миңа бик гаҗәп тоелды. Бушка бит әле. Рәхмәткә! Мин дә үземнекен чутлап чыгардым: 130 мәртәбә балалар белән очрашканмын. Белүемчә, башка балалар язучылары да очрашуларда еш була. Шушы мисал үзе генә дә балалар язучыларының яшь буынны тәрбияләүдә армый-талмый эшләүләре турында, балаларыбызны кайгыртып яшәүләре турында сөйли.

Әмма, ничек кенә булмасын, язучының хезмәтен аның китапларына карап бәялиләр. Шушы күзлектән чыгып караганда, ике съезд арасында төрле жанрдагы, төрле сыйфаттагы эреле-вaклы 100 ләп балалар китабы дөнья күргән. Тукай, Җәлил, Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи, Ш. Мөдәррис, китапларын да өстәсәң, йөздән дә артып китәр, мөгаен. Билгеле, бу аз түгел. Күп тә түгел. Аннары ул китаплар «чиста» балалар язучыларыныкы гына түгел, ә 300 ләп якын язучыларның барысыныкы да.

93 яшьлек Гомәр ага Бәширов соңгы елларда балаларыбыз өчен махсус ике китап бастырып чыгарды: «Бибек нигә елый» һәм «Кечтеки тел бистәләре». Беренчесе — искиткеч бер хикәя. Икенчесе — мәзәкләр. Икесе дә балалар әдәбиятын бизәп торырлык. Икесе дә — балаларыбызга олы бүләк. Рәхмәт сиңа, Гомәр ага!

Балалар әдәбиятын жанрларга бик үк бай димәс идем. Шул ук шигырь, әкият, хикәя, юмореска, повесть... Хәер, шактыйга җыела икән үзе. Әкиятчеләрдән мин Ф. Яруллинны, Батулланы, Җ. Тәрҗемановны, Р. Хафизованы аерып куяр идем. Әкият осталары алар. Соңгы вакытта бигрәк тә Ф. Яруллин актив эшләде. Аның кебек шигъри әкиятләрне Алиштан соң, белмим, тагын кем язды икән? Аның әкиятләре — рифмалы проза, ритмик проза. Аларны укуы рәхәт. «Зәңгәр күлдә ай коена» исемле әкиятләр китабы — шуның бер мисалы. Шигъри осталык дигәннән, мине Татарстанның халык артисты Хәлим Җәләлов шаккатырды. Һәм сөендерде. Аның «Сабантуй»га алып килгән «Корчаңгы тай һәм таз малай» әкиятен укып чыккач, исләрем-акылларым киткән иде. Халык әкиятенә нигезләнеп язылган ул әкиятнең теле, образлары, йөгереклеге! Укыганда әкиятнең артыннан житешеп булмый. Җырлап тора. Шигъри әкиятләрне күп укырга туры килде, ләкин мондый тел белән язылганы, мөгаен, Ф. Кәримдә генәдер.

Балалар прозасында миңа аеруча өч китап — Р. Бәширнең «Иртәгә дә яшисе бар», К. Кәримовның «Күләгәдә төлке бар» һәм Н. Акмалның «Килер бер көн» исемле китаплары ошады. Беренчедән, алар бик мөһим темага: тәрбия, әхлак, мәхәббәт темасына язылганнар. Икенчедән, талантлы итеп язылганнар. Шулай ук Ф. Садриев белән Н. Әхмәдиевнең, Р. Низамова белән Н. Гыйматдинованың, Р. Гыйззәтуллин белән В. Нуриевның, Хәйдәр белән Г. Гыйльманның, Ф. Әһлия белән З. Мәхмүдинең дә матур-матур проза китаплары дөнья күрде. Мин инде монда барлык яңа китапларны да санап бетерә алмам. Шулай да хөрмәтле өлкәннәребез А. Тимергалин белән Ш. Рәкыйповның, Г. Сабитов белән К. Тимбиковаҗың да балаларыбызны яңа китаплары белән сөендерүләрен әйтми кала алмыйм. Тагын шунысын да әйтергә кирәк: мона кадәр онытылган, күптән инде басылмаган элеккеге язучыларыбызның да әсәрләре укучыларыбызга яңадан әйләнеп кайта башлады. Шундыйларга Г. Исхакый әсәрләрен, Г. Рәхим, Ә. Айдар, Ф. Агеев китапларын кертер идем. Балалар әдәбияты ул китапларсыз һич тә тулы булмас иде.

Балалар драматургиясе дигәндә без инде, гадәттә, курчак театрын, соңгы вакытта Академия театрының «Балачак» студиясен күз алдында тотабыз. Бәхетебезгә, алар эшләп тора, яңа спектакльләр куела тора. Авторларның иң күренеклесе, әлбәттә инде, Туфан Миннуллин. Шагыйрь Зөлфәтнең балалар драматургиясендә актив эшләве дә бик күңелле хәл. Р. Харис белән Г. Рәхим, С. Шәмси белән М. Гыйләҗев, Р. Корбан... Менә шулар. Башка юк. Әмма яңа авторлар килми калмас, дип ышанам.

Шулай да бүгенге балалар әдәбиятының йөзен, миңа калса, шигърият билгели. Һәм бу гаҗәп тә түгел. Чөнки аның башлангычы, чыганагы — фольклор,

халык иҗаты. Чишмә башында — бөек Тукай. Бөек балалар шагыйре. Тагын шунысын да онытмаска кирәктер: шигырь, балалар шигыре — бүген иң киң таралган жанр. Аның кулланылыш даирәсе гаҗәп киң. Балалар шигыренең файдалы эш коэффициенты бермә-бер күбрәк. Бу жанрда безнең зур шагыйрьләребез иҗат итә: Ш. Галиев, Х. Халиков, Р. Мингалим, М. Фәйзуллина, Р. Бәшәр. Аларның китаплары — һәрчак балалар кулында,— һәрчак җиңүчеләр арасында. Мәсәлән, узган елгы республика конкурсында Ш. Галиевнең «Кем нәрсә ярата», Р. Мингалимнең «Галстуклы кәҗә» исемле китаплары балалар арасында иң популяр китаплар булдылар һәм беренче-икенче урыннарны яуладылар. Әлеге шагыйрьләр — балалар әдәбиятының йөз аклыгы. Алар белән янәшә әле тагын бик күп шагыйрьләр балаларыбызга хезмәт итә: М. Шабай, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, М. Әгъләмов, М. Галиев, Ә. Габиди, Г. Рәхим, С. Шакир, Р. Вәлиев, Э. Мөэминова, Р. Вәлиева, Җ. Дәрзаман, Н. Измайлова, Ш. Җиһангирова, Г. Морат, Б. Рәхимова, Ф. Зыятдинов, Г. Садә, Ф. Зыятдинова, Э. Шәрифуллина, К. Булатова, Г. Мөхәммәтшин, Д. Гарифуллин, З. Гомәрова, Я. Игәнәй, Р. Хисмәтуллин... Исемнәрне күпләп саный дип күпсенмәгез, әлеге шагыйрьләрнең һәр шигыре, һәр китабы безнең балалар әдәбияты өчен бик тә кадерле.

Яшьләр турында һәм бездән яшьрәкләр турында бүген аеруча басым ясап әйтәсем килә. Балалар әдәбиятына яшь көчләр килә. Мин монда талантлылары турында әйтим. Мөмкинлекләр генә булсын, аларның талантлары да, көч-егәрләре дә җитәрлек. Алар бүген үк инде балалар әдәбиятын талантлы, үзенчәлекле әсәрләр белән баеттылар. Бүген мин 30 яшендә фани дөньядан китеп барган искиткеч талантлы Афзал Нигъмәтуллинны сагынып искә алам. Аның үзеннән соң чыккан «Галәмдә сабан туе» дигән китабы — әдәбиятыбызда вакыйга булырлык иде. Беркемне дә кабатламый торган, балалар күңелен нечкә тоемлаучы шагыйрь безгә гүзәл шигырьләрен калдырып китте. Ләбиб Лерон — гаҗәп талантлы балалар язучысы. Универсал. Фантазер. Ул үзенең хикәяләрендә, әкиятләрендә күнеле булганчы «дуракавалять» итә, сүзләр белән уйный, туйганчы шаяра, укучыларын да шаярта... Нәтиҗәдә, заманча, бүгенге балаларның үзләре кебек үк тынгысыз, шаян әсәрләр барлыкка килә, «Шәп!»тән башка бер сүз дә әйтеп булмый. Р. Корбан, киресенчә, җитди шагыйрь. Б. Рәхмәтләр традициясен дәвам итүче, шул юнәлештә актив эшләүче шагыйрь, әдәбиятта үз урынын алган шагыйрь. Тагын ике яшь шагыйрьне әйтеп китим. Алар — Рафаил Газизов һәм Илгизәр Солтан. Икесе дә — бик әйбәт балалар шагыйре. Икесе дә — авыл малайлары. Икесе дә — балачак иленнән. Икесе дә икешәр балалар китабы чыгарган егетләр. Шуларга өстәп мин Р. Мулланурова белән Ләлә Сабированы, Йолдыз белән Нурия Сәйярны, Н. Каштан белән Мөҗәһит Әхмәтҗановны да бүген шушы биек мөнбәрдән беренче тапкыр исемләп китәм. Алар инде беренче китапларын чыгардылар. Балалар әдәбиятында җигелеп эшлиләр. Һәм, һичшиксез, Язучылар союзы әгъзалары булырга хаклылар.

Безнең балалар әдәбиятына иҗади көчләр тормышның үзеннән килә. Алар Татарстанның төрле төбәкләрендә яшиләр, төрле һөнәр ияләре. Аларның һәрберсе балалар әдәбиятына яңа сулыш, яңа үзенчәлек алып киләләр. Юри генә игътибар итегез әле: Р. Низамова — укытучы, авылда яши. Р. Газизов белән М. Әхмәтҗанов — мәктәп директорлары, авылда яшиләр. Илгизәр Солтан — агроном, авылда яши. Н. Каштан — табиб, Казанда яши. Д. Гарифуллин — журналист, авылда яши. Г. Мөхәммәтшин — җитәкче эштә, авылда яши. Х. Җәләл — артист, Ф. Яхин — галим, Ф. Зыятдинов — галим. Калганнары — журналистлар, укытучылар...

Яшьләр килә, димәк. Күптән түгел безнең секция яшь прозаик Алмаз Гыймадиевның балалар өчен язган хикәяләрен тикшереп, нәшриятка тәкъдим итте. Әйбәт яза. Әйбәт балалар язучысы булыр дигән өметем бар. Шунысы куанычлы, аңа әле нибары 22 яшь. Ә менә яшь шагыйрә Энҗе Афзаловага әле 11 генә. Ә үзенең инде «Кояшка хат» исемле китабы бар. Энҗе шагыйрь булып туган, шагыйрь булып үсә, шагыйрь булып эшли. Китапны төзеп чыгаручы Г. Гыйльманов язганча, «аның һәр шигыре, һәр сүзе — Галәм тарафыннан кешелеккә иңдерелгән Сүз, Тәгъмимат, Дога төсле».

Гомумән, бүгенге татар балалар шигъриятенең «планкасы» шактый биек. Аның аша бөтен шигырь язучылар да сикерә алмый. Ә менә балалар үзләре кайчагында, үзләре дә сизмәстән, шагыйрьләр көнләшерлек шигырьләр язып куялар. Узган ел Татарстан китап нәшриятында «Сабантуй» исемле җыентык дөнья күрде. Балалар иҗатыннан үрнәкләр тупланган әлеге китап нәкъ әнә шундый шагыйрьләр көнләшерлек әсәрләрдән гыйбарәт. Һәм шунысы кызык,

балалар язган шигырьләр белән балалар өчен язылган шигырьләр үзара бик тә охшаш, бер-берсенә бик тә якын тора. Түбән Камадан Алмаз Гыймаев менә нинди дүртьюллык язган:

Әни, кайчан бетә инде
Шушы «үзгәртеп кору»?
Бик кыен бит нәниләргә
Кәнфит ашамый тору.

Шәп әйткән бит. Чын балалар шигыре! Иң мөһиме, шушы 4 юлга бүгенге балаларның бөтен фаҗигасе сыйган. Балалар үзләре шушындый шигырьләр яза икән, безнең әдәбиятыбыз саекмаячак әле.

Ике съезд арасында тагын бер зур вакыйга булды: «Балалар фольклоры» дөнья күрде. Бу — безнең барыбызның да уртак куанычы. Кызганыч, андый китаплар бездә әлегә бик сирәк чыга. Югыйсә, хәзер республикада утызмы-кырыкмы нәшрият эшли. Ләкин балалар китабы чыгарырга берсе дә ашкынып тормый. Бөтен өмет үзебезнең Татарстан китап нәшриятында һәм «Мәгариф» нәшриятында. Фәкать алар гына безнең балалар китабына булган мохтаҗлыгыбызны киметергә сәләтле. Аларга игътибар булса, балалар язучыларына да игътибар булыр диясе килә. Ә безнең балалар язучыларының, фәкать әйбәт язарга гына хакыбыз бар. Балалардан, 93 яшьлек Гомәр ага Бәшировтан, 11 яшьлек Энҗе Афзаловадан үрнәк алыйк!

---



## Рөстәм Мингалим

### УҢАЙ КҮРЕНЕШЛӘР

Корылтайлар арасында безнең тормыш зур үзгәрешләр кичерде. Шул дулкында, бата-калка, без шаулы-тавышлы гына яшәдек. Уңышлы гына иҗат иттек. Уңышлы иҗат иттек дип, мин әдәбиятыбызның барлык жанрларын да истә тотып әйтәм. Үз-үзеңнән канәгать булырга өндәвем дип аңламагыз, бүген эшләребезгә дә игътибар итик, күрә белик дип әйтүем генә.

Драматургиябез үсеше мине шатландыра. Беренчедән, безнең прозаиклар, шагыйрьләр җиң сызганып эшләделәр, драматургиябез өлкәсенә дә зур җанланыш китерделәр. Әйтик, Мәдинә Маликова «Оҗмах балалары» дигән әсәр язды, ул Казан һәм Минзәлә театрларында куелды; «Йөрәк ничек түзсен» — Әлмәттә, Минзәләдә куелды. «Моңнар төште башыма» — Минзәләдә. М. Маликова «Сөембикә» дигән яңа пьеса тәмамлады. Фоат Садриев Әлмәт театрының ышанычлы авторы булып калды. Әле соңгы көннәрдә театрга «Син сандугач, мин каен» дигән яңа уңышлы әсәре кергәнне дә ишеттек. Разил Вәлиев Тинчурин театры сәхнәсен шаулатып торды. «Әйдә барыйк, кызлар карыйк», «И машина, машина...» әсәрләре барды. «Куркыныч уен»ы куелырга әзерләнә. Гәрәй Рәхим әсәре курчак театрында уйналды, Минзәлә театрында уңыш белән уйнала.

Зөлфәт Хәким әсәрләре сәхнәләргә ныклап аяк бастылар. Әхәт Мушинский, Лев Кожевников үзләренең әсәрләре белән курчак театрына йөрүче балаларыбыз-

ны шатландырдылар. Прозаик Зиннур Хөснияр, шагыйрь Ләбиб Лерон да әсәрләр яздылар, әсәрләре секциядә уңай бәяләнде. Драматургиягә, әле башка съездлар арасында күрелмәгәнчә, күп кенә яңа исемнәр килде. Мәсәлән, Сәрия Вильданова — бүген Язучылар берлегенә алырлык һәм алыныр да; Данил Салихов әсәрләре секция утырышында уңай бәяләнеп, Язучылар берлегенә алынды; Хәбир Ибраһимов әсәре Әлмәт театрында уңышлы уйнала, Язучылар берлегенә алынды; Эсфир Яһудин — бүген Язучылар берлегенә алырлык, әсәрләре Әлмәт, Тинчурин театрларында уйнала. Бу авторның секциядә 6 әсәре каралды, уңай бәя алды. Тиздән Язучылар берлеге әгъзасы булыр. Рәшидә Җиһаншина, Гафур Каюмов, Фәнәвил Галиев, Аманулла исемнәре афишалардан кычкырып тора. Әле күптән түгел генә Сәмига Сәүбанова әсәре секциядә тикшерелде — уңай бәяләнде. Х. Нигъмәтуллина һәм Актаныш егете Илфак Ибраһимов иҗаты яшьләр белән эшләү бүлегендә тикшерелде. Соңгысы беренче пьесасын язган, кимчелекләре бар, киләчәктә камил пьесалар язарлыгы да бар. Шигырьләре китап нәшриятына тәкъдим ителде.

Тагын шуны да әйтим: бу съездлар арасында, драматургия өлкәсендә, йөкнең иң авырын халыкка күптән мәгълүм драматурглар тарттылар. Иң саллы, театрларның асыл йөзен күрсәтүче әсәрләрне алар язды һәм күп яздылар. Туфан Миннуллинның «Акбай авыл эте» — 5 серия. Ул тагын «Хушыгыз», «Илгизәр + Вера», «Кәҗә мал түгел, бажа туган түгел» дигән әсәрләрен халыкка җиткерде. Шагыйрь Илдар Юзеев һаман үзенең драматургия өлкәсендәге затлы урынын югалтмады. Аның «Безнең әти мировой» дигән әсәре Минзәлә һәм Тинчурин театрларында, «Гашыйклар тавы» Чаллы яшьләр театрында һәм Кәрим Тинчурин театрында иң уңышлы спектакльләр рәтендә торды. «Еракгагы кәккүк авазы» опера һәм балет театрында барды. Аның «Ак калфагым төшердем кулдан» дигән, татар халкының трагедиясен сөйләгән әсәре Уфада М. Гафури исемендәге театрда уңыш казанды. Ризван Хәмиднең «Исәнлеккә-саулыкка?!» дигән шаян тамашасын Казанлылар К. Тинчурин театрында тамаша кылдылар. «Ак тамырлар», «Хан кызы» — Юныс Сафиуллин әсәрләре иде.

Шушы ике съезд арасында өр-яңа кинодраматургиябез туып килә. Гариф Ахуновның кинофильм булып чыккан «Идел кызы»ның аягы җинел булды. Тукай турында күп серияле фильм туарга тора. Киносценарийләрне Ризван Хәмид (ул 5 серия язды), Гариф Ахунов, Әхтәм Зарипов әзерләделәр. Гәрәй Рәхимнең «Исә болгар җилләре» дә кинодраматургиябез хәрәкәттә икәнгә дәлил. Ризван Хәмид белән Рөстәм Мингалим Идегәй турында өч серияле киносценарий тәмамладылар.

Бүгенге яшәү шартларыбызны, реаль тормышыбызны истә тотып, аек акыл белән күзәткәндә, язучыларыбызның иҗатында һәм иҗат оешмасындагы үзгәрешләрдә дә күп кенә уңай күренешләр күрергә мөмкин. Ул үзгәрешләр асылда өстебеезгә килгән кыенлыкларны җиңеп чыгу юлларын эзләүгә, әдәбиятыбыз утын сүндермичә саклауга юнәлтелгән. Ләкин, хөрмәтле каләмдәшләр, соңгы елларда безнең күңелләребез бер-беребезгә хөрмәтсезрәк якка үзгәрә. Бер-беребезгә җылы карашыбыз кими. Бер-беребезнең яхшысын күрмәскә, яманын табарга тырышабыз. Сөйләшеп йөргән сүзләребездә дә, матбугатта чыккан язмаларыбызда да моңа дәлилләр җитәрлек. Мәскәү язучылары тешләшә дип, без дә тешләшә башладыкмы, читләшә башладыкмы? Таркалырга тырышабызмы? Мондый иярү безнең ахмаклык булыр. Алар язмышы башка, безнең бөтенләй бүтен. Алар күптән җыелганнар, чәчәк атканнар. Без, ни гомер яшәп тә, әле юньләп җыелырга да мөмкинлек күрмәгән кешеләр. Безнең язучылар төрле милләт арасына таралып, адашып, яшәргә тырышып, каңгырышып йөриләр.

Киләсе съездга хәтле безгә ныграк берләшергә, барлык өлкә һәм республикалардагы яшәүче язучыларыбыз сыярлык татар язучылары үзәге булырга, җыелырга, мөнәсәбәтләребез җылынырга язсын иде. Халкыбыз язмышы бездән шуны таләп итә.



# Владимир Корчагин

## ТОРМЫШТАН КАЛЫШМЫЙЧА

Татарстанның урыс телендә иҗат итүче әдипләре — прозаиклар, шагыйрьләр, драматурглар һәм тәрҗемәчеләр — ике съезд арасында төрле жанрларга караган егермедән артык китап чыгардылар. Язучыларыбыздан Г. Паушкин, В. Корчагин, Д. Вәлиев, Р. Кутуй, Н. Орешина, Л. Кожевников, Н. Беляев, Н. Алешков, М. Скороходов, В. Лавришко, Ә. Мушинский, Р. Кожевникова, В. Трофимов, Б. Вайнер, И. Киндер, Р. Сабиров, А. Гарзавина, М. Гоголев һ. б. лар әдәбият сөючеләрне яңа әсәрләре белән сөендерделәр.

Казанда һәм Чаллыда яшәүче яшь прозаикларның хикәяләреннән тупланган «То светлое и нежное» исемле җыентык (төзүчесе Ә. Мушинский) әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан яратып кабул ителде. Шагыйрь Н. Беляев тарафыннан әзерләнгән «Стихи казанских студентов. 1970—1990» мәҗмугасы да шигырь сөючеләр өчен күркәм бүләк булды.

Яшь каләм ияләре Е. Бурундуковская, О. Левадная, И. Җамалиев, Т. Алдошин, Г. Хәеров, А. Архипов-Федоров, Е. Сухов, С. Гордиенко үзләренең китаплары һәм көндәлек матбугатта чыккан әсәрләре белән әдәбият сөючеләрнең хәтерендә калдылар.

Безнең язучылар Казанның фантастика сөючеләр клубы эшендә актив катнаштылар. Урыс әдәбияты секциясе ярдәме белән фантастикага тартылган яшь каләм ияләре әсәрләреннән җыентык әзерләнде.

Шунысын әйтеп үтәргә кирәк, финанс кытлыгы аркасында нәшриятләрдә китап бастыру авырлашты. Кайбер әдипләр үзләренең әсәрләрен иганәчеләр ярдәме белән чыгара башладылар.

Соңгы вакытта «Яшел мич янында» дип аталган телетапшырулар циклы тамашачыларда кызыксыну уятты. Бер сәгать дәвамында баручы әлеге тапшырулар телевизор карауучыларны күренекле язучылар белән очраштыра, аларның халык тормышы турындагы уй-фикерләре, әдәби иҗат серләре белән таныштыра. Видеоязмалар аерым фонотекага тупланып бара.

Урыс телендә яза торган әдипләребез драматургия өлкәсендә дә нәтиҗәле эшләргә омтылалар. Төрле театрларда Д. Вәлиев, Л. Кожевников, Б. Вайнер, Г. Хәеров пьесалары куела.

Балалар өчен рәсемнәр белән бизәлгән «Барабашка» журналының беренче саны чыкты. Аны язучы Б. Вайнер редакцияли.

Урыс әдәбияты секциясе әгъзалары татар язучыларының әсәрләрен русчага тәрҗемә итү өлкәсендә дә актив эшлиләр.

Язучыларыбыз әдәбият сөючеләр белән якыннан элемтәдә торалар. Мәдәният сарайларында, мәктәпләрдә, китапханәләрдә, югары уку йортларында әледән-әле очрашуларда катнашалар.



# Әмирхан Еники

## ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ!

Без кайчандыр барыбыз да бертөсле идек, хәзер күп төрлегә әйләнеп беттек. Элек үзара бәйләнешләр дә, якынлык-дуслык та көчлерәк иде. Хәзер исә читләшү, ераклашу елдан-ел көчәеп бара. Элек барыбыз өчен дә уртак «совет язучысы» дигән исемебез бар иде, хәзер мин үземне кем дип атарга да белмим.

Дөрес, талант ягыннан без бер-беребездән шактый нык аерыла идек, күп нәрсәгә фикер-карашларыбыз да бертөсле генә түгел иде, тормыштагы үзгәрешләргә дә мөнәсәбәтебез төрлечәрәк иде, әмма шушы аермалыкларга карамастан, без 70 ел буена тоталитар системага күпмедер дәрәҗәдә яраклашып, алай да, хәлебездән килгән кадәр үзебез, теләгәнчә тырышып, бөтен бер иҗат коллективы рәвешендә яшәп килдек. Бу коллективның төп бурычы — социализм төзүчеләрне коммунистик рухта тәрбияләү иде.

Инде менә ул система гүя җимерелде, юкка чыккан шикелле булды... Аның урынына демократик җәмгыять төзелергә тиеш иде кебек... Без моны бик теләп, бик көтеп алган идек... Ләкин, ни хикмәттер, искедән яңага күчү коточкыч авыр, газаплы, фаҗигале бер эш булып чыкты. Без һич көтелмәгән әллә нинди һәлакәтләр, үзара сугышлар, акылга сыймас җинаятьләр чорына килеп кердек (Советлар Союзы кебек дөньяның иң куәтле бер дәүләтен таратып ташлау шул җинаятьләрнең иң зурысы түгелме соң?!) Нәрсә аркасында болар барысы да?.. Менә хәзер генә моны бөтен тирәнлеге белән аңлавы да читен, әйтүе дә читен... Ләкин шулай да бүгенге шаккатыргыч тамашаның бер сәбәбе, миңа калса, халыкка ачык булса кирәк. Без бит кешелек җәмгыятенең югары баскычы булып саналган социализмнан аның түбән баскычы — капитализмга кире күчеп маташабыз. Социализм бирә алмаган муллыкны, иркенлекне, хөрлекне безгә капитализм бирергә тиеш иде кебек (әнә, Европа илләрендәге шикелле.) Әмма социализмны вата-җимерә туып килгән капитализм коточкыч кыргый, вәхши, комсыз, кансыз бер албасты булып чыкты... Хәер, гадел кәсепкә, ачык конкуренциягә нигезләнгән, кеше ихтыяҗын ничек тә әйбәтрәк канәгатьләндерергә тырышкан чын капитализммы соң бу? Әллә булмаса, хакимият тирәсендәге һәм дәүләт милкенә якын торучы ниндидер бер төркемнең халыкны талап, ил байлыгын үзләштереп тизрәк баеп калырга омтылышы гынамы? Икътисадый реформаның без белгән нәтиҗәсе хәзергә шул гына ич!.. Яңа байлар кемнәр алар? Дәүләт структурасындагы номенклатура белән шулар тирәсенә сырышкан мафиоз эшкуарлармы?.. Без аларны күреп тә, ишетеп тә беләбез. Әмма бу яшерен байларга ачыктан-ачык дошман, хәерчелектә интегүче күпчелек халыкны яхшы күреп, тоеп торабыз... Әйе, бүгенге җәмгыятьтә тирән социаль тигезсезлек, упкын хасил булды.

Тарихның бездән мәсхәрәле-әче көлүе дип әйтергәме, тик иң гаҗәбе шунда ки, күпме корбаннар биреп социализмны төзүчеләр дә, хәзер исә халыкны тәкатьсез калдырып капитализмга күчеп маташучылар да бер үк фирка кешеләре, ягъни кичәге большевиклар... Безнең язмышыбыз бүген дә шулар кулында...

Билгеле инде, социаль яктан аерылышу, бер-беребездән ераклашу һәм читләшү язучылар арасына да килеп керде. Кемнең ничек яшәгәнен без ачык кына белмибез, әмма бик күпләрнең авыр хәлдә яшәүләре берәүгә дә сер түгел. Карт язучыларның пенсиядән, яшьләрнең күпме-азмы хезмәт хакыннан башка бүтән бернинди килере юк — китап чыгарып, гонорар алулар бетте хәзер... Ихтимал, җитәкчелеккә якын торучы, зур урын биләүче, китабын да чыгара алучы язучы гына әйбәт, иркен торадыр, ләкин андыйлар бармак белән генә санарлык... Күпчелек исә тирән бөлгенлектә утыра.

Алда да өметле бернәрсә дә күренми... Хөкүмәткә ышаныч бетте диярлек. Ул әнә атна саен, ай саен бәяләрне өзлексез арттырып кына тора (бигрәк тә көнкүреш хезмәтләренә). Ни өчен, нәрсә хакына — моны аңлавы бик читен. Гүя халыкның чыдамлыгын сынар өчен эшләнә бу...

Шушы талауларның һаман дәвам итүе, бөлгенлекнең һаман көчәя баруы нәтиҗәсендә кешедә рухи торгынлык та туа башлады. Нидер көтеп, алданып яшәү тәмам туйдырды. Берләштерә, рухландыра торган уртак идеал да юк... Элек без обкомга кирәк идек, хәзер кемгә кирәк без — белгән юк.

Менә шушындый шартларда үзеннән-үзе бер котылгысыз сорау туа: язучыларны берләштерү мөмкинме, моңарчы яхшы яшәп килгән язучылар берлеге безгә кирәкме?.. Бу сорау күпләрне, һичшиксез, уйландыра торгандыр.

Менә мин дә, озак баш ватканнан соң, бер фикергә килдем: бөтен авырлык-каршылыкларга карамастан, Язучылар берлеген шулай да сакларга кирәктер... Әлбәттә, аңа ниндидер үзгәрешләр кертеп, яңалыклар өстәп сакларга тиешбез.

Моны ике максат таләп итә: беренчедән, язучыларның иҗади мәнфәгатьләрен яклау өчен, аларга материаль ярдәм күрсәтү, яшәү һәм эш шартларын яхшырту өчен... Икенчедән, әдәбиятыбызның халык тормышында тоткан урынын саклау һәм ныгыту өчен... Татар халкы борын-борыннан ук китап сүзенә колак салып килгән. Бүгенгедәй гаять киеренке, буталчык бер заманда язучының гадел, туры сүзе аңа аеруча кирәктер дип беләм... Аннары, бу заман безнең алдыбызга үтә мөһим изге бер бурычны китереп куйды. Әйтергә кирәк, советлар дәверендә без, күпчелек язучылар, татар халкының милләт буларак инкыйразга (бетүгә) табан баруын ачык тоеп, бик борчылып яшәдек... Менә хәзер шул хәвефтән котылу, милләтебезне саклап калу, терелтү, тәрәккый иттерү мөмкинлекләре туып тора. Бу мөмкинлекләр безне таркату түгел, һичшиксез, берләштерергә тиеш. Һичбернинди фикер каршылыкларына карамастан!..

Әгәр без шушы карарга киләбез икән, Язучылар берлеген ничек итеп саклау турында уйланырга тиешбездер инде. Бу хакта тәкъдимнәр күп булыр. Минем исә кыскача гына шуны әйтәсем килә: хәзерге шартларда Язучылар берлеге белән җитәкчелек итү искиткеч зур чыдамлык сорый торган гаять четерекле, җаваплы бер вазыйфа ул. Бу эшкә кемне генә сайлап куйсаң да, ул бөтен язучыларга да ярап бетмәячәк. Хәтта алланың кашка тәкәсен сайлап куйсак та!.. Ә эшне алып барырга кирәк. Бигрәк тә язучыларга ярдәм оештыра ала торган тәҗрибәле кешеләр безгә кирәк булачак. Шуңа күрә мин, әгәр үзләре риза булсалар, иске җитәкчеләрне алыштырмау хәерлерәк булыр дип саныйм. Алар инде бер-берсе белән аңлашып, килешеп эшләргә өйрәнгәннәр... Аннары, кичү чыкканда атларны алыштырырга ярамый, дигән акыллы мәкаль дә бар... Кыскасы, искеләрне калдырыйк, әмма бер шарт белән: идарә составын бик нык үзгәртергә, ә рәиснең үзен шушы съездда расларга кирәк. Һәм алар сан ягыннан бик күп булмаска да тиеш. Элеккеләрдән мин Роберт Миңнуллинны, Әхсән Баянны һәм Ркаил Зәйдулланы калдырырга тәкъдим итәр идем. Калганнары күбрәк яңа кешеләр булырга тиеш. Монда төп максат — рәис тирәсендә яңа бер группа оешуны булдырмаска кирәк. Күп ризасызлыклар еш кына җитәкчелектә тар бер группа хасил булудан килеп чыга. Яңа әгъзалар рәис кешегә, һичшиксез, хәерхаһ булырга, аны аңларга, акыллы киңәшләре белән хаталардан сакларга, ярдәм итеп торырга тиеш. Хәерле сәгатьтә!



# Равил Фәйзуллин

## СҮЗ КӨЧЕ

Мөхтәрәм каләмдәшләр!
Кадерле кунаклар!

Тарихи мәгънәсе, эчтәлеге белән без кичергән соңгы дүрт-биш ел — элек яшәлгән әллә ничә дистә елларга тиң торырлык. Ни өчен шулай дим? Дәлилем шул: йотылуга, «совет халкы» дигән абстракт исем астында актив рәвештә руслашуга, милли йөзен югалтуга барган халык, «без уяндык Бишенче елны таң белән» дигәндәй, ниһаять, янә бер үзенең бар икәнлеген, элеккеге шәүкәтле чакларын бөтенләй үк онытмаганын, тарихи Хәтернең исән икәнлеген раслады. «Татар халкы», «Татарстан» дигән сүзләр дөнья халыклары телләрендә ешрак тибрәнә башлады. Төрле кыйтга илләре белән аралашулар көчәйде. Үзебез дә күзгә күренеп үзгәрдек. Халыкның бөтен катлауларында да сизелә бу үзгәреш. Фәкать дөнья көтү — җан асрау, өс-баш бөтәйтү белән генә мәшгуль булган миллионлаган милләттәшләребездә дә эчке уяну — үткән, бүген, киләчәк турында уйлану башланды. Дөрес, бу дүрт-биш ел эчендә бүтән халыклар да йоклап ятмады, аларның да казанышлары җитәрлек. Әмма нәрсә бәрабәренә бит! «Пәри башка, җен башка» дигәндәй, безнең тарихыбыз да үзенә бер төрле бит әле! Без бит эстоннар яки грузиннар кебек империя читендәге халык түгел. Ни өчен Татарстан белән санлаша башладылар? Ни өчен байтак халыклар безгә игътибарлырак була башлады? Әллә җир-суларыбыз, территориябез үзгәрдеме? Юк! Әллә Израильдәге кебек, татарлар бер җиргә актив туплана башладылармы? Алай түгел шикелле. Әллә бөтендөньяны шаккаттырырлык гасыр ачышлары булдымы бездә?..

Хикмәт шунда: элек үзенең дәүләтчелеге булган халыкның генофонды үзенең әлегә тере икәнлеген белдерде. Кызулык белән түгел, сабырлык белән; корал белән түгел, акыл белән эш итү кирәклеген сиздерде тарихи Хәтер! Менә шуңа күрә дә без шаһитләре булган әлеге биш еллык ара байтак дистә елларга тора дип әйтәм дә.

Бу рухи күтәрелештә безнең әдипләребезнең дә өлеше шактый дип уйлыйм мин. Халык язучысымы ул, әллә яңа гына Берлек әгъзасы булган каләм иясеме, язучы-депутатмы, әллә пенсионер әдипме, яшьме-картмы, ир-атмы, әллә хатын-кызмы, шагыйрьме, драматургмы, прозаик яки тәнкыйтьчеме, төп мәсләктә — халкыбызга ирек кирәклеге мәсьәләсендә шактый ук бердәм була алдылар. Кемдер күбрәк көч куйды, кемдер — әзрәк, кемнеңдер эше Данко йөрәге януы шикелле бар халыкка күренеп торды, кемдер кызган торф кебек астан, эчтән янды һәм кирәген яндырды... Ә инде әдәби-оештыру елъязмасын янә бер күздән кичерсәң, Язучылар оешмасы ягыннан да бу юнәлештә эшлекле инициативалар байтак булган.

Шулай да, миңа калса, бу соңгы елларда әдәби-нәфис сүзгә караганда, иҗтимагый-сәяси сүзнең куәте көчлерәк булып чыкты. Теләсә теләмәсә дә, коеп

куйган әдипләребезнең дә күпчелеге сәясәтчегә әйләнде. Күрәсең, тарихи ихтыяж, заман таләбе шундый. Бу күренешне закончалык дип, Азатлыкка, Бәйсезлеккә бару юлының бер авыр этабы үтелү билгесе дип тә карарга кирәктер.

Ә инде әдәби әсәрләргә — фәлсәфи мәгънәгә, эстетик тәэсиргә ия әсәрләргә конкретрак килгәндә, күрә белик — алар да аз язылмады бу чорда! Хәтерегездәдер: үткән съездда күләмле әсәрләрдән И. Сәлаховның «Тайгак кичү»е, М. Хәсәновның «Язгы аҗаганы» һәм тагын кайбер романнарны уңай бәяләгән идек. Бу зур җыенда да без андый әсәрләрне саный алабыз. Әйтик, ел ахырында гына журналыбызда чыккан «Йәгез, бер дога» (А. Гыйләҗев) әсәре югары кимәлдә язылмаганмени? Яки Ф. Садриевның «Таң җиле»?.. Ә тарихи романнар? «Казан утлары»нда гына алар бишәү басылды. (Мин биредә Ф. Латыйфи, Батулла, М. Хәбибуллин, Җ. Рәхимов, Р. Мөхәммәдиев әсәрләрен күздә тотам.) Төрле дәверләргә караганнары бар. Болгар чоры дисеңме, Казан ханлыгы еллары, соңрак чорлар... Әлбәттә, аларда бәхәсле моментлар да җитәрлек. Әмма мондый романнарның ишәюе әдәбиятыбыз өчен уңай күренеш.

Менә без аерым жанрлар буенча берничә кыска доклад-чыгышлар тыңладык. Әдәбиятыбызның үсеш тенденцияләрен ачыклаучы байтак кызыклы фикерләр яңгырады. Бер нәрсә бәхәссез: без заманнан арттарак калып барабыз. Заманны аңлау буенча да һәм әлбәттә, аны язмада беркетеп калдыру буенча да. Тоталитар режим тәрбиясендә тибрәнеп, йокымсырап, оеп ятканда — кинәт иркле хөр фикер стихиясенә керә алу уен эш түгел. Без югалып, хәтта куркыбрак та калдык шикелле. Шунсы гаҗәп: цензура кысалары үтә нык чакта да шактый гына саллы, хөр, хәтта ки ул заман өчен еретик саналган кыю фикерләр әйткән язучылар ничектер тыныбрак калды. Кайчандыр авыз тутырып тын алырга да базмый торганнар үтә актив «көрәшче»ләргә, хакыйкатьнең мөгезеннән элэктерүчеләргә әверелделәр. Чөнки киртәләр җимерелеп, бөтен көтү-табун печәнлеүләнле җирне тойгач, күпләр гайрәтләнде... «Япунны мөселманлыкка чыгарган» Батыргали агайга әйләнде. Бу, бәлки, начар да түгелдер. Әмма кычкыру белән кычкыруның, әйтә белү белән әйтә белүнең, яза белү белән яза белүнең аермасы бик зур шул. Ният-теләкләре изге булып та, язу куәсләре чамалы булган авторларның әсәрләре матбугатны басып китте. Кыскасы, яхшыны уртачадан, уртачаны начардан аеру критерийлары югалды. Бәлки, болар — күчеш, тетрәнү, катаклизмнар чоры өчен табигыйдер дә. Әмма, вакыт узар, эстетик категория кануннары тулы яшәү хокукын барыбер алыр.

Югарыда әйтелгән нәтиҗәләргә китергән факторларның тагын берничәсен әйтеп узасы килә. Аларның берсе: классик мәгънәдәге асыл зат әдипләрнең сирәкләнүе, ягъни күркәм традицияләребезнең тотрыксызлануы... Гасырларыбызның беренче яртысында яшәп иҗат иткән әдипләр кагортасын, әйтик, Дәрдеменд, Г. Исхакый, С. Максуди, Г. Гобәйдуллин, Г. Ибраһимов, К. Тинчуриннарны әйтеп тә тормастан, әле күпләребезнең хәтерендә булган И. Гази, М. Әмир, Ә. Фәйзи, Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арслан кебек чын мәгънәсендәге әдипләрнең безнең арада юк дәрәҗәсендә аз булуы күңелне сыкрата. Аларның иҗатлары, исемнәре, яшәү рәвешләре дә үзләреннән соң килгән каләм ияләренә — яшьләргә әдәпсез һәм әхлаксыз яшәргә мөмкинлек тә, ирек тә бирмиләр иде. Үз заманнарына хас ортодоксальлекләре булса да, принципиаль, компромиссларга бирешми торган олпат затлар иде алар. Кызганыч, бүгенге җитмеш яшьлекләребезнең кайберләренә әлеге сыйфатлар бик тә җитенкерәми шул.

Икенчесе: әдәбиятыбызның заманнан артта калуына тагын бер сәбәп: без соңгы елларда, нигездә, (кайберәүләребезнең чит ил әдәбиятлары белән бәйләнешне ныгытуларын инкарь итмичә) фәкать үз казаныбызда гына кайнавыбызда. Дөрес, бу хәлнең файдасы да юк түгел: үз тарихыбызны ныграк өйрәнә башладык, үзебезнең мәшһүр шәхесләребезне барлыйбыз, тарихыбызның җуелган чылбырларын ялгыйбыз. Әмма, икенче яктан, без үзебезнең рухи хезмәтләребезне бүтән халыклар ирешкән казанышлар белән чагыштырып караудан мәхрүмрәк хәзер. Элегрәк тугандаш халык әдәбияты вәкилләре белән очрашулар-декадалар, совет әдәбияты көннәре, төрле юбилейлар еш була иде. Һәм алар, мәгълүм бер дәрәҗәдә, әдәбиятыбызны үстерүдә уңай йогынты ясый иде.

Өченчедән, әдәбиятка яңа килгән, дөресрәге Берлек әгъзалыгына яңа кабул ителгән каләм ияләренең яшь ягыннан шактый ук өлкән булулары. Картлар яки яшьләр әдәбияты булмаса да, бүгенге бу процесста әдәбиятта сыйфатый янарыш була алмый. Карагыз, ике съезд арасында Берлеккә кабул ителгән язучы иптәшләрне. Алар җитмештән артык. Күбесенең яше илледән ашкан... Хәер, биредә хәзерге яшьләрнең язучылык хезмәтенә реаль карашын да онытмыйк. Кызганыч:

каләм хезмәте бу чорда нормаль яшәүгә гарантия була алмый. Талант бәяләнми торган чорда яшибез.

Һәм, дүртенчедән, (монда тагын бишенчедән, алтынчыдан... унынчыдан дигән пунктларга кадәр барып житәргә мөмкин) без — татар язучылары, хәзергә Татарстан җирлеге белән генә чикләнәбез. Гәрчә дүрт-биш татар кешесенең фәкать берсе генә Татарстанда яшәсә дә. Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә без халкыбызның реаль силуэтын тулырак итеп тойдык. Кая безнең бүтән төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез турында чын мәгънәсендәге киң масштаблы әсәрләр? Нижгар, Касыйм татарлары дөньяда юкмени? Мәскәү, Урта Идел, Әстерхан, Оренбург, Чиләбе, Троицк, һәм, ниһаять, Уфа ягы татарлары турында хезмәтләребез кая? Анда безнең халкыбыз юкмы? Әллә алар тормышын колачларлык әдипләр юкмы? Стратегик ялгышлар турында уйландыра бу фактлар. Зур кыенлык белән Башкортстанда ачылган татар язучылары оешмасына безнең реаль ярдәм бик кирәк. Тәҗрибәбез, киңәшебез кирәк. Иншалла, андый оешмалар бүтән регионнарда да ачылыр. Алар да өмет белән Казанга караячак бит.

Сүземнең ахырында үзебезнең «Казан утлары» турында да берничә сүз әйтеп китим. Журналның бүгенге тиражы 23 мең чамасы. Аны бер елга, ягъни 12 гә тапкырласаң 300 меңгә якын өр-яңа әсәрләрдән торган калын китап дигән сүз. Үзенә күрә бер нәшрият. Татарстан китап нәшриятының татарча чыгара торган китаплары өлешенә якынлаша безнең саннар.

Хәтерегездәдер, «Казан утлары» озак дистә еллар буенча Татарстан Язучылар союзы органы булып исәпләнде. Үткән съездда да журналның статусы әле шулай иде. Ә 1991 елның уртасыннан башлап журнал яңа юридик статус алды. Хәзерге көндә журналны оештыручылар — ягъни гамәлгә куючылар булып Татарстан хөкүмәте, Язучылар берлеге, редакциянең хезмәт коллективы санала. Юстиция, матбугат һәм информация министрлыклары раслаган безнең үз уставыбыз бар. Һәм без андагы положениелар нигезендә эшлибез дә. Журнал бүгенге көндә, нигездә хөкүмәт биргән дотация акчасына яши. Һәр сан уртача 10 млн. сумга төшә. Әбүнәчеләрдән, ягъни подписчиклардан кергән акчага нибары ике-өч сан чыгарып була. Спонсорлардан кергән керемебез дә бик аз микъдарда. Язучылар берлеге, табигый, үзе дә хөкүмәт акчасына яшәгәнлектән безгә матди яктан булыша алмый. Журналны, асылда югарыда әйтелгән өч оештыручының икесе чыгара: хөкүмәт акча бирә, редакция коллективы журналны әзерләп укучы кулына тапшыра. Шулай да, без Язучылар берлеген журналны оештыручыларның берсе булуын табигый саныйбыз. Чөнки безнең төп авторларыбыз — язучылар, талантлы әсәрләр никадәр күп булса, халык арасында безнең абруебыз да шул нисбәттә зуррак булыр, халыкның рух дәрәҗәсе дә үсә барыр.

Сүз уңаеннан соңгы елларда редакция эшчәнлегенә кагылышлы кайбер эшләребезне әйтеп үтү дә урынлы булыр. Иң мөһиме: бу авыр шартларда без тиражыбызны чагыштырмача канәгатьләнерлек дәрәҗәдә саклап кала алдык. Бу елларда журналның матди-техник базасы ныгыды. Бөтендөнья татарлары конгрессы көннәрендә тантаналы рәвештә журналның 70 еллык юбилеен уздырдык. Журналның үткән тарихын һәм бүгенгесен яктырткан, ике кисәктән торган документаль фильм эшләнде.

Хөрмәтле иптәшләр!

Төшенкелеккә бирелмик: талант ияләре өчен бу авыр еллар үтәр. Кешелек яшәгәндә Сүз кодрәтенең көче кимемәс. Әйдә, каләм хакы нәфес кузгатырлык булмаса да, күңел түреннән төшкән иң яхшы әсәрләребезне милли басмаларыбызда, «Казан утлары» кебек төп журналларыбызда ташка бастыра барыйк. Тарихи елъязма булып калсын алар. Язучыларның бу съезды аңлашу һәм туганлашу жыены булсын. Мөстәкыйльлеккә юл тоткан дәвердә милли бердәмлек иң мөһиме бит.

Кайбер талантлы каләмдәшләребезнең, әйтик, Т. Миңнуллин, Н. Фәттах, М. Юныс, Разил Вәлиев, Г. Рәхим, Р. Кутуй, Ш. Хөсәенов, И. Нуруллиннарның съездыбызда булмавы бераз уйландырды мине. Катнашмау өчен мөһим сәбәпләре булгандыр дип уйлыйк. Игътибарыгыз өчен рәхмәт.

**Әхсән**

**Баян**



## КЫЕН ЧАКЛАР

Сүзне кечкенә искәрмәдән башларга туры килә. Гадәттә, әдәби фонд эше турындагы мәгълүматны фондның директоры ясый торган иде. Директорлар алмашынып торганлыктан (биш ел эчендә өч директор булды) Берлек идарәсе бу чыгышны миңа тапшырды.

Әгәр патшалар еш алмашынып торса, моның илдәге хәлләрнең ниндилеген күрсәтә торган иң дөрес галәмәт икәнен яхшы беләбез. Фонд директорларының ни өчен китә торуын да шул мәгънәдә аңларга мөмкин. Турысын әйткәндә, хәлебез мактанырлык түгел. Беренче һәм хәлиткеч сәбәп финанс дигән нәрсәгә кайтып кала.

Элекке зур илдә, шул исәптән Татарстанда китап чыгару әйбәт булган чакларда, РСФСР әдәби фонды бүлекчәсе буларак, безне Россия әдәби фонды финанслый иде. 1992 елдан башлап, безгә Мәскәүдән бер тиен дә акча килми.

Татарстан хөкүмәте безнең әдәби фондны үз бюджетына кабул итә алмады. Шул рәвешле әдәби фонд керемсез калды.

Съездда информация ясау хакында сүз чыккач, кайберәүләр: «Әдәби фондны ничек итеп таратуыгыз турында сөйләрсез инде»,— дип шаяртырга тиеш тапты. Мондый сүзләрнең чынлап әйтелгәннәрен дә ишеткәләгәнгә күрә, моңа җавап бирергә кирәктер. Җавап шулдыр: кыргый базар афәтләрен без уйлап чыгармадык. Әдәби фонд идарәсе илдә иң фәкыйрь бәндәләр булып язучылар калсын дип тырышмады.

Әйе, элгәрге байтак автономияле, хәтта союздаш республикаларда әдәби фонд вазифалары Язучылар союзлары идарәләренә тапшырылып, фонд булудан туктады. Аңлашылса кирәк, безнең моңа катнашыбыз юк. Ә безнең хәлне рәсми яктан караганда да әйбәт дияргә җай юк түгел.

Татарстан язучыларының әдәби фонды халыкара иҗтимагый «Әдәби фонд» оешмасына кабул ителде, статусы элеккеге союздаш республикалар әдәби фондларыныкы белән тигезләште. Иҗат йортларына юлламаларны без хәзер шуннан алабыз. Әмма Россия әдәби фондыннан да аерылып беткәнебез юк. Бу мәсьәләдә хәзергә үзебез уртак фикергә килә алмадык.

Акча керемнәре тукталганнан соң, әлеге фондта бердәнбер берәмлек булып бухгалтер калды. Ул булган мөлкәтне саклаучы да, бүлмәләрне тәртиптә тотучы да.

Алдагы көннәр турында берничә сүз.

Мин киләчәкне бөтенләй өметсез димәс идем. Ләкин моның өчен кайбер шартлар кирәк булачак: Татарстанда авторлык хокукларын саклау оешмасы ныклап эшли башларга тиеш; ул оешып килә. Әдәби фондка аның аша күпмедер акча керә алыр иде. Шул ук вакытта республикада китап басу эшен юлга салу — хәлиткеч чараларның иң мөһимедер. Моннан килгән күпмедер керемнең әдәби фондка күчүе — законлы хәл. Әгәр китап басылмый икән, әдәби фондның

гына түгел, гомумән, язучыларның да кирәге калмый дигән сүз. Базарга безнең хәзер үк инде кирәгебез бик тә чамалы.

Базар дигәннән, әдәби фондка кәсепчелек тә рөхсәт ителә. Моның белән шөгыльләнсен өчен без директор итеп бер яшь иптәшне куеп карадык, вәкаләтләребезне аңа тапшырдык. Ул эшләп карады, сату итте, зур-зур планнар корды. Мәгәр кәсеп шундый булып чыкты ки, фондның соңгы тиеннәре, тәтенгә әйләнеп, торбадан очты.

Әдәби фондка язучыларның үзләреннән өлеш кертү хакында да уйлыйсы бар. Ул әүвәл кирәк чакта ярдәмләшү өчен язучыларның үз акчаларыннан җыелган бит. Безнең заманда исә кассадан акчаны алу хакында гына сүз бара. Ахрысы шундый заман җитте ки, кирәк чакта синең турыңда кайгыртсыннар өчен, әдәби фонд язмышы хакында барыбыз бергәләп һәм берәм-берәм хәзер без кайгыртырга тиеш булабыз.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ

## XII СЪЕЗДЫ РЕЗОЛЮЦИЯСЕ

Язучылар берлеге идарәсе рәисенең докладын һәм әдәби жанрлар буенча махсус чыгышларны тыңлап тикшергәннән соң, Татарстан язучыларының XII съезды КАРАР бирә:

**1.** Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең хисап чорындагы эшен канәгатьләнерлек дип санарга.

**2.** Татарстан Язучылар берлегенә, яңа иҗтимагый һәм социаль шартларга туры китереп, структур үзгәрешләр кертергә.

**3.** Татарстан Язучылар берлегенең яңа идарәсенә иҗат оешмасын яңартуда съезд кабул иткән Декларацияне нигез итеп алырга, съездда әйтелгән тәкъдимнәр, теләк-киңәшләр, уй-фикерләргә таянып, киләчәктә гамәлгә ашырыласы чаралар планын эшләргә.

**4.** Язучының гражданлык, социаль һәм профессиональ хокукларын яклау, иҗат ирекен юридик яктан тәэмин итү, күпкырлы әдәби хәрәкәтне координацияләү буенча даими кайгыртучанлык күрсәтергә, аеруча мөһим һәм катлаулы мәсьәләләрне хөкүмәт югарылыгында карауга ирешергә.

**5.** Татарстан Язучылар берлеге каршында, иганәчелек кылырга теләк белдергән эшмәкәрләрне тартып һәм башка финанс чыганакларын табып, аерым әдипләргә матди ярдәм күрсәтү фондын нгытырга.

**6.** Нәшрият эшләре, китап сәүдәсе, гомумән, әдәбиятның киләчәк язмышына бәйле мәсьәләләрне, шулай ук авторларга түләү — гонорар сәясәтен даими игътибар үзәгендә тотарга, шушы өлкәдәге проблемаларны хәл итүдә югары дәүләт оешмалары белән якыннан бәйләнештә торырга.

**7.** Җәмгатьчелеккә моңарчы аз билгеле булган рухи кыйммәтләрне, шулай ук чит илләрдә саклана торган әдәби мирасыбызны барларга һәм дөньяга чыгару турында даими кайгыртырга.

**8.** Күренекле әдипләрнең истәлеген мәңгеләштерү, аларның иҗат мирасын туплау, фәнни нигездә өйрәнү һәм дөньяга чыгару, аерым әдипләрнең музей-йортларын ачу эшенә дәүләт кайгыртучанлыгына ирешергә.

**9.** Татарстан халыкларының телләрен, аерым алганда, татар телен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программасын тормышка ашыруда һәрьяклап ярдәм күрсәтергә.

**10.** Татар әдәбияты музеен ачу мәсьәләсен хөкүмәт дәрәҗәсендә хәл итәргә.

**11.** Сугышта шәһит киткән һәм репрессия корбаны булган әдипләргә Язучылар йорты бинасында мемориал-стэлла булдыру проектын тәгаен тормышка ашырырга.

**12.** Төркиянең әдәби-мәдәни оешмалары ярдәме белән төрки халыклар язучыларының әдәби журналын чыгару мөмкинлеген карарга.

**13.** Әдипләрнең юбилейларын тиешле дәрәҗәдә үткәрү өчен югары дәүләт оешмалары һәм мәдәният учреждениеләренең җаваплы вәкилләре катнашында координацион үзәк төзүне кулай дип санарга.

**14.** Әдәбият тарихында тирән эз калдырган кайбер мәшһүр әдипләрнең юбилейларын ЮНЕСКО дәрәҗәсендә үткәрү мәсьәләсен куярга.

**15.** Идел яисә Чулман буенда язучыларның иҗат йортын булдыруны тормыш ихтыяҗы тудырган мәҗбүрият дип санарга һәм әлеге мәсьәләне якын вакытта тәмам хәл итәргә.

**16.** Иҗат яшьләренә бирелеп килгән республика күләмендәге бүләк — элекке Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясенең башка аталышта яңадан торгызылуына ирешергә.

**17.** Иҗтимагый тормышыбызда килеп туган көнүзәк мәсьәләләр һәм аеруча җитди вакыйгаларга язучылар мөнәсәбәтен киң җәмәгатьчелеккә белдерү өчен мөрәҗәгатьләр, ачык хатлар һ. б. шундый ашыгыч акцияләр эшләүне игътибар үзәгендә тотарга.

**18.** Яңа сайланган идарәнең һәрбер әгъзасына анык бурыч йөкләргә, тапшырылган эш өчен аларның шәхсән җаваплылыгына һәм хисап биреп баруларына ирешергә.

**19.** Съезд яңа сайланган идарә рәисенә шушы резолюциядә каралган мәсьәләләрнең үтәлеше турында еллык гомуми җыелышларда хисап биреп баруны йөкли.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНӘ

## СТРУКТУР ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА

## ДЕКЛАРАЦИЯ

Без, язучылар съезды делегатлары, ике җыен арасындагы елларда гаять зур һәм тетрәткеч вакыйгалар шаһите булдык: СССР таркалды, КПСС эшчәнлеге тукталды, марксизм-ленинизм тәгълиматы хаким идеология вазифасын югалтты, гомумән, элек күпмедер тотрыклылык белән яшәп килгән канун, структура һәм системалар җимерелде. Төпле концепциясез башланып киткән «үзгәртеп кору», җәмгыятьне гаять авыр сынауларга дучар итеп, егерменче гасырда әле беркайчан да булмаганча, мәдәниятне дә бөлгенлек хәленә китерде. Икътисади реформаның тәрәккый кысаларга сыешмаган башбаштаклыгы нәтиҗәсендә, халыкны миллләт буларак саклап килгән, мәдәниятнең беренчел нигезен тәшкил иткән әдәбият ансат кына үтә алмаслык упкын алдында калды. Әмма без шуны тирәнтен аңлыйбыз: яңа икътисади мөнәсәбәтләргә күчү, шулай ук дәүләт төзелешенең яңаруы милли мәдәниятне үстерү җаваплылыгыннан беркемне дә азат итми. Гомумән, мәдәниятне саклмыйча торып, җәмгыятьнең яңарышына ирешеп булмаячак.

Югарыда бәян ителгән кыенлыкларны башыбыздан кичергән хәлдә, без шундый ачы хакыйкатькә дә битараф кала алмыйбыз: кире кагылгысыз рәвештә сайлап алынган базар икътисады юлы, иртәме-соңмы, халык тормышының үтә нәзберек өлкәсе булган мәдәниятне дә үзенең катгый кысаларына кысрыклап кертәчәк. Дөрес, яңа икътисади мөнәсәбәтләргә күчү чорында күпмедер тотрыклылыкка ирешкәнчегә чаклы дәүләтебез әдәбиятка мөмкин булган кадәр кайгыртучанлык күрсәтер. Әмма иҗат әһелләре тормыш чынбарлыгы тудырган яңа шартларда яшәү өчен барыбер алдан әзерләнергә тиеш. Моның өчен:

Беренчедән, үзебезнең алтмыш еллык яшәү дәверендә, каләм ияләрен мөмкин булганча бер гаиләгә җыеп, әдәбиятны халыкка хезмәт иттерү юлында берничә буын әдипләр тарафыннан күп кенә уңай тәҗрибә туплауга ирешкән язучылар оешмасын саклап калырга кирәк.

Үзенең табигате белән үк яклауга мохтаҗ иҗат әһелен кырыс язмыш алдында бөтенләй ялгыз калдырган бүгенге болгавыр чорда язучының гражданлык, социаль һәм профессиональ хокукларын яклаучы, иҗат ирегән юридик яктан тәэмин итүче, чиста сәясәтне әдипнең иҗат һәм яшәү ихтыяҗларыннан аеруда ярдәм итүче, әсәр язу һәм аны бастырудан гына тормаган күпкырлы әдәби хәрәкәтне конкрет координацияләүче үз оешмабызның булуы бик тә

зарури дип саныйбыз. Гасырлар буена читләргә чәчелгән халкыбызның инде хәзер «җыелу инстинкты» эшли башлавын да онытмаска тиешбез. Коммерция, конкуренция һ. б. шундый яңа икътисади чынбарлык үзләренең законнарына буйсындыра барган чорда бездән көч-куәтебезне, белемебезне һәм профессиональ осталыгыбызны ныграк берләштереп эш йөртү таләп ителә. Суверенлык юлыннан баручы республикабызның халыкара хокук мөнәсәбәтләре системасына керүе дә, аерым алганда, үз оешмабызның Халыкара язучылар берлекләре бердәмлегендә, шулай ук Төрки халыклары язучылары берлегендә күмәк әгъза булып торуы да безнең абруйлы дәрәҗәгә ия мөстәкыйль оешма булырга тиешлегебезне искәртә. Иҗат оешмалары институтын совет хакимияте уйлап тапмаган. Мондый бердәмлекләр тәрәккый көнбатыш илләрендә хәзер дә оешып тора. Аннары халкыбыз язмышының шундый үзенчәлеген дә истән чыгармыйк: милли тел, әдәбият һәм мәдәниятне киләчәк буыннар хакына саклап калу һәм үстерү җаваплылыгы бөтен җитдилеге белән әдипләр җилкәсенә төшә. Ә мондый иң мөкатдәс бурычны таркалган хәлдә үтәп булмый.

Икенчедән, бүгенге язучылар оешмасын төзелеш ягыннан үзгәртү сорала. Язучылар берлеге эшчәнлегенең яңаруын җәмгыятебездә ныгып килүче яңа чынбарлык һәм бөтен икътисадның актив структур үзгәреш чорына керүе таләп итә. Һәм, әлбәттә, яңартылган оешма һәртөрле идеологик басымнан, административ-бюрократик эш алымыннан, бер язучының башкалар өстеннән хакимлек итүеннән бөтенләй азат булырга тиеш.

Декларациянең югарыда санап үтелгән принципларын гамәлгә ашыру өчен иҗат берлеге төзелешенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә кирәк:

**1.** Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең иң югары органы булган съезд 3 елга бер тапкыр чакырыла; һәрбер елга әдәби ел йомгакларына багышланган гомуми җыелышта нәтиҗә ясала.

**2.** Финанс мөмкинлекләренең соң дәрәҗәдә кыен һәм тотрыксыз булуы сәбәпле, Язучылар берлеге идарәсе съезддан соң ук үзенең аппаратын җәмәгатьчелек тәртибендә тотуга хәзерлек эшләре башлап җибәрергә тиеш.

**3.** Съездда ачык тавыш бирү юлы белән сайланган идарә үз составыннан идарә рәисен сайлый: рәис ел саен йомгаклау җыелышы һәм идарә алдында даими рәвештә хисап тота; ихтыяҗ булган очракта идарә, рәиснең отчетын тыңлап, оештыру мәсьәләсен карый.

**4.** Идарә өч айга бер мәртәбә әдәбият һәм иҗтимагый тормышның көнүзәк мәсьәләләренә багышлап гомуми җыелышлар үткәрә.

**5.** Аеруча мөһим һәм бәхәсле мәсьәләләрне карап тикшерү өчен съездда Аксакаллар шурасын сайларга һәм аның даими эшләвен тәэмин итәргә.

**6.** Әдәбият фондын Язучылар берлеге карамагында калдырырга. 1991 елның 15 мартында үткәрелгән чираттан тыш съездда кабул ителгән Уставын үз көчендә дип санарга, фондка финанс чыганакларын табу юлларын эзләргә.

**7.** Язучылар берлегенең контроль-ревизия комиссиясе, кабул итү коллегиясенең Татарстан язучыларының 1991 ел, 15 мартта булган чираттан тыш съездында расланган яңа положениеләрен үз көчендә калдырырга.

**8.** Төзелеш һәм эш алымнары ягыннан бүгенге таләпләргә җавап бирмәгәнлектән, жанрлар буенча иҗат секцияләрен (барлыгы 9) бетерергә һәм алар урынына 4 остахanә (мастерской) — поэзия, проза һәм драматургия, балалар әдәбияты, урыс әдәбияты остаханәләре төзергә; иҗат остаханәләренең положениеләрен съездда расларга; остаханә җитәкчеләренә хезмәт хакы түләү мөмкинлеген табарга.

**9.** Матур әдәбиятны пропагандалау бюросы белән язучыларның Г. Тукай исемендәге клубын берләштерү мөмкинлеген карарга, яңача эшләү алымнарын билгеләргә.

**10.** Язучылар берлеге аппаратын, сайлап куела торган җитәкчеләрдән тыш, контракт нигезендә тупларга.

**11.** Идарә эшчәнлеген киңрәк яктырту, каләм ияләрен матбугат органнары эшенә тагын да ныграк якынайту максаты белән идарә каршында Матбугат үзәге булдырырга.

**12.** Структур яктан үзгәртелгән Язучылар берлеге үзенең эшчәнлеген шушы Декларациядә бәян ителгән принциплар һәм гамәлдәге Уставның әлеге принципларга каршы килмәгән положениеләре нигезендә алып бара.

*Декларация Татарстан язучыларының*

*1994 ел, 3 июньдә булган XII съездында кабул ителде.*

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ М. ШӘЙМИЕВКӘ, ЮГАРЫ СОВЕТ РӘИСЕ Ф. МӨХӘММӘТШИНГА, ПРЕМЬЕР-МИНИСТР М. САБИРОВКА, РЕСПУБЛИКАНЫҢ ШӘҺӘР ҺӘМ РАЙОН ХАКИМИЯТЛӘРЕ БАШЛЫКЛАРЫНА

## МӨРӘҖӘГАТЬ

Хөрмәтле җитәкчеләр!

Без, Татарстан язучыларының XII съездында катнашучылар, Сезнең игътибарны инде әдипләр тарафыннан күп мәртәбәләр күтәрелгән, киң җәмәгатьчелек фикеренә әверелгән, әмма бүгенге көндә бик акрын гамәлгә ашырылучы яисә бөтенләй диярлек хәл ителмәгән мөһим мәсьәләләргә, мәдәниятебезнең киләчәк язмышына бәйле проблемаларга тагын бер мәртәбә юнәлтергә телибез.

Беренчедән, язучыларның һәммәсен халкыбызны милләт буларак саклап килгән тел мәсьәләсе борчый. Татар теленең дәүләт теле булып кабул ителүенә инде байтак вакыт үтте. «Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында» Закон кабул ителде, аны үтәү буенча ТР Министрлар Кабинеты беренче чираттагы чараларны билгеләүче карар чыгарды. Әмма, элекке тоталитар җәмгыятьнең күп вәгъдә итеп тә берни бирмәгән программалары кебек, телебез турындагы һәртөрле рәсми актлар башлыча кәгазьдә генә кала бирә: югары дәүләт оешмаларында, предприятиеләрдә һәм учреждениеләрдә эш кәгазьләре ике теллелек таләп иткән төгәл тәртиптә алып барылмый, гомуми белем бирү мәктәпләрендә, махсус һәм югары уку йортларында татар теленең ролен күтәрүгә бәйле үзгәртеп кору бик сүлпән гамәлгә ашырыла, республиканың шәһәр һәм районнар хакимиятләре ике теллелек турындагы Законны үтәү буенча эшлеклелек күрсәтмиләр. Һәртөрле вывескалар арасында «элекке СССР»дан калганнары байтак; татарча хаталы язылганнарында телебез мәсхәрә ителә. Авыл һәм күмәк хуҗалык исемнәрен, географик атамаларны татарча язу да бүгенге көнгә кадәр тел кануннарына тәңгәл китерелмәгән.

Җөмһүриятебез башкаласында, шәһәр һәм авылларындагы урамнарның, мәйданнарның заманында халыкны дошман күргән «юлбашчы»лар исемен йөртүе дә, районнардагы дистәләрчә колхозларның һәм совхозларның аталышындагы «кызыллык»ның хәзергәчә уңмавы да, яңа микрорайон урамнарына республикага бернинди бәйләнеше булмаган ялган интернационализмга хас исемнәрнең әлегәчә кушылуы, килеп туган хәлне үзгәртергә теләк булмавы да әдипләрне бик борчый. Күпчелек шәһәр һәм район советларын телебезнең шушы рәвешле тернәкләнә алмыйча интегүе канәгатьләндерә, күрәсең.

Икенчедән, хөрмәтле җитәкчеләр, сезнең игътибарны телебез язмышына турыдан-туры бәйле гаять мөһим мәсьәләгә — латин графикасына кайту зарурлыгына юнәлтәбез. Мәгълүм булганча, телебезнең фонетик-грамматик кануннарына туры килгән, телдәге аваз системасын шактый тулы чагылдырган латин язуына күчү омтылышы җәмәгатьчелектә берничә дистә еллар дәвамында зур хәрәкәт буларак көчәя барды. Әле соңгы елларда гына да шушы җитди мәсьәлә уңаеннан югары дәрәҗәдәге конференцияләр, җыеннар, киңәшмәләр үткәрелде, көндәлек матбугатта, телевидение һәм радио тапшыруларында бик күп чыгышлар булды, язучыларның, тел галимнәренең, мәдәният әһелләренең дәүләтебез җитәкчеләренә мөрәҗәгате чыкты. Әмма киң җәмәгатьчелекнең өлгереп җиткән әлеге фикеренә шушы эш белән шөгыльләнергә бурычлы югары дәүләт оешмаларының тиешле дәрәҗәдәге игътибары һаман җитми. Шуны тирәнтен аңласак иде: латин алфавитына кайту буенча якын вакытта билгеле бер этапларны эченә алган дәүләт программасын эшләү һәм кабул итү бөтен җитдилеге белән көн тәртибенә килеп басты.

Өенчедән, халыкны миллләт буларак саклап килгән бөтен сәнгать төрләренең анасы, мәдәниятнең беренчел нигезе булган әдәбиятның яңа икътисади шартларда бик тә авыр хәлдә калуы безне, язучыларны, гаять дәрәҗәдә борчый. Тоталитар хакимият басымыннан котылуга ирешкән әдәбият икътисад басымы астына керергә тиеш түгел. Һәрбер әдипнең язмышына бәйле шушы мәсьәлә уңаеннан җәмәгатьчелектә күп мәртәбә чаң кагылса да, язучыларның социаль һәм профессиональ ихтыяҗларын дәүләт дәрәҗәсендә канәгатьләндерүгә тиешле игътибар бирелми. Без, съезд делегатлары, дәүләт җитәкчеләреннән шуны сорыйбыз: нәшрият эшләре, полиграфия, китап сәүдәсе, авторларга түләү, әдәби журналлар, гомумән, татар матбугаты язмышы һ. б. шундый көнүзәк мәсьәләләр якын вакытта дәүләтебез тарафыннан хәл ителергә тиеш.

Язучыларның сезгә булган бу мөрәҗәгате — татар халкының да җан авазы. Ул авазны, ниһаять, сез дә ишетерсез, игътибарсыз калдырмассыз, күтәрелгән мәсьәләләрне чишү юлларын табарсыз, аларны тормышка ашыруда ашыгыч һәм нәтиҗәле чаралар күрерсез дип ышанабыз.

*Мөрәҗәгать Татарстан язучыларының*

*1994 ел, 3 июньдә үткәрелгән XII*

*съездында кабул ителде.*

## ИКЕ СЪЕЗД АРАСЫНДА ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНӘ ӘГЪЗАЛЫККА КАБУЛ ИТЕЛГӘН ӘДИПЛӘР ИСЕМЛЕГЕ. (ТУГАН ЕЛЛАРЫ, ЯШӘГӘН УРЫННАРЫ ТУРЫНДА КЫСКАЧА МӘГЪЛҮМАТЛАР.)

| | | |
|---|---|---|
| 1. Рөстәм Акъегет (Фәйзуллин) | 1951 | Казан |
| 2. Фәнзаман Баттал | 1939 | Казан |
| 3. Наилә Вәлитова | 1946 | Казан |
| 4. Разим Вәлиуллин | 1942 | Лениногорск |
| 5. Әзһәр Габиди | 1926 | Сарман |
| 6. Рафаил Газизов | 1947 | Мамадыш |
| 7. Әсрар Галиев | 1938 | Лениногорск |
| 8. Фәйзи Галиев | 1925 | Әтнә |
| 9. Фәнил Галиев | 1939 | Казан |
| 10. Наис Гамбәров | 1947 | Казан |
| 11. Дамир Гарифуллин | 1939 | Сарман |
| 12. Рәшит Гатауллин | 1938 | Уфа |
| 13. Рафис Гыйззәтуллин | 1955 | Казан |
| 14. Галимҗан Гыйльманов | 1957 | Казан |
| 15. Ильдус Гыйләҗев | 1946 | Азнакай |
| 16. Заһирә Гомәрова | 1930 | Чаллы |
| 17. Фаяз Дунай | 1936 | Чаллы |
| 18. Марк Зарецкий | 1937 | Казан |
| 19. Зәки Зәйнуллин | 1933 | Казан |
| 20. Сәйдә Зыялы | 1941 | Казан |
| 21. Фирая Зыятдинова | 1945 | Казан |
| 22. Фарсель Зыятдинов | 1937 | Казан |
| 23. Рим Идиятуллин | 1940 | Уфа |
| 24. Илсөяр Иксанова | 1966 | Казан |
| 25. Вахит Имамов | 1954 | Чаллы |
| 26. Фәйрүзә Исмәгыйлова | 1963 | Азнакай |

| | | |
|---|---|---|
| 27. Наил Касыймов | 1955 | Казан |
| 28. Хатыйп Касыймов | 1932 | Түбән Кама |
| 29. Мөхәррәм Каюмов | 1941 | Казан |
| 30. Рафис Корбанов | 1957 | Казан |
| 31. Нәзифә Кәримова | 1947 | Мәскәү |
| 32. Владимир Лавришко | 1944 | Казан |
| 33. Флүс Латыйфи | 1943 | Казан |
| 34. Ләбиб Лерон | 1961 | Казан |
| 35. Алексей Литвин | 1931 | Казан |
| 36. Шаһидә Максудова | 1926 | Казан |
| 37. Сергей Малышев | 1950 | Казан |
| 38. Халисә Мөдәррисова | 1953 | Башкортстан |
| 39. Асия Минһаҗева | 1952 | Казан |
| 40. Сафуан Муллагалиев | 1927 | Казан |
| 41. Газинур Морат | 1959 | Казан |
| 42. Шаһинур Мостафин | 1948 | Казан |
| 43. Фәйрүзә Мөслимова | 1954 | Казан |
| 44. Гарифҗан Мөхәммәтшин | 1941 | Балтач |
| 45. Рушания Низамова | 1944 | Аксубай |
| 46. Таһир Нәбиуллин | 1933 | Түбән Кама |
| 47. Диләвер Осман | 1959 | Кырым |
| 48. Петр Прихожан | 1940 | Чаллы |
| 49. Фәридә Рәсулова | 1948 | Казан |
| 50. Бикә Рәхимова | 1939 | Казан |
| 51. Рөстәм Сабиров | 1951 | Казан |
| 52. Индус Сирматов | 1937 | Казан |
| 53. Данил Салихов | 1958 | Казан |
| 54. Әхәт Сафиуллин | 1936 | Казан |
| 55. Гакыйль Сәгыйров | 1938 | Димитровград |
| 56. Рөстәм Сүлти | 1969 | Казан |
| 57. Гурий Тавлин | 1925 | Казан |
| 58. Валерий Трофимов | 1960 | Казан |
| 59. Заһит Фәйзи | 1933 | Казан |
| 60. Миргалим Харисов | 1939 | Казан |
| 61. Мизхәт Хәбибуллин | 1940 | Түбән Кама |
| 62. Данис Хәйруллин | 1945 | Чаллы |
| 63. Хәниф Хөснуллин | 1935 | Чаллы |
| 64. Зиннур Хөснияр | 1961 | Казан |
| 65. Илдар Хөсни | 1951 | Әлмәт |
| 66. Рәниф Шәрипов | 1950 | Казан |
| 67. Мансур Шиһапов | 1940 | Казан |
| 68. Вахит Юнысов | 1930 | Мәскәү |
| 69. Марат Әмирханов | 1933 | Казан |
| 70. Илдар Әхсәнов | 1935 | Әлмәт |
| 71. Фирдәвес Әһлия | 1954 | Казан |
| 72. Шәмсия Җиһангирова | 1951 | Казан |
| 73. Рәшит Шиһапов | 1938 | Лениногорск |
| 74. Фәрит Яхин | 1961 | Казан |
| 75. Хәбир Ибраһимов | 1960 | Казан |

## «КАЗАН УТЛАРЫ» журналының 1989—1994 еллардагы эшчәнлеге турында кыскача мәгълүмат

Айлык әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал. Оештыручылары: Татарстан хөкүмәте, Татарстан Язучылар берлеге, редакциянең хезмәт коллективы. Күләме — 16,8 басма табак. Тиражы — 23 мең. Редакция коллективында 17 кеше эшли, шуларның 8 е Татарстан һәм Россиянең мактаулы исемнәренә, әдәби бүләкләренә ия әдипләр.

Басманың юлбашы рәсми рәвештә «Безнең юл» журналыннан санала (1922 ел). «Казан утлары» җитмеш елдан артык дәвердә 858 санда чыгып, татар халкының бердәнбер калын әдәби-мәдәни журналы булып килде һәм бүген дә халык тарихын һәм рухи хәзинәсен чагылдыруда шул миссияне үтәп килә. Үзенең төп мәсләгенә һәм укучыларына тугрылык саклап, ватандарлык һәм халыклар дуслыгы идеяләрен раслап, талантлы әдипләребезнең иң яхшы яңа әсәрләрен меңнәр-миллионнарга җиткереп бара. Соңгы биш елда журналда басылган әсәрләр шуңа дәлил. Кайберләрен генә санап үтик.

Романнардан: А. Расих — «Ишан оныгы», М. Маликова — «Фидая», Г. Ахунов — «Гомер юлы», Н. Фәттах — «Кичү», Ә. Гаффар — «Олы юлның тузаны», Г. Тавлин — «Афәт» (трилогия), Ф. Садриев — «Таң җиле», А. Гыйләҗев — «Йөгез, бер дога», Р. Мөхәммәдиев — «Сират күпере», Җ. Рәхимов — «Батырша», Р. Батулла — «Сөембикә» (кыйсса), М. Хәбибуллин — «Хан оныгы Хансөяр», Ф. Латыйфи — «Хыянәт»; повестьлардан: Ф. Бәйрәмова — «Кыңгырау», Ә. Баян — «Урланган ай», Н. Гыйматдинова — «Сихерче», Р. Низамиев — «Кызыл кар яугач», А. Хәлим — «Өч аяклы ат»; поэмалардан: Рәшит Әхмәтҗанов — «Карачкы», Ф. Яруллин — «Нәсел агачы», Р. Зәйдулла — «Матәм», З. Мансуров — «Хозыр галәйһис-сәләмне эзләү», Ф. Гыйззәтуллина — «Ирек юлы», Ә. Рәшитов — «Колшәриф», Г. Морат — «Ачлык», Р. Харис — «Өч үбешү», Р. Закиров — «Гамьле моң»; мәшһүр шагыйрьләрдән — Н. Арслан, Г. Афзал, И. Юзиев, М. Әгъләмов, Зөлфәт һ. б.ларның шигырь цикллары... Җыйнап әйткәндә, 1989—1994 елларда «Казан утлары» үзенең укучыларына 24 роман, 37 повесть, 48 хикәя, 9 поэма, 7 сәхнә әсәрләре һәм тарихка, әдәби тәнкыйтькә, публицистикага, сәнгатькә караган йөзләрчә фәнни-популяр язмалар тәкъдим итте.

Илебездәге тарихи үзгәрешләр, ачыктан-ачык сөйләшү заманы журналның эчтәлегенә һәм эшчәнлегенә шифалы йогынты ясады. Тыелган темаларның бетерелүе халкыбыз тарихын, андагы «ак тапларны», күпгасырлык рухи мирасыбызны тулы һәм дөрес итеп чагылдырырга мөмкинлек ачты. Мәсәлән, озак еллар тыелып килгән әдип Гаяз Исхакыйның әсәрләрен халыкка кайтаруда, аның тормыш һәм иҗат юлын яктыртуда журнал беренчеләрдән булып игелекле зур эш башкарды. Шулай ук, татарның мәшһүр уллары Дәрдемәнд, С. Максуди, Р. Фәхретдин, Һ. Атласый, Й. Акчура һ. б. лар турында яңа язмалар дөнья күрде.

Шулай ук «Дөнья әдәбияты җәүһәрләреннән» дигән рубрикада япон, латин америкасы, төрек, мадьяр, эстон әдәбиятларының яхшы әсәрләре лаеклы урын алды.

Татар тарихына (Борынгы Болгарда ислам динен кабул ителүнең 1100 еллыгы, Алтын Урданың 750 еллыгы уңае белән) һәм күренекле шәхес-әдипләр юбилейларына багышланган материаллар да шактый мул басылды.

Моңарчы укучылар күңеленә хуш килгән күркәм традицияләрне дәвам итү белән бергә, яңа рубрикалар ачылды: «Әдәбиятлар дуслыгы — халыклар дуслыгы», «Мәдәниятебез тарихыннан», «Әдәби мирас», «Остаханә», «Яңа исемнәр», «Тарих сәхифәләрендә — татар шәхесләре», «Татар халкы: төрле төбәкләрдә, төрле илләрдә» һ. б. Милләтебезнең бүгенге көне һәм киләчәге, гореф-гадәтләребез, туган телебез язмышы һәрвакыт игътибар үзәгендә. Журналда

Корьәннән сүрәләр, гарәп һәм латин әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре, яшьләр иҗатыннан үрнәкләр, драма әсәрләре, сәнгать сәхифәләренә дә киң урын бирелде.

Соңгы елларда күренекле әдипләр катнашы белән «Тукайлар рухы» дигән циклдан әңгәмәләр, «Безнең тормыш. Безнең әдәбият» дигән темага дәвамлы дискуссияләр үткәрелде. «Замандашлар» девизы астында иң яхшы хикәяләргә конкурс игълан итү дә язучыларның иҗади активлыгын арттырды. Журнал тышлыгында 60 ка якын күренекле татар язучыларының портрет-сурәтләре чыкты. Шулай ук, бүгенге сәнгатебезнең, бигрәк тә сынлы сәнгатебезнең хәзерге казанышларын чагылдырган йөзләрчә репродукцияләр басылды.

Фән һәм публицистика бүлекләре татар халкының тарихын, үткәндәге мирасны, төрки дөнья белән тарихи бәйләнешләрне барлауда нәтиҗәле эшләделәр.

Кыскасы, бүгенге әдәбиятыбызны пропагандалау, тарихыбызны һәм күренекле шәхесләребез язмышын яктырту, Татарстанның мөстәкыйльлеген ныгыту кебек иң актуаль темаларны укучыларга җиткерү юнәлешендә журнал биш ел дәвамында үзеннән сизелерлек өлеш кертте. Журнал үзенең 70 еллык юбилее уңаеннан Татарстан Республикасының Мактау грамотасына лаек булды.



## ТЕЛ ЯЗМЫШЫ — ҮЗӘКТӘ

18—21 июль көннәрендә Казанда Татарстан Югары Советының XXI сессиясе эшләде. Анда дәүләткүләм байтак мөһим мәсьәләләр каралды. «Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында»гы Законны гамәлгә ашыру буенча Дәүләт программасын тикшерү мәсьәләсе исә үзәктә булды.

Әлеге мәсьәлә буенча төп докладны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин ясады, өстәмә доклад белән Югары Советның даими комиссиясе рәисе, язучы Р. Вәлиев чыкты. Фикер алышулар барышында депутатлардан А. Зыятдинов, Ф. Сафиуллин, А. Ефремов һәм башкалар татар телен чын мәгънәсендә дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү буенча эшлекле тәкъдимнәр кертте.

Сессия, депутатларның тәкъдимнәрен тикшергәннән соң, Татарстанда телләрне үстерүнең Дәүләт программасын нигездә кабул итте. Программада Татар милли университетын ачу да каралган.

## ИДЕЛГӘ УРАЛ ЯКЫНАЯ

4—5 июль көннәрендә Свердловск өлкәсе Думасы Рәисе, Урал төбәге өлкәләре һәм республикаларының үзара икътисади элемтәләр ассоциациясе Президенты Э. Россель җитәкчелегендәге делегация Казанда булды. Визит барышында Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев, Югары Совет Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Татарстан вице-президенты В. Лихачев, республикабыз хөкүмәте һәм Югары Совет Президиумы әгъзалары белән очрашулар һәм рәсми сөйләшүләр уздырылды, һәр ике якны да кызыксындырган күп мәсьәләләр буенча фикер алышулар булды. Урал төбәге һәм Татарстан арасындагы бәйләнешләрне җайга салу турында уртак фикергә киленде.

## КЫРЫМ — ТАТАРСТАН КИЛЕШҮЛӘРЕ

4—6 июльдә Премьер-министр М. Сабиров җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы хөкүмәт делегациясе дуслык визиты белән Кырым Республикасында булды. Биредә Татарстан һәм Кырым Республикалары арасында сәүдә-икътисади һәм техник хезмәттәшлек, һава транспорты, банк эше һәм финанс-кредит мөнәсәбәтләре өлкәсендә хезмәттәшлек турындагы килешүләргә кул куелды. Севастопольдә Татарстанның Кырымдагы сәүдә-икътисад вәкиллеге ачылды.

## ПРЕЗИДЕНТЛАРГА — КОЛ ГАЛИ БҮЛӘГЕ

Узган ел «Мирас» фонды тарафыннан татар халкының Кол Гали исемендәге халыкара премиясе булдырылган иде. Әлеге премия комитеты җитәкчесе итеп Татарстан Җөмһүриятенең Аксакаллар Шурасы Рәисе Рәфикъ ага Хәмидулла билгеләнде.

Татар халкының күп гасырлык тарихи-мәдәни мирасын барлау, кайтару һәм пропагандалау өлкәсендәге казанышлары өчен, 1994 елда Кол Гали премиясен Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевка, Татарстан Фәннәр Академиясе Президенты, язучы-академик Мансур Хәсәновка, «Дегере Энтерпрайзес групп А. Ш.» фирмасы Президенты Эртерек Дегергә бирү турында карар чыгарылды.

## «ТАТАР-ИНФОРМ»НЫ ДӨНЬЯ БЕЛӘ

Мәгълүм булганча, Татарстан Президенты М. Шәймиевнең 1993 елгы 27 март Указы нигезендә, «Татар-Информ» мәгълүмат агентлыгы оештырылган иде. Әлеге агентлык (генераль директоры — Гомәр Богдалов) Җөмһүриятебезнең, Россия Федерациясенең, БДБ илләренең һәм чит ил дәүләтләренең массакүләм информация чараларында Татарстанның сәяси, икътисади, иҗтимагый, мәдәни тормышын чынбарлыктагыча яктыртуны үзенә төп максат итеп куйды. Хәзер аның Мәскәү, Санкт-Петербург, Ташкент, Улан-Удэ, Төмән, Саратов шәһәрләрендә үз хәбәрчелек пунктлары бар. Төркиядә исә «Татар-Информ»ның үз хәбәрчесе — Җанна Һидиятуллина эшли.

Агентлык үз эшчәнлеген көннән-көн киңрәк җәелдерә: «Татар иле», «Татарские края» газеталарын чыгара, инглиз телендә «Татар яңалыклары» газетасын нәшер итеп, аны барлык илләрнең илчелекләренә җибәреп тора...

1 июльдә «Татар-Информ» агентлыгын тәкъдим итү кичәсе (презентация) булды. Анда Татарстан Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары З. Вәлиева, Премьер-министр урынбасары И. Хәйруллин, республикада һәм татарлар күпләп яши торган төбәкләрдә чыгучы газеталарның баш мөхәррирләре, район хакимияте башлыклары урынбасарлары катнашып, тәбрикләү сүзләре белән чыктылар, агентлык хезмәткәрләренә хак сүзне дөнья халыкларына җиткерүдә нәтиҗәле эшчәнлек теләделәр.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

Татарстан язучыларының июнь башында булып үткән XII корылтаенда Язучылар берлегенә структур үзгәрешләр кертү турында Декларация кабул ителгән иде. Шул уңайдан, Язучылар берлеге идарәсенең 30 июньдә узган утырышында оештыру мәсьәләләре каралды. Анда моңарчы эшләп килгән иҗат секцияләре урынына 4 остаханә төзелде. Поэзия, проза һәм драматургия, балалар әдәбияты, рус әдәбияты остаханәләре җитәкчеләре итеп танылган язучыларыбыздан Илдар Юзеев, Гариф Ахунов, Шәүкәт Галиев, Владимир Корчагин сайланды.

Идарә утырышы язучыларның Аксакаллар Шурасы җитәкчесе итеп Татарстанның халык язучысы, «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы Аяз Гыйләҗевны, яшь язучыларны берлеккә кабул итү Коллегиясе рәисе итеп «Татарстан хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире, шагыйрь Ренат Харисны билгеләде. «Казан утлары», «Салават күпере» журналларының баш мөхәррирләре итеп яңадан Равил Фәйзуллин һәм Зиннур Хөснияр расланды.

Утырышта шулай ук нәшрият эшләре һәм китап тарату, иҗат яшьләре белән эшләү, мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбиятын укыту, әдәби мирас, мәдәни бәйләнешләр, юбилей-бәйрәмнәр үткәрү, ветеран язучылар һәм аларның гаиләләре турында кайгырту, көнкүреш мәсьәләләре һәм башка юнәлешләр буенча аерым әдипләргә җаваплы вазифалар йөкләнде.

* * *

19 июльдә Татарстан Язучылар берлеге урнашкан бинада (Комлев урамы, 14 йорт) проза һәм драматургия остаханәсенең беренче утырышы булып үтте. Аны, кыскача кереш сүз белән, остаханә җитәкчесе Гариф Ахунов ачты. Утырышта остаханә эшчәнлегенә җитәкчелек итү өчен 5 кешедән торган Шура (Г. Ахунов, Р. Мингалим, Ә. Баян, М. Хуҗин, Р. Низамиев) сайланды, якын киләчәктә башкарылырга тиешле мөһим эшләр барланды.

* * *

Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында «Төрки дөньяда милли аңның үсеш проблемалары» дигән темага гыйльми-практик конференция булып үтте. Аның эшчәнлегендә Төрек дөньясын өйрәнү фонды директоры, Истанбул университеты профессоры Туран Язган, галимнәрдән Хөсәен Һадиүзәл, Шабан Караташ кебек чит ил кунаклары белән бергә, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, Татарстанның халык язучылары Ә. Еники, М. Мәһдиев, академик М. Зәкиев, Татарстан Фәннәр Академиясенең гамәли әгъзасы А. Әхмәдуллин, филология фәннәре кандидаты, шагыйрь Н. Хисамов һ. б. катнаштылар.

## М. СОЛТАНГАЛИЕВ ЯШӘГӘН ТӨБӘКТӘ

15—16 июльдә Башкортстанның Кырмыскалы районы үзәгендә халкыбызның атаклы улы Мирсәет Солтангалиевнең бәйрәмен — тууына 102 ел тулу көнен билгеләп үттеләр. Кырмыскалының үзәк урамы, «Социалистическая» исемен үзгәртеп, Солтангалиев урамы, дип йөртелә башлады. М. Солтангалиев туып-үскән йортка мемориаль такта куелды. Киләчәктә исә Кырмыскалыда Солтангалиев музеен булдырырга җыеналар.

Әлеге тантаналы чараларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе, М. Солтангалиев турындагы «Сират күпере» романы авторы Ринат Мөхәммәдиев, Кырмыскалы районының хакимият башлыгы Юрий Садыйков, «Кызыл таң» газетасының баш мөхәррире Расих Ханнанов, Башкортстанның татар иҗтимагый үзәге рәисе Кәрим Яушев, М. Солтангалиевнең туганнары һәм якташлары катнашты.

## УКМАСКА УКМАСЫЙ КАЙТТЫ

Җөмһүриятебезнең Балык Бистәсе районындагы Укмас авылында быелгы Сабантуй бәйрәме бик эчтәлекле һәм истәлекле булып узды. Нәкъ шул көнне бу авылда үз чорының алдынгы мәгърифәтчесе, шагыйрь Миргазиз Укмасый (Зәбиров) туган йортка (хәзер анда кибет урнашкан) мемориаль такта куелды. Шагыйрьнең 110 еллыгы хөрмәтенә үткәрелгән бу тантанада Татарстан Язучылар берлеге рәисе Р. Мөхәммәдиев, Татарстан халык язучысы М. Мәһдиев, шагыйрь М. Шиһапов, танылган галимнәр Н. Юзиев, З. Рәмиев һәм район хакимияте башлыгы Х. Газизов катнашты.

Тантанадан соң табигатьнең матур урынында шигъри Сабантуй дәвам итте. Мәйданда М. Укмасыйның шигырьләре, җыр-музыка яңгырады.

## БАШКОРТ АРТИСТЛАРЫ КАЗАНДА

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия драма театры сәхнәсендә бер ай дәвамында М. Гафури исемендәге башкорт академия драма театрының гастрольләре гөрләп барды. Театрның танылган артистлары Нурия Ирсаева белән Фидан Гафаровка, Татарстан Президенты фәрманы белән, «Татарстанның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде. Ә театрның баш режиссеры Рәфкать Исрафилов, татар драматургиясен пропагандалаганы һәм бу өлкәдәге уңышлары өчен, «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мәртәбәле исемгә лаек булды.

Башкорт дусларга олы бүләкләрне саубуллашу кичәсендә Татарстан Премьер-министры М. Сабиров тапшырды.

# АНЫҢ ДӨНЬЯСЫ

Рәссам Зиннур Миңлеәхмәтнең төсләр дөньясы хисләрне киеренке халәткә кертә; хәтәр кузгалышлар белән каядыр билгесезлеккә, төпсез упкынга таба алгысытып, «минә авам, минә өзеләм...» дигән хәвефле җисем-инсаннарны шөкәтсез рәвешләргә кертеп зәгыйфьләндерә, вәхшилек чалымнарының асылын ачып шомландыра... Монда, әлбәттә, самими сәнгать үзенчәлекләре: нәзакатьле матур таплар да, нәзберек сызыклар да, сыннарның нәфислеге дә, купшы төсләр дә юк. Гүя рәссам безгә мәгълүм булмаган тектоник көчләр тәэсиреннән убылып, балчык кантарларына әйләнгән төсле архитектураны тасвирлый. Монда син әллә нинди җанварлар, нәсел билгесен югалткан тере җисемнәр, шәрә-соры алиһәләр, канлы авызлы бүреләр, мәһабәт кыргый кош-кортлар күрәсең — болар барсы да, кариатида сыман, тормыш бинасын гәүдәләре белән чак күтәреп торалар.

Ниндидер бер мизгелдә яшәеш гөмбәзенең җөй-сүрүе кинәт сүтелеп китәр дә аннан хәрабәләр генә торып калыр сыман. Аның соңгы «җимешләре», игелексез сәнгате чамадан ашып китеп үз-үзен юк итәр, ә бу гөнаһларны үз өстенә алган Җир шары чатнап ярылыр да, ком-таш кузәнәкләренә, тузан атомнарына әйләнеп галәм киңлегенә таралыр шикелле...

Авыш-тәвеш силуэт-шәүләләр, килбәтсез шәкелдәге рәсемнәр, тетрәнүле сызыклар, купайтылган дәһшәтле образлар ташкыны гүя үз явызлыгы-тотанаксызлыгыннан коты алынган цивилизациянең соңгы ялваруы, әрнүле аһәңе, тәүбә итеп, акыл гармониясенә кире кайту өчен башкарган куркыныч догасы...

Рәссамның үзгәрүчән эчке дөньясын, аның хәвефле хисләрен, сагаеп куркынган күз карашын, тотрыксыз, уалучан матди фантомнарның чатнау авазын шәрехләгән бу сәнгать, хәлбуки, ясалмалылыкка, төгәллеккә, камиллеккә, дөрес формаларга, детальләүгә каршы. Минимализм («азсурәтчелек») ысулы белән, беренче чиратта, пумала белән рәсемнәр, экзистенциаль аң агышын төсле монологлар, экспрессив сөйләмнәр аша тәэссоратлы итеп торгызырга омтылган бу сәнгать — наив, примитив тоела; рәссамның кайсыбер картиналары әйтерсең балалар кулы белән язылган. Руниканы яисә гыйммарәтләргә, таш диварларга, мәгарә куышларына язылган беренчел язмаларны хәтерләткән текстлар — безне турыдан-туры аның аянычлы шәхесе, чоры-вакыты, аңа карата «чит вә ят» дөнья эченә алып кереп китәләр. Кара күмер белән ак җитен тукымага читләтеп сынландырылган рәссам сурәте һәм аның моделе — тузгак чәчле һәм килбәтсез формалары ертылып-актарылып беткән, ямьсез күзле, симез тәнле алиһәдән гыйбарәт. «Парижга, Марина Влади янына барасым килә» әсәре — безгә мәгърур чех язучысы Франц Кафканы һәм аның «океан артында» беркайчан да булмый торып, «Америка» романын язуын хәтерләтә... Кафканың бу әсәре шәхес белән мохитның дошманлашуы, капма-каршы килүнең иң гыйбрәтле үрнәге булып санала... Зиннур Миңлеәхмәтнең Парижы да рәссам күргән, ул сөйгән, теләгән шәһәр, Монмартр яисә Лувр түгел... Аның идеалларының чынбарлыктан ераклыгы, шәхеснең ялгызлыгы, тормышның абсурдлыгы, ачы ирониясе...

Зиннур Миңлеәхмәт, мөгаен, үз чорын шулай ачык, усал һәм тугры итеп сурәтләүче бердәнбер рәссамдер. Һәм ул шушы хәләл миссиясе белән сәнгатебезнең 90 еллар сәхифәсенә кереп тә калыр... Чаң кагучы, рухны уятучы булып яд кылыныр...

Рәссам бөтен җаны-тәне белән бу бөек чатнауның — җәмгыять һәм адәмне савыклый, яңарта торган законлы процесс икәнен аңлый. Һәм аның уйлары зур хәрабә даирәсеннән китеп, Татарстан, этнос, милләт тирәли әйләнә. Бередә рәссам явыз образларын, куркыныч төшләрен үзеннән куа... «Кара урман», «Сак-сок», «Кичке көннәр... кичке төннәр» гыйбарәләре аша халык язмышының мәңгелек хәрәкәтен, аның тәрәккыйлык инерциясен, үлемсезлеген исбатлый.

Розалина ШАҺИЕВА,
сәнгать белгече.

Тышлыкның I битендәге фотосурәт «Туран» фонды коллекциясеннән алынды.

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Зиннур Миңлеәхмәтнең «Кара урман» картинасыннан фоторепродукция.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган шагыйрә Клара Булатова.

М. Козловский фотосурәте.

# БАРЫГЫЗ ДА —
# «КАЗАН УТЛАРЫ» ЯКТЫСЫНА!

**Мөхтәрәм милләттәшләр, журналыбызның якын дуслары!**

**Билгеле булганча, ошбу елның сентябрь аеннан 1995 елның беренче яртысы (январь, февраль, март, апрель, май, июнь айлары) өчен, газета-журналларга язылу башлана.**

**«Казан утлары» сезне яңадан үз яктысына чакыра — күпьеллык элкерсез дуслыгыбыз элеккечә матур дәвам итсен, кадерле дуслар!**

**Журналыбызга язылу бәясе, башка кайбер басмалар белән чагыштырганда, шактый арзан (моны сез каталогтан карап белә аласыз). Элемтә бүлекчәләрендә әбүнә тартмалары (абонящиклары) булган укучыларыбыз өчен безнең басманы алдыру тагын да очсызгарак төшәчәк.**

Ф. СП-1

Министерство связи СССР
„Союзпечать"

АБОНЕМЕНТ на ~~газету~~ журнал 73210 (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания) — Количество комплектов:

на 1995 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| X | X | X | X | X | X | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ | место | литер — на ~~газету~~ журнал 73210 (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания)

| Стоимость | подписки | ___ руб. ___ коп. | Количество комплектов: |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ___ руб. ___ коп. | |

на 1995 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| X | X | X | X | X | X | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

# БҮЛӘККӘ — ЖУРНАЛ!

**Алдагы еллар тәҗрибәсен һәм күпсанлы укучыларыбызның теләкләрен искә алып, журналыбызга язылуны җиңеләйтү максатыннан, бу санда 1995 елның беренче яртысына әзер әбүнә кәгазен (абонемент үрнәген) тәкъдим итәбез. «Казан утлары»н январь — июнь айларында алдырырга теләгән һәр кешенең, шушы квитанциягә үзенең тулы адресын, исем — фамилиясен язып, аны үзе яшәгән җирдәге элемтә бүлекчәсенә тапшыруы сорала. Онытмагыз: индексыбыз — 73210.**

**Мөмкинлектән файдаланып, урыннардагы хакимият башлыкларына, предприятие-учреждение хуҗаларына, авыл хуҗалыгы, мәгариф, мәдәният һ. б. өлкәләрдә эшләүче җитәкчеләргә мөрәҗәгать итәбез: «Казан утлары» журналы — хезмәт алдынгыларын хөрмәтләү өчен бик яхшы бүләк ул!**

---

**ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!**

На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.

При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается подписчику с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки).

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки «ПВ — МЕСТО» производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

Обл. .ип., г. Кострома

# ЯҢА КИТАПЛАР




Таһиров И. Р. Бәйсезлек баскычлары (Суверенлык турында уйланулар).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1994,— 279 б. Тиражы — 3000 данә.

Татарстан китап нәшрияты чыгарган бу китапка тарихчы-академик, җәмәгать эшлеклесе һәм публицист Индус Таһировның соңгы елларда язылган мәкаләләре, уйланулары тупланган. «Татар милләтендә яшәү көче бармы?», «Көрәшчеләребезне искә төшерик!», «Бәйсезлеккә ничек ирешергә?» дип аталган өч бүлектә автор милләтебезгә хас төп сыйфатлар, татарның нинди милләт булуы, тарихи язмышлары хакында фикер йөртә. Шулай ук күренекле шәхесләребез — Садри Максуди, Муса Бигиев, Гаяз Исхакый, Галимҗан Баруди, Мирсәет Солтангалиевләр эшчәнлеген күздән кичерә. Ахыргы бүлектә ул Татарстанның суверенлык юлында үткән этапларын барлап чыга, Татарстан — Россия сөйләшүләрен алып баручы дәүләт делегациясенең даими әгъзасы буларак, әлеге процессның яктыртылмаган якларын ачып сала.

Фарваз Миннуллин. Балта явызлар кулында: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре (Т. Галиуллин кереш сүзе).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1994,— 344 бит. Тиражы — 1500 данә.

Татарстан китап нәшрияты тарафыннан чыгарылган бу китапта авторның бүгенге татар әдәбиятының гомуми мәсьәләләренә, шулай ук күренекле язучыларыбыз иҗатына багышланган мәкаләләре урнаштырылган. Татар әдәбиятындагы актуаль проблемаларны яктыртулары, әһәмиятле теоретик күзәтүләре һәм гомумән оригиналь фикерләүләре белән кызыклы булган бу хезмәтләр җыелмасын әдәбият сөючеләр яратып кабул итәр дип уйлыйбыз. Ул шулай ук әдәбият фәнен өйрәнүче югары уку йортлары студентлары һәм урта мәктәпнең югары сыйныф укучылары өчен әдәбиятны өйрәнү, танып белүдә зур ярдәм итә алырдай чыганак буларак та тәкъдим ителә.



Бәясе 1100 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог